# казан утлары

5
МАЙ • 1978

# Казан утлары

**АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ**
**ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ**
**1922 елның май аеннан башлап чыга**

**5**
**МАЙ**
**1978**

## Бу санда

**Р. ФӘЙЗУЛЛИН.** Кыска шигырьләр . . . . . 3
**Х. ӘЮПОВ.** Бәхет. Шигырьләр . . . . . . . 8
**Р. СОЛНЦЕВ.** Көймә ватылса — утын. Повесть . . 10
**Р. МИҢНУЛЛИН.** Шундый минем туган ягым. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . 83
**С. ГӘРӘЕВА.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . 88

С. АЙНИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

**С. АЙНИ.** Беренче тәэсирләр. Хикәя. . . . . . 91

ОЧЕРКЛАР

**У. АЛИЕВ.** Гомерлек сабак . . . . . . . . . . 98
**Ш. РӘКЫЙПОВ.** Днепр ярларында таллар бар . 108

ПУБЛИЦИСТИКА

**Ш. ХАММАТОВ.** Дәһшәтле еллар авазы . . . . 120

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

**Ә. КӘРИМУЛЛИН.** Гөлнар ханым . . . . . . . 131

ТӨРЛЕСЕННӘН

**Д. БАҺАУТДИНОВА.** Шагыйрь китапханәсе . . 137

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

**Н. ЮЗИЕВ.** Әдәбият фәне методологиясенә — камиллек . . . . . . . . . . . . . . . 143

БҮГЕНГЕ ПОЭЗИЯ ТУРЫНДА СӨЙЛӘШҮ

**Х. ГОСМАН.** Яшьләр һәм остазлар . . . . . 153

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. УРМАНЧЕЕВ.** Тукай томнарын укыганда . . . 163
**А. ЛИТВИН.** Татар совет китабы узган юл . . . 167

**КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ**
**КАЗАН**

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Зариф Бәшири . . . . . . . . . . . . . 170
Р. ЯГЪФӘРОВ. Кайнар йөрәкле галим . . . . . 174

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

З. НУРИ. Хатка каршы хатлар яздык. Хикәя . . 174
Г. АФЗАЛ. Уены-чыны белән. Шигырьләр . . . 181
КАШФЕЛ ЗАДӘ. Чехов язганча. Шигырьләр . . 183

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Р. МИНГАЛИМОВ. Миңа ничек ышанырсың! Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . 185

Укучылар сүзе . . . . . . . . . . . . . 187

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: Зәки Нури

Редколлегия: Әхсән Баянов (баш редактор урынбасары), Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова (җаваплы секретарь), Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 20/I-1978 ел. Басарга кул куелды 29/III-1978 ел. ПФ 07040. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91000 экз. Заказ В-18. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1978 ел.

## Равил Фәйзуллин

# КЫСКА ШИГЫРЬЛӘР

### ЯШЬЛЕК

Кай якка барсаң да сукмагың кояшлы!
Ишекләр — алдыңда үзләре ачыла!
Кайда да кирәксең, кайда да көтәләр!
Баскан төшең — Җирнең кыл уртасы!..

### ХЫЯЛ АТЛЫ НӘФИС НӘФЕС

Төнбоеклы тыныч күл дә,
балкыр ут та,
гөл бөресе дә буласы килә
бер үк мәлдә!

### БИЕКЛЕКТӘ

Кыя — текә, җилләр — йолка.
Кузгала таш... Кая басыйм?
Колакта өн: менгәнсеңме —
егылам дип кычкырма син!

●

Китапханәләргә кергәч бөрешеп калам
китап киштәләре алдында.
Бөек уйлар тулы изге храмнан соң
кичке күккә карыйм нарасыйланып.

Анда да мәңгелек йолдызлар...

### БАКЧА. ТӨНГЕ УЧАК. ИЮНЬ

Утырабыз өчәү: учак, уй да мин.
Төнге тынлык.
Бөек берлек.
Идиллия.
Рәхәт.

... Чү! Тагын кем анда?!
Өч-дүрт адым якында гына
алсу шартлау булып мәк ачылды!

... Әллә Син дә инде
утырасың кайдадыр еракта,
ялгыз ут ягып,
мине сагынып?..

Ялкыныңмы минем янга төште
мәк чәчәге булып, кызарып?..

## ЙОЛДЫЗЛАР

Йолдызларга йодрык күрсәтмиләр.
Сокланып, таң калып багалар.
Аларда миллиард кешеләрнең
күзләреннән күчкән нур яна.

## КҮҢЕЛ — ҖӘЯ

Нәфрәттән, сөюдән,
ачудан, көлүдән —
шундый хәлдә күңелем:
тартылган җәя!
Шундый җәя —
тыймасаң, бер юлы дүрт якка атачак!

Сөю угын гына атмакчымын да,
ай, авыр шул!..

## КҮҢЕЛ ТЕЛИ КҮКНЕҢ ҮЗ ӨНЕН...

Әллә Күк күкри,
әллә берәр дәһшәт очкыч?
Әллә транзистор,
әллә кош сайрый?

Колаклар сак хәзер.
Күңел тели
ерак бабайларча,
Күктән иңгән табигыйлекне —
Күк күкрәвен,
кошлар тавышын,
яңгыр авазын...

## ЭШЧЕ

Иртә-кичен
шундый озын
этинең күләгә-һәйкәле.

## КАРАТАУ. СҮНГӘН ВУЛКАН

Ут сулаган чаклар!..
Түбәмә менгәннәр дә адәмнәр (и язмыш!)
тымызык яңгырдан — шалашта
ышыкланып торалар...

Берсе учак тергезмәкче дә...
Шырпысы чыланган.

## КҮРЕРСЕЗ!

Диңгезгә аккан чишмә суыдай
буталды яшьләрем
гомер дәрьясында...

Энҗе ташлар булып бер чыгар!
Күрерсез!

## НӘСИХӘТ № ...

Бушка алма берни бу дөньяда.
Җиңел килгән рәхәтлектән саклан.
Язмыш дигәннәре костырыр бер.
Ә косканың булыр — чат кан!

Чеп-чи юләр булсаң гына шатлан:
җиңел килде диеп бу мәхәббәт,
бу мал, бу дан...
Җиңел үлемеңә генә шатлан!

●

Җителдеме гомеремнең яртысына?
Билләр сына. Гөлләр сына. Илләр сына...

Дөнья болай тыныч кына...

## ТАУ ТӨШҮ

Бер утызны узгач
түбән таба —
текә икән гомер тавы!..
Тәгәри таш!

Торган саен моңсулана бара
җәен кошлар тынган чаклар,
айның ундүртләре узган көннәр,
үткән поездларның
борылмада югалулары...

Күзне сагышлатып, әчеттерә күбрәк
кабатланып килгән язларның
битне иркәләүче җилләре...

## ТӨНГЕ СУ КОЕНУ

Чалкан йөзеп киттең ай юлыннан...
Йолдызлар дерелдәп куйдылар
ялангач тәнеңне күрүгә!

... Энҗе түгел,
чуерташлар тездем чыгу юлыңа.
Көйдереп тамды кулларыма
чәчләреңнән көмеш тамчылар.
Салкын күкрәкләрең яндырды тәнемне.

Кочагыма атылып керүгә —
Ай мәтәлеп төште дулкынга.
Кырым таулары
бөтерелеп йөрде диңгездә...

## ТИЛЕ ЙӨРӘК

Күк катларында шаша йөрәк!

Җирдән килә өн:
«Ишетү кирәк —
сөешкәннәр күп,
кавышкан сирәк!..»

Ишетәме соң йөрәк!

## КАЙЧАК КИЛӘ...

Кайчан җир сөрүче буласы килә.
Кайчак галәм белән юанасы —
йолдызчы галим булып. Кайчак килә —
гомерлек ярың булып уянасы...

## БӘЙРӘМ УЗГАЧ, ИРТӘН...

Кояш уянды.
Онытылган шәм
каршылады таңны.
Күренми янды,
яшьләре тамды...

«Исемең матур, кемнәр куйган!..»

Чәч тасмаңа, әй сеңелем,
бал корты кунган
Ник мин түгел иренеңнән
бал тәмен тойган?..

Исемең матур...

## ЕШ КЫНА...

Күп күрдем сандугач оясын.
Берәүләр — күралмый гомергә!

Әнә шул берәүләр еш кына
өйрәтә — кай төштә күрергә.

## КАЙДА ДА...

Эльбруска, Витошага, Чатырдагка[1]
менеп кычкырдым.

Кайтаваз булып һәр чакта
синең аваз ишетелде.

## АПОЛЛИНЕРДАН

Борча-көя, дуслар, сөяркәләр
мәрхәмәтсез: безне сөяләр.
Сөяләрме, димәк, тешли алар,
башың ашый... Сак бул, ир адәм!

[1] Эльбрус, Витоша, Чатырдаг — тау исемнәре.

## Харрас Әюпов

### Бәхет

Бәхетлеме сез дип сорамагыз,
Юлыгыз нинди диеп сорагыз.
Ак атларда төшегезгә керсәк,
Изге сәфәр диеп юрагыз.

Шундый сәфәр бит бу — ялгыш кына
Абынсаң да заман кичермәс,
Ил тапшырган олы әманәтне
Юньле җайдак җиргә төшермәс.

Бәхетлеме сез дип сорамагыз,
Мин бәхетле димәс ир-егет,
Бәхетлегә ил картлары килер,
Рәхмәтләрен әйтер бил бөгеп.

Шундый итеп узыйк бу сәфәрне —
Телдән-телгә күчеп сөйләнсен,
Без эзләмик әле бәхетләрне,
Бәхет безне үзе эзләсен!..

●

Киләчәк һәм үткән арасында
Кечкенә бер нокта мин бары.
Шул ноктада чорлар кисешәләр,
Җаным аша уза юллары.
Бәрелешә миндә ак һәм кара,
Көрәш бара җанда, буталыш,
Киләчәктән урын алыр өчен
Хыянәтне җиңә Ышаныч.
Гасырлардан килгән мәхәббәтнең
Мәңгелеккә китеп барышы —
Кулыңны суз, яшьлек! Абынмасын,
Сөрлекмәсен бездә, ялгышып.
Үткәннәрнең әманәте килә,
Мең йөрәкнең миндә мең моңы.
Киләчәккә шулай кайнар килеш
Илтәлермен микән мин моны?
Җирдән киткәннәрнең иренендә
Әйтелмичә калган сүзләрен
Нәкъ аларча әйтә алырмынмы,
Рәнҗетмәмме икән үзләрен?..
Гасырларның җиле бәрелә-сугыла,
Җаным аша узган минутта
Басып торам чорлар каршысында,
Мин — очкындай кызган бер нокта...

•

Агач башлары шаулыйлар —
Җилдәнме, яңгырданмы,
Әллә елларга сөйлисе
Моңнары авырданмы?

Җилләргә сибелә җырлар,
Яфраклар тузып кала,
Күз түгел, урман үсләтеп
Гомерләр узып бара.

Сыгыла агач башлары
Безнең бәгырьгә тиеп,
Шуларны тыңлыйсыз бугай
Агачлар шаулый диеп.

Киткән-озаткан чакларда
Түзәлер кемнең җаны?
И сабыр икән урманнар! —
Шаулыйлар гына бары.

## Төнге очыш

Йолдызлар тарта, йолдызлар,
Күкләргә ашкан чагым,
Дөньялар каршына басып,
Талпына бүген җаным.
И Җирнең тиңсез-бәясез
Кадерле мизгелләре!
Кайларга сибелештегез?
Бу йолдыз диңгезләре
Кемнәрнең серен яшергән,
Кайларга дәшә тагын?
Агызып китәр шикелле
Мине бу төнге агым.
Галәм түренә нур булып
Таралган дәверләрне
Куып җитәрләр шикелле
Җанның бу давыллары.
Кагылыр сыман кулларым
Кемнеңдер толымына,
Ышанмам аның кайчандыр
Җир кызы булуына.
Танырмын әллә кайлардан
Җирнең беренче җырын,
Алдына башны куярмын
Ул җырны җырлаучының.
... Төнге дөньялар каршына
Нур булып агам сыман,
Югалсам, эзләрсез мине
Йолдызлар арасыннан.

## Роман Солнцев

# КӨЙМӘ ВАТЫЛСА — УТЫН

ПОВЕСТЬ

### 1

Ислам бабай әллә нинди зәңгәрсу-яшел, кызгылт-шәмәхә тырнаклы аякларын ятагы өстеннән берьюлы идәнгә алып ташлады да, кашын җыерып, ачу белән тирә-ягына каранды. «Менә бит, гөнаһ шомлыгы, нинди җүләрлек эшләдем кичәгенәк, хәзер искә төшерергә дә оят!» — дип, эченнән үкенеп уйлады ул.

Карт гомере буе, җәен дә, кышын да, йокыдан тәүлекнең гел бер үк вакытында — иртәнге сәгать дүрттә уянырга гадәтләнгән иде. Аның бу гадәте фәкать сугыш елларында — фронтта йөргәндә генә бозылса бозылгандыр. Мәгълүм ки, фронтта көн белән төнне аерып тормыйсың, төн караңгысыма анда яки һавадагы очып барган тилгәннән төшкән күләгә кыйпылчыгымы, җае чыкты исә, башыңны берәр түмгәккә төртәсең дә, ходай биргән кадәр черем итеп аласың.

Ә хәзерге имин заманда бөтенесе башкача, күнегелгән гадәтләрнең хөнен көнгә кабатланып торуы да гаҗәп түгел.

Кыскасы, Ислам бабай иске толып җәелгән ятагыннан иртәнге сәгать дүрттә, әтәчләр белән бергә тора иде. Ятуы исә кәефенә бәйле: артыграк төшереп кайткан булса, ул чишенмичә генә ятып йоклый, ә инде өенә аек баш белән, чайкалмыйча, төз атлап кайтып кергән чакларында, хатыны Нәгыймә карчык аны әлеге ямьшәеп-бөтәрләнеп беткән җирән йонлы толыбы өстенә ак җәймә җәеп яткыра иде.

Андый чакларда Нәгыймә тутәй Ислам бабайны бусага төбеннән үк елмаеп каршы ала, бөркетнекедәй кәкре борыны белән картының авызын исни-исни, юри шаяртып-көлеп:

— Акыллым! Йөрәк парәм! Ничек әле син бүген шулай аек кайттың! Күрше-күләне дә керми бит ичмасам, бер күрерләр иде аек вакытыңны, ай, син, бәгырь кисәгем, алтыным минем! — дип такмакларга тотына.

Озын гомер юлында ул Ислам бабайның төрле чагын күргән һәм аның күп кенә кыланышларын шулай көлке, җор сүз белән үткәреп җибәрергә, гафу итәргә күнеккән иде. Хәер, ничек үткәреп җибәрмисең дә, ничек гафу итмисең ди! Инде күпме гомерләре калгандыр, үлчәсән, шәт, тавык борыны кадәр дә булмас!

Картына урын-җир җәйгәндә дә карчык үзалдына сукрануыннан, мыгырдануыннан туктамый: күкәйне кайда туры килсә шунда, хәтта күрше ишегалдына кереп сала дип, тавыкларыннан зарлана, янсә, я бик акрын, я болындагы сыер көтүен өркетерлек дәрәҗәдә акырып сөйли дип, үзләреннән еракта түгел, авыл мәйданында баганага куелган радио репродукторын сүгәргә тотына.

Боларның һәммәсен Ислам бабай күп вакыт дәшми генә тыңлый. Хатын-кызның теле ни сөйләмәс, әйдә, тик мыгырдый бирсен! Ир кешегә алар белән сүз көрәштерү килешми. Аннан соң авыз эчендә тикмәгә һава болгатудан ни мәгънә — һава коймак түгел, май язылмас!

Моның өстенә, Ислам бабай авылның иң могтәбәр, иң хөрмәтле кешеләреннән санала — мәшһүр балыкчы ул, алай гына да түгел, балыкчылар артиленең башлыгы! Бакча түтәлендәге таш кабак чатнап ярылса ярылыр, әмма Ислам бабай юк-бар сүзгә авызын ачып җавап бирмәс!

Менә шундый кеше ул Ислам бабай.

Кичә кичен исә ул урынга чишенмичә генә ятып йоклаган иде, чөнки кичә көне буе аларда кунаклар булды. Район үзәгеннән — Минзәләдән кияве Мурзин килгән иде. Гомумән, бу атна, гөнаһ шомлыгы, әллә ничек бик мәшәкатьле, гауга, ыгы-зыгы белән узды.

Карт җәһәт кенә аягына торып басты, кояшта уңып төссезләнгән фланель күлмәгенең изүен каптырды һәм, кыска чәчле йомры башын югары чөя төшеп, кытыршы учы белән тамак астын сыпырып карады. «Кырынырга вакыт җиткән икән дә, тик кырынып булмас, ахрысы — куллар калтырый. Әйдә, чукынмас әле!» — дип, җыерчыклы, хатын-кызныкыдай кабарынкы-түгәрәк йөзен чытып, ачу белән кулын селтәде ул.

Аннары, сондык аша гына атлап һәм мич буендагы шыгырдык сәкегә орынмаска тырышып, күнегелгән сак адымнар белән түргә узды. Сәкедә, йоннары чыккан алсу тышлы түшәк өстендә, җидегә бөгәрләнеп, карчыгы Нәгыймә түтәй йоклап ята иде.

Кече якта әле караңгы иде. Ислам бабай, калын саллы ефәк чыбылдыкны ике якка каерып, өйнең түр ягына чыкты һәм ирексездән күзләрен йомды: офык читеннән күтәрелеп килгән кояшның кызгылт-алсу нурлары бөтен бүлмә эчен яктырткан иде.

Яшьләр әле уянмаган. Өстәл өстендәге тоз кояш нурында кызыл бөрыч сыман җемелди, ә кара өйгә алып чыга торган ишекнең сары яңаклары әйтерсең лә алтынга манчылганнар иде.

«Гомер таңы яшьлек тә әнә шундый: ишекләре башта саф алтын кебек күренә. Ә соңыннан, карыйсың, ул корт төшкән черек бер агач икән», — дип, үзенчә нәтиҗә ясады Ислам бабай.

Карт ишек яңагының кояш нурында балкып җемелдәгән җылы, кытыршы йөзлегенә учын куйды да аптыраулы-уйчан күзләре белән бер мәл шуңа текәлеп карап торды.

Ул арада артта, түр стена буенда, шыелдый-шыелдый, дүрт тапкыр каты итеп сәгать сукты һәм, «күк-кү» дип, шул ук мәртәбәдә аның маңгаендагы караңгы куышта утырган калай күкесе кычкырды. Әйтергә кирәк, кичләрен, кояш баеганда, ян тәрәзә аша төшкән кыйгач нурлар бу ахмак күкенең оясына да барып җитә һәм аны шәфәкъ төсенә мана иде.

Сәгать суккан тавышка картның оныгы яткан урынында кыбырсып куйды, килене уянды. Карт, елмаюын яшереп, йөзен чытты, ишек уен-

тыгына корылган марля пәрдәне бер якка эшереп, ишекне ачты да кара өйгә, аннан болдырга чыкты.

Дөнья ярып әтәчләр кычкыра. Көтү китәр вакыт җиткән. Әнә инде шыштыр-шыштыр, ашыгып атлаган аяк тавышлары да ишетелә — бу хатын-кыз халкы үзенең иртәнге матавыгын башлаган. «Бүген нигәдер соңарып торганнар әле. Ахрысы, кичә кунак сыйлап, табын җыеп, савыт-саба юып, артык соң яткан булганнардыр».

Ислам бабай, үзалдына уйга батып, әле кашын җыерды, әле елмаеп куйды. «Карт җүләр мин, һаман җәнҗал, гауга чыгарудан туктый алмыйм. Аның каравы, йокыдан һәммә кешедән иртәрәк торам, эшне дә һәммәсеннән күбрәк эшлим!»

Карт, аягына иске башмак элеп, баскычтан төште. Җир өсте коп-коры, чык дигән нәрсәнең әсәре дә юк. Димәк, бүген дә көн эссе булачак. Шундый кыздырыр, чалбар балагына сызып шырпы кабызырга булыр, мөгаен.

Кояш әнә хәзердән үк инде, Суыксу урманы артыннан күтәрелеп җитәр-җитмәс үк, тәнне пешереп-пешереп ала.

Ишегалды кинәт дәррәү кубып кычкырган сарыклар бәэлдәве белән тулды. Ул да булмады, урам яктан боларга шундый ук икенче бер мәгънәсез-ахмак хор килеп кушылды һәм исәпсез-хисапсыз тояклар дөпелдәве ишетелде. Ишегалдындагы көдрә мәхлуклар, бер-берен төртә-ашыктыра, өерелешеп капкага ташландылар һәм бер мизгелдән барысы бергә, һавада алсу-соры тузан болыты күтәреп, Бикташның борылмалы тыкрыгына кереп югалдылар.

Төнге хатирәләреннән, төшендә күргән хозур манзараларыннан аерылырга теләмәгәндәй, аптыраулы кыяфәт белән теләр-теләмәс кенә атлап һәм күзләрен сәер мөлдерәтеп, абзардан мукләк сыер чыкты. Ислам бабай, кулын сузып, аның сыртыннан сыйпады. Болыннар көепяныып беткән, бу мәхлуклар каян азык тапсын инде? Елга буе үзәнендә үлән күп-күбен дә, әмма ул җирләр колхоз чабынлыгы санала, җитмәсә әле, үләне дә шәптән түгел — тоташ кыяк... Токмач урынына умач дигәндәй...

Казлар үз телләрендә аваз салып, яссы сары томшыклы үрдәкләр бакылдашып куйды.

Йоны киезләнеп, чуалып беткән карт эт Буран да, ак төшкән моңсу күзләренә шатлык әсәре бирергә тырышып, такта оясыннан өстерәлеп чыкты һәм балдаклы тимер чыбыкка бәйле муенчак чылбырын шалтыр-шолтыр яңгыратып, ишегалды буйлап әйләнеп килде. Ул калын, карлыккан тавышы белән ырылдап яисә өреп куя, ал тәпиен күтәрепкүтәреп ала, әмма әүвәлгечә өрергә, уйнап сикергәләргә аның инде тавышы да, көче-дәрманы да калмаган иде.

Ислам карт аңа тавышланмаска боерып бармак янады һәм, койма тактасына кадакка элеп куелган юынгычка таба барышлый, этенең хуплавын ишетергә теләгәндәй:

— Бүген бик эссе булыр, ахрысы, әйеме? — дип куйды.

Карт юынгыч астына башын тыгып, бөке-күтәртмәне югары таба этәрде. Әмма юынгычта тамчы да су юк иде. Шуннан өйалдына кире кереп, чиләк белән су алып чыкты, юынгычка салды. Аннары юына башлады. Ул әле баш түбәсе белән, әле муены, әле чигәсе белән кискен хәрәкәт ясап, юынгычның пружинадай авыр-салмак тимер бөкесен югары таба чөеп җибәрә дә, салкынча су, юынгыч тишегеннән чаптырып чыгып, аның бит-яңаклары буйлап җәелә, рәхәт кытыклап, борын очларыннан шыбырдап ага иде. Ахырда ул, шулай ук бик озак, башын янтайтып селеккәли-селеккәли, колак эченә тулган суны чыгарып маташты, канәгать бер төстә учы, бармаклары белән аралый-сыпыра, чәч араларындагы су тамчыларын кагып төшерде...

«Ярты чиләк суны сарыф иттем ләбаса, — дип эченнән уйлады ул — Хәер, сарыф итсә соң, кызганычмыни! Килен алып кайтыр әле. Елга янәшәдә генә. Бабай кешегә рәнҗемәс. Мин бит инде чынлап бабай. Үзләре шулай сөйләп йөриләр. Җитмеш өч яшь тутырып киләм.... Әйе...»

Юынтык су, коп-коры, тузанлы җир өстенә агып төшеп, кара-кучкыл төстәге юеш эзләр — кечкенә ерганаклар салып узган иде. Шул ерганаклар өстендә кинәт алтынсу тәнле ике бал корты пәйда булды. Алар бик эшлекле кыяфәттә безелдәп әйләнәләр-әйләнәләр дә, ерганак «ярына» кунып, су эчәләр. Менә берсе Ислам бабайның аяклары тирәсендә бөтерелә башлады, аннан кинәт аның тишек бармагы очыннан тырпаеп күренгән яшькелт-зәңгәр тырнаклы шәрә бармагына килеп кунды, ул да булмады, икенчесенә — кызгылт төстәгесенә күчте, ахырда, бернинди хәтәр эш, явызлык кылмыйча, һавага күтәрелеп, очып китеп барды.

«Минем үз кортларым шул алар, мине берваКытта да чакмыйлар!» — дип, горурлык белән уйлап куйды Ислам бабай.

Ул чыннан да хаклы иде. Кайчакны, өйгә кунак төшеп, мәҗлес кызыбрак китә башласа, Ислам карт, ничектер, мәзәк ятьйсы яки үз балы белән мактанасы килепме, кулына төтәткеч белән савыт ала да, битлек-мазар кимичә, туп-туры умарталары янына бакчага чыгып китә торган иде. Умарта күче карт тирәсендә усал безелдәп, кара болыт сыман очып әйләнә, бал кортлары аның баш түбәсенә, маңгай, яңакларына төшеп куналар, әмма чакмыйлар, бераздан тагы кире очып китәләр иде. Мондый чакта карт мыек астыннан гына серле елмаеп, үзенең яраткан сүзләрен кабатлый:

— Кортларым миңа тимиләр шул, әйеме? — ди торган иде.

Кичәгенәк ул әнә тагын шундыйрак бер мәзәк эшләп ташлады. Их, онытасы иде дә үзен, онытып булмый, хәерсезне!

Ислам бабай бал кортларының, җир өстендәге юеш эзгә һәм юынгыч тимере очына эленеп калган тамчыга борыннарын төртеп, су эчүләрен һәм, сусыннары басылгач, офыкта кызарып калыккан кояшка таба ашыгып очып китүләрен елмаюлы, канәгать чырай белән озатып калды да, йөзенә юри усаллык галәмәте биреп, тирә-ягына күз төшерде. Янәсе, ишегалды тәртиптәме?

Йортның ике тәрәзә арасындагы кадакта җете зәңгәр төскә буялган көянтәләр эленеп тора. Койма буенда су чиләкләре ялтырап күренә. Шул ук койма буйлатып, бәрәңге бакчасына хәтле, карап торышка шактый яңа өч балыкчы җәтмәсе кибәргә сузып салынган. Боларның икесе, коңгырт һәм саргылт төстәгеләре, нәзек, нык тегәрҗептән үрелгән, ә өченчесе «импортный» — кечкенә, җиңел батыргычлы капрон җәтмә иде. Төпкә тизрәк батсын өчен, заманында Ислам бабайга бу җәтмәнең һәрбер батыргычына аерым-аерым өстәмә авырлыклар тагып чыгарга туры килгән иде.

Җәтмә дигәннән, картның болардан башка да җәтмәләре күп. Ул бит балыкны үз кирәге өчен тотмый, балык һәммә кешегә кирәк. Әнә сарайда тагы унлап җәтмә эленеп тора — алар арасында җәенгә сала торганы да, вак балыкка сала торганы да бар. Ә Ык елгасына һәм күлләргә салып куелганнары күпме! Санасаң, шәт, ике дистәгә тулар. Кичә әнә искергән бер җәтмәдән гамак ясап куйганнар, хәерсезләр... Әйдә, чукынсын! Барыбер ертылып эштән чыккан иде инде... Аллаһы тәгалә үзе кичерсен дигәндәй аларның ул шуклыкларын...

Ислам карт, ниһаять, көймәсе каршына килеп басты. Менә ул, нәзек, зифа, җиңел гәүдәсе белән йөзтүбән капланып, утын әрдәнәсе янында таралып ята. Юан тупыл кискәсеннән чокып ясалган һәм, әле чын-чынлап сумалаланып та җитмичә, җәйге эссе кояш астында бер ай вакыт эчендә тәмам кибеп-коргаксып өлгергән бу яңа көймә хәзер борыныннан койрыгынача кыл үзәге буйлап икегә ярылып чыккан иде.

Инде аны нишләтергә? Ярыгына калай ямау салып беркетергәме? Юк, алай булмый. Ул инде бөтенләй эштән чыккан, кипкән борчак кузагы сыман, шартлап икегә аерылган! Ярык юлына туры килгән бер чөе-бөкесе хәтта тишегеннән атылып чыккан, әнә хәзер шунда бер кырыйда — сыек сумала чәчрәп буялган чирәм өстендә аунап ята. Андый агач чөй-бөкеләрнең саны һәр көймәдә өч йөзгә якын, аларны гадәттә көймәнең төбен киңәйтү өчен кагалар. Ислам бабай имән бөкене учына алып, мыек астыннан гына көлемсерәде дә, аны кычыткан арасына атып бәрде. Нигә хаҗәт ул хәзер? Чәкүшкәгә дисәң — кечкенә. Колак бөкесе итеп файдалансаң гына инде. Теге, хатын-кыз, кардәш-ягынмарның буш лыгырдауларын ишетмәс өчен! ,

— Әйеме?..

Карт ярык көймә каршында шактый вакыт уйланып басып торды.

«Бик тә яман эш эшләп ташланды шул кичәгенәк! Хуш, бәхил бул, көймәкәем. Син чыныгып җитәр-җитмәс борын дөнья куйдың менә. Син хәзер инде утынга гына ярыйсың. Ай яктысында елтырап яткан төнге су өстен борының белән ярып барырга да, үз артыңнан кул яссысы киңлегендәге җемелдәвек эзләр калдырып, куе камыш сабакларына түшең белән ышкылып үтәргә дә сиңа бүтән беркайчан да насыйп булмас инде...»

Шул чак капка тарафыннан килене Нәҗиянең көр, ачык тавышы яңгырады:

,— Әткәй! Мин киттем!.. Ферма яныннан узасы булсаң, кереп чык, сөт эчеп башыңны төзәтерсең!

Ислам бабай кырт борылып карады, әмма капка янында киленнән җилләр искән иде инде. Картның ачудан чырае сытылды, мәченеке төсле түгәрәк елтыр күзләре кысылып килде. Ул калтыравык тавыш белән:

— Бәйләнмәгез миңа! Бәйләнмәгез дим! — дип кычкырып җибәрде. Аның чал төкле, хатын-кызныкыдай кабарынкы битләре, йомык авызы эчендә нидер тырышып чәйнәгәндәй, тулганып селкенергә тотынды. Бердәнбер исән тешен аңу аралаш шулай теле белән какшатырга маташуы иде бу аның. Карт, бүтән бер сүз әйтмичә, беравык шулай пошкырына-пошкырына басып торды да, янә көймәсенә таба борылып, башын түбән иде.

«Бар, киленкәй, бар, юлында бул! Мин чынлап картайганмын инде, сез һәммәгез дә дөрес әйтәсез. Фермаңа да бүтән барып, сине мәшәкатьләп йөрмәм. Миңа, ир башым белән, анда барып, гайбәт азыгы булып чәйнәлү нигә хаҗәт? Әйе, мин, бәлкем, чынлап та әле һаман ир кешедер, ә? Кһм... Их, онытырга иде шул кичәге көнне! Оятыңнан җир тишегенә керерсең, валлаһи! Әйе, көймәкәй, мин сиңа нидер әйтмәкче идем бугай... Һәммәсе безгә комачаулый шул, көймә дустым. Киленне мин үз улымны яратканнан бер дә ким яратмыйм югыйсә... Мөлаем, итагатьле, булган хатын ул, өйдәге бөтен эшне эшли. Миннән калганын, әлбиттә! Карчыгым Нәгыймә инде картаеп эштән чыккан, аның бөтен белгәне сукрану да шыңшу. Ә улым Рөстәм... Җүләрне чәчеп үстермиләр ди бит, буе колга дисәң колга җирән шайтанның, ә кулыннан бер эш килми. Җитмәсә, хәзердән үк чәче коела башлаган. Хәлләр менә шулай, көймә дус! Ишетәсеңме мине? Сиңа нидер әйтә башлаган идем шикелле... Әйе, исемә төшердем... Синең түшең астында, тирәндә бүтән беркайчан да чуар тәңкәле чуртаннар, көмеш чабаклар уйнаклап йөзмәс, комлы төптән иренчәк кыслалар титаклап узмас. Ак күлдәге ак төнбоекларның чыклы яфраклары синең зифа гәүдәңә орына алмас. Яр буенда куерып үскән тал-тирәкләр сине җилфер яфраклары белән шаулый-шаулый озатып калмас. Яр буе патшасы — кара бөрлегән дә пәрәвез сарган җимешләрен синең өстеңә коймас. Их! Миңа да, сиңа утырган килеш, кытыршы янтыкларыңа кызгылт

карасу тәңкәләрен коеп, аяк астында шап-шоп сикеренгән эре корбан балыкларын, тимгелле алабугаларны күреп сөенергә туры килмәс... Хуш, бәхил бул, көймәчегем! Атка ияләшкән кебек, көймәгә дә мин шулай бөтен җаным белән ияләшеп бетәм. Теләсә нинди дулкында, тын суда көймәгә җай белән утыра белү кирәк. Ә бу осталык көймәгә ияләшкәннән соң гына килә. Нәҗия әнә көлә, яңа чалбар алып бирим үзенә, ди, монысы каешланып беткән, көзгедәй ялтырап тора, ди. Битрәк тә төбен күздә тотып әйтүе. Нәрсәсе гаҗәп: сумала, балык тәңкәсе, лайла — ялтырамый нишләсен! Көннәр буе кызу кояш астында кыбырсып утыр әле син! Чалбар төбең көзге түгел, әллә ни төсле булыр. Их, көймә, көймә, насыйп булмадың шул син миңа!..»

Ислам бабай әкрен генә атлап ишегалдын әйләнеп чыкты. Бераздан чырае янә ачылды: рәшәткәле койма һәм бакчадагы алмагачлар өстендә пыр тузып карлыгачлар бөтерелә иде. Алар карт турысына томырылып очып киләләр дә, бәреләм дигәндә генә кырт күтәрелеп, югарыга таба атылалар һәм зәңгәрсу рәшә белән өртелгән күк йөзендә эреп күздән югалалар иде. Ни булды икән боларга? Әллә югыйсә яңгыр хәбәр итүләреме?

— Әйеме?

Гомер юлында нинди хәлләр булмас, моннан яманраклары да булгалады. Шул көймә өчен җанны нигә шулай талкырга? Көймәсез калмас әле, яңасын сатып алыр. Ә вакытлыча искесендә дә йөреп торырга була. Читен ягы тик шунда гына: аны гел бер урыннан икенче урынга — елга артындагы күлләрдән бу як ярга, умарталык буена, аннан иске елга үзәненә күчереп йөртергә туры киләчәк. Ә менә кичәге гауга өчен, алай гына түгел, атна буе өзлексез дәвам иткән күңелсез хәлләр өчен аңа чыннан да оят... Ләкин барыбер борын салындырырга кирәкми, борын белән җир сөрү мәгънәсез эш, ник дисәң, җирне борын белән сөреп чәчәрдәй орлык дөньяда булганы юк әле!

Карт ат абзары янына килеп туктады.

Абзардагы айгыр, аяк тавышыннан хуҗасын танып булса кирәк, әкрен генә пошкырып куйды.

Ислам бабай абзар ишеген ачып, эчкә керде, күзе караңгыга ияләшкәнче бераз туктап, көтеп торды, аннары аяк астындагы тизәк йомыларына басмаска тырышып, түргә узды. Ак бәкәлле зифа-сылу туры айгыр, караңгыдан башын калкытып, кайнар ипеннәре белән хуҗа кешенең учына сузылды. Тегесе исә, аның ялын сыйпап, үрә катып тырпайган каты сеңерле колак яфракларына орынып алды.

— Әйдә, Йолдыз кашка, кузгалырга вакыт.

Алар шулай икәүләп иртәнге кояш нурларына чумган иркен ишегалдына чыктылар. Карт айгырга ярты чиләк чамасы солы салып бирде.

«Менә синең дә гомереңнең иртәнге кояштай алтын чагы,— дип, сөеп-яратып, эченнән генә атына эндәште Ислам бабай.— Әйеме?»

Ат солы бөртекләрен керт-керт чәйни бирде; ә картның аны ярату хисеннән тамак төпләренә хәтле кытыкланып куя иде.

Аннары ул, ызбруйны һәр яктан барлап-тикшереп, ат җигәргә тотынды. Ыңгырчак шактый искергән икән инде, киезе тәмам юкарып, ашалып беткән; каешы да бернигә яраксыз, катырак кысып тартсаң, өзелеп китмәгәе. Ә камыты менә әлегә ярыйсы, сүз әйтерлек түгел.

— Әйеме? — дип, гадәтенчә тагы сорап куйды карт.

Йолдыз кашка, аның сүзен раслагандай, башын чайкады.

Ислам бабай һәрбер хайванны адәм телен, аның ни уйлаганын аңлый дип ышана иде. «Аңлый» тынамы? Картның фикеренчә, кеше белән хайван арасында гомумән берниндн аерымлык юк иде. Ул һәрбер җан иясен үз күрә, ярата, кайчакны хәтта аларны бер-бере белән буташты-

ра ук башлый иде. Мәсәлән, ул, шулай буталып, ике яшьлек кыз оныгына «аягыңны күтәр» диясе урында ялгыш: «Тоягыңны күтәр!» дип ычкындыра, яисә, ияген һәм күкрәк читлеген учы белән ышкый-ышкый, карчыгына: «Саңагым авырта әле!» — дип зарланырга тотына... Карлыгачлар, бал кортлары, атлар, казлар, чикерткәләр, сарыклар — болар һәммәсе Ислам бабай каршында зур бер гаилә тәшкил итә, һәм бу гаиләгә гаид һәр җан иясен ул үзенең кан кардәше итеп саный, аларны аңлый, берсен, әйтик, азрак, икенчесен күбрәк ярата һәм вакыты булганда бу чәрелдәвек, безелдәвек туган-тумача өеренә җирән керфекле кысык күзләре белән сәгатьләр буе ялыкмый карап тора ала иде...

«Хәзер кузгалабыз, Йолдызкай, — дип күңеленнән генә янә атына эндәште Ислам бабай. — Мондагы җәтмәләр әлегә шушында калып торсын, без аларны синең белән кирегә узышлый кереп алырбыз».

Карт арба көймәсенә брезент плащын ыргытты да ат абзарының капкасы төбендә үк аунап яткан итеге белән аяк чолгауларын җыеп алып, киенергә тотынды. Һәр кичне, Ислам бабай эшеннән кайткач, Нәгыймә карчык бу итек белән аяк чолгауларын, сасысы чыга дип, баскыч төбеннән ат абзары янына илтеп ташлый иде...

Итекләрен кигәннән соң, карт амбар стенасындагы чөйдән кайчандыр бик шәп булганга охшаган, әмма хәзер ямьшәеп, искереп беткән коңгырт төстәге эшләпәсен алып, башына каплады да жигүле атны капкага таба әйдәде.

Болдырда ялан аякка резин калош кына элгән Нәгыймә карчык пәйда булды.

— Кайчан кайтасың?

Карт, җавап бирмичә, капканы ябарга борылып керде.

— Син ник әле дәшмәгән буласың? Кирәкмәгән чакта тегермән чарыгы кебек туктаусыз тыкылдарга сиңа куш, ә кирәк чакта сынар тешеңне телең белән урап куясың да, авызыңнан бер кәлимә сүз алып булмый. Җә, синнән сорыйм бит? У-у, эшләпәле карачкы! Синең яшьтә җүнле кеше эшләпә түгел, түбәтәй киеп йөрер иде. Эшләпәсе эшләпә булса иде, адәм ыстырамы! — дип, Нәгыймә карчык болдыр башыннан кулларын болгый-болгый сукрануында дәвам итте. — Әнә, бер чите бөтенләй аерылып төшкән! Тасмасы кеше карарлык түгел, әллә инде карлыган өстендә аунаткан! Җә, телеңне йоттыңмы әллә?

Карты үзалдына мышный-мышный арбага утырып маташа иде.

— Ник дәшмисең дим? Теге, ничек әле, «Бе-өф» дигән җилемне эчеп, авызың ябышып катмагандыр бит?

Ислам бабайның, ниһаять, сабыры бетте. Арбадан җиргә сикереп төште дә капка аша карчыгына кычкырды:

— Туктат лыгырдавыңны! Бар өеңә кереп кит! Ир кеше эшенә тыгылганчы, казаның тирәсендә кайнашсаң хәерлерәк булыр, аңладыңмы шуны, тавык ми! Мин бер өч сәгатьтән кайтырмын.

— Күптән шулай диләр аны. Юкса, ата күркә кебек, түшеңне кирәсең дә, кыяфәтең белән канны бозасың, — дип, ачу катыш шаяртып, Нәгыймә түтәй баскыч башын җыештыра башлады. — Сез ирләр барыгыз да шундый!

Ярсудан картның тыны кысылды.

— Әле син һаман лыгырдыйсыңмы? Кая, юкмы шунда берәр саллы таяк, мин сине хәзер...

Ләкин болдырдагы Нәгыймәдән җилләр искән иде инде.

Ислам бабай маңгай тирен сөртте, аякларын салындырып арбага менеп утырды да дилбегәне тартты.

Буран, бәй чылбырын шалтыр-шолтыр җирдән өстерәп, хуҗасы артыннан карлыккан тавыш белән өреп калды.

2.

Ул, тыкрыкка борылып, элегрәк заманда тимерче алачыгы торган елга ярына таба юл тотты. Тау битендәге корыган чокырлар өстеннән кайнар җил йөри; тау үзе шактый текә булып, әрекмән һәм каз үләне каплаган чирәмле юлның як-ягында, эсседән чәчәге көеп саргайган салынкы башлы кычыткан сабаклары арасында, яртылаш җиргә батып күгәргән трактор тырмалары һәм тимер тәгәрмәчләр аунап ята иде.

Ислам бабайның аты тау башында шып туктап калды.

...Элек бу текә таудан җигүле ат белән бик еш төшеп-менеп йөри торганнар иде, чөнки ул чакларда аста елга аша күпер бар иде. Түбән төшкәндә атлар, тыела алмыйча, тәгәрмәч-тояк тавышлары эчендә җан-фәрманга яр буена чаптырып төшәләр дә, колакларын шомартып һәм тирә-юньдәге халыкның йөрәгенә шом-курку салып, нечкә бүрәнә, чыбыклардан түшәлгән, култыксасыз тар күпер өстенә дулап килеп керәләр. Арбада утыручы йөкче хатыннар, дилбегә очын һавада чыжылдатып болгый-болгый, дөнья ярып көләләр, хахылдыйлар:

— Һей-ә! Алдырт әйдә!.. — дип атларын куалыйлар иде.

Чит авылдан атка төялешеп кунакка килүче-китүчеләр дә гадәттә шушы күпер аша узып йөриләр иде. Бәлеш, чәкчәк ише тәмле ризыклар ашап, ачы бал эчеп изрәгән, арбасына күчтәнәчкә дип төрле тәмтом, прәнник, әтәч сурәтле алсу пыяла конфетлар төягән кайбер кайнар башларның шулай, таудан артык кызу чаптырып төшеп, атлары-арбалары белән бергә күпердән елгага капланган очраклары да булды. Ислам бабай гомерендә монда әллә биш, әллә унбиш кеше батып үлде. Һәрхәлдә, берсен —Суыксуның аучы егетен — ул әле дә бик яхшы хәтерли. Төлкенекедәй очлы, чандыр танаулы бу кешене бик бай, күп акча эшли дип сөйли торганнар иде. Ничек кенә булмасын, бер заман бу кызлар кодалау нияте белән Бикташка бик еш килә башлады. Нинди генә бүләкләр ташымады ул авыл кызларына, нинди генә хикмәтле кыйссалар сөйләп башларын әйләндерергә тырышмады аларның! Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы дигәндәй, Бикташ кызларының башта берсе, аннан икенчесе моны кире какты. Берсенә, янәсе, егетнең учак янында эт кочаклап йоклавы ошамаган, икенчесенә аракы эчүе һәм башын якасына яшереп, бөкрәеп йөрүе ят күренгән... Ахырда, ниһаять, өченче бер кыз ризалык биргән икән дигән хәбәр таралды. Ничек иде соң әле анысының исеме?.. Халисә бугай?.. Әллә Фәхернисамы?.. Шул, кыз ризалык биргәч, егет туй хәстәрен күрү һәм яшь кәләшкә бүләкләр алу өчен шундук үз авылына кайтырга атын җигә. Көз ае иде бугай... Әйе, әйе... көз ае. Казлар җылы якларга очып китә башлаган вакытлар... Балык та инде блеснага гына каба иде... Шул, җигүле ат шушы таудан шундый каты чаптырып төште ки, ярты юлда ук мичәү бавы өзелеп, күпер өстенә килеп керүгә, атның тизәккә басып әллә аягы таеп китте, әллә күпер агачы шартлап сынды, — кыскасы, көймәле арба берьюлы янтайды да хуҗасы-ние белән бергә елгага капланды! Көпчәкләре өскә әйләнгән арбаның су өстеннән бөтерелә-бөтерелә агып китүе Ислам бабайның әле булса күз алдында тора. Ә егет, мескен, шунда һәлак булды — йөзеп чыга алмады. Мәетен багорлар белән дә эзләп караганнар иде, барыбер таба алмадылар. Бу фаҗига соңыннан лыгырдык карчыкларга адәм ышанмастай гайбәт чыгарырга сәбәп булды: имеш, егет арбада бөтенләй булмаган, ул, имеш, шулай күз буяп, Бикташ кызын мәсхәрә кылып, яшерен рәвештә Себергә — аюлар ауларга китеп барган. Тел бистәләре, чәчләренә гатырша мае сөртеп, тәсбих тарта-тарта юк-бар сүз сөйләнеп утырудан ничек армыйлар дигең! Кыз үзенең гыйффәтлеген исбат итеп, егеткә яла ягу урынсыз икәнлеге ачыклангач та, алар һич туктамадылар: «Тфү... хәсис... җен

алыштырган аны, маңгаена мөгез, артына эт койрыгы үсеп чыккач, Себергә китми нишләсен!» — дип, һаман үз якларын каердылар.

Ислам бабай, үзалдына әле елмаеп, әле әче балан капкандай йөзен чытып, тау башында шулай күптәнге хатирәләрне күз алдында яңартып торды. Корткаларны яратмый иде ул.

Ат ара-тирә башын сузып пошкырынып куя — күрәсең, җил белән таралган кайнар ипи, төтен, көйгән май исе аның борынын кытыклый. Иртәнге салкынча һавада янгын чыгу куркынычы азрак булганга, һәр өйдә диярлек мич якканнар иде...

Әйе, кайчандыр анда, бу тау астында, күпер бар иде шул. Әнә, бу ягындагы балчыклы ярында әүвәлге субайлардан сакланып калган өч черек багана төбе әле дә караеп күренә. Елга буенда, көнен-төнен дигәндәй, тәгәрмәч-тояк тавышы яңгырап тора һәм үтүче-сүтүчеләрнең һәммәсе тимерче алачыгы, Ислам бабай йорты каршыннан уза иде. Мозаффар оста арба тәгәрмәче тугымлаган яисә атны дагалаган арада, төбәкнең иң мәшһүр балыкчысын күреп чыгарга теләүчеләр дә еш була.

Андыйлар, өйалды бусагасын атлап кергәч тә, туктап, оялчан төстә бер урында таптанып торалар, түргә үк узарга кыймыйлар иде.

— Суыксудан без... Нурулла Ибраһимыннан сәлам тапшырырга гына дип кергән идек...

— Без Поисеводан... Иван Сидоров күреп чыкмассызмы дип үтенгән иде...

Ислам бабай юлчыларны кара өйгә узарга кыстый, яңа клеенка җәелгән табынга таба кулы белән ишарәли-ишарәли:

— Ирештергән сәламнәрегез өчен рәхмәт, туганнар... Әйдәгез, чәй эчәргә утырыгыз, — ди.

— Мәшәкатьләнмәгез, без хәзер китәбез, атны дагалап кына бетерсен...

— Кем? Мозаффармы?! — дип, шул чак зур мич артыннан, кара күзләрен елтыратып, кулына майлы канат тотып, Нәгыймә түтәй чәчрәп чыга. — Уф, аллам, үләм! — ди ул кеткелдәп көлә-көлә һәм бөкре борыны белән һаваны чукый-чукый, Мозаффарны яманларга керешә: — Һи-һи-һи! Мозаффар бер кадак кагып бетергәнче йолкыш тавык бишалты тапкыр күкәй салыр!

Бу аның шулай юри телләнеп сөйләнүе генә, асылда ул, башкалар кебек үк, Мозаффарның менә дигән тимерче икәнлеген бик яхшы белә.

Инде юлчыларның аеруча кадерлерәкләре килеп чыкса, Ислам бабай аларны эссе кара өйдә генә калдырмый, ак өйгә алып керә. Анда иркен, чиста, стена буенда аяклы зур көзге, уртада озын өстәл тора, тәрәзә төпләрендә гөлләр яшелләнеп утыра.

Кунаклар, үтә сокланулы күз белән як-якка каранып, уңайсызланалар, мактау сүзләре мыгырдыйлар:

— Оҗмах бу! Шундый чиста... Паласларга гына бер карагызчы, күз явын алырлык! (Палас дигәннәре, һәммә өйләрдәгечә, идәнгә сузып салган гади келәмнән гыйбарәт югыйсә...) Кашыкларны инде әйтәсе дә юк, шундый авыр-салмак, мөгаен, эче алтыннан коелгандыр. Юк, юк, Нәгыймә апа, өске ягы гына шулай кургашын аларның, ә астында алтын булырга тиеш! Аһ, рәхмәт, мәшәкатьләнмәгез, бер генә чынаяк эчәм!..

Ислам бабай йортын бирәү дә читләтеп узмый, чөнки анда һәммә кешене якты чырай, тәмле сүз белән каршы алалар иде. Озатканда да буш кул белән җибәрмиләр, күчтәнәчкә дип, бәлеш сыныгымы анда, кипкән балыкмы — ни дә булса кыстырып җибәрәләр. Кунак өчен һич нәрсә җәл түгел. Ә ныклап уйласаң, ул кадерле кунак дигәннәрнең, шәт, биштән бере генә Ислам бабайга чыбык очы туган исәпләнгәндер әле.

Шулай артык киң күңелләнергә кирәк булдымы икән соң?

Хәзер әнә һәммәсе үзгәреп бетте... Күперне икенче урынга күчерделәр. Тимерчелек ябылды — аның эшен хәзер РТСтагы махсус цех башкара. Мәйданга хәзер яшьләр чыкты. Фәкать Ислам бабайның йорты гына әүвәлге урынында, иске рәвешендә торып калды. Элек ике бүлмәле гаять зур бер йорт булып күренә иде ул, инде, барлый башласаң, ин фәкыйрь диган гаиләләр дә андый йортта яшәмиләр. Ярар, хәерле булсын!

— Җә, атла, Йолдызкай! Нәрсә туктадың? На, әйдә!

Күңел төбендә кымтырыкланган ниндидер үкенү хисенә буйсынып, карт ачу белән дилбегәне тартты. Ат сак, вак адымнар белән, алгы аякларын бер-беренә янәшә куя-куя, текә таудан түбән төшә башлады.

Күпер хәзер моннан өч чакрымлап читтә, авылның югаргы очында, таллык артындагы үзән җирдә.

Бикташ зур авыл, бер очыннан икенче очына җәяү барырга уйласаң, ярты көнеңне алдан ук бәхилләп куй. Авыл дага сыман түгәрәкләнеп сузылган биек яр өстенә, Ык елгасы буена салынган иде. Елганың аргы ягы — тукранбаш, кузгалак һәм башка шуныңише болын үләне белән капланган тигез, үзән җир; анда камышлар арасында кечкенә-кечкенә күлләр ялтырап ята. Ә еракта, бер унбиш-егерме чакрымнар ары, күгелҗем рәшә эченнән чак кына төсмерләнеп, Суыксу таулары күренә. Ык — киң түгел, иңе йөз метрдан да артмас, әмма үзе тиз агышлы һәм бик салкын сулы елга. Төбе ком. Елга бер үзәннән озак агарга яратмый, бер як ярына әкренләп ком өя-өя, гел читкә авыша һәм үзенә яңа юл сала бара. Тимерче алачыгы янындагы күпернең киләксезгә чыгуы да нәкъ менә шуның аркасында иде. Соңгы сигез-ун ел эчендә көчле агым бу урынга шул кадәр күп юшкын-ком ташыды ки, елга үзәне әкрен-әкрен артка чигенеп, күпер тәмам сайда, яр читендә утырып калды. Язгы ташулар вакытында исә Ык бөтенләй ярыннан чыга һәм, әлеге Суыксу тауларына кадәр үк барып җитмәсә дә, һәрхәлдә, ярты болынны су астында калдыра, күлләрне басып, яңа үрчем — маймычлар исәбенә аларның балык байлыгын арттыра. Үзәнлектә анда-санда шактый биек калкулыклар да бар; кургансыман күтәрелеп торган бу калкулыклар — шулай ук елга эшчәнлеге нәтиҗәсе. Аларның итәкләре тирәли кара бөрлегән куерып үсә, үрдәрәк — чикләвек куаклары, ә аннан да югарырак, калкулык түбәсендә, кояшта көйгән саргылт чирәм япмасыннан башка бүтән бернинди агач та юк. Анда җил уйный һәм ара-тирә берәр адашкан сыер гына күзгә чалынса чалына. Борынгы заманнарда мондый түгәрәк калкулыкларны кирмән дип йөрткәннәр, имеш.

— Н-на, Йолдызкай!

Ат көймә чылбырлары бәйләнгән карт өянке агачлары яныннан, елга буйлатып, салмак кына юртып бара башлады. Югарыда, яр башында, авыл яңа көнне башлап җибәрергә әзерләнә. Һавада дару үләне — ак ромашка исе аңкый иде.

Ислам бабай, юлда сирәк-мирәк очраган көянтәле-чиләкле кыз-хатыннарның сәламнәренә юньле-рәтле җавап та кайтармыйча, эшләпәсен маңгаена ук төшереп, үзалдына тирән уйларга чумып барды.

«Инде шулай картаюым җитте микәнни? Җитмеш өч яшь бит! Бар иде күңелле заманнар — һәммә кеше миңа килә торган иде. Менә елга юлын үзгәртте — килүчесе дә бетте. Инде малаем олыгаеп бара. Күптән утыз тулып узды үзенә. Ә минем өчен ул әле һаман малай... Кичә әнә аның белән ачуланышырга туры килде, бүтән туганнар белән дә бозылыштым... Бәлки, алар әйткәнчә, мин чыннан да гаугалы, кире беткән картка әверелгәнмендер? Кешедән артык күпне таләп итәм шул мин. Ә ник итмәскә? Үзем соң — гомерем буе кем ни теләсә шуның җаен күреп яшәргә тырышмадыммыни? Шуннан ни булды? Елга үзенең агар юлын үзгәртте — менә шул! Менә бу юлдан мин элек ат белән үтә алыр идемме? Үтәрсең, бар — ул чакта монда су төбендә җәен посып ята иде!

Бәртәс, опты балыклары уйнаклап йөзә иде! Ә хәзер — малай-шалайның үкчәсен чылатырлык та су юк... Һай, гомерләр!..»

Кояш офыкта күтәрелгәннән-күтәрелә барды. Су өсте алсу нурда коена, күзне камаштыра иде. Ислам бабай юл уңаеннан бөтенләй күзен алып, елгага таба аркасы белән борылып утырды.

Әнә берничә яшүсмер малай тау астындагы тиреслектә суалчан эзләп маташа. Кояш кызуыннан тирес өеменең өске катламы бөтенләй кипшереп беткән, агарып, аксылланып тора. Кая инде аңда суалчан булсын — суалчаннар һәммәсе тирәнгә, дымлы төпкә киткән булырга тиеш. Суалчанны хәзер тирестән түгел, мунчадан, ләүкә астыннан эзләргә кирәк.

... Әйе, кайчандыр Ислам бабайның өе кешедән өзелми иде. Күңелле заманнар. Акчаны да һич җәлләп яшәмәде ул, табыны сый-нигъмәткә — тәм-том, варенье, ачы бал, эчемлек ише нәрсәләргә һәр вакыт мул булды. Ләкин елга үзенең юлын үзгәртте. Әнә ул инде кайда ага! Хәзер Ислам бабай атта барган бу комлык — ул аның яшьлектәге балык тотып йөргән җирләре ләбаса. Аңа хәтта шулай тоела: ул хәзер нәкъ менә үзенең кайчандыр су төбенә китеп югалган батыргычлары, кармаклары, кордашлары, яшьлегенең алтын һәм бакыр акчалары өстеннән атлап бара кебек. Алай гына да түгел, ак яуларның пулялары, сөякләре өстеннән атлап бара кебек. Ничек инде алай булырга мөмкин? Мөмкин икән шул. Чөнки елга үзенең агар юлын үзгәртте. Их, кем аңласын Ислам бабайның бу хисләрен! Ул үзе дә моны аңлап җитми әле. Соңгы вакытларда аны нидер борчый, йоклаганда әллә нинди сәер төшләр кереп, төннәр буе актык тешен шыкырдатып чыгарга мәҗбүр итә...

— Әйдә, атлачы, Йолдыз! Кызулый төш бераз! Карыйм, син бөтенләй ялкауландың. Болай булса, син озакламый үзеңә утырырга урындык, йокларга карават та сорый башларсың, ә?

Күпергә җитәрәк карт, дилбегәне кагып, атны елгага таба борды — әйдә, бераз су эчеп алсын. Аннан күпер өсте дә буш түгел — каршыдан әнә ГАЗ-69 машинасы чыгып килә. Машинадагы кешенең парторг Илдар икәнлеген Ислам бабайның очлы күзе шундук шәйләп алды.

Бу як ярга чыгуга, Илдар да машинасын туктатты һәм, кабинадан сикереп төшеп, җете ак тешләре белән елмая-елмая, Ислам картка сәлам бирде:

— Исәнме, Ислам бабай! Картаеп буламы? Тешләр коелып бетмәдеме әле?

Бу егетне карт бик тә ярата, үз күрә иде.

— Илдар! — дип, калтыраулы саңгырау тавыш белән, ничектер ургәлеп, кирәгеннән артык кычкырып эндәште ул аңа. Аннары, кинәт кенә уңайсызланып, күз төпләрен сөртеп алды, арбасыннан ком өстенә сикереп төште. — Ни... Каян кайтып киләсең, улым?

Парторг, күз карашын Ык буйларына юнәлтеп, кулы белән һаваны айкады һәм әүвәлгечә көләч елмаеп:

— Менә... болыннарны карап кайтышым иде, — диде. — Зайцева янындагы борчак басуында да булдым. Көйдерепме-көйдерә — борчак сабагы тимер чыбык кебек каткан. Сәмум эссесе...

Карт, башын чайкап, телен шартлатып куйды.

— Эшләр шулайрак, Ислам бабай... Үзеңнең хәлләр ничек соң? — дип сорады Илдар.

Һаваларның болай торуы Ислам бабайны бик пошындыра, шуңа күрә ул икмәк мәсьәләсендә Илдар кебек елмаеп сөйләшә алмый иде.

— Хәлләр шул: иписез калачакбыз, — диде ул һәм кесәсендәге икмәк кисәген тартып чыгарды. — Менә карап кал, моны бәлки күрә дә алмассың.

Парторг, күзләрен кысып, янә елмайды.

Илдар түгәрәк битле, озын керфекләре астыннан елтырап торган чем-кара күзле, карап торышка гади генә күренгән, шаянрак табигатьле бер егет иде. Сөйләгәндә ул гел башын боргалый, җор сүзләре белән һәммә кешене көлдерә һәм үзе дә рәхәтләнеп көлә иде.

Кыскасы, таш астыннан чыккан егет!

— Кайгырма, Ислам бабай! — диде ул. — Бәрәнге ашарбыз!

— Бәрәнгесе дә күп бетсә ничек?

— Балык ашарбыз. Син бирүзең бөтен авылны туйдырырлык балык тотасың бит!

Бу сүзләр Ислам бабайның кәефенә бик хуш килде.

— Шулаймы? — дип, сүзен дәвам иттерде Илдар, картның йөзенә төбәлеп. — Ничек соң, быел балык әләгәме?

— Бик аз! Юк! — дип, гадәттәге әзер җавабын әйтте карт. — Корбан, табан балыгыннан эреләре бөтенләй калмады диярлек, һәммәсен тотып бетердем. Вакларын тирәнрәк күлләргә күчердем... Имәнкүл белән Җиләскүлгә... Эсселекне кара... Тончыгып үләчәкләр бит...

— Күчергән икәнсең шул, ишеттем.

— Шулай, елгада балык бетте. Төпкә китте, салкынга. Камага качулары да ихтимал. Ләкин планны үтим.

— Тик менә бригадаңда халык бик аз калган диләр.

— Бер Митька калды. Бүтән беркем юк. Ибрай авырый, Хәсән, беләсең... Җылым белән балык тотмаганга биш-алты ел буладыр инде. Җәтмә белән әкрен генә тоткалап маташам шунда... Мурда да салгалыйм... Кордашлар бер-бер артлы дөньядан китә тора. Ат өчен рәхмәт сиңа. Атсыз кыл да кыймылдатып булмас иде... Ә болай үзеңне чын эштә итеп тоясың. Миннән атны тартып алмаслар бит? Син нәрсә көләсең, малай актыгы?

— Теләсәң, сиңа яшь бер айгыр да бар, ал. Шикәр кебек, елкылдап тора. Бәһасе өч йөз сум. Ну, монысын кире тапшырсаң, ярты йөзне өстәп түлисең дә, айгыр — синеке. Йә? Бик сылу, шәп айгыр.

Карт су читендә басып торган Йолдызына күз төшереп алды, кашын җыерып, кулын селтәде:

— Кирәкми... Йолдызга ияләшкәнмен инде... Рәхмәт... Хикмәт атта түгел, менә иген харап була, шунысы яман,— дип, сүзне яңадан икмәккә күчерде ул. — Син менә шул хакта сөйлә.

Илдарның йөзеннән елмаюы качты. Башта сәгатькә, аннан зәңгәрләнеп җемелдәгән төпсез күк йөзенә карады, авыр сулап:

— Әйе, — дип куйды. — Кояшның юмартлыгына чик юк быел... Игеннең сабагы йомран сыртын да кымәрлек түгел. Ә бит инде июльнең егерме өчесе җитте! Яңгыр кирәк! Яңгыр теләп, карчыгың догаларын укымыймы соң ичмасам? Ә?

Карт, хатын-кызларныкыдай шешенке, түгәрәк битен чытып, ачу белән җиргә төкерде:

— Тфү, ул ахмаклардан, тавык миләрдән ни көтәсең!

Шулай дип, янә тынып калды.

— Ник алай дисең?

Ислам бабай йөзен читкә борды. Күңеле артык йомшарып, сабыры бетә башлаган, күрәсең — күз төпләрендә яшь тамчылары пәйда булды.

— Ярар, калдырыйк бу сүзне, Ислам бабай,— диде Илдар, бераз вык дәшми торганнан соң. — Әле кая баруың иде? Киленең янынамы?

— Карале, — дип, кинәт Илдарга эндәште карт. — Бәлагә юлыктым әле мин.

— Ни булды?

— Кичәгенәк яңа көймәмне ватып ташладым.

— Ничек инде алай? — диде Илдар әкрен генә.

— Менә шулай килеп чыкты инде. Кичәгенәк киявем, әлеге Мурзин бездә кунакта булган иде, ул миңе бик рәнҗетте, бөтенесе менә шул

рәнҗүдән килеп чыкты. Менә монда, күкрәктә, нидер сызлый, эчне пошыра. — Карт кояш ашаган җыерчыклы бармаклары белән туктаусыз күкрәк читлеген тырмачлый иде. — Юк, менә монда. Син ник көләсең?

— Ислам бабай, кадерлем! Юкка борчыласың, икенчесен булдыру сиңа кыен эшмени? Алырга үзем ярдәм итәрмен...

— Юк! — дип, шактый каты тавыш белән кычкырып җибәрде карт. — Мин бит яңа көймәне ваттым! Бөтенләй утырып та карамаган яңа көймәмне ваттым! Менә хәзер теге, борынгы елга үзәне болынына иске көймәмне илтмәкче булам. Авыл аша алып барырга туры киләчәк... Мурзин — бик яман кеше, — дип нәтиҗә ясады кинәт Ислам бабай, егетнең йөзенә текәлеп. — Җә, ичмасам, син ни дә булса әйт!

— Яман, алдакчы кеше! — дип, шук, хәтта шатлыклы бер аһәң белән, картның сүзен расларга ашыкты парторг. — Җир астыннан — бөркет, һавадан бәрәңге табып кайта торган адәм.

— Иртән... алар килеп кергәч... уйлыйм: кая, үзләрен яңа бал белән сыйлыйм әле, мәйтәм. Шунда адашкан бер корт Мурзинның күз төбен чагып куймасынмы! Тегенең күзе шеште дә чыкты! Ух, кәефе кырылды да инде, ачудан кара күзлеген киде... Югыйсә корт чакмаган беркем калмаган иде, хәтта Рөстәмгә дә эләкте. Ә миңа тимәделәр... Быел бал бик уңды, тик шунысы бар — артык куе...

Ислам бабай иңбашларын калкыта төшеп, чак кына ялагайлану сизелгән тавыш белән кеткелдәп көлде дә бая башлаган сүзен әйтеп бетерде:

— Корт чакты! Һәммәсен чакты! Берсен-бер калдырмыйча! Уңга да, сулга да! Шуның өчен Мурзин миңа үпкәләде.

Шулай дип, Ислам бабай беравык дәшми торды, аннары уңайсызланып кына:

— Өйләнергә җыенмыйсынмы әле? — диде.

Илдар, машина капотын ябып маташкан шоферына күз төшереп алып, җитди чырай белән әкрен генә җавап кайтарды:

— Юк, Ислам бабай, җыенмыйм. Өйләнү өчен генә хатын сайлау — болында яшел кишәрлек сайлау белән бер ул. Карыйсың, әнә тегендәге кишәрлектә үлән дә куе, көтү дә йөрмәгән кебек тоела, ә якынрак барып баксаң — шундый ук тапталып беткән җир... Йөрәк шартлап ярылырдай сөю-ашкынулар үтте инде хәзер. Шәт, хатын-кыз арасында да андыйлар юктыр. Һәммәсе дә космонавт та артист дип хыяллана. Ә мин кем? Крәстиян малае.

Һәм, хәрбиләрчә күнегелгән хәрәкәт белән ярым борылып, ләкин күз карашын Ислам бабайдан алмыйча, Илдар кызларныкыдай матур-тигез ак тешләрен ыржайтып көлде дә машина янында маташкан шоферга кычкырды:

— Хәким! Ничек анда эшләр?

— Бензин насосы чыгымлый... — диде тегесе, мыгырданып. — Шулай да китәргә кирәк булыр.

Илдар белән башланган сүзнең болай кисәк кенә өзелеп калуына Ислам бабайның кәефе кырылды.

— Насос та насос, — диде ул, үртәләп. — Техника, насос-масослар — һәммәсе ике тиен бер акча! Әнә ул иң яхшы техника! Шулаймы, Йолдыз?

Айгыр су читендә, колакларын уйнакландырып, теге як ярга карап тора иде.

— Мәзәк кеше син, Ислам бабай, — диде Илдар, кабинага менеп утырып. — Әйдә, балыкны күбрәк тот. Ә көймә мәсьәләсен җайларбыз.

Көймә сүзе чыккач, Ислам бабайның ирексездән кашы җыерылды. Ул кабинага таба сизелер-сизелмәс кенә баш какты да бер читкә тайпылды һәм шунда, машина артыннан күккә кадәр күтәрелгән тузан болыты эчендә, бик озак басып торды...

— На, на, Йолдыз! Әйтәм бит, бик ялкауландың әле син! Озаклаunion мый караватта йоклый башларсың, ахрысы. Азыкны да өстәл янына гына утырып ашарсың инде, ә? Әйдә, атла, атла!

Ат адымнарын кызулата төште.

Ислам бабай, башын түбән иеп, арба яныннан артка таба шуышкан юл буйларына карап барды. Комлы урыннарда яшел чәнечкеле шайтан таяклары үсеп утыра, туфраклы урыннарда исә кояшта көеп саргайган ат кузгалагы һәм түмгәк-түмгәк булып караеп торган йомран оялары очрый иде. Картның миендә һаман баягы уйлар бөтерелде. «Их, заманында Илдарны минем кызга, Шәргыяга өйләндерергә кирәк булган икән шул. Тукта, Илдарга хәзер ничә яшь әле? Утыз ике. Рөстәм белән яшьтәш ул. Ә Шәргыягә? Кырык яшь. Ул Мурзинга кияүгә унтугыз яшендә чыкты. Ә ул чакта Илдарга күпме булган? Тәк, тәк, тәк... Утыз икедән алсаң егерме берне... тәк, тәк... унбер килеп чыга. Һм... Унбер яшьлек малай, әлбәттә, өйләнмәс иде аңа. Әгәр мин үзем үтенеп сорасам, егерме-егерме ике яшьләрендә, бәлки, өйләнгән дә булыр иде. Ә Шәргыягә ул вакытта ничә яшь булыр иде соң? Аңа инде утыз яшь тулган булыр иде. Аерма зур түгел. Хатын-кызның иң дәртле чагы. Хәзерге заманда хатын-кыз нәкъ менә шул яшьтә кияүгә чыга да инде. Барын күреп-белеп бетергәч дигәндәй... Мурзинның Шәргыягә алдан өйләнеп куюы харап итте шул!.. Әгәр, әйтик, Илдарны малайның, Рөстәмнең кызына өйләндерсәк ничек?! Рөстәм кызына хәзер ике яшь. Бер унбиш елдан аны кияүгә курыкмыйча бирергә була. Ә ул чакта Илдарга күпме булыр? Кырык җиде? Ирләр өчен менә диган яшь!!! Ләкин ул унбиш ел көтәрме соң? Мин аның белән сөйләшермен, ризалатырмын. Бәлки аны Мурзин кызына өйләндерергәдер, ә? Ни әйтсәң дә, әнисе минем кыз бит. Зур кызларына күпме әле аларның? Тугызынчыда укый бугай... Алсу битле, таза кыз. Бер елдан аңа... Нәрсәдер бутала башладым. Бер елдан күпме була соң әле аңа?..»

Арба түмгәкле такыр юлга чыкты.

Карт, күзләрен кысып, кул бармакларын бөгә-бөгә, нидер санадысәпләде, бөтенләй буталып бетте. Аның башында уйлар берсе артыннан икенчесе туып кына торды. Илдарны Мурзин кызына өйләндерү уеннан Ислам бабай шулай ук баш тартты: «Илдарга ул һич пар түгел! Борыны, әтисенеке кебек үк, нәкъ үрдәк борыны; сөйләшкәндә өске иреннен, җылак бала сыман, гел өскә таба бүлтәйтә. Җитмәсә, артык иркә үзе! Чиләк-көянтә белән су да алып кайтмас, янәсе иңбашын саклый... Юк, юк, Илдарны аңа өйләндерәмме соң! Булмый торсын әле! Алайса нишләргә соң? Тфү, тәмам баш катты!.. Шундый алтын егет күз алдында харап була бит...»

Ислам бабай эшләпәсен батырыбрак киде дә авыз эченнән генә җыр көйләп җибәрде. Ат, иркен сулыш алып, юыртудан туктады, арба да, сикәлтәләрдә артык сикермичә-дыңгырдамыйча, талгын гына тирбәлеп бара башлады.

Ниһаять, көтүлек җирләрне узып, юл әрәмәлеккә килеп керде. Ләкин монда да сыеры-сарыгы күп йөргән булса кирәк: карлыган, эт җиләге куаклары, тәбәнәк таллар шәп-шәрә утыралар. Үләнне инде әйтәсе дә юк — ул тамыры-ние белән тәмам йолкынып-кыркылып беткән.

Иртәнге сәгать алтылар тирәсе булса да, кояш инде бик каты кыздыра иде.

Карт, кызгылт-кара уч төбенә аркылы салган дилбегә очын тибрәлдерә-тибрәлдерә, җырын дәвам иттерде:

Алтын кармак ла салдым зур суларга,
Ак балыгын алдым кулларга.

Карасам ла күземнең нуры кала
Яшьлек ярым ла киткән юлларга...

Һава коточкыч бөркү, бөтен тирә-як күгелҗем томанга өртелгән кебек. Ат, башын түбән салындырып, салмак кына атлый.

Эчкәрәк кергән саен, әйләнә-тирәдәге агачлар куера барды, шактый биек яшь имән ешлыклары, усак, шомырт агачлары күбрәк очрый башлады. Әмма аңа карап һаваның эсселеге кимемәде, киресенчә — арта гына төште. Монда җилнең әсәре дә юк, кызудан тын кысыла, башлар әйләнә иде.

Биек тау башына, әй, меналмыйм,
Менсәм дә лә, кошлар тоталмыйм.
Син лә, бәгырькәем, исемә төштен,
Капкан кисәгемне лә йоталмыйм.

Вакыт-вакыт әрәмәлек як-якка аерылып, киңәеп китә дә, ачыклык хасил булып, алда нинди дә булса кечкенә күлнең кара өсте ялтырап күренә. Быелгы челләдә күлләрнең күбесе бик нык саекты, яр читләрендәге кыяк үлән, табигый яшеллеген югалтып, калай төсенә керде, корышып-катып калды. Монда тынчу, ләм исе аңкый, су читләрендә ком төсендәге вак бакалар сикерешә, ә әүвәлге сазлы урыннар аша чыбыкчабык түшәлгән ат юллары хәзер бөтенләй тап-такыр иде.

Юл өстендәге беренче күлгә Ислам бабай үзе Имәнкүл дип исем кушкан иде. Шул күлгә барып җитүгә, ул:

— Тырр! Тукта! — дип, дилбегәне тартты да, арбасыннан төшеп, камыш сабакларын аралый-аралый, күл ярының корырак урынына килде. Чүгәләп, учын суга манчыды, аннары аны авызына якын китереп, теле белән татып карады.

— Ачы су... күкерт тәме килә... — дип мыгырданды карт.

Хәзер аның чырае үтә җитди иде. Чигә-яңакларындагы чал төкләр тырпаеп кабарган, авызы турсайган, йонлач кашлары, түбән таба җыерылып, күзләрен каплаган. Аның бөтен торышы көлкеле-дәһшәтле бер кыяфәт алган иде. Шул рәвешендә ул яр буенда бик озак басып торды.

Ахырда учларын чалбарына ышкып алды да ары кузгалды.

— Дөрес әйткәнмен ич... — дип, янә үзалдына мыгырданды ул. — Ә сез көлгән булдыгыз... Соңыннан үзегез үк рәхмәт диярсез әле. Минем борын бик тиз сизә! Әйеме?

Ат адымын кызулатты; арба түмгәкләр өстеннән ава-түнә шыгырдап алга тәгәрәде.

Имәнкүлдәге балыкны Ислам бабай инде күптән Җиләскүл суына күчергән иде. Йөзагач күлендәгесен дә ул шулай берсен-бер калдырмыйча сөзеп алып, икенче бер күлгә илтеп салган иде. Ни өченме? Сәбәбе болай.

Моннан ун көннәр чамасы элек Ислам бабай өенә Илдарның энесе Рәшит атылып килеп керде. Бик каты дулкынланган, сулышын көчкә ала. Абыйсы шикелле үк, чуртанныкыдай калку тешле, артка табарак очлаеп торган башлы чая бер малай иде ул. Килеп керде дә, бер сулыштан:

— Ислам бабай, теге як ярда көрәп балык сөзәләр! — дип кычкырып җибәрде.

Ислам бабайның улы Рөстәм ата каз тавышы белән гаңгылдап куйды, ләкин карт аңа таба шундук дәһшәтле күз карашын юнәлтте. Малай сүзеннән ул эшнең нәрсәдә икәнен бик тиз аңлады. Мондый хәлнең булу ихтималын күздә тотса да, ул аны болай якын арада булыр дип һич көтмәгән иде. Әйе, яман хәбәр иде бу!

Карт, күп сөйләшеп тормыйча, атны җикте, вак күзәнәкле җәтмәләрне арбага салды да, малайны ияртеп, елганың аргы ягына ашыкты.

Иөзагач күленә барып җитүгә Ислам бабай яр буенда ыгы-зыгыланып йөргән өч авылдашын шундук таныды. Тегеләр, картны күргәч, аптырабрак калдылар һәм, штраф түләүдән куркып, кызып-кызып акланырга тотындылар:

— Нәрсә, тотарга ярамыймыни! Барыбер тончыгып үлеп бетәчәкләр бит! Әнә кара, инде бөтенләй мингерәүләнгәннәр, койрыкларын көчкә селкетәләр. Җә әйт, без нинди яман эш эшләгән? Ярар, алайса, үзенә булсын, ал...

Карт шунда бер читтә яткан ике чыпта сумкага күз төшерде: ләм һәм яшькелт суүсемнәр ябышкан соры тәңкәле эре-эре кәрәкәләр, кызыл күзләрен акайтып, сумка авызыннан бер-бер артлы җиргә сикерәләр иде. Кимендә бер утыз килограмм булыр!

Ислам бабайның тәмам җен ачулары чыкты, ул хырылдаган, бусарынган тавыш белән, аяк тибә-тибә, авылдашларына җикерде:

— Эзегез дә калмасын монда! Адәм актыклары! Ярабби, сөякләре тамагыгызга кадалсын, бугазыгызга аркылы ятсын! Барыгыз, башка бүтән күземә дә чалынасы булмагыз!

Шулай дип, ул имән бармагы белән авылга таба төртеп күрсәтте.

Тегеләр, каушаудан ни дип җавап бирергә дә белмичә, дәррәү урыннарыннан куптылар, ләкин карт, сеңерле йодрыгы белән һаваны ярып, аларны янә туктатты:

— Ә балыкны! Харап иткәнсез икән — үзегез белән алып китегез! Җир битләр! Мин сезне төрмәгә яптырырмын! Туган тиешле кешем милициядә эшли минем! Ялкаулар!...

Браконьерлар, сумкаларны эләктереп, тиз генә таллык арасына кереп шылдылар.

Хәзер күлдә калган вак балыкны ничек тә коткарырга кирәк иде.

Чыраенда әле һаман ачуы сүрелмәгән Ислам бабай чалбар балакларын сызганды.

— Рәшит, тот җәтмәнең теге очыннан.

Алар, суга кереп, иңе ун-унике метрлы түгәрәк күл әйләнәли җәтмәне яр буйлатып суздылар да, төптән шудыра-шудыра, каршы як ярга таба сөзеп бара башладылар. Тирәнлек күлнең урта җирендә дә нибарысы бот тиңентен генә иде. Ислам бабай белән Рәшит шулай, авыр җәтмәне як-яктан аһ-ваһлап сөйри-сөйри, ярга тартып чыгардылар. Җәтмә койрыгында эресе-вагы бергә, шактый күп санда кәрәкә һәм чабак балыклары кыймылдаша иде.

— Тизрәк! Шнеллер! — дип кычкырды карт. — Арбага саз үләне ташы.

Ул үзе дә, яңадан суга кереп, шарт-шорт кыяк үлән, төнбоек сабаклары йолкырга, су өстеннән бака ефәге җыярга тотынды. Боларның барысын бергә арбага җәеп салдылар. Малай хәлдән тайган, сулышын көчкә ала иде. Бабай аны гел дәртләндереп торды:

— Бөтен авылга бердәнбер акыллы, чын ир кеше табылды — ул да булса син, Рәшит. Илдар абыең шундый энекәше булуына бик шатланыр инде. Туп-туры миңа килеп бик әйбәт эшләгәнсең, маладис... Ай-яй, шул кадәр кибәр икән күлләр... Суы җып-җылы, андый җылыда балык түзәме соң? Тагын ике-өч көн болай барса, ләм белән укмашып бөтенләй һәлак булып бетәчәкләр.

Аның үзенең дә борыны һәм яңаклары буйлап шабырдап тир ага, агып төшеп авызына керә, шуңа күрә сөйләгәндә юеш иреннәре чупырдап-чупырдап куя иде. Шул ук вакытта картның куллары, өзлексез хәрәкәтләнеп, эшне эшли бирделәр. Тиздән җәтмәдәге балык арбага, дымлы үлән арасына илтеп салынды.

Алар шулай, икәүләшеп, җәтмә белән тагы бер кат күлне сөзеп чыктылар. Бу юлы да ике чиләк чамасы кызгылт-алтынсу тәңкәле вак ба-

лык элэкте, алар арасында картның эшләпәсе зурлыгында дигәндәй ике корбан балык та бар иде.

— Ух, менә бу балык ичмасам! — дип пышылдады малай, күзләрен шарландырып. — Патша балык!

— Алары сиңа, — диде карт эре генә. — Хезмәтең өчен.

Тотылган бар балыкны төяп, өстен юеш үлән белән каплагач, Ислам бабай белән Рәшит арбага сикереп менеп утырдылар да, атны чыбык белән куалап, янә кузгалдылар.

— Хәзер аларны кая куябыз инде? — дип сорады малай.

— Җиләскүл суына җибәрәбез, — диде карт.

Бу әрәмәле, җиләкле урыннардагы сулыклардан Җиләскүл иң озыны һәм иң ышанычлысы санала иде. Аның уң ягында имән урманы үсеп, сул яры буйлап болын җирләре сузылып киткәнгәме, монда һәр вакыт җиләс һәм салкынчарак иде.

Ислам бабай белән Рәшит тере йөкне күлгә бушаттылар да кирегә борылдылар. Балыклар әле миңгерәү хәлдә, шуңа күрә суда алар шундук корсаклары белән әйләнделәр.

— Мин беләм, алар терелэчәк, — диде Рәшит. — Балык ул бик яшәүчән була, бигрәк тә карабалык, иеме, Ислам бабай? Табага кыздырырга салган җиреннән сикереп чыга.

Карт тешсез авызын ерып көлеп куйды һәм атны куалады.

— Сезнең эш кызыклы шул,— дип, авыр сулады Рәшит. — Үскәч, мин дә балыкчы булам. Мине үзегезгә алырсызмы?.. Ә ник... ә ник сезнең булышучыларыгыз юк, Ислам бабай? Сезнең бригада булырга тиеш бит?

— Бригада булырга тиеш димсең? Ә ник булмасын! Менә мин үзем бригада түгелмени? — дип, шаяртыбрак җавап бирде Ислам бабай, анныры җитди төстә сүзен дәвам иттерде: — Абыеңа рәхмәт инде, ичмасам ул булышкалый. Менә ат сатып алырга рөхсәт бирде, җәтмәләр табарга да ярдәм итә... Их, улым, улым, кеше дигәнең акчасыз эшне бигүк өнәп бетерми шул ул. Колхозда өч тапкыр артыграк акча эшләргә мөмкин булганда, нигә әле ул иртәдән кичкә чаклы эссе кояш астында көймәдә пешеп утырсын яки, саз жырып, авыр җәтмә сөйрәп йөрсен? Әнә, кара — хөкүмәткә балыкның килосын утыз ике тиеннән алалар. Ә суда балык кимегәннән-кими бара. Әйт, ниндидер утыз тиен хакына бригада төзеп, бергә матавыкланып йөрү кемгә хаҗәт? Хәзер халыкта акча күп, балык кирәк икән, ул аны килосын бер тәңкәдән сатып ала да ашый, ә кайберәүләр яшерен рәвештә үзләре үк тоталар. Тоталар гына түгел, шул ук берәр тәңкәдән кешегә саталар. Әйе, шундыйлары да бар. Көндезен колхоз эшендә, төнен — елга буенда.

— Сез инде шулай гел ялгыз калдыгызмыни? — диде малай, Ислам бабасын кызганып.

— Ялгыз дип... Митька бар.

— Аны эчә диләр бит!

Карт малайга таба гаҗәпсенгән күз карашы ташлап алды.

— Аның каравы — алтын куллы. Ясаган көймәләрен күр, нинди!.. Әйдәле, атла, Йолдыз!

Алар яңадан Йөзагач күле ярына килеп туктадылар. Яңадан өч мәртәбә шушы кечкенә күлне җәтмә белән аркылыга-буйга сөзеп чыктылар. Карт та, малай да баштанаяк кара сазга батты. Күл суы тәмам болганчыкланды. Балыклар, кызуга чыдый алмыйча, сүүсемнәр, камыш сабаклары астына — ләмле төпкә үк төшеп яшеренгәннәр, аларны урыннарыннан кузгату өчен, ләмне аяк бармаклары белән сөреп-тырмалап йөрергә, үләннән чистартырга туры килде. Зур-зур кәрәкәләр, чабаклар болганчык суда ары-бире атыла, шома, авыр-салмак тәннәре балтырларга бәрелеп китә; өлгеррәк эш итсәң, аларны хәтта кул белән элэктереп алырга да мөмкин иде.

— Уф! — дип, авыр сулады малай, ак тешләрен ыржайтып.— Балыкны болай тотканны ишеткәнем дә юк иде. Менә карагыз әле — кулым белән тоттым. Үземә алыйммы?

Ислам бабай баш какты.

Рәшит шундук яр буендагы өянке куләгәсенә таба йөгерде. Анда үлән арасында аның бая Ислам бабай биргән ике зур балыгы ята иде. Малай үзе тоткан чабакны да шулар янына яшерде. Ә янәшәдә, брезент астында, тагын бер өем эре балык — анысы Ислам бабайның үзенеке. Аларына соргылт тоз сибелгән иде.

Вак балыкны бу юлы да Җиләскүлгә илттеләр. Бая китерелгәннәрнең берсе-бер су өстендә күренми — һәммәсе, терелеп, анга килеп, төпкә, шифалы салкынга качканнар. Күл өсте кояш нурлары астында әкрен генә шадраланып җемелди иде.

Бабай белән малайның кыяфәтләренә карарга да куркыныч: тәннәре, киемнәре баштанаяк балык тәңкәсенә, лайлага, яшькелт-көлсу үлән сабакларына пычранып беткән иде.

— Җә, ничек соң, безнең эш ошадымы үзенә? — дип сорады малайдан Ислам карт.

Үлеп арыган Рәшит, күз кабакларын йомып, бер сүз белән җавап кайтарды:

— Ошады!

— Шулай булмыйча... — диде Ислам бабай, малайны мактап.— Үсеп җиткәч, миндә эшләрсең менә. Үзеңә кыз да табып бирермен.

Алар Йөзагач күленә соңгы тапкыр әйләнеп кайттылар. Карт, ялгызы гына суга кереп, аяк табаннары белән төпне капшый-капшый, күлне янә бер кат тикшереп чыкты.

— Биш-алты көннән күл бөтенләй кибеп бетәчәк. Иртәгә тагы бер мәртәбә сөзеп карарга кирәк булыр. Ә хәзер — киттек икенче күлгә. Күңелем тоя: анда да хәлләр яман булмагае...

Болай да аягында көчкә басып торган Рәшитнең йөзе шундук турсайды. Ул инде эш бетте дип уйлаган иде.

— Әйе-е... — дип сузды Ислам бабай, уйга калып.

Алар шунда, яр буенда, кайнар җир өстенә утырдылар.

Аяз күк йөзендә күзләрне камаштырып кояш балкый, ерактагы күгелҗем калкулыклар рәшә эчендә тирбәлә, ә ат тирәсендә бызылдап бөгәлчәннәр әйләнә иде.

Шул чак авыл ягыннан бире таба атлап килүче бер кеше күренде.

Карт төбәлебрәк карады да җиргә төкерде.

— Кире борылган... Мөгаен, җәтмәсен алырга киләдер. Кызык, баягынак алар күл төбен ни белән тырмачладылар икән? Син, Рәшит, кирәк белән дигән идеңме әле?

Малай, Ислам бабасының иңенә сөялеп, тәмле йокыга чумган иде. Карт аны әкрен генә иңбашыннан тотып җиргә сузып яткырды, аннары, күләнкә булсын өчен, малай янәшәсенә кояш ягыннан ат арбасын чигендертеп куйды. Үзе исә авылдашы каршысына таба атлады.

Тегә, кепкасын салып, як-ягына карана-карана, сүзне ерактан башлады:

— Гаеп итмә, Ислам бабай. Зинһар, гаеп итмә! Авылга җитәр-җитмәс кире борылып килдем. Сиңа әйтәсе сүзем бар.

— Син миңа ни әйтмәкче буласың? — дип сорады карт төксә генә.

— Иманкүл суының төсе бермә-бер каралган, нәкъ менә сумала диярсең. Аннан бик нык саеккан — балыкларның йөзгәндә сыртлары күренеп кала. Ә Яшелкүл бөтенләй кипкән диярлек. Күлдәвек кадәр генә калган. Бүген суында кулым юган идем, ике кысла эләкте.

Карт дәшмәде.

— Вак балыгы төптә, ләм эчендә качып ята. Эреләреннән бер унлап корбан балыгы тоттык тотуын, әмма башкаларына тимәдек. Валлаһи менә, ышан сүземә, Ислам бабай.

Вафир исемле бу кызыл битле егетне Ислам бабай күптән белә иде. Ялгышмаса, ул аңа җептәй нечкә чыбык очы туган да тиешле иде бугай әле.

Карт НЯК ікакты. Янәсе, сөйли бир.

— Әгәр каршы булмасаң, мин сиңа булышырга дип килгән идем, Ислам бабай. Юкса сиңа берүзеңә бик кыендыр...

— Булышыр кешеләрем бар минем, — диде карт, тавышына серле бер аһәң биреп.— Малай гына да түгел... Ярар, анысы калып торсын... Сине әйтәм, ичмасам әйләнеп килә белгәнсең. Димәк, вөҗданың үз урынында икән әле. Аны каеш белән тагы да катырак бәйләп куй, ярыйммы?

Ислам бабай йоклап яткан малайга карап алды. Аңа хәзер, бүген үк башка күлләрне дә йөреп чыгарга кирәк иде. Ләкин тотылган эре балыкны кая куярга? Центнер ярым чамасы бар бит ул!

— Әй, Рәшит улым! Тор!

Малайны төрткәли-төрткәли ничек кирәк алай йокыдан уяткач, карт аңа болай дип белдерде:

— Хәзер үк авылга кайт та, атны безнең ишегалдына җертеп, Рөстәм абыеңа әйт: балыкны кар базына төшерсен, аннары капчыклар алып, җигүле атта тиз генә Яшелкүлгә килсен; әгәр без анда булмасак, Имәнкүлгә юл тотсын. Аңладыңмы?

— Аңладым, — диде Рәшит. Ул әле һаман йокысыннан айнып җитмәгән, сул күзен челт-мелт йомып, битенә ябышып каткан балык тәңкәләрен бармагы белән куптарып маташа иде.

Балыкны арбага төяделәр, шунда бер кырыйга Рәшитнекен дә яфракка төреп салдылар. Ислам бабай, кайсыдыр сумкасының кесәсеннән бер чеметем тоз алып, аны малайның балыкларына сипте.

— Рәхмәт сиңа, улым, — диде ул. — Бүген бүтән килеп йөрмә инде, бу зурлар эше, өзлегерсең. Кирәк булсаң үзем чакыртырмын. Колагыңны өй кыегында тот!

Шуннан алар, Вафир белән икәүләп, авыр җәтмәләрне җилкәләренә салдылар да Яшелкүлгә таба карап киттеләр. Малай исә атны Бикташка куалады.

Ислам бабайның әле дә исендә: ул көнне бик иза чиктеләр алар — кичкә кадәр саеккан күлләрдән Җиләскүлгә балык ташыдылар. Балыкның һәр төре — кәрәкәсе, чабагы, эресе-вагы һәммәсе бергә апарадай куе, кара лайлалы суда тулгана; алар шул кадәр каралар, пычраклар иде ки, хәтта карарга, кулга тотарга да куркыныч иде.

Яшелкүлнең, суы кибеп, сазга әверелгән төбен балыгы һәм ләм катыш үләне белән бергә җәтмәгә җыеп алып, арбага төяделәр.

Кояшның утлы шары күк йөзе буйлап күтәрелгәннән-күтәрелә бара иде. Кызган һава сулышны кыса, юеш беләкләрне һәм аяк балтырларын бөгәлчән, кигәвеннәр сырып алган — алар тешлиләр, яндырып-яндырып тәнгә укларын кадыйлар; тозлы тир, җыерчык араларына тулып, муенны әчеттерә, күзләрне каплый иде.

Рөстәм, — бөкрәебрәк йөргән озын буйлы, чандыр гәүдәле, урта яшьләрдәге кеше, — эшнең һич җаен таба алмыйча, маңгае турысыннан баш түбәсенә таба тар юл сыман сузылган һәм пәке белән кыркылгандай шомарып ялтыраган дымлы, алсу пеләше тирәли тузгып тырпайган җете җирән көдрә чәчләрен селеккәләп, гел бер тирәдә таптанып әйләнде һәм этисенең ачуын кабартканнан-кабарта барды.

— Син нәрсә баганадай катып торасың... — дип сүкте аны Ислам бабай.— Кыяфәтен генә күр: торуы тору, атлавы атлау түгел! Иелсәң билең сынар дип куркасыңмы әллә? Профессор пеләшеңне берәр чүпрәк белән капла да эшкә тотын!

Шулай дип, карт үзе жиргә иелә, бармакларын житез хәрәкәтләндереп, жәтмә күзәнәкләренә чуалган үсемлек калдыкларын чүпли, кыслаларны, пычрак төсендәге ябышкак сөлекләрне кагып төшерә.

— Ә нишләргә соң миңа? — дип, ихтирам белән сорый улы һәм, баскан жиреннән генә кулын сузып, бармак очларын жәтмәгә тидереп ала.

— Бар әнә, үлән йолкы!

Шуннан соң утыз яшәр малай, ике яшьлек кыз бала атасы, культура йорты директоры, жиргә чүгәли, мыек астыннан гына мәсхәрәле көлемсерәп, нечкә муенлы тубал башын әле бер якка, әле икенче якка боргалый-боргалый, әйләнә-тирәсендәге кыяк үләнне ярсып-ярсып йолкырга керешә. Әтисенең сөйләнүләренә, эндәшүләренә ул бөтенләй жавап бирми, фәкать ара-тирә секундка башын калкытып, гасабилы һәм курыкган кыяфәттә картка таба жете зәңгәр күзләрен төбәп тора, аннары тагын үз эшенә тотына иде.

— Ярар, житәр! — дип кычкырды, ниһаять, Ислам бабай. — Сыер ашлыгына дип йолкымыйсыңдыр бит? Балык өчен монысы да житеп ашкан! Бар, Жиләскүлгә атла. Чәй кайната тор. Вафир белән мин килешкә бөтенесе әзер булсын! Кара аны, чәеңә карлыган яфрагы салырга онытма!

Карт белән кызыл битле егет, соңгы йөкне төяп, Жиләскүлгә барып житкәндә, Рөстәм чынлап та бөтенесен әзерләп куйган иде инде. Учак өстенә аскан казанда быгыр-быгыр нидер кайный — төсе белән имән урманындагы тәгәрмәч эзләренә жыелган суны хәтерләткән хуш исле, куе-каты чәй иде бу.

Ләкин башта эшче халык әйбәтләп су коенып, юынып алырга булды. Баткаклыкта йөри-йөри, бөтен тән әллә нинди яшькелт-зәңгәр, шәмәхә төстәге таплар белән капланган иде. Аларны юып төшергәч, арка-балтырларда яңалары — камыш һәм кыяктан тырналган кызгылт эзләр бүртеп чыкты.

Ислам бабай, авыз эченнән әкрен генә кеткелди-кеткелди, рәхәтләнеп коенды. Аның арыган тәне шундук жиңеләеп киткәндәй булды.

— Әйдә, улым, син дә коен! Кояшта пешеп үләсең бит инде! — дип, ягымлы тавыш белән эндәште ул Рөстәмгә.

Тегесе су читенә барып басты, түбәнчелек белән:

— Әти... Минем коенасым килми; әйтергә мөмкин, миңа болай да рәхәт, — диде.

Коенучылар, күл өстендәге ярым миңгерәү һәм тиздән саф суда тәмам жанланырга тиешле вак балыклар арасыннан үзләренә юл ача-ача, ярга чыктылар да учак янына килеп утырдылар.

— Менә ичмасам чәй! — диде Ислам бабай, кружканы иреннәренә тидереп, һәм канәгать бер кыяфәттә күзләрен йомды.

Рөстәм чәй эчмәде. Ялтыр пеләшен туп-туры әтисенең күзенә терәп, берни сөйләшмичә, башын иеп тик утырды. Ислам бабайның кыстау сүзләренә дә:

— Рәхмәт, эчәсем килми. Эшне сез эшләдегез бит — чәйне дә үзегез эчегез, — дип кенә жавап бирде.

Карт үзалдына ачулы көлемсерәп куйды, әмма каршы сүз әйтмәде...

Икенче көнне Ислам бабай, Митька, авыру Ибраһим һәм Рәшит, дүртәүләп, Иманкүлдәге балыкны коткару эшенә керештеләр. Күл галәмәт зур — кимендә бер ун-унике тапкыр сөзеп чыкканнардыр. Башта эре күзәнәкле жәтмә белән уздылар — егерме потлап эре балык эләкте. Арада кило-кило ярымлы ерткыч чуртаннар да бар, ләкин күпчелеге табан балык белән кәрәкә иде. Аларның һәммәсен авылга кайтарып куйдылар. Аннары вак күзәнәкле жәтмәләргә нәүбәт житте, һәм эшнең барышы нәкъ кичәге тәртибендә кабатланды. Бөтен әйләнә-тирә тир исе,

саз, күкерт исе белән тулган, кояш рәхимсез кыздыра иде. Болай да хаста Ибраһимның шәрә иңбашлары тәмам янып-пешеп чыкты, температурасы күтәрелде — ул бертуктаусыз чәй эчә, ничек кенә үгетләсәләр дә, өйгә кайтып китәргә теләми иде. Ислам бабайга яшьтәш диярдәй Митька карт, махмырдан чырае әле ачылып та җитмәгән булуга карамастан, шулай ук дөнья җимертеп эшләде...

Ул арада авылда сүз таралды: Ислам карт бер күлдән икенче күлгә чиләкләп су ташый, арбага төяп балык күчерә икән, мондый хәлнең дөньяда булганы юк иде, тәгаен, акылыннан язгандыр ул, дип сөйләнделәр. «Йөри шунда үзенә мәшәкать арттырып! — диделәр икенче берәүләр, әзергә хәзерне яратучы акыллы башлар. — Нияте мактаулы да, нәтиҗәсе ничек булыр! Балыкны аны тоткач шулпага салырга кирәк! Икенче күл суында ул әллә терелә, әллә юк — анысы билгесез әле. Табан балык судан чыгаргач өч минут эчендә үлә, ә кәрәкә — ун минуттан. Чуртан — ярты сәгатьтән. Бушны юкка аудару бу, карт көлкегә генә калачак...»

Ләкин карт үз эшен бик белеп эшләде. Юеш үлән эчендә нинди балык күпме үлмичә тора алганлыгын ул инде гомере буе белә иде.

Ислам бабай үзенең ярдәмчеләре белән бергә (Илдар аңа ярдәмгә ун кеше, биш ат бирдерткән иде) ун көн буена шулай иртәдән кичкә чаклы балык үрчемнәрен коткарып йөрде. «Әгәр миңа алтын манара салып бирсәләр, мин шул манараның очына менәр идем дә, шуннан торып, әлеге бушбугаз, тук тамакларның башларына лач итеп төкерер идем!» — дип, көрсенеп уйланды ул.

Эшләрне бетергәч, ул эчүгә бирелде... Аннан Мурзин килеп йөрәкне бозды...

Ә хәзер ул менә Җиләскүл һәм Зур күлдәге җәтмәләрне һәм эләккән балыгын алып кайтырга дип бара. Берьюлы иске көймәсен дә алыр. Ул күлләргә бераз ял бирергә кирәк. Ә елганың сул як ярындагы күлләрдә Ислам бабайның инде бер ай чамасы булганы юк, ул хәзер бөтен эшне шунда күчерәчәк.

Карт, тәмам кипшереп, караеп утырган Имәнкүл яныннан уза-узышлый, үзалдына мыгырданып сөйләнде:

— Нигә минем Рөстәмем шундый булды икән? Нигә Илдар минем улым түгел дә, Рәшит минем төпчек малаем яки оныгым түгел икән? Әгәр Рәшитне минем оныгыма — кызымның кызына өйләндерсәк ничек булыр, ә? Ай, тиле баш, ни сөйлим! Рәшиткә — унбиш, ә минем онykka ике генә яшь ләбаса. — Карт кул бармакларын бөгә-бөгә янә саный башлады. — Туктале, бик шәп килеп чыга түгелме? Шулай шул! Булды: унбиш елдан, димәк, мин оныгымны Рәшиткә кияүгә бирәм дә Илдар белән туганлашам. Ул чакта миңа ничә яшь була? Исәплик әле. Һм, сиксән сигез икән. Хәер, нәрсәсе гаҗәп! Әнә Арслан абый, аллага шөкер, инде туксанны тутырды. Арслан абый дигәннән, аны күптән күргән юк. Бүген, иске елга үзәнендәге күлләргә барышлый, кереп чыгарга кирәк булыр!.. Умарталыкка ягъни. Ул инде күп кешене танымый диләр... Мине дә танымас микән? Юк, таныр, танымыймы соң!.. Их, бу ялгызлык, каһәр суккан ялгызлык!.. Сәхра уртасында ялгыз янган ут та бер, мин дә бер...

Шулай сөйләнә-сөйләнә һәм башына батырып кигән эшләпәсе астыннан тирә-ягына күз салгалап, Ислам бабай юлын дәвам иттерде. Гөлҗимешләр быел иртәләгәннәр — инде саргаеп киләләр; моннан өч атна элек чабылып, кечкенә кибәннәргә өеп куелган печән дә, уңып, үзенең табигый яшеллеген югалткан, соргылт төскә кергән; җил очырмасын өчен кибән түбәләренә бастырган өянке ботакларының яфраклары исә, бөтенләй коргаксып, уалып коела башлаганнар. Кая карама анда чикерткәләр сикерә иде.

Юл һаман әрәмәлекләр эченнән, кара карлыган, эт җиләге куаклары яныннан бормаланып бара. Ара-тирә яшь имән ешлыклары очрый, алар сизелер-сизелмәс җилдә дә калай төсле каты яфраклары белән әкрен генә шыбырдашып калалар иде.

Ислам бабай имәнне бик ярата иде. Аның йөзенә горурлык галәмәте чыкты.

«Нык агач! Яфрагы да нык! Заман аны, кәҗә кебек, һәр ягыннан кимергән дә кимергән. Ә ул карышкан, дошманны якын җибәрмәс өчен, учарланып, ботакларын киң җәеп үскән. Һәм исән калган. Минем кебек үк. Уйлап карасаң, ни генә күрмәде минем баш!.. Ачлык... ике сугыш... нэп... Үзбәкстан, Төркмәнстан... Хәвефле, хәтәр төннәр... Ә мин әле һаман исән-имин!»

— На-а, атла, Йолдызкай! Нәрсә, тагы йокың киләме? Түшәк җәеп биримме әллә? Оят кирәк, иптәш!.

«Перекоп янсә басмачылар турында сөйли башладым исә, көлгән булалар, эт җаннар... Булмаганны сөйлиммени мин? Барысы да үз башымнан кичте, үз башымнан! Ә Рөстәм әйтә: «Җитәр, һаман бер нәрсәне чәйнәмә... бу теманы синнән күп ишеттек инде!» — ди. Һм!.. Бу теманы, имеш. Ник кадалып китмисез шунда...»

Ат, әледән-әле койрыгын селтәп, бөгәлчәннәрне куа, юлдан кояшта кибеп кызган сыер тизәге исе килә иде. Ислам бабай борын эченнән генә тагы баягы җырын башлап җибәрде:

Алтын кармак ла салдым зур суларга,
Ак балыкны алдым кулларга.

## 4

Кинәт ат туктады, чәнечкеле гөлҗимеш һәм кара бөрлегән куаклырына барып төртелмәс өчен, башын югары чөеп, бөтен гәүдәсе белән читкә тайпылды. Димәк, Җиләскүл, килеп җиттек.

Ислам бабай атны тугарды да, озын бауга арканлап, утларга җибәрде. Монда, күл буенда — камышлык белән кара бөрлегән куаклары арасындагы ачык полосада, комлы калкулыклар һәм бөтен үзән буенча сибелгән исәпсез-хисапсыз вак таллыклар әйләнәсендәге аланнарда, — печән инде күптән чабып һәм җыеп алынган, хәзер аның чүмәләләре генә, сирәк утраучыклар сыман, әле монда, әле тегендә караеп күренәләр иде. Ләкин чалгы очы барып җитмәгән куак төпләрендә, колмак ешлыкларында аз-маз азык табарга мөмкин иде әле, һәм Йолдыз кашка туп-туры шунда юнәлде, күләгәле ботак асларына башың тыгып, әкрен генә чемченеп йөри башлады. Ул шулай бер урыннан икенче урынга күченгәндә, аркан бау, тураеп, камыллы түмгәкләрне сыдырып-сыдырып ала иде.

Карт тирләгән муенын сөртте, нәфрәт белән аяк астындагы учак көленә күз төшерде. Учак тирәсендә әле һаман буш шешәләр, икмәк, азык калдыклары, яна башлап та, юеш булганга янып бетмәгән соргылт кәгазь кисәкләре һәм башка төрле чүп-чар аунап ята иде. Кичә шушында сыйландылар алар, Мурзин белән ачуланышу да шушында башланды. Тфү!

Карт, куакларны як-якка шаулатып аерып, коңгырт чуклы камышлар арасыннан күл ярына таба атлады.

Аллага шөкер, әле ярый шушы Җиләскүл бар! Монда ул — хуҗа да, эшче дә, монда ул — ирке чикләнмәгән патша!

Күл кояш нурында көзгедәй ялтырый, өстеннән күренер-күренмәс вак дулкыннар йөгерешә; юк, дулкын да түгел бу, җиләс һаваның су өстендә уйнаган зәңгәр күләгәсе бары...

Ислам бабайның яшерен җиргә куйган нәрсәләре һәммәсе үз уры-

нында иде. Хәер, Ислам бабайның нинди яшерен җире булсын? Яшерен җир дигәне — яр читендәге гадәти камышлык арасы; озын камыш сабакларын бер-беренә аркылы-торкылы авыштырып беркеткән дә, өстенә чыбык-чабык ташлаган. Шул камыш, чыбык-чабык астында аның көймәсе саклана (әгәр күл авылга якын булса, көймәне ул яртылаш суга батыра, ә монда, Җиләскүлдә, коры җиргәрәк өстерәп чыгарып, аны йөзтүбән әйләндереп калдыра иде). Көймә эчендә исә Ислам бабайның бөтен байлыгы — чиләк, тоз, балык өркеткеч таяк, ишкәк, алты данә калай кружка, балта, аннан тагы леска, бау, чыпта, капчык ише төрле балыкчы кирәк-яраклары ята...

Ислам бабай көймәне авыз ягы белән өскә әйләндереп, суга төртеп төшерде дә ярдан кузгалып китте.

Ул җир салкыны сеңгән дымлы, рәхәт эскәмиядә гәүдәсен баганадай төз тотып утыра һәм, юеш, сыңар ишкәген күнегелгән, өлгер хәрәкәтләр белән кулында ялт-йолт уйнатып, көймәне бик оста йөртә иде.

Көймәсе дә коры-җиңел һәм идарәгә бик сизгер булып, картны яр камышлары буеннан беренче җәтмә салынган урынга таба элдертеп алып китте.

Карт, ишкәге белән кирегә каерып, көймәне күлгә аркылы борды һәм беренче җәтмәне әкрен-әкрен тартып чыгара башлады. Батыргычлар көймә кырыена шакылдап бәреләләр дә пылт-пылт иткән тавыш белән янәдән суга чумалар иде. Җәтмәнең теге яки бу өлешендә күпме балык эләгүен карт авырлык буенча чамалады, су үләне катыш җеп араларыннан йомры алабугаларны башларыннан тартып, чыгарганда елмаеп-елмаеп куйды, ә вак балыкларны шундук суга кире җибәрә торды.

«Юк шул, юк, балык әз, — дип уйланды ул. — Эссе җәй харап итте балыкны, су кимеде. Әле дә бу күл тирән, буе чакрым ярымнан ким булмас; бөтен өмет хәзер шушы күлдә. Ләкин аңа да ял кирәк. Яңа күчерелгән балык мондагылары белән әйдә бераз таныша торсын. Барлык җәтмәләрне чыгарам, берсен генә — әлеге теге, төрмә рәшәткәседәй, киң күзәнәклесен, эре балыкка дигәнен генә калдырам...»

Ислам бабайның аягы астында, чыпта өстендә, эре-эре алабуга һәм кәрәкәләр кыймылдаша. Көймә төбендәге җыентык су бераз алсуланып тора, — җәтмә җебеннән ычкындырганда карт зур бер табан балыгының саңагын сытып, үт куыгын шартлаткан иде — күрәсең, шул агып чыккандыр. Әнә ул үзе дә бер кырыйда хәрәкәтсез ята. Кабырчыклы борынгы калканмыни — каракучкыл-алтынсу тәңкәләре кояшта җемҗем уйный...

Карт беренче җәтмәне бер очыннан икенче очына кадәр барлаптикшереп чыкты. Кыскарак икенче җәтмәне, күтәреп караган уңайга ук җыя барып, көймә төбенә төреп салды.

Аннары ул күлнең борылышына аркылы салынган өченче җәтмәгә таба йөзеп китте. Махсус өркеткеч таяк — бер очына түбән ягы ачык авызлы киң калай торба кисәге беркетелгән озын колга ярдәмендә бу җәтмәгә таба балык кудырырга кирәк иде.

Ислам бабай инде болай да тирләп-пешеп чыккан иде. Эшләпәнең һич файдасы күренми — эссе кояш нурлары, су өстеннән чагылып, барыбер күзгә төшә, күзне камаштыра. Карт, иелеп, учына су җыеп алды да иреннәренә тидерде. Аннан, күзен-кашын җыерып, кулындагы колгасының калайлы башын көч һәм «Куырк! Куырк!» дигән сәер, каты тавыш белән суга чумыра-чумыра, балык өркетергә тотынды. Су өстенә күбек калыкты, теге «Куырк! Куырк!» дигән тавыш тирә-якка кайтаваз булып таралды.

Бераздан карт, туктап, суның тынычланганын көтте һәм яшькелт төптә җемелдәшеп хәрәкәтләнгән вак балык көтүләрен һәм су үләннәре, камыш сабаклары арасында посып яткан ерткыч чуртаннарның ка-

ра шәүләләрен күрде. Ислам бабайның күңеле берьюлы яктырып китте, һәм ул көймә кырыена аякларын салындырып утырды да, шушы сихри су асты дөньясына ниндидер хакими, илаһи күз карашы белән хуҗаларча елмаеп һәм сокланып шактый озак карап торды.

«Бу минем икенче гүзәл дөньям, — диде ул эченнән генә. — Син мәңгелек, син бетмәячәксең. Шулаймы?»

Аннан соң карт тагы ярсып-ярсып балык өркетүен дәвам иттерде: «Куырк! Куырк!»

«Әйе, күлләргә ял кирәк. Мин аларны болай да инде шактый сыктым. Ә быел, өстәвенә, әнә җәе нинди... Өченче көн, пәнҗешәмбе бугай, Мурзин Минзәләдән шалтырата: «Балык алып кил әле! — ди.— Зур бер кунак кеше буласы иде — балык кирәк!» — ди. «Балык юк бит,— дим моңа.— Менә яңа көймәм белән җәтмәләрне иске елга үзәненә күчерим әле, шул чакта булыр балык!» — дим. Ә ул әйтә: «Синең,— ди,— Ык елгасының уң як ярындагы күлләрдә җәтмәң дә, көймәң дә бар ич,— ди.— Миңа, киявеңә, шәт, ихтирамың бетмәгәндер әле! Зинһар, китереп китче! — ди.— Мине кияү итеп саныйсыңмы, юкмы? Мин сине көтәм. Кичен үзеңне алырга машина җибәрермен»,— ди.

Ул көнне карт почта йортыннан бик кәефе кырылып чыкты. Нишләргә? Ахырда, үз-үзенә тәмам ачуы кабарып, күзен-кашын җимереп, Йолдызны арбага җикте дә аргы яктагы күлләргә чыгып китте. Аннан кичкә таба гына әйләнеп кайтты. Арба чыптасында бер өем эре балыклар ялтырап ята иде.

Мурзинның чая шоферы балыкны, үзе белән махсус алып килгән брезент букчага тутырып, ГАЗ-69 машинасына илтеп салды, картка әйтте:

— Тиз булыгыз, Ислам бабай, мин сезне көтәм, — диде.

Ислам бабай аты янында аптыраган кыяфәттә таптанып басып тора иде.

— Бәлкем, миңа барып йөрмәскәдер, ә? Балыкны Мурзинга үзең генә бирер идең... — диде ул.

— Юк, юк, Ислам бабай! Хуҗаның боерыгы бу, үтәми бернишләп булмый! Ул сезне... кунагы белән таныштырырга тели... Могтәбәр кеше белән, — дип пышылдады шофер.

Карт нафталин исе аңкып торган коңгырт-кара чалбар һәм улының чуар чәчәкле, агач төймәле күлмәген киде. (Үз күлмәге күзенә чалынмады, ә аны ныклап эзләргә өйдә кеше юк: яшьләр — эштә, ә Нәгыймә карчык оныгы белән каядыр биләмгә чыгып киткән иде...)

Шофер гөрелдәтеп машинасын кабызды, һәм Ислам бабай, ирексездән дигәндәй, кияве Мурзиннарга кунакка китеп барды.

Ислам бабайның аларда бер өч ел чамасы булганы юк иде инде, шул вакыт эчендә Мурзин үзенә менә дигән яңа йорт салдырып куйган иде.

Кайчандыр Мурзин Бикташ авылында кибетче булып торды, аннан, курслар тәмамлап, район үзәгенә эшкә күчте, анда төрле урыннарда эшләп йөргән арада, читтән торып, институт бетерде. Хәзер ул зур гына бер тәзү оешмасының җитәкчесе иде. Моннан егерме еллар элек, Мурзин Шәргыягә өйләнү турында сүз кузгаткач, Ислам бабай аның бу теләгенә ничектер каршы килмәде. Мурзин ул вакытларда да, хәзерге кебек үк, урдәкнекедәй тупый борынлы, киң иякле бер кеше иде. Ләкин буе зифа-нәзек, тавышы яшь, хәрәкәтләре өлгер — кыскасы, авылның менә дигән чая, шат күңелле бер егете. Бикташта эшләгәндә ул үзен ифрат намуслы кеше итеп танытты. Аның турында хәтта шундый бер кыйсса да сөйләп йөрделәр. Бервакыт кичен ул, имеш, Мәфтуха исемле авыл карчыгының өенә килгән дә, карчыкның кулына унике тиен акча тоттырып, болай дигән: «Мә, әби, ал үзеңнең хәләл акчаңны! Исен-

дәме, бүген кибеттә син тегене-моны сатып алганда, мин сиңа артып калган акчаңны кайтарып биргән идем. Тик син чыгып китүгә, нәрсәдер күңелемә шик төште: дөрес бирдемме соң әбигә акчаны, аны алдамадыммы соң, мәйтәм? Мин үзем дә ярлы кеше, тиеннең кадерен беләм. Кеше ишетмәсә дә, алладан яшереп булмый дигәндәй, гөнаһсы калмасын... Көне буе сине уйлап йөрдем. Өч мәртәбә алган әйберләреңнең бәясен кабат санап-исәпләп чыктым. Исәпләгән саен, уникe тиен аерма килеп чыга — сиңа биреләсе уникe тиен ягъни... Гафу ит, кичер мине, Мәфтуха апа, тәҗрибәм җитмәгән!» Мондый сүзләрдән соң Мәфтуха әбинең тәмам күңеле нечкәргән, күзләренә яшь килгән, ди, имеш..

Соңгы елларда Ислам бабай үзенең кызы Шәргыя, аннан да битәр кияве Мурзин белән бөтенләй диярлек аралашмады. Кияүләр, күчтәнәчкә бирәр төрле тәм-том — лимон, шоколад-конфет, колбаса яисә баш яулыгы ише импорт әйбере кыстырып, бабай йортына әллә нигә бер, фәкать бәйрәм көннәрендә генә килеп киткәлиләр иде.

Кызын Ислам бабай һич аңлый алмады. Төскә-биткә шактый чибәр саналса да, Шәргыя кечкенәдән үк кыргыйрак булып үсте. Күз карашын каядыр читкә, бушлыкка төбәп, ул авыз эченнән әкрен генә гел бертөрле моңлы җыр көйләп йөрергә гадәтләнгән иде. Үзе югыйсә ялкау да түгел, аш-суга дисеңме, өй җыештырырга, идән юарга дисеңме — һәммәсенә кулы ябышып тора, әмма әлеге сәер гадәтен барыбер ташлый алмый: күзен бушлыкка теки дә үзенең моңлы җырын әкрен генә көйләпме-көйли бирә. Кияүгә чыккач, ул чем-кара матур чәчләрен җирән төскә буятты, нәкъ марҗа кыяфәтенә керде. Кирелеге исә тагы да артты. Иреннәрен чытырдатып кыскан — авызыннан бер кәлимә сүз алып булырлык түгел. Кемгә охшап шулай кире булды икән ул? Әллә югыйсә Ислам бабайның үзенә охшаганмы? Кирелек аңарда да җитәрлек бит. Ни генә булмасын, Шәргыя Мурзинны бик тиз аңлады — аңа нәкъ менә шундый кияү кирәк тә иде инде. Тиздән алар бай, мул тормыш белән яши башладылар. Әти-әнисенә кунакка барганда, Шәргыя, мәсәлән, үзе белән бер чемодан кием-салым алып килә һәм көненә җидешәр тапкыр дигәндәй өстен алыштыра иде. Яңа өй бетереп кергәндә, алар картларны да өй туена чакырганнар иде, ләкин, күрәсең, чакырулары шундыйрак булгандыр — картлар анда бармадылар. Моңа, әлбәттә, Ислам бабайның горурлыгы да беркадәр сәбәп булды, чөнки карт калай кружканы көмеш кружка белән чәкештереп утыруны үзе өчен хурлык саный иде.

Өченче көн Ислам бабай, тәмам аптыраулы бер халәттә, шушы Мурзиннарга дип китте дә инде.

Минзәләнең үзәгенә килеп җитүгә, шофер машинаны яшел төстәге биек капка каршында туктатты да сигнал төймәсенә басты.

Сигнал тавышына шалтор-шолтыр калитка ачылып, ишектән бабайның алсу битле, өстенә зәңгәр төстәге, ялтыравык бизәкле, кыйммәтле күлмәк кигән кызы Шәргыя килеп чыкты.

— Әти! — дип, шатланып кычкырып җибәрде кызы. — Килеп бик әйбәт иткәнсең. Әйдә, уз, әти. Балыкны да онытмагансың икән, бик зур рәхмәт.

Ислам бабайның керфекләре дымланды: күрче, Шәргыя аны ярата түгелме соң? Балык турында да әтисен кочаклап үпкәч кенә сүз кузгатты. Ислам бабай сабыр гына тамагын кырды да, кызына ияреп, ишегалдына керде һәм гаҗәпләнүдән туктап калды.

— Әйдә, әйдә, өйгә уз! — дип, ашыктырган булды аны җирән чәчле Шәргыя. — Хәерчелек күрмәгән кеше түгелсеңдер, нәрсәсен карыйсың? — Ә үзе шундук кырыс тавыш белән шоферга боерыклар бирә башлады: — Балыкны кухняга, Фаидәгә керт, ул инде анда пычагын үткенләп көтеп тора, тиз бул, тиз бул! И әти! — дип, Шәргыя янә Ислам бабайга эндәште. — Безнең хәерчелекне! Син бүтәннәрне күрсәң иде!..

Ләкин карт болай да күрде — кызы бик канәгать. Канәгать булмый, булырсың да шул!

Мәйдан кебек иркен, зур ишегалды. Капкадан өй болдырына кадәр дүрт буй кызыл кирпечтән матурлап тезеп сукмак сузылган. Ишегалды түрендә, таш нигез өстендә, ике ишекле озынча һәйбәт жылы абзар тора. Ул икегә бүленгән булып, аның бер бүлеге — сыер, икенчесе сарыклар өчен билгеләнгән иде, ахрысы. Абзарның такта кыегында флюгер әйләнә. Уң кулда яшелгә буялган тимер гараж, аның артында, койма аръягында, тавык абзары булса кирәк, чөнки ул яктан бертуктаусыз, тегү машинасында эшләгәндәге сыман, чырлау-кыртлау тавышлары ишетелеп тора. Ишегалдының сул кырында исә — үрмә тимер чыбык койма белән әйләндереп алынган ярты гектар чамасында зур бакча. Анда чәчәк түтәлләре балкып утыра, түрдәрәк, алма һәм башка жимеш агачлары арасыннан, ак мунча шәүләсе күренә иде.

Биек болдыр баскычының түбәнге басмасы төбендә үк суүткәргеч краннын жиз борыны ялтырый — моны, күрәсең, баскычка күтәрелер алдыннан аяк киемен юу өчен махсус эшләгән булганнардыр. Минзәләдә суүткәргеч торбалар сузу мәсьәләсе әлегә кадәр хыялда гына кала бирә. Димәк, Мурзин бу суүткәргеч торбаны якындагы колонкадан үзе суздырткан иде.

— Әйдә, өйгә кер, эти! — дип ашыктырды һаман Шәргыя.

— Һай, сезнең монда бик шәп икән! Әкият! — диде карт, иелеп, ботинка бауларын чишә-чишә.

Ислам бабай йортны тышкы ягыннан жентекләп карый алмады, тик аның бик күп тәрәзәле икәнлеген генә шәйләде. Андый күп тәрәзәләрне карт күрсә шул шәһәрдәге больница биналарында гына күргәне бар иде.

Ислам бабай, кабаланып һәм шулай кабалануы өчен үз-үзенә ачуы килеп, кызы артыннан болдырга күтәрелде. Болдырның кырып юылган сап-сары такталарына игътибар итеп тә өлгермәде, кинәт өйалды ишеге ачылып, бусагада кәкре борынлы, чит-читләре кара белән чигелгән кызыл башмаклар пәйда булды. Карт, беркадәр каушый калып һәм бер үк вакытта мыек астыннан мәсхәрәле көлемсерәп, башын югары күтәрде. Аның каршында кияве Мулланур Мурзин басып тора иде.

— Әссәламе-галәйкем! — диде кияү, көйләп.

— Сәлам, сәлам, вәгаләйкем-әссәлам!.. — дип жавап бирде Ислам бабай, кабаланып, һәм Мулланурның күрешергә дип сузылган кулын учларына алып кысты.

Йорт хуҗасы хәзер әүвәлге, Шәргыягә өйләнергә йөргән чагындагы чандыр гәүдәле, малай кыяфәтле, өлгер-чая егет түгел иде инде. Гәүдә бермә-бер җәелгән, авырайган — шәт, бер йөз-йөз ун килограмм чамасы булыр; хәтта ки башы да әүвәлгедән зурайган шикелле, түрә кешеләр башы сыман, ничектер шакмакланып киткән. («Кимендә, алтмышынчы размер баш киеме йөртергә тиеш», — дип уйлап куйды Ислам бабай.) Дөрес, борынында үзгәреш сизелми, ул һаман шул ук — үрдәкнекедәй, тупый борын. Әүвәлге киң ияк исә хәзер, ит кунып, тагы да түгәрәкләнә, авырая төшкән, һәм уймактай кечкенә авыз, төрле яктан кысылып, тәмам бөрешкән, сызгырырга әзерләнгән сыман, чак кына ачылып тора иде.

Мурзин, читкә тайпылып, каенатасына ясалма бер түбәнчелек белән юл күрсәтте һәм:

— Кадерле кунак! Уз әйдә! — диде. — Бик сирәк киләсез, сагындырып кына. Шәргыя, башмак китер әле. Яшелен алып кил...

Махсус фуганка белән дулкынландырып юнып, нарат тактасыннан эшләнгән өйалды эчендә якты, иркен һәм тәмле агач исе аңкый иде.

— Тегендә — чолан, тегендә — веранда, — дип аңлатты Мурзин һәм, көлеп, өстәп куйды: — Сиңа кайсысына?

Хурланудан, рәнҗүдән Ислам бабайның бөтен тәне буенча утлы бер кымырҗык йөгерде. Моны Мурзин да шундук сизеп алды, карт белән бик сак булырга кирәклеген абайлап, аны дустанә кочаклады да, челтәр пәрдәләр белән бизәлгән веранданы һәм чоланны артык һаваланмыйча, җитди төстә күрсәтеп чыкты.

Аннары алар төп йортның ишек төбе бүлмәсенә уздылар. Мурзин, кулын сузып, стенадагы электр кнопкасына басты. Бүлмә эче балкып-яктырып китте. Монда стена буена китап шкафы куелган, бер кырыйда телефон өстәле һәм түшәмнән идәнгә кадәр зур көзге тора иде.

— Әкият... — дип мыгырданды Ислам бабай. — Китапханәгез, шулаймы?

— Шулайрак... урын җитми... китапларны монда күчерергә туры килде...

Шулай дип, Мурзин шаркылдап көлеп җибәрде һәм, китапларның монда күчүе бик җиңел аңлашыла дигән сыман, картка күз кысып, аны иңбашыннан янә кочаклап алды. Ислам бабай исә үзалдына: «Карт җүләр мин... үзем теләп шушында килдем бит», — дип үкенеп уйланды.

Шуннан соң алар кухняга керделәр. Монда күмерләре шартлап зур мич яна; мичнең тышкы ягы сыек зәңгәр төстәге кафель плитәләр белән капланып, әйләнә-тирәсен куе-кызгылт торбалар чорнаган иде.

— Үзебез эшләткән җылыткыч системасы, — дип аңлатты аны Мурзин. — Шәһәрдәгечә, тырышкан булабыз инде... Менә монысы ашханә... Кечерәк кечерәген, әмма гаилә өчен бик җиткән.

Мурзин шулай, бер бүлмәдән икенчесенә күчеп, каенатасын йорты белән таныштырып йөрде. Ул, атлаган уңайга, әллә нинди кнопкаларга басып уза, һәм шул ук секундта түшәм-стеналарда гөлт итеп утлар кабына, радиоалгыч уйный башлый яисә, линолеум идәндә чагылып, телевизор экраны яктырып китә иде.

— Монысы кызлар бүлмәсе... бусы малайныкы... Ул әлегә армиядә, шуңа күрә аның бүлмәсен вакытлыча үземә кабинет итеп алдым. Өй эчендә сөйләшү өчен безнең монда махсус телефоныбыз да бар.

Чыннан да, зур телефон аппараты белән янәшә, бәләкәй өстәлдә җете сары төстәге кеп-кечкенә икенче бер аппарат та тора иде. Бу аппараттан ишек аша каядыр чит бүлмәгә өстәмә чыбык сузылган иде. Мурзин трубканы алуга, йортның икенче башында тонык кына булып телефон шылтыравы ишетелде.

— Алло! Кем әле бу? Светланамы? — дип сорады Мурзин. — Хәлләр ничек соң, Светлана? Яхшы дисеңме? Ул чакта һәммәсе әйбәт. Юк, анысы юк. Хәзергә бернинди яңа күрсәтмәләр дә юк... Ха-ха-ха...

Мурзин кулъяулыгы белән тирләгән битен сөртте. Алар яңадан коридорга чыктылар. Хуҗа кеше, бераз икеләнеп торганнан соң, янәшәдәге зур, ике якка ачылмалы зәңгәр ишек каршына килде дә аны каерып ачып җибәрде.

Ислам бабайның үз гомерендә мондыйны күргәне юк иде әле.

Бүлмә, зурлыгы ягыннан, шәт, аның өе кадәр ике булыр. Салкынча һавасында хушбуй исе аңкый. Аяк астында болын мүгедәй йомшак келәмнәр. Стеналарына кызыл һәм яшел төстәге кыйммәтле кашагалар эленгән, атлы сугышчы сурәтләре төшерелгән әллә нинди гаҗәеп тәлинкәләр кадакланган. Сул кулда, күзгә күренмәс җепкә кидерелеп, якйкка багана сыман җыеп куелган яшел бәрхет чаршау артында, ак мендәр һәм челтәр җәймәләре белән кара-ялтыр лаклы ике карават калкып күренә. Уң кулда, почмакта, аяклы зур көзге, янәшәсендә чемодан кадәр экранлы тагын бер телевизор, шунда ук өч аякта алтын сызыклы пыялалары белән ялтырап зур радиола тора. Мурзин боларның һәммәсе янына барып, сыйпап-сыйпап узды, кабызды, тоташтырды, һәм бер минуттан бөтен бүлмә эче җанланып китте, балкып-җемелдәп, сөйләшү, музыка, җыр тавышлары белән тулды.

— Ай-яй-яй...— диде Ислам бабай, бүтән ни әйтергә белмичә.
Мурзин каенатага ясаган бу тәэсирдән бик канәгать иде.
— Утыр, үз өеңдәгечә хис ит, тартынма,— диде ул.— Син бит безнең иң кадерле кунагыбыз. Әй, кызлар, ничек анда сезнең? Өлгертәсезме? Карагыз аны, безне үпкәләтә күрмәгез.
Кухня ягыннан ашыгып җавап бирделәр:
— Өлгертербез, өлгертербез... Бер сәгать вакыт бар әле.
Зур залның урта бер җирендә, буйга сузып, ак җәймә каплаулы озынча тар өстәл — табын әзерләнгән иде.
Уң як стена буена исә ак чехоллы егермеләп урындык тезеп куелган. Ислам бабай шул урындыкларның берсенә барып утырды да шундук кире торды — урындык аңа артык йомшак тоелды. Икенчесенә, ишеккә якынрагына күчеп утырды — монысын уңайрак дип тапты.
Мурзин бүлмә уртасында папирос кабызып маташа иде.
«Йа илаһи, йа алла... Бүлмә дисәң дә бүлмә! Ә урындыкларына нигә күлмәк кидерделәр икән, ә?» — дип гаҗәпләнеп уйлады Ислам бабай.
Мурзин, папиросының кайнар көлен учына коюдан кытыкланып көлә-көлә, эре генә әйтеп куйды:
— Менә шулай яшәп ятабыз инде... Әлегә ярыйсы дигәндәй... Син безгә кышын кил, мунча кереп китәрсең. Минем бит мунчам да бар. У-у, шәп мунча, искитмәле...
Ул сүзеннән туктады, сәгатенә карап алды.
«Ә-ә, алар кемнедер көтә түгелме соң? — дип исенә төшерде карт.— Казаннан кунак булырга тиеш дигән иде бит шофер. Әлбәттә, шуның килеп җитүен көтәләр».
Мурзин, каенатасының ни уйлаганын сизенеп, хәлне йомшартырга кирәк тапты:
— Юк, юк! Начальство соңарса соңарыр, иң мөһиме — кардәш кешенең күңелен күрү!
Шулай дип, ул өстәл янына килде һәм табын өстенә капланган җәймәне каерып ачып җибәрде.
— Тс-с-с...
Тиз өлгерә торган җәйге алма дисеңме, башкаладан китертелгән апельсин, кып-кызыл Ташкент помидорлары, туралган ит, колбаса, кара икра дисеңме... бу табында ниләр генә юк иде! Ислам бабай бу муллыкка шундук үз бәһасен бирде, шул ук вакытта аның очлы күзе тау-тау өелгән ризык арасында эреле-ваклы шешәләргә дә игътибар итеп өлгерде.
— Әйдә, табын янына утыр, кадерле бабакай, безнең иң сөекле кунагыбыз, — дип кыстады Мурзин.
Ислам бабай аптыраган кыяфәттә ишеккә таба шөбһәле күз карашы ташлап алды. Мурзин шаркылдап бер көлде дә, картның аптырау катыш шатлыклы йөзеннән күзен алмыйча, кулын сузып, ниндидер гөл савыты артында торган кечкенә телефон аппаратына таба үрелде.
— Кызлар! Бу мин, Мурзин. Без монда могтәбәр бер кеше белән табын янында тилмереп утырабыз. Сезнең тарафтан нинди күрсәтмәләр булыр икән? Ә?
Һәм, үзе уйлап тапкан шуклыгына сулышы буылырдай эчке бер рәхәтлек, куану кичереп, Мурзин телефон трубкасын картка таба этәрде. Тегесе, иелә төшеп, трубкага йонлач колагын якынайтты.
— Бераз сыйланырга рөхсәт итәбез... — дигән көлү катыш чәрелдек тавыш яңгырады трубка эченнән.
— Ишеттеңме? — диде Мурзин, трубканы кире урынына куйды да, Ислам бабайга һәм үзенә коньяк бүлеп салды.
— Бәлкем миңа... гадиеннән генә салырсың? Монысын үзең... берәрсе килгәч эчәр идең әле... кыйммәтле нәрсә бит...

— Зарар юк,— дип суздЫ Мурзин, каенатасы белән чәкеште дә, рюмкадагы эчемлекне берьюлы авызына каплады.— Эч тә буена сеңдер. «Так» сказал бедняк,— дип өстәде аннары, русчалатып.

Табын янында аның шулай, кыланчыкланып, русча сүзләр кыстырып сөйли торган гадәте бар иде.

Ислам бабай, тешсез авызында ипи йомшагын әвәләп, сүзсез генә баш кагып утырды. Коридорның түрге башыннан табада балык кыздырган чыжылдау тавышы торган саен көчлерәк ишетелә иде.

— Шәргыя! — дип сөрән салды кинәт Мурзин. — Безнең янга кереп чык әле.

— Хәзер, — дип җавап бирде тегесе һәм бер минуттан кереп тә җитте. Ул шул ук зәңгәр күлмәктән, ләкин бу юлы күлмәк өстеннән алъяпкыч бәйләгән иде.

— Кая, этиең белән чәкештереп, син дә берне эч әле, — диде Мурзин.

— Ә ник, эти белән чәкештереп тә эчәргә була, — диде Шәргыя чытлыкланып.

Ул, рюмка төбенә аз гына коньяк салып, ирләр белән чәкеште дә, эчемлектән авыз иткәч, янә кухнясына йөгерде. Сөйләшү тавышларына караганда, анда Шәргыядән башка тагы икеме-өчме булышучы хатын бар иде булса кирәк.

— Шулай, димәк, — диде Мурзин,. әңгәмәне ничек дәвам иттерергә белмичә.— Шундыйрак хәлләр, значит.

Карт дәшмәде. Мурзин урыныннан торды, телевизорны тоташтырды. Кайдадыр көньяк өлкәләрдә мамык җыюны күрсәтәләр иде. Бераздан экранда мамык җыючыларны кулына газета тоткан икенче берәү алыштырды.

Мурзин үзе бүтән эчмәде, ләкин каенатасына бер-бер артлы тутыра торды. Хәер, рюмкалар уймак кадәр генә иде, аннан соң утырышу үзе дә әллә нинди сәер, күңегелмәгән, шуңа күрә Ислам бабай баштарак бөтенләй диярлек исермәде.

Алар шулай, теге-бу турыда аз-маз сөйләшкәләп, тагы күпмедер вакыт утырдылар. Икесе дә күңелләрендә бер-бере алдында ниндидер уңайсызлану тоя иде. Ниһаять, Мурзин, сәгатенә күз төшереп, авыр сулап куйды.

— «Та-ак» сказал бедняк... — дип кабатлады ул, күңеленнән нидер чамалап. Аннары каенатасына эндәште: — Булмаса, без синең белән минем кабинетка күчеп утырыйк, хатын-кызларның монда табынны бераз рәткә китерәселәре бар бугай. Тагын бер кунак килеп җитәргә тиеш бит әле... Килми икән инде — үзенә үпкәләсен...

«Үзенә үпкәләсен» түгел икәнлеген Ислам бабай Мурзинның йөзеннән үк ачык күрде, ләкин бу хакта хәзер сүз куертып торырга теләмәде.

— Сезгә зур мәшәкать булдым инде мин... Уңайсыз хәтта... Якты йөз белән каршылавың өчен рәхмәт сиңа,— диде ул, акланган дай.

Мурзин җавап бирмәде, тамагы төбеннән ниндидер аңлаешсыз авазлар чыгарып, авыр-салмак адымнар белән кабинетына таба юнәлде. Ислам бабай исә аның артыннан тыраклады.

Ул арада кызлар, залга ябырылып кереп, беркадәр төсе югалган табынны минут эчендә яңадан тәртипкә китерделәр һәм өстен әүвәлгечә ак җәймә белән каплап куйдылар. Бу кызлар Мурзинга чыбык очы кардәш туры килә иде; алар Минзәләдә ПТУдамы, ниндидер училищеда укыйлар һәм, Мурзиннарда торып, шул игелеклелек бәрабәренә аларның өйдәге барлык кара эшләрен көнен-көнгә эшләп баралар иде.

Кабинетка Шәргыя килеп керде. Аның йөзенә ризасызлык билгеләре чыккан иде.

— Сәгать тугыз... Кайда соң синең Вәлиевең? — дип сорады ул.

— Кем белә инде аны,— диде Мурзин аптыраган чырай белән. Ул үзе дә борчыла, кабинеты буйлап ишекле-түрле киләп сара иде.

Бераздан ул Ислам бабайны бөтенләй онытты, өйалдына чыгып китте, электр кнопкаларына чалт-чолт суккалап, утларны сүндереп йөри башлады. Ислам бабай чамалады: соңыннан, зур кунак килеп житеп, аны өйгә алып кергәндә, Мурзин бу утларны эффект өчен бер-бер артлы үзе яндырып барырга уйлый иде, күрәсең.

Ниһаять, өйалдында ирләр гөрләшүе ишетелде, ул да булмады, аңа Шәргыянең, бала чагындагыча, көйләп-вәзенләп әйткән нечкә тавышы килеп кушылды:

— Әйдәгез узыгыз! Рәхим итегез! Һай! Безнең әле берни дә әзер түгел! Өйнең асты өскә килгән, бөтен жирдә тәртипсезлек... Керегез, кер!

— Зарар юк,— диде беркадәр карлыкканрак калын тавыш.— Без простой кешеләр, гаепләмәбез.

— Без фәкыйрь провинциалларны шулай аңлагач, гаепләмәгәч, алардан көлмәгәч, бик әйбәт инде ул, рәхмәт сезгә! — дип тәтелдәде Шәргыя.— Без нәрсә, чүп... аяк астындагы туфрак бит.. Мулланур, кадерле кунакны залга алып кер, без хәзер... Юк, юк, аяк киемен салып маташмагыз!

— Аяклар бераз ял итсен, сезнең монда чиста, ялтырап тора бит.

— Алайса менә башмак киеп жибәрегез, менә бу кызыл башмакларны. Әйдәгез, рәхим итеп, өйгә узыгыз, — диде Мурзин һәм, Ислам бабай чамалаганча, электр кнопкаларына, стенадагы кандалаларны сыткандай, бармагы белән баса-баса, кунакны үзе артыннан ияртеп китте.— Менә бирегә, Ибраһим Ибраһимович. Сез инде бездән көлмәгез... Булдыралганча тырышкан булабыз. Сездәгечә, ванна ише нәрсәләр юк...

— Оһо-оһо! — дип гөрелдәде кунак.— Күрәм, яшәү шартларың начар түгел синең, Мурзин.

— Кая инде ул? Авыл авыл инде.

— Авыл безне ашата, — дип куйды кунак, акыл өйрәткәндәй.

— Анысы шулай, килешәм!.. Авылны бик яратам мин. Чөнки бөтен жаным-тәнем белән авыл кешесе, крәстиян малаемын... Әйдәгез, узыгыз, уз. Менә монда. Күптәнме әле чабатадан йөри идек... Аһ, ул фәкыйрь яшьлек дигәнең!

Кунак ни сәбәптәндер көлеп жибәрде. Ахырда Мурзин да аңа кушылып көлде.

— Мин бит үзем дә асыл шәһәр малае түгел. Авылдан бөтенләй аерылып бетмәгәнмен әле, — диде кунак, беравык тын торганнан соң.

— Беләм, Ибраһим Ибраһимович. Сарманда сезнең кардәшләрегез бар.

— Каян беләсең?

— Шулай, беләм инде. Шымчыларның хажәте юк бу мәсьәләдә. Халык үзенең яхшы кешеләрен гел искә алып сөйли торган була, Ибраһим Ибраһимович.

Ислам бабай, боларның һәммәсенә колак салып, бер ялгызы Мурзинның кабинетында утыра бирде. Ул үзен чакырып алырлар дип көтә иде. Ләкин тегеләрнең уйларында да юк иде, күрәсең. Менә зал ягында телевизор чыжылдаган тавыш ишетелде, музыка уйнап жибәрде.

Ислам бабай, тезеннән кулларын алып, урыныннан кузгалды, чалыш-чолыш атлап зал ишегенә таба китте.

— Исәнмесез... — диде ул каушаганрак тавыш белән, бусага төбендә туктап.

Мурзин, каенатасының монда икәнлеген әле генә исенә төшергәндәй, корт чаккандай урыныннан сикереп торды. Ул уңайсызланып калган иде. Ә кунак кешенең, картны күреп, йөзенә үтә кызыксынучан бер елмаю жәелде.

— Сезне таныштырырга да онытканмын, Ибраһим Ибраһимович, — диде ниһаять Мурзин, исен жыеп.— Бу карт минем каенатам, Ислам бабай була, мәшһүр балыкчы, икс зур сугышны башыннан кичергән герой.

Кунак, урыныннан торып, карт белән кул биреп күреште. Ул шактый озын буйлы, озынча-чандыр битле, үткер күз карашлы бер кеше булып чыкты. Бераз корсак та үстереп җибәргән. Өстенә ул күз явын алырлык ап-ак йон күлмәк һәм һәйбәт чалбар кигән иде.

— Бик шат, бик шатмын, — диде ул карлыкканрак калын тавыш белән. — Иске гвардия дигәнең — менә шул инде ул! Ничә яшь хәзер сезгә, Ислам бабай?

— Житмеш өчне тутырам.

— Бик хуп, бик хуп. Сез, безнең эти-бабайлар, бернинди белемегез, грамотагыз булмаган көенчә, нинди зур эшләр башкардыгыз бит, безгә хәзер сездән тик көнләшергә генә кала.

— Мин грамотасыз түгел, — дип, аклангандай әйтеп куйды Ислам бабай. — Укый да, яза да беләм.

— Анысын болай гына, гомумән алып әйтүем,— диде кунак, елмаеп, һәм урынына утырды да сүзен дәвам иттерде: — Чыннан да шулай. Мондый простой кешеләргә һәр авылда һәйкәл куярга кирәк! — Аның тавышы тагы да катылана төште. — Һәммәсенә! Изге сугыш кырларында яраланган батырны багып терелткән гади авыл карчыгына; кулына корал тотып, ак бандитларга каршы көрәшкән чал сакаллы бабайга; савым күләмен ике мең ярым литрга җиткергән яшь кызга — һәммәсенә, һәммәсенә дә һәйкәл куярга кирәк! Әйе, килер заман — аларның һәрберсенә һәйкәл куярлар! Һәрбер авыл саен булыр андый һәйкәлләр... Авыл — ул безнең тормышның нигез ташларыннан берсе. Моны истә тотарга кирәк.

Мурзин белән Ислам бабай, кунакның сүзләрен хуплап, башларын кага-кага тыңладылар.

Ишектә берме-икеме тапкыр Шәргыя дә күренгәләп китте, ләкин эчкә узмады — ирләрнең житди әңгәмәсенә комачауларга теләмәде, күрәсең.

— Ә сез молодец, Ислам бабай! — диде кунак, картның иңбашына кулын куеп. — Шундый каенатаң булуына мин бик шатмын, Мурзин. Беләсең, мин үзем дә авылдан чыккан кеше. Катык та, гармун да яратам дигәндәй.

— Мин уйный беләм! — дип, шатланып кычкырып җибәрде кинәт Ислам карт. Мурзинның иске тальяны барлыгы аңа мәгълүм иде. Ул шундук урыныннан торырга җилкенде, ләкин кунак аңа ирек бирмәде.

— Уйный белүегез бик әйбәт, — диде ул, аны тынычландырырга тырышып. — Сезнең белән танышуыма сөенеп бетә алмыйм. Яныгызда бер утыру да йөрәкне дөп-дөп тибәргә мәҗбүр итә...

Ислам бабай шулай да исергәнрәк иде. Аның йөзе ихластан балкып китте.

— Сезнең белән таныштырасыларын миңа алдан ук әйттеләр. Мин, риза булып... килдем менә... Минем аркада никадәр мәшәкатьләнгәннәр бит... Табындагы сый-нигъмәтне күрсәгез, исегез китәр!

Мурзин, мыек астыннан гына елмаеп, кунагы белән күзгә-күз карашып алды, аннары шаркылдап көлеп җибәрде, тегесе дә елмайды. Хәтта горур табигатьле Ислам бабай үзе дә, көлүнең сәбәпчесе асылда ул үзе икәнлеген һич аңышмыйча, авызы эченнән генә ишетелер-ишетелмәс тавыш белән кеткелдәргә тотынды. Аның тәмам теле ачылды.

— Сәмәркандта, басмачылар белән сугышканда, миңа аларның бер атаманын алырга туры килде, — диде ул, мактана башлап. — Исеме дә хәтеремдә әле: имам Дофар... Менә кулдагы бу яра әзе шуннан калган... Юк, ялгышамын икән, гафу итегез мин картлачны, монысы Перекопны кичкәндә алган яра... Вафен финляген! Һенде һоһ! Ягъни мәсәләң! Мин инглизчәне дә аз-маз сукалыйм әле... М-м...

Мурзин белән кунак кеше, бер-беренә серле күз карашы ташлый-ташлый, һаман шырык-шырык көлүләрендә булдылар. Ислам бабай, ниһаять, нидер сизенеп, сөйләүдән туктады һәм сагаеп калды.

— Әткәй, безнең кадерлебез! — дип, каенатасын ярым кочаклап, аны янә тынычландырырга ашыкты Мурзин.— Кадерлебез! Синнән башка без нишләр идек икән?..

Аннан кычкырып хатынына дәште:

— Бичәкәй!

Ишек бусагасында шундук Шәргыя калыкты. Бу юлы ул изүе ак капрон челтәр белән каймаланган ачык-шәмәхә төстәге икенче күлмәктән иде.

— Ужин! — дип, русчалатып, кыска гына боерык бирде хуҗа кеше.— Бабакайны бер сыйлыйк әле булмаса! — һәм ул тагы көлеп җибәрде, аңа кушылып, кунак белән Шәргыя дә шыркылдашып куйдылар. Ислам бабай исә тагы сагайды: «Болар миннән көләләр түгелме соң? Әллә кәефләренең шундый күңелле чагымы? Һай, чынлап җүләрдер мин, һични аңламыйм...» — дип, эченнән шөбһәләнеп уйланды.

Кунак кеше уханы бик яратты. Хуҗалар махсус аның өчен дип, кабыгын төрле мәзәк-мәзәк җәнлекләр рәвешендә фигуралап кисеп, өч апельсин әрчеп куйганнар иде, ләкин ул аларга кагылып та карамады... Күбрәк балыкка ябырылды, бәрәңгене мактап ашады (вак булса да, яңа, быелгы бәрәңге бит!). Ашау әйбәт булгач, эчемлеге дә ярыйсы күп эчелде.

— Ислам бабай, фамилияң ничек синең? — дип сорады кинәт кунак кеше.

— Әхмәтев.

— Һы, алайса мин синең турыда күп ишеткәнем бар! — Кунак аңа ихтирамын белдергән кыяфәттә бер карыш читкәрәк күчеп утырды. — Антонов дигән кеше, Василий Михайлович, синдә кунакта булганы бармы?

Ислам бабай учы белән маңгаен сыпырып алды.

— Әйе, бар. Беләм андый кешене.

— Бик мактый ул син пешергән уханы. Ниндидер секретын белә, ди. Әхмәтев Ислам... Ничек истән чыккан диген?!

Карт тыйнак кына утыруында булды.

— Ә син беләсеңме, кем ул хәзер? — диде кунак, тавышын серле пышылдатып. — Обком кешесе... җитәкче эштә... бу соңгы конференциядән соң күтәрделәр...

— Егет кеше... хәтта мина баскыч ясашырга булышты, кадак кагышты, — диде Ислам бабай, мактап.

Беравык һәммәсе тын калдылар. Аннан кунак, бернинди елмаюсызнисез хуҗага карап, тост тәкъдим итте:

— Искиткеч әйбәт кеше синең каенатаң, Мурзин! Әйдәгез, Ислам бабай исәнлегенә эчик! Кайвакыт без үз туганнарыбызның, шул белемсез, грамотасыз ата-баба, әни-әбиләребезнең кадерен белеп бетермибез...

— Минем грамотам бар... — дип, тагын чәчрәп чыкты Ислам бабай.

— Әйе, әйе, укый-яза белә ич! — диде Мурзин, мыек астыннан көлемсерәп, ләкин шундук янәдән җитдиләнде.

— Грамотага алар пулемет, миномет утлары астында өйрәнгәннәр,— дип сүзен дәвам иттерде кунак. — Әгәр безнең нинди дә булса абруебыз, бәһабез бар икән, бу фәкать алар аркасында, бүгенге көн аларның дөньяда яшәүләре аркасында! Синең исәнлеккә күтәрик, Ислам бабай!

Һәммәсе дә рюмкаларын бушаттылар, һәм Ислам бабай тагы: «Юк, алар миннән көләргә һич тә уйламыйлар...» — дип күңелен тынычландырды. Бераздан аның кәефе бөтенләй күтәрелде, җырлыйсы-уйныйсы килеп китте, һәм ул, батыраеп, Мурзиннан гармун алып килергә сорады.

Мурзин, зур кунагы белән күзгә-күз карашып алгач, каяндыр иске тальянын тартып чыгарды.

Ислам бабай, учы белән берьюлы гармун телләренә басып, аны мәзәк бер рәвештә кычкыртып торды-торды да кинәт башын югары чөйде һәм, бармакларын бер үк урында дигәндәй калтыратып йөртә-йөртә, борынгы озын, моңлы көйләрнең берсен сыздырып уйнап җибәрде. Кунак кеше, башын кырын салып, күзләрен йомды. Мурзин белән Шәргыя бабай уйнаган көйгә әкрен генә җыр башладылар.

Шулай берме-икеме җыр җырлагач, кунак, кулын югары күтәреп, гармунчыны туктатты, боеручан көр тавыш белән:

— Молодец, Ислам бабай! Булдырдың! Без сиңа бер махсус килербез әле... иптәш Антонов белән! Безне кабул итәрсең бит? Шунда иркенләп гармун уйнаганыңны да тыңларбыз, ә? — диде.

Ислам бабай дәшмәде. Аның хәтере калган иде.

Бераздан хуҗа хатын табынга зур таба белән кайнар бәлеш кертеп утыртты. Бәлеш җиренә җитеп пешкән, өске камыры авыз суларын китереп, кызарып, хуш ис бөркеп тора иде. Бәлешне гадәттәге тәртип белән кисеп-тураклап, тәмләп ашарга керештеләр. Шәргыя бертуктаусыз кунакларны кыстады:

— Ашагыз, тартынып тормагыз!.. Кая, бирегез әле тәлинкәгезне, салыйк!.. Гаеп итмәгез инде, пешүе ничек булгандыр... Кулдан килгәнчә тырыштык...

Бераздан тамаклар тәмам туйды, башка да шактый йөгерде, — хәзер инде ашыйсы да, эчәсе дә артык килми иде. Табында битараф бер тынлык урнашып калды.

— Сез, Ибраһим Ибраһимович, Минзәләгә иптәш Хәсәнев белән бергә килдегез түгелме соң? Нигә ул бездә күренәсе итмәде икән? — дип сорады кинәт Шәргыя, бу тынлыкны бетерергә тырышып.

— Ул авырый, — диде кунак, аннары, икърар итәргә дә авырсынган бер кыяфәт белән, ачыктан-ачык сәбәбен аңлатып бирде: — Аңа эчәргә ярамый. Без генә ул... алла бәндәләре... үзебезне кызганмыйбыз.

— Килмәсә килмәгәндер инде! — дип, хатынының шундый четерекле сорау бирүен яратмагандай, ачу белән әйтеп куйды Мурзин. — Без простой кешеләр. Менә мин, мисалга, эштә тәмәке тартам... Чынлап, Ибраһим Ибраһимович, врачлар ачулана, ә мин тартам!

— Әйе, әйе, Ибраһим Ибраһимович! Ул үзен һич кызгана белми, — дип хуплады Шәргыя, күзләрен шарландырып. — Урамдагы теләсә нинди килмешәк этне кызгануы мөмкин, әмма үзен кызганмас. Эш ди-ди янып-көеп бетәр.

— Анысы ярый, — диде кунак. — Безгә шундый работниклар кирәк тә. Шундый кешеләрдән җитәкче кадрлар чыга. Гомер буе авыл йортында пыскып ятмассыздыр бит, ахыр чиктә... Музыка да ишетәсе килә дигәндәй. Ә үзеңне нәрсә кызганырга? Эш өченме? Җәмгыять өченме?.. Юк, ю-ук, башкача мөмкин дә түгел, дөресен әйткәндә.

Йөзе-бите кызарган бәхетле Мурзин кунакны тагы кыстарга керешге:

— Менә. Менә тагы бер кисәк ашагыз инде, Ибраһим Ибраһимович.

Шул чак бәләкәй генә бер күңелсезлек булып алды. Кунак алдына өстәлгә, өлеш тәлинкә сыйфатында, чит-читләре һәм төбе чын алтын, слюда кисәкләре белән бизәп эшләнгән һәм, асылда, декоратив әйбер буларак кына файдаланыла торган кыйммәтле (иксән сумлык) Мисыр тәлинкәсен куйганнар иде. Менә шул тәлинкәгә салып бирелгән бәлеш сыныгын ашаганда, чәнечке очына эләгеп, күрәсең, кечтеки генә алтын пластинка кубып чыккан һәм кунак аны бәлеш белән бергә ялгыш авызына кабып җибәргән иде. Моны күргәч, Мурзин курка калды, кунак ачуланмагае дип, тизрәк:

— Алтын гына ул! Аңардан берни булмый! — дияргә ашыкты

— Зарар юк,— диде тегесе дә.— Әүвәл кешеләр гел алтын, көмеш савыттан гына ашаганнар әле, аңа карап үлмәгәннәр, киресенчә, озаграк яшәгәннәр.

Шулай дип, ул теше арасына кысылган алтын пластинканы тартып чыгарды, кызганулы, теләр-теләмәс бер кыяфәт белән, аны өстәл өстенә куйды. Мурзинның исә: «Алыгыз, ул сезнеке!» — дияргә кыюлыгы җитмәде.

Бу вакыйгадан соң мәҗлеснең яме ничектер сүрелеп калгандай булды.

Ислам бабай, исерек булса да, боларның барысын күреп-аңлап һәм күңеленнән кичереп утырды.

Шәргыя, урындыгында кыбырсый-кыбырсый, тагын бер мәртәбә сүз куертырга омтылыш ясап карады:

— Беркөн Индия картинасын караган идем, шуннан искә төште... Анда кино сәнгате, минемчә, бездәгедән яхшырак үскән. Радж Капурны гына алыйк... Аларның киноларында бөтенесе ничектер матуррак килеп чыга... Бертуктаусыз бииләр, җырлыйлар... Киемнәре матур... Артисткалары да чибәр... Ә безнең киноларда — өзлексез сөйлиләр дә сөйлиләр... күңелсез. Артисткалар комбинезон кигән, хәтта фуфайкадан йөриләр...

Кунак кеше елмаеп куйды:

— Тәнкыйтегездә дөреслек юк димәс идем.

Тагын тынлык урнашты.

— Бәлкем карта сугарбыз, ә? — диде кинәт Мурзин.

Кунак, гаҗәпләнгәндәй, кашын җыерды.

— Юк, мин карта уйнамыйм.

— Мин дә уйнамыйм уйнавын! — дип акланырга ашыкты Мурзин, урындыгында кыбырсып.— Сезнең теләк юкмы диюем генә иде. Карталары да үзебезнеке түгел, кайсыдыр ялгыш онытып калдырган булган. Кешесен белеп, кире бирергә кирәк булыр. Яки бөтенләй юк итәргә. Сез ничек уйлыйсыз, Ибраһим Ибраһимович?

— Юк итәргә дә мөмкин, — диде кунак һәм авыр кузгалып урыныннан күтәрелде.— Сый-хөрмәтегез өчен рәхмәт, дусларым! Мәҗлес искиткеч шәп булды!

— Ә чәй?! — дип чәчрәп чыкты Шәргыя.— Чәй эчми китәсезмени? Алай әйбәт түгел бит, йола бозыла!

— Һәммәсе өчен зур рәхмәт! Чәйгә урын калмады, вакансия бетте, ягъни, ха-ха! Сез искиткеч әйбәт кешеләр.

Кунак ишеккә таба атлады, Мурзин, авызын бөрештереп, ухылдыйухылдый, аның артыннан иярде. Ярты юлда кунак, туктап, артына борылды, хуҗа кешенең иңбашына кулын салды, һәм алар шулай икәү бергә ишектән чыктылар.

— Бар, тиз генә йокларга ят, — дип пышылдады Шәргыя этисе янына килеп.— Инде исереп беткәнсең, селәгәең агып тора. Бар! Ичмасам оялa да белмисең!

Ислам бабай, әпен-тәпен атлап, коридор аша өйалдына чыкты. Өйдә бөркү, җан саф һава тели иде.

Караңгы күк йөзендә йолдызлар җемелди. Җылы җил картны чыгуга ук үз кочагына алды. Урамда, капка төбендә, тегеләр хушлашу сүзләре әйтешәләр иде.

— Үпкәләп китмәгез инде, Ибраһим Ибраһимович, без простой кешеләр...

— Нинди үпкәләү ди ул, бик әйбәт булды. Ярый, озатып торма — гостиница якында гына бит, юлын беләм. Зур рәхмәт сиңа.

— Кайберәүләр хәзер гостиница бүлмәсендә сөт эчеп утырадыр, мөгаен... Әйдә утырсын... Без үзебезне кызганмыйбыз... Ул әнә мине

санга сукмады, мәҗлескә килмәде, ләкин минем өчен сезнең бер бармагыгыз аның дүрт аягыннан мең мәртәбә кадерлерәк!

— Ха-ха-ха... Кара аны, Мурзин! Мондый сүзләрең өчен үкенергә туры килмәсен! Хәер, мин сине рәнҗеттермәм... Без әле башкаланың үзендә яшәрбез, шулаймы? Хуш, сау бул, дустым...

Шакылдап капка ишеге ябылды, Мурзин, Ислам бабайны күрмичә, янәшәдән тиз-тиз атлап өйгә кереп китте.

Карт ишетеп торды: алгы бүлмәгә керүгә үк, Мурзин уенчык телефоннан хатынына шылтыратты:

— Алло! Шәргыя! Яңа күрсәтмәләр шундый: чәй әзерлә, бик каты чәй; без үзебезне кызганмыйбыз...

Ислам бабайны алар фәкать ярты сәгатьтән — туйганчы чәй эчеп, йокларга ятарга җыенганда гына исләренә төшерделәр. Шуңарчы карт баскыч башында бер ялгызы аларның дәшеп алуларын көтеп утырды.

## 5

Карт озын-авыр колгасы белән әле һаман балык куа иде. Күл өстендә бертуктаусыз кайтаваз яңгырап торды: куы-ы-ырык! Ку-ы-ырык! Бу инде Ислам бабайның озынча күлне унынчымы, уникенчеме тапкыр әйләнүе иде. Ул тәмам арыды. Тозлы тир тәнне әчеттерә, тезләр калтырый, авыр, юеш колга кулдан менә-менә төшеп китәр төсле иде.

Соңгы әйләнүендә балык бөтенләй аз эләкте. Барлы-юклы шул балыкны чуалган җеп араларыннан чүпләгәндә, Ислам бабай кояшны шелтәләде: «Җә, ни дип шулкадәр кыздырасың инде? Быелгыча, артык юмартлана башласаң, синең бу яктың әллә ни озакка бармас бит, кара аны! Менә мине ал. Мин гомерем буе эшлим. Әгәр минем аяк-кулымны бәйләп куйсалар, мин икенче көнне үк үләчәкмен. Ләкин мин гел бер төрле эшне эшлим, җайлап эшлим, шуңа әнә озак яшәдем дә, әле тагы яшәячәкмен, алла боерса. Ә син? Синең эшең — җирне җылыту. Анысы өчен сиңа зур рәхмәт. Ләкин ник син җирне кирәгеннән артык җылытасың? Әнә кара, күлләр кибә. Басу-кырларда игеннәр көя. Хәтта кешеләреңнең буе кечерәя, чөнки каннарында су кимегән. Кая суырасың син ул суны? Нигә шулкадәр кирәк ул сиңа? Әллә аны, болытларга җыеп, җирнең икенче ягына, теге Америка дигән илгә илтеп түгәсеңме? Ярый, анда да яудыр яңгырыңны, моңа минем һичбер каршы сүзем юк, Америкага бәла теләмим мин. Мин беркемгә дә бәла теләмим. Мин бары гаделлек кенә телим. Ләкин ул гаделлегең кайда соң синең? Һәр агачның, һәр җан иясенең эчендә кечкенә үлчәү бар диләр. Әгәр кем дә кем аларны рәнҗетсә, бу үлчәүләр шундук моны әйтеп күрсәтеп бирәләр, ди. Зинһар, кызуың белән бу кадәр өтәләмә безне, кояш...»

Ислам бабай юеш җәтмәне үлән һәм куак ботаклары өстенә җәеп салды: ярты сәгатьтән ул шакыраеп кибәргә тиеш. Аннары балыкны урнаштырырга керешге: чыпта капчыкларга тутырып, аны дымлы камыш арасына илтеп яшерде, өстенә чыбык-чабык ташлады. Ниһаять, көймәне судан сөйрәп чыгарып, яр башына менгезде — озакламый бу көймәне яңа сәфәр көтә иде.

Ислам бабай күккә карады, башын чайкап куйды.

Ухылдый-ухылдый, үрмәләп, арба астына — күләгәгә кереп ятты.

Аның кыймылдар хәле дә юк, бөтен тәне ватылган, сызлана-газаплана иде.

«Тиздән үләрмен, ахрысы, — дип, шомланып уйланды ул. — Их, яңа көймәм кызганыч, рәхәтләнеп бер йөзә дә алмадым үзендә. Чиклавек кабыгыдай икегә аерылды да куйды...»

Ислам бабай, салынкы кашлары астыннан күзләрен йөртеп, ми эреткеч кызу кояш нурында көмештәй җемелдәгән күл өстенә, әйләнә-тирәдәге көйгән аланнарга, кара карлыган, эт шомырты куакларына карап ятты; ахырда, янәшәсендәге иске учак көленә һәм аның тирәли аунап яткан буш шешәләргә күзе төшеп, ирексездән иреннәре калтырап китте: «Аһ, нинди әшәке кеше бу минем кияү!.. Бөтенесе аның аркасында килеп чыкты...»

Мурзиннардагы теге мәҗлестән Ислам бабай өйгә икенче көнне төш вакытында гына кайтып җиткән иде. Иртән аңа салкын бәлеш калдыклары ашаттылар, куе-кызыл төстәге ниндидер бик каты, хушбуй исле эчемлек эчерттеләр. Ислам бабай бу эчемлектән баш тартырга теләгән иде дә, кызы Шәргыя аны көчләп дигәндәй эчертте.

— Мә эч, бераз игә килерсең, ичмасам. Кыяфәтеңә карарлык та түгел, исерек баш, — диде ул.

— Исе яман, хушбуй тәме килә. Мондыйны ничек эчмәк кирәк? — дип киреләнде карт.

— Аны, беләсең килсә, чит ил кешеләре эчә. Бөтен районга нибары алты ящик китергәннәр иде. Мәйтәм, кая бер ящигын үземә алып калыйм әле. Дус-ишләргә бирермен, әтине сыйлармын, мәйтәм. Ә ул — хушбуй тәме килә ди! Аңа урыс аракысы бир! Әй, Мулланур, ишетәсеңме?

Мулланур иртәнге якта эчми иде. Тиз генә киенеп, одеколоннар сөртеп, ул эшкә китеп барды.

Картны өенә шул ук машинада кайтарып куйдылар.

Киткәндә, кызы Шәргыя капка төбеннән аңа:

— Әнигә сәлам әйт. Җиләк җыеп куйсын, варенье кайнатырга. Без сезгә якшәмбе көнне килеп китәргә уйлыйбыз әле, — дип кычкырып калды.

... Якшәмбе көнне алар, «Җигули» һәм ГАЗ-69 машиналарына төялешеп, бөтен өерләре белән килеп төштеләр.

Иртәнге сәгать сигезләр тирәсе иде. Карт, үзенең кара уйларына батып, сарайда җәтмәләрен тәртипкә китереп маташа иде. Ул йорт каршына машина килеп туктавын ишетми дә калды.

Ниһаять, аның колагына:

— Әй, хуҗалар, сез өйдәме? — дигән тавыш ишетелде.

Ислам бабай сараеннан чыкты, капканы ачып, кунакларны ишегалдына кертте.

Мурзин, машинадан төшеп, балдаклы ачкычын бармагында әйләндерә-әйләндерә, каенатасы янына килде һәм аны җиңелчә иңбашыннан кочаклады.

— Нәрсә, бабакай? Көтмәгән идегезме әллә? Әллә теге көнне бездән рәнҗеп киттеңме?

— Юк, юк. Нишләп рәнҗим, рәнҗемәдем, — диде карт.

Шәргыя ике кулына хуҗалык сумкалары тоткан — күчтәнәч төяп килгән. Аны каршыларга дип, болдыр баскычына ашыга-ашыга Нәгыймә карчык килеп чыкты. Ул рәешкә генә кия торган чачаклы ситсы күлмәктән иде.

— Әни, исәнме!

— Кызым! Балакаем!

Кыз белән ана кочаклашып күрешкән арада, машинадан башкалар да коелыштылар. Мурзин яңа кунакларны исемнәрен әйтә-әйтә таныштырырга кереште.

Алар алдында үзен ничектер уңайсыз сизгән Ислам бабай, кабаланып, әле монда, әле тегендә сугылды, чалбарын рәтләде, аяк астында йөргән казларны читкә куалады.

— Кадерле кунаклар, өйгә рәхим итегез. Юлда тамагыгыз кипкәндер, чәй куеп җибәрербез...

— Без балык ашарга килдек, балык! — диде Мурзин, шаярулы төстә күзен кысып. — Табигать кочагына чыгып, ягъни.

— Балыгы да, күкерте дә булыр...— дип, шулай ук шаярып җавап бирде Ислам карт. — Сезгә, акыл кешеләренә, күкерт кирәк ди түгелме соң?.. Әйдәгез, өйгә уза торыгыз. Мин хәзер чәй янына яңа бал алып керермен. Керегез, кер, монда тормагыз. Юкса, үзегезне корт чакмагае.

Баскыч башыннан Нәгыймә карчык кунакларны шулай ук өйгә керергә кыстый иде.

— Әйдәгез инде, узыгыз. Бабагыз дөрес әйтә: быел кортлар бик усал — очраган бер кешегә ташланырга гына торалар!

— Ә минем күрәсем килә, бабайның ул кортлар белән ничек эш иткәнен күрәсем килә, — диде Мурзин.

— Минем дә! Мин кортлардан курыкмыйм! — диде Света, Мурзинның кече кызы, шатланып. Артка таралып төшкән озын, кара чәчләре өстеннән башына панамка киеп куйган алсу битле чибәр генә бер кызчык иде бу.

Мурзинның юлдашларыннан түгәрәк йөзле, кара күзлекле берәү шулай ук ишегалдында калды. Ул киртә буена, кибәргә эленгән җәтмәләр янына барып басты.

Ислам бабай, өйгә кереп, төтәткечкә самавардан утлы кисәү салды да, соры төтенгә уралып, яңадан ишегалдына чыкты.

Аннан ул, бакча түренә узып, иң кырый умартаның капкачын ачты. Кисәк тынычлыклары бозылган кортлар дәррәү һавага күтәрелделәр һәм, алтынсу канатларын кояшта җемелдәтеп, картның башы очында ярсып-ярсып бөтерелергә, безелдәргә керештеләр. Алар картның кыска чәчле башына, бит-яңакларына, муенына кунып, тиздән аны бөтен ягыннан тоташ кара тап сыман сырып алдылар. Ләкин үзләре аңа тимиләр иде булса кирәк, чөнки карт, авыз эченнән кеткелдәп көлә-көлә, тыныч кына үз эшен эшли бирде: авыр бер рамны кәрәзле балы белән бергә умарта эченнән чыгарып ипләп-җайлап ак фарфор савытка куйды, умартадагы бушаган урынга исә яңа, кәрәзсез рамны кертеп урнаштырды. Бу эшләрне башкарганда ул фәкать берме-икеме мәртәбә генә битенә таба төтәткечтән төтен бөркетеп алды.

Карт ифрат канәгать иде. Ул умартаның капкачын япты да, кәрәзле савытны кулында сузып тотып, ашыгыч адымнар белән өйгә таба юнәлде.

— Әй, читкәрәк китегез! Читкәрәк!

Ләкин боларның һәммәсен бакча ишеге янында сокланып күзәтеп торган Мурзин аны-моны абайлап өлгерә алмады, кинәт: «Ау! У-ух!.. В-в!» — дип улап җибәрде дә бөтен авыр гәүдәсе белән кисәк җиргә чүкте, аннары, янәдән тураеп, баскан урынында бөтерелергә тотынды.

— Ни булды, Мулланур Рамазанович, ни булды? — дип, аның янына ташланды күзлекле кунак, ләкин шундук кулларын болгый-болгый үзе дә кирегә йөгерде.

Ислам бабай, фарфор савытны кулында тоткан көе, буыла-буыла көлә башлады, аңа карлыккан тавышлы Буранның өрүе килеп кушылды. Бу минутта Мурзинга болар бөтенләй киресенчә: Буран — көлә, карт — өрә шикелле тоелды.

— Нәрсә авызыгызны җырдыгыз, карт пәриләр! — дип, үз-үзен белештермичә ярсып кычкырды ул.— Кайдан чакты бит әле, нәкъ күз өстен! Ә миңа рульгә утырырга кирәк... өстәвенә, иртәгә киңәшмә буласы... Күз инде әнә капланып ук бара... Ух, шайтан!

Ул арада өйдән, бармак очына бер чеметем май әләктереп, Рөстәм ашыгып чыкты.

— Алай артык борчылмагыз... Кая, корт чаккан җиреегезгә май сөртик әле... — дип, Мурзинга таба атлады ул, ләкин аңа барып җитәр-җитмәс, майлы бармагын үз күзенә каплап, шыңшып куйды: — М-м...

Май, эреп, яңак буйлап җәелде. Мурзинның кызы Света да куркудан чәрелдәп җибәрде һәм, башыннан панамкасын йолкып алып, шуның белән тиз-тиз селтәнергә тотынды. Бал кортлары, әлбәттә инде, шундук аның өстенә ябырылдылар.

Өйдән атылып чыккан Шәргыя, баскыч башыннан торып, аңа:

— Болгама панамкаңны, кил монда! — дип кычкырды.

Ләкин кызчык аны-моны аңлаудан узган иде инде. Шул чак ул артка салынып төшкән озын чәче арасында нидер кыбырсынып йөргәнен тойды.

— Уй, аркамны!..

Ислам бабай, эшнең хәтәр якка авышуын абайлап, шомлана калды һәм, кулындагы савытка төтен өрдерә-өрдерә, ашыгыч-вак адымнар белән өйгә таба элдертте:

— Әй, җәмәгать, читкә тайпылыгыз!..

Бал савытын өйдәге өстәл өстенә куеп калдырып, ул яңадан кызчык янына чыкты. Анда инде Шәргыя дә кайнаша иде. Картның төтәткеченнән бөркелгән төтенгә кызчык йөткеренә, күзләрен угалый башлады. Шәргыя шактый дорфа рәвештә этисен читкә этәрде:

— Бар әле, буталмачы монда! Бөтен корт өере синең арттан ияреп йөри... Кызым! Кайда ул? Кортны әйтәм?..

— Чәчтә. Быжылдый да быжылдый... Әнием!

Шәргыя Светаның шомырт-кара чәч толымын учына аркылы салды һәм тоткын бөҗәкнең ярсулы безелдәвен үз колагы белән ишетте. Шуннан ул, калын толымны бармаклары белән аралый-аралый, аны селеккәләргә, тузгытырга тотынды. Үзе ул куркудан башын читкә бора һәм бертуктаусыз этисен сүгә иде. Бер мәртәбә Светага да:

— Кыбырсынма, тик кенә тор! — дип җикеренеп алды.

Ләкин бөҗәкнең чыгар нияте юк иде, күрәсең.

Ислам бабай мәсхәрә белән көлемсерәп куйды.

— Хатын-кыз дисәң хатын-кыз! Кая, үзем карыйм әле!

Шәргыя чәч толымын ташлап, читкә тайпылды. Карт бик эшлекле кыяфәттә кызчыкның чәчен бер бөртеген калдырмыйча төптән үк учына җыеп тотты да, кискен хәрәкәт белән аска таба сыдырып төшерә башлады. Чәч арасында нидер чыртлап куйды. Ислам бабай учын ачты һәм, сулышын өргәләп чәч бөртекләрен аралый-аралый, канатыннан эләктереп үле кортны тартып чыгарды.

— Менә эше дә бетте! — диде ул, гаепле кешедәй елмаеп.

— Эше дә бетте, имеш! — дип үртәде аны Мурзин, тынкыш борыны аша авыр сулап.— Күз бөтенләй шешеп чыкты әнә. Ә минем иртәгә... Әллә йөри шулай эшләдең инде... Шулаймы?

— Йа алла, нишләп йөри булсын, син ни сөйлисең? — дип, килештерүчән тавыш белән, баскыч башыннан аваз салды Нәгыймә карчык.— Мин сезне алдан ук кисәттем бит: быел бал кортлары бик усал, сак булыгыз, дидем! Рөстәм улым, бар, җизнәңә кар базыннан боз кисәге алып мен әле, күзенә куеп торсын. Менә күрерсең, бераздан шешнең эзе дә калмас!

Тынычланган Света чытлыкланып өске иренен кабартты:

— Минем өйгә кайтасым килә, шәһәргә!

— Өлгерерсең,— диде әнисе, Светаны баскычка таба тәрткәләп.— Министр хәтле министрлар да ял саен авылга барып йөри... Шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп бетәрсең әле...

Кунаклар, як-якларына сагаеп карана-карана, ахылдап-ухылдап, түрге өйгә керделәр һәм өстәл тирәли урындыкларга утырыштылар. Табын башында самавыр гөрләп утыра, кызыл бизәкле өр-яңа өлеш тәлинкәләренә һәр кеше саен үтә күренмәле, калын кисәкле кәрәзле бал бүлеп салынган иде. Кәрәзләрдә урыны-урыны белән бармак яки

кашык эзләре күренә — ул урыннардагы сыек бал, күзәнәкләрдән сытылып чыгып, кәрәз тирәли тәлинкәгә агып төшкән иде.

Мурзин кар базыннан Рөстәм алып менгән зәңгәрсу боз кисәкләрен озаклап-озаклап уң кашы өстенә кысып утырды. Аның яңагы, суга чыланып, ялтырап тора иде.

— Ә корт чагу файдалы нәрсә ул! — дип, чәй ясый-ясый, киявен тынычландырырга тырышты Нәгыймә карчык. — Беркөн радиодан сөйләп маташтылар: корттан чактырып, аяк сызлавын, аннан йөрәкне дәвалыйлар, имеш. Син инде, кияүкәй, бабаңа үпкәләмә, бабаңның монда һичбер гаебе юк. Аның үзен әнә гомере буе корт чага, аңа карап берни дә булмый. Киресенчә, корт чакканга шундый таза, нык та ул. Корт-лардан ул үзе теләп чактыра!

— Иң кирәге — тазалык, сәламәтлек шул! — диде Мурзин, ачуы сүрелә башлап. — Минем үземнең ишеткәнем бар: хәтта миллионерлар да, корттан чактыру өчен, махсус рәвештә умарталыкларга барып йөриләр, ди. Сәламәтлеккә файдасы бар, димәк. Әнә бит, күз алдында — безнең бабакай нинди таза, күз генә тимәсен! Шу-лай.

Ислам карт, гаепле кеше сыман, чәйле чынаягына төбәлеп, дәшмичә тик утырды. Соңгы көннәрдә аның бераз күкрәк-аркалары сызлап тора иде.

— Ник син дәшмисең? — дип, инде бөтенләй дусларча сорады ахырдан Мурзин.

— Сине бәлки бераз аракы белән дәваларга кирәктер, шешең тизрәк бетәр иде, — диде Ислам бабай, хәйләкәр елмаеп.

Мурзин көлеп куйды һәм хатынына ым какты: кая, китер, янәсе!

Әлбәттә инде, картны да өлешсез калдырмадылар. Эчкәч, аның күкрәк-арка сызлавы ничектер сүрелә төшкәндәй булды.

— Хак сүз — кешегә иң беренче сәламәтлек кирәк... Ләкин без үзебезне сакламыйбыз шул! — дип, сөйләвен дәвам иттерде Мурзин. Ул әледән-әле авызына кәрәзле бал алып каба һәм аны тәмам чәйнәп-сыгып бетергәннән соң, түбен — коңгырт-сары балавыз йомарламнарын тәлинкәсе янына өя бара иде. — Менә миңа, мәсәлән, ябыгырга кирәк... Ә ничек ябыгырга? Мин болай да инде ипи ашамыйм, сыра, квас ише нәрсәләрне бөтенләй авызыма капмыйм.

Табын янындагылар бер-беренә шөбһәле-сынаучан күз карашы ташлашып алдылар.

— Барыбер файдасы тими! Чөнки эшебез шундый. Кемдер анда, әйтик, урамда тырай тибеп йөри, ә без бүлмәдә баш ватып, уйлап утырырга мәҗбүр. Бил язарга да вакыт юк.

— Сез хаклы, Мулланур Рамазанович. Һәрбер начальствоның ашаганы буйга сеңә бара, — диде кара күзлекле кунак; аннан бик һавалы төстә, тагын нәрсәдер әйтмәкче булган иде дә, авызына капкан зур кисәкле кәрәздән сулышы кысылып, туктап калды, тик ахырдан гына: — Балы бик тәмле, искиткеч тәмле... — дип өстәргә кирәк тапты.

Чәйдән соң һәммәсе ишегалдына чыктылар, тирләгән муеннарын сөлге белән сөрткәли-сөрткәли, амбар күләгәсенә утырышып, күк йөзенә иренчәк күз карашларын юнәлттеләр. Их, бер генә минутка яңгыр явып үтсә соң!...

Кузгалыр вакыт җиткән иде. Карт лапастагы кар базына төшеп, кечкенә бер капчык белән балык алып менде, аны шоферга тоттырды. Үзе Йолдыз кашканы арбага җикте дә алдан кузгалды. Озакламый аны машинада куып җитеп, узып киттеләр.

Ислам бабай эсседән тәмам миңгерәүләнгән бер хәлдә Җиләскүлгә килеп җиткәндә, тегеләр инде учак ягып, балык әрчи башлаганнар иде, ә чирәм өстендә Мурзинның транзисторы шыгырдый иде.

Ислам бабай көймәсен суга төртеп төшерде дә, тиз генә бер җәтмәнең балыгын алып кайтты (сез әрәмтамакларга бер җәтмәдәгесе дә

житәр, янәсе!) һәм әрчергә дип аларны хатын-кыз халкына тапшырды. Кара күзлекленең хатыны балыкны һич җаен белмичә, пычагы белән бөтен эчен шытырдатып актара-актара чистарта иде. Ислам бабай аңа кызганып карап торды-торды да, ахырда түзмәде:

— Их, булмаганнар, кем инде шулай балык чистарта! Иң тәмле җирен чүпкә ташлыйсыз бит! — дип шелтәсен белдерде.

Ләкин аны балык чистарткан җирдән шундук куалап җибәрделәр.

Карт ирләр янына китте. Алар печән чүмәләсенең кыска күләгәсе астына сыенышканнар да әкрен искән кайнар җилгә ачык изүләрен куеп, ниндидер гәп башлап җибәргәннәр. Дөресрәге, Мурзин сөйли, ә кара күзлекле белән тагын бер кунак һәм шофер аны ихтирамлы төстә тыңлап утыралар иде.

— Мондагыдай уханы сез беркайда, хәтта Мәскәү ресторанында да ашый алмыйсыз. Ә чәй? Чәе дә монда үзенә аерым, карлыган, җиләк һәм хуш исле яфрак салып пешерелгән була.

Тегеләр, бу хакта бик хәбәрдар булсалар да, Мурзинның сүзләрен йотылып тыңлагандай күренергә тырышалар иде.

Ислам бабай, авыр сулап, аларның янәшәсенә килеп утырды.

— Син бик шәп җирдә яшисең, бабай. Молодец! Без синең янга гел шулай килеп йөрербез, ярыймы?

— Миңа нәрсә! — дип, иңбашын сикертте карт. — Кунак килгәнгә мин гел шатмын.

— Минем сиңа тагы бер сүзем бар әле, анысын соңыннан, уха ашагач әйтермен, — диде Мурзин, серле итеп.

Ләкин уха пешәргә әле ерак, ә Мурзинның үз йомышын бик тә әйтәсе килә иде, шуңа күрә ул Ислам бабайны култыклады да куаклыклар арасындагы полиэтилен пленка җәелгән табын янына алып китте. Алар шунда үтә күренмәле, юка, ябышкак, пленка өстенә йөзтүбән сузылып яттылар. Мурзин, теге вакыттагы кебек җете кызыл төстәге шәраб шешәсен ачып, рюмкаларны тутырды.

— Беләсеңме, нәрсә, — дип башлады ул сүзен, картның йөзенә хушбуй сулышы бөркеп. Аннан, аскы иренен кабартып, өстәп куйды. — Беләсеңме, нәрсә? Әйдә без синдә дөньяда һәркем көнләшерлек шәп бер ял урыны оештырып җибәрик. Ә?

— Монда тагы нәрсә җитми соң сиңа? — диде Ислам бабай, гаҗәпләнеп. Эссе иде — ул йөзен чытты.

— Син мине аңламадың! Мин әйтәм, монда шундый шартлар булдырыйк, дим,кирәк чакта, әйтик, синең янда ял итәргә һәр җирдән... ну, мисалга, Казаннан иң зур начальство килеп йөрерлек булсын... Хәтта министрлар да! Аңладыңмы? Җә, ни дисең?

— Ни дим, кирәк икән, алып кил соң.

— Юк! Аларны син үзең чакырырга тиеш!

— Мин? Ничек итеп?

— Хат язып. Син укый-яза беләсең ич?!

— Яза беләмдер дә, тик ни рәвешле язарга соң аны? Теге бланка дигән кәгазьгә язып салыргамы? Алар шундый хатларны гына укыйлар ди түгелме соң?

Мурзин шаркылдап көлеп җибәрде.

— Шыр җүләр син, валлаһи. Әкият сөйлисең! Димәк, килештек: син кунакка чакырып хат язасың.

— Кемгә?

— Беренче чиратта — Антоновка. Ул синдә бер тапкыр кунак булган бугай ич инде? Василий Михайловичны әйтәм. Ул үзе сине яхшы хәтерли. Менә шул: тот та аңа хат язып җибәр. Никадәр аламарак язсаң, шул кадәр әйбәтрәк. Хәзер простой кешеләрне яратарак төшәләр. Фәлән дә төгән... Сезне балык, кәрәзле бал көтә, диген. Ул сиңа җавап язып салыр. Бәлки җавап язып та тормас, үзе үк килеп җитәр... Анар-

дан күрмәкче инде... бүтән могтәбәр кешеләр дә... монда агыла башлар. Син аларны балык шулпасы белән сыйларсың, рәхәтләнеп бер сөйләшеп утырырсыз... Ну, ризамы?

Ислам бабай Мурзинга таба мыскыллы күз карашы ташлап алды:

— Син дә, әлбәттә, монда булачаксың инде, шулаймы?

— Әйе, мин дә! Ә нәрсә? Киявенне читкә кагар идеңме әллә?

— Юк-юк, рәхим итә күр, — дияргә ашыкты карт, кияүнең үпкәләвеннән куркып.

— Соң, ничек, язарсыңмы?

— Уңайсыз булыр бит... — дип, башын түбән иде Ислам карт. — Син яз, ә мин пуштага илтермен.

Мурзин, тез башын ышкый-ышкый, аз гына уйланып торды.

— Дөрес әйтәсең. Алай эшләргә дә була.

Ул Ислам бабайны кочаклап сөйде дә, авыз эченнән генә ниндидер җыр көйләп, яңадан иптәшләре янына китте. Карт аның артыннан: «Нинди хәйләкәр! Төлке дисәң төлке! Ярар, мин дә төшеп калганнардан түгел!..» — дип, үзалдына көлемсерәп калды.

Шул чак әрәмәлек арасыннан, озын гәүдәсе белән юлындагы кыргый колмак сабакларын чытырдатып өзә-сындыра, кулына миски тоткан Рөстәм килеп чыкты. Мискигә ул әрәмәлектә үзе җыйган төрле җиләк-җимеш: бер уч кара карлыган, шул ук чамада кара һәм кызыл бөрлегән, аннан тыш тагы кибеп төссезләнә башлаган аз гына вак шомырт тутырган иде. Аланга чыгуга, Рөстәм корт чаккан һәм, шешеп, хәзер бөтенләй диярлек кысылып ябылган сул күз кабагын яшерер өчен кесәсеннән кара күзлеген алып киде дә, әтисенә игътибар да итмәстән, туп-туры кунак хатын-кызлар төркеменә таба атлады.

— Тукта! Үз хатыныңа ни дә булса җыйдыңмы соң син? — дип эндәште аңа Ислам бабай.

Улы әллә ишетмәде, әллә ишетергә теләмәде — битараф бер кыяфәттә юлын дәвам иттерде.

— Көнне әйтәм, шактый әйбәт күренә, — диган булды күзлекле кунак, картның игътибарын читкә юнәлтергә теләп.

Карт аңа кулын гына селтәде. Беркем аңламый шул аны монда. Нәгыймә карчыгы белән килене әнә, тавык ашы һәм бәлеш пешерергә дип, өйдә калдылар. (Алар өчен уха да балык кунак ашымыни!) Менә аларга да күчтәнәч итеп бераз җиләк җыеп кайтасы иде дә, тик хәл юк — Мурзинның аракысы нәрсәдер башны чуалтты. «Тиздән үләрмен, ахрысы», — дип уйлап куйды кинәт Ислам бабай һәм ярым исерек бер гаҗәпләнү белән әйләнә-тирәсендәге табигатькә күз төшерде. Әнә катлы-катлы булып карлыганнар алсуланып күренә; ерактарак, чокырлы урыннарда, эсседән яфракларын коя башлаган сары тал куаклары утыра һәм шулар белән янәшәдә үк — сусаган җирнең мәңгелек сакчысы сыман, вакыт җилләре, эт һәм ерткыч кошлар киртләчләп телгәләгән тимер яфраклы мәгърур имән тора... «Әйе, мин үләрмен. Ә болар? Болар да үләрләрме?»

— Уха, уха өлгерде! — дип кычкырдылар хатыннар.

Ашар алдыннан Шәргыя кружкаларга тагы теге куе кызыл төстәге эчемлекне салып чыкты. Балык шулпасы һәм арзанлы венгр ромы — моннан да гайре табигый кушылма, мөгаен, бүтән булырга да мөмкин түгелдер.

Ислам бабай түзмәде, йөзен кыйшайтып:

— Карале, кызым, моның бер шешәсе күпме тора соң? — дип сорады.

— Аның бәясе сиңа нәрсәгә? — диде Шәргыя, ачуы килеп.

— Әйт инде.

— Ну, биш тәңкә, тиеннәре белән.

«Саран! — дип эченнән уйлады Ислам бабай. — Аңлашыла. Ярты литры түгел, җиде йөз илле граммы биш тәңкә тора ич. Ак аракы алуга караганда күпкә файдалырак, димәк. Коньяк сыман үзе...»

Табын янында һәммәсе уханы, Ислам бабайны, Ык буйларын мактадылар...

Ислам бабай исә, үзалдына кара көеп, сөйләшмичә утырды. Хәтере калган иде аның. Бердән, Шәргыя аның белән бик дорфа сөйләшә; әтисен яратмаганы әллә каян күренеп тора. Икенчедән, картка улы Рөстәмнең Мурзиннарга җиләк җыеп кайтуы ошамады. Ә менә үзенең Нажиясен оныткан! Нажияне карт үлеп ярата иде...

Ашап-эчеп туйганнан соң кунаклар карта уйнарга утырдылар. Шарты бик гади — оттырган кеше карта белән үзенең борынына суктыртырга тиеш. Бу җәзаның иң күбе күзлекле кунакка эләкте. Ләкин ул моңа артык пошынмады шикелле: оттыруга, күзлеген салып, черек гөмбәгә охшаш борынын уйнаучыларга таба суза да:

— Әйдәгез... Үз кешеләр бит... Әйтсәм әйтим, шактый шәп кичә булды бу... — дип куя иде.

Аннан җыр җырладылар; кумәкләшеп һәм аерым-аерым, камышлы күл, әрәмәләр янында рәсемгә төштеләр.

Кояш төшлектән авышып, көн бераз сүрелә башлаган иде инде.

...Ниһаять, калдык-постык нәрсәләрне машинага төягәч, кунаклар яңадан Бикташка юл тоттылар. Анда аларны өй ризыгы көтә иде. Ислам бабай да, атын җигеп һәм арбасына ертык җәтмәне салып, алар артыннан кузгалды...

Башта әйтерсең лә ут өермәсе — ул һаман кияве турында уйлады һәм уеның рәтенә һичничек чыга алмады. Карт беркемгә бернинди явызлык теләми, ләкин белә: аңа Мурзин тәкъдим иткән шакшы бәхетнең бер тиенгә дә кирәге юк иде.

Карт, кайтып, өйгә кергәндә, анда мәҗлеснең иң кызып барган чагы иде. Тәлинкәләрдә итле бәрәңге калдыклары ята, токмач ашы ашалган, хәзер бәлеш кертелергә тиеш иде. Карават өстендә исә Мурзинның транзисторы шыгырдый иде.

Ислам бабайны ура кычкырып каршы алдылар:

— Яшәсен бөек балыкчы Ислам бабай!

— Авылның иң могтәбәр аксакалы!

— Түргә уз, хөрмәтле хуҗа!

Карт йөзен кыйшайтты, кунакларның кыстауларына игътибар итмичә, башта кухняга узды, анда бик озак карчыгы һәм килененең май канатын кайнар майга мана-мана бәлеш майлавын, зур-зур тәлинкәләргә матурлап-хасиятләп шәңгә, суган, алма пироглары кискәләп тезүләрен, аерым савытларга бүлгәләп чәк-чәк, карлыган кагы ише чәй ризыклары куюларын күзәтеп торды. Хатын-кызлар көне буе мич янында кайнашып, арып, әлсерәп беткәннәр иде, билгеле. Карт аларны кызганып куйды.

— Нәгыймә!..

Аннан, ялгышын төзәткәндәй, киленена эндәште:

— Нажия!..

Ислам бабай киленне кочаклап, аркасыннан сөйде. Ул аңа күп нәрсә әйтә алыр иде, ләкин нигә сүз әрәм итәргә? Аны монда аңлаучы кеше бармыни? Шуннан ул кире кунаклар янына чыкты.

— Карале, бабакай! — дип каршы алды аны Мурзин. — Без монда бер мәсьәлә турында киңәш-табыш итеп утырабыз әле. Каенэнегә, синең улыңа, аерым йорт салып бирик, мәйтәм! Яшәсеннәр иде шунда үзбашларына! Бер төзүче бригада җибәрсәм — атна-ун көн эчендә йортны торгызып та куячаклар!

Карт аңламыйчарак торды:

— Ничек инде алай?

— Ничек булсын, шулай: боерык бирәм дә, йорт әзер дигән сүз. Сезнең монда үзегезгә дә бик кысан бит,— дип, ияк астын кашый-кашый, тагын рәхәтләнеп аңлатырга керешә Мурзин.

— Менә әйбәт булыр иде бу! — дип, дәррәү хуплап кычкырдылар кунаклар. Ишектән бәлеш күтәреп кергән Нәгыймә дә моны шундук эләктереп алды:

— И-и-и, рәхмәт инде, кияү, бик зур рәхмәт! Искиткеч зур бүләк бит бу безнең Рөстәмгә! Шулай булырга язсын, йа илаһым! — дип, көйләп-вәзенләп сайрарга керешә.

Мурзинның кәефе шәп иде. Шәргыя тагы аңлатырга кирәк тапты:

— Аңа бу эшнең һич авырлыгы юк. Наряд яза да, аннан... ну, үз кешеләр лабаса, нәрсәсен сөйләп торырга... Рөстәм, син рәхмәт әйттеңме соң җизнәңә? Әллә ишетми генә калдыммы? Ә, Рөстәм?

Бурлаттай кызарынган Нажия, ни әйтергә белми, ишек төбендә басып тора иде.

Ислам бабай әкрен генә:

— Ә мин тагы... без үлгәч, алар шушы йортта калыр дип уйлаган идем, — диде.

Дөресе, ул болай дияргә теләмәгән иде. Улы Рөстәмдә кайчан ирлек горурлыгы, гаилә башы горурлыгы уяныр, кайчан ул бүтәннәр алдында ялагайланып йөрүдән, чүпрәк булудан туктар — менә шул көн җиткәнне көтә икәнлеген аңлатырга теләгән иде Ислам бабай. Юкса бит инде әнә кызы бар, идәндә үрмәләп йөри, ә Рөстәм әле һаман сарык дисәң сарык!

Кунаклар, картның башында нинди борчулар булуын һич аңламыйча, кулларын болгый-болгый:

— Яшә, Ислам бабай, йөз иллегәчә яшә!

— Безнең кадерле Ислам бабаебыз!.. — дип, шаулашып кычкырырга тотындылар.

Ислам бабай, күңелендәге каршылыклы хисләр шаукымыннан ни эшләгәнен үзе дә аңышмыйча, стаканга мөлдерәмә аракы тутырып авызына каплады да, ишекне каты ябып ишегалдына чыгып китте.

— Оһо! Үпкәләде. Әллә шатлыгыннанмы? — диде Мурзин, кашларын югары чөеп. — Кая, чыгып, үзе белән сөйләшеп керим әле...

Мурзин болдырга чыкты. Баскыч башында кызы Света елап утыра иде.

— Ни булды? Күңелсезме әллә? Хәзер өйгә кайтырбыз.

— Ю-ук... Дәү әти ачуланды.

— Анысы нәрсә өчен тагын?

— Тырнакларымны кисә башлаган идем.. Энгер-меңгердә тырнак кисәргә ярамый, ди... әти-әниең үләр, ди. Әтием, ул дөрес әйтми бит, иеме?

— Әйе, кызым. Бар, өйгә кер. Анда сине тәмле бәлеш көтә... Һей, кайнатай, син кайда?

Ислам бабай җавап бирмәде. Ләкин Мурзинның кысык, очлы күзләре аны ак күлмәге буенча шундук күреп алдылар.

Мурзин, кайнатасы янына килеп, янәшә утырды.

— Та-ак... сказал бедняк, — дип сузды ул. — Шула-ай...

Карт дәшмәде.

Көнбатышта офык чите кызгылт-якты нурлар белән яна, әмма авыл өстендә күк йөзе инде тәмам карангыланып, йолдызлар калыккан, бакчалар өстеннән төнге җылы җил шуыша иде...

— Соң, син улыңа бәхет теләмисеңмени? — диде Мурзин, үҗәтләнеп.— Хәер, син беркемгә дә бәхет теләмисең бугай. Миңа да теләмисең. Юкка алай уйлыйсың. Мин лично сиңа бик яхшы карыйм. Алай яхшы караган кешеләрем бик сирәк була минем. Җә, әйт алайса, ник син улыңның башка чыгуын теләмисең?

Карт әллә елмая, әллә йөзен чыта — карангыда берни дә шәйләрлек түгел иде.

— Сәбәбен әйтимме? — дип, кинәт мәсхәрә катыш исерек тавыш белән пышылдады Ислам бабай. — Мин киленем Нәҗияне яратам шул...

— Ык! — дип куйды Мурзин, кемдер кинәт янтыгына бармак белән китереп төрткәндәй, һәм шаркылдап көлеп җибәрде. — Аһ, менә нәрсә икән!.. Ай-яй-яй!..

— Ул да мине ярата.

— Әйдә, әйдә, сайра. Бу, ягъни, теге платоник мәхәббәт дигән нәрсә була инде, шулаймы?

— Син мине, Мулланур, валлаһи акылдан шаштырасың...

— Ярар, яратышыгыз әйдә, — дип кулын селтәде Мурзин. Шаяртуны аңлый торган кешемен... Ә менә Рөстәмгә йорт салу мәсьәләсендә шаяртуның һич кирәге юк. Валлаһи, бу эшне мин күз ачып йомганчы башкарып чыгам... Тик әйт кенә. Ә синең өйдән без үзенә күрә бер кунакханә, музей ясар идек. Анда мылтык дисеңме, борынгы әйберләр — чабата, сукыр лампа дисеңме — һәммәсе булыр иде. Ну, телевизор да, әлбәттә. Эчемлеген инде — әйтәсе дә юк...Ниләр генә кыландырмас идек без монда! Безгә дәрәҗәле кунаклар, Антоновлар килеп йөрер иде. Бәлки Хәкимов үзе дә килер иде... Кыскасы, син ризалыгыңны гына бир. Бөтенесен үзем башкарып чыгам! Без кардәш кешеләр бит!.. Без синең яңа көймәңә утырып...

Мурзинның үзеннән һәм чиркангыч сүзләреннән болай да саруы кайнап утырган Ислам бабай, көймә сүзе чыгуга, кинәт урыныннан сикереп торды да, киявенә курку катыш нәфрәт белән янган күзләрен кадап:

— Юк, андый эш булмас! — дип кычкырып җибәрде һәм, үз-үзен белештермичә, бүкәнгә чабылган балтаны эләктереп, шунда, ике адымда гына йөзтүбән каплап куелган яңа көймәсенә таба ыргылды.

— Юк, булмас! Булмас, булмас андый эш! Менә сиңа — көймә! Менә сиңа — Антонов! Менә сиңа! Менә!.. Менә!..

Ул шулай, йөрәгенең иң төпке катламнарыннан ургылып чыккан җан ачуы белән, көймәне тукмаклады, тукмаклады да балтаны кычыткан арасына атып бәрде, аннары, эштән чыккан көймәгә тагы бер мәртәбә аягы белән тибеп, үзалдына нидер кычкырына-кычкырына болдыр ягына ташланды.

Калганын Ислам бабай бик аз хәтерли.

## 6

Куаклар өстендәге җәтмәләр кипкән, ахрысы — тәмам аксылланып күренәләр.

Ислам бабай арба астында яткан җиреннән күккә карады — кояш инде үзенең иң югары ноктасына якынлашып бара. Бернинди кошкорт тавышы ишетелми, хәтта чикерткәләр дә көндезге эсседән каядыр яшеренеп, тынып калганнар. Хәер, янәшәдә генә бер тынгысызы кыштырдап куйды куюын, аннары, һавага атылып, бер сажин читкә — үзенчә, дөнья читенәдер инде — очып барып төште. Ләкин исән-имин калды микән, утлы һава аша узганда канатлары көеп һәлак булмадымы икән?

Карт, терсәкләренә таянып, арба астына тагы да эчкәрәк үрмәләде. Тупас тукымадан тегелеп, каешланып беткән чалбарының кояш астында тимердәй кызган балаклары ялан балтырларны чеметтереп пешереп алды.

— Их, бер яңгыр явып үтсә соң!.. Юк шул! Кичәгенәк, карыйм, умарта эчендәге кортларның яртысына якыны стенаны сырып алган. Шулары дулап чыкты да инде аның капкачны ачуга! Димәк, бу чел-ләнең бетәсе юк әле. Кичәгенәк кичен урман аша кайтканда үзем дә чак кына тончыгып үлмәдем. Болындагыга караганда урманда ун өлеш бөркүрәк. Алга табан ничек яшәргә соң?..

Карт аптыраулы кыяфәттә каршысындагы аланга күз ташлады. Әнә, әрәмәләр аксылланып ялтырый, кичәге учак янында зур бүксәле буш шешәләр кояшта җемелди. Малай-шалай кулындагы зурайткыч пыяла сыман, ул шешә дигәненнән ут чыга күрмәсен тагы. Печәнгә кабынса, бетте дигән сүз. «Таң» колхозы урманында шулай булган ди бит: пыяла аша төшкән кояш нурыннан мүккә, ылыска ут капкан да, уникеме чакрым урманны тоташтан кырып та салган.... Пыяла бит ул кояш нурын җыя. Ташландык шешәнең дә, нур төшеп, шундый бәла-каза китереп чыгаруы ихтимал...Ай-яй-яй! Болай булсак, алга табан ничек яшәмәк кирәк? Ә бит киләчәкне уйларга, хәзердән үк уйларга кирәк югыйсә... Бүген нигәдер ялкауландым әле. Инде бер сәгать буе тик ятам. Ярамый болай.

Ислам бабай арба астыннан чыкты да аландагы буш шешәләрне камыш арасына илтеп ташлады. Җәтмәләрне җыеп, арбага салды. Чып-тадагы балыкларны да шунда урнаштырды, өстән аларны әйбәтләп юеш кыяк үлән белән каплады. Шуннан соң көймәсе янына килде.

Ул яр итәгендә ята иде. Инде тәмам коргаксыган; сумалалы түшенә кул тидерерлек тә түгел — пешерә, сумаласы кулга ябыша. Борын якта әнә алсу-чуар бер күбәләк сыңар канаты белән сумалалы шома өслеккә ябышкан да шунда үлемен тапкан. Тоташ агач кисәгеннән уеп ясалган дүрт метрлы, бер кешелек караваттай тар гына көймә иде бу. Өйрәнмәгән кешегә анда йөзәргә түгел, утырырга да куркыныч — миз-гел эчендә йөзтүбән әйләнәсеңне көт тә тор. Ә шул көймә Ислам карт-ка ничәмә-ничә еллар хезмәт итте: исәпләп карасаң, ул аңа утырып кимендә йөз мең чакрым, ә бәлки аннан да артыграк юл үткәндер. Ул аңарда көчле яңгырлар астында — су өсте күбекләнеп, каралып дул-кынланган, ә көймә үзе авыр йөктән һәм бүртүдән яртылаш суга бат-кан чакларда да; хәзерге кебек, коточкыч корылык вакытларында — саеккан елга-күлләрнең йомшак-тымызык дулкыннары, кибеп җиңе-ләйгән юка көймә кырына уйнаклап бәреләсугыла, һәр тирбәлеше белән, гүя картның барлык нерв күзәнәкләрен кытыклап кузгаткан чакларда да өзлексез йөзде, үзенең балыкчы юлларын әйләнде. Көймә аңа үзенә күрә өй хезмәтен үтәде. Кирәк чакта, ул анда, эшләпәсен маңгаена батырып һәм, дулкын көймәне яр читеннән әчкә алып кереп китмәсен өчен, бер тотам озын камыш сабагын үз астына утыргычка бөгеп салып, тәмле-тәмле йокылар да кичерде. Ә иске елга үзәне, Югаргы күлләр һәм сазлы, сай болын култыкларында йөзгәндә, көй-мәне ул, як-якта үскән камыш сабакларын ике кулы белән алмаш-тилмәш тарта-тарта, ишкәксез генә йөртте; андый чакта юл өстендәге куе камышлар, көймә кырына ышкылып яисә бөтенләй көймә түше астында изелеп, өзлексез чыжылдыйлар, елашып калалар шикелле иде... Караңгы, яңгырлы төннәрдә күл-елга буенда кунарга туры кил-гәндә исә, Ислам бабай берәр кашлаграк урында көймәне йөзтүбән әйләндереп, түбә сыман җайлаштырып куя да, плащын җиргә җәеп, шунда кереп ята торган иде. Тирә-якта ялт-йолт яшеннәр ялтырый, тышкы яктан көймә төбен бертуктаусыз көчле яңгыр тамчылары чы-быркылый, шыбырдап су ага, ә ул, Ислам карт, сумала һәм балык исе аңкыган ышык-коры көймә гөмбәзе астында әкрен генә тәмәкесен көй-рәтә...

Быел карт үзенең яңа көймәсен дә суга төшерергә теләгән иде дә,

тик менә насыйп булмады. Кичәге хәл комачаулады. Тәкъдирдә шулай язылгандыр, күрәсең.

Ислам бабай хорафатларга ышанмый иде. Шулай да яңа көймә ватылу белән аның үзендә дә нидер ватылгандай булды.

Нишләмәк кирәк, хәзергә шушы иске көймәдә йөреп торырга туры килә инде.

Ул көймәне арба янына сөйрәп китерде. Аны йөзтүбән әйләндереп, авыр койрыкны, гадәтләнелгән өлгер-төгәл хәрәкәтләр белән, арбадагы җәтмәләр өеме өстенә күтәреп салды, аннары тагы бер кочаңүдә борын өлешне дә шунда күтәртте. Җайлы урнашты, барырлык. Менә шулай, барып та җитәр. Борынына ябышкан алсу күбәләге белән бергә барып җитәр.

Ислам бабай атын җикте.

Чиләк, кружкаише нәрсәләр — әйдә шушында, яшерен урында калсыннар. Яңгырлар явып үткәч, ул монда янә кайтыр әле. Шуңарчы күлләр ял итәрләр. Мурзин хәтта Мәскәү кунакларына дип сораса да, карт монда бүтән балык тотарга килеп йөрмәячәк.

Ислам бабай арбага ян яктан аяк салындырып утырды да дилбегәне тартты:

— Н-на, Йолдызкай!..

Эсседән миңгерәүләнер хәлгә җиткән ат әкрен генә атлап китте. Карт үзе дә аны әллә ни ашыктырмады — кичкә кадәр ерак әле, барып җитәр...

«Картайганмындыр, ахрысы,— дип, үзалдына моңсуланып уйланды ул.— Җә, кичәге кычкырынуым нигә кирәк иде инде? Ана сөте белән кермәгәнне сүз сөйләп кенә кертә алмассың. Ә мин бусарынырмы-бусарындым. Әйбәт түгел болай. Элек әйтә торганнар иде: түтәлдәге яшь кабак шартлап ярылса ярылыр, әмма Ислам бабай юк-бар сүз өчен авызын ачмас, диләр иде. Ә мин хәзер бөтенләй тел бистәсенә әйләндем. Авызымның йомран оясы тишеге сыман, йомылганы да юк. Әүвәлге сабырлыкның әсәре дә калмаган, әсәре дә. Ләкин ул Мурзинга ничек түзмәк кирәк соң? Яшәвендә аның берниндн иман дигән нәрсә юк бит — бөтен тормыш рәвеше «мин — сиңа да, син — миңа!» га буйсынган!.. Заман чирләре! Теге, ничек диләр әле, үлтер-фиалит диләрме, әнә шундый күзгә күренмәс чирләр!.. Рөстәменә хәтле шул Мурзин булып кылана. Тегесе: ипи ашамыйм, симерәм, дисә, монысы минут саен йөрәген тотып зарлана, баш авырта дип, көн-төн әллә нинди дарулар йота. Эштән, кулы пычранудан куркып яши ул. Нииндидер үзешчәннәр белән баш катыра, игълан-афишалар яза. Ин гаҗәбе — шуны эш дип саный бит әле... Янәсе, уйлый, акыл өйрәтә. Нәрсә уйлый алсын ул? Маңгай җыерып утыру — ул әле уйлау дигән сүз түгел. Резин туп та тыны чыкса җыерыла... Кырда иген яңа — менә шуның хакында баш ватарга кирәк хәзер. Халык арыган — менә шул турыда уйларга кирәк. Сугыш булмасын — менә шуны кайгыртырга кирәк! Ә ул, гүя бу мөһим эшләрнең берсе-бер булмагандай, бөтен дөньясына кул селтәп, йөзен чытып яши: йөзен чытып елмая, йөзен чытып китап укый, йөзен чытып ашый... Яки, әйтик, кешеләр өчен балык тоту — мөһим эш түгелмени? Ә ул минем эздән барырга теләми. Ярар, балыкчы булырга теләмәсен дә! Ә бит тагы механизатор дигән, нефтьче, агроном дигән кәсепләр бар — нигә соң ул шул юл белән китмәде? Әллә соң инде үзем артта калганмынмы, үзем бутыйммы — хәзер игъланчы, үзешчәнче дигән яңа профессияләр дә бармы? Мин карт кеше, адәм баласына бәхет, иминлек телим. Һәр кеше менә шул бәхет, иминлек хакына күзгә күренеп торган эш эшләргә тиеш. Ә Рөстәм ни эшли? Белмим. Җыелышларда читтән килгән начальникларга ягымлы елмая, алар өчен кибеткә аракыга чаба — күзгә күренгәне менә шул.

Эшләпә, галстук кигәнлектән, аңа аракыны кибеттә гәзиткә төреп бирәләр, — гадәттәгечә, күпшә сыман итеп тә түгел, ә авызы җаенке, төбе очлы кап сыман итеп төреп бирәләр. Янәсе, кәнфитме, манный ярмасымы алган дип уйласыннар. Ләкин халык җүләр түгел бит, күрә...»

Картның берөзлексез авызы кыймылдый, ул хәтта, үз фикерен үзе хуплагандай, баш кагып-кагып та куя иде.

Ара-тирә уң бот янындагы чыпта капчыкта балык тыпырчынырга тотына. Андый чакта картның чырае кисәк кенә ачылып, яктырып китә, ләкин бу озакка бармый, бераздан ул янәдән әүвәлге уйчан-моңсу төсенә кайта иде.

— Н-на! Кызурак атла, Йолдызкай! — дип, атын ашыктырды Ислам бабай.— Бәлкем сиңа май ягып ипи бирергәдер, ә? Әллә перәнник кирәкме? Перәнникне бирермен мин сиңа, кара аны...

Айгыр, пошкырып һәм әрсез бөгәлчәннәрне койрыгы белән куа-куа, юыртып бара башлады.

...Көндезге сәгать икенче киткәндә ул инде үзенең йорт ишегалдында иде. Аңарчы ул тотылган балыкны колхоз складына илтергә өлгерде, шуннан кайтышлый, юлда улын очратты. Шешкән күз кабагын яшерер өчен кара күзлек киеп куйган Рөстәм колхоз идарәсе каршында җыелган һәм ниндидер гәп белән мәшгуль булган бер төркем кешеләр янында моңаеп басып тора иде. Карт аңа сүз кушарга кирәк тапмады...

Ислам бабай Йолдыз кашкага тагы солы салып бирде дә өйгә керде. Кара өйдә Нәгыймә түтәй күрше карчыгы Зәмзәмбану белән тәмләп ләчтит сатып утыра иде.

Карт, Зәмзәмбануга коры гына сәлам биреп, кичәге хәлләр өчен оялудан тагы да кырыслана, басынкылана төшкән төрпе тавыш белән, карчыгы Нәгыймәгә чәй әзерләргә кушты һәм, тирләп юешләнгән күлмәген алыштырырга дип, ак өйгә узды.

Нәгыймә карчык аның артыннан, кабаланып, ыгы-зыгыланып:

— Хәзер әчәрсең, эчәрсең, чәй әзер,— дип кычкырып калды.

Ул, мич янына килеп, бәләкәй самаварга күмер салды, көйрәтеп, торбасын куйды, ә янәшәсендә торган ярты чиләк сыешлы иске, зур кайнар самаварны әһ тә итмичә өстәл башына менгереп утыртты. Авылның ишле гаиләле һәм мул тормышлы һәрбер йортындагыча, Нәгыймә карчык өйдә ике самавар тота, һәм алар монда беркайчан да суынырга өлгермиләр иде диярлек!..

Ислам карт тәнгә ябышкан юеш күлмәген көч-хәл белән өстеннән салып, корысын киде. Аннан яңадан кара өйгә чыкты.

Күрше карчык, аны гына көткәндәй, учы белән лыгырдык ияген сыйпый-сыйпый, сайрарга тотынды:

— И-и, Исламетдин, шатлыклы хәбәр ишеттем әле: улыгызга яңа йорт салып бирмәкче буласыз икән. Киявегезне әйтәм, нинди игелекле, туган җанлы кеше икән! Һич алай ук мәрхәмәтле булыр дип уйламаган идем. Инде, ходай кушып, үзенә сәламәтлек кенә бирсен, гомере буена бу игелегенең әҗерен күрергә язсын...

Ислам бабай эчендә кайнаган ачудан авызын чупылдатырга тотынды.

Күрше карчыгы исә сүзен дәвам иттерде:

— Дөньяда бик сирәк очрый бит андый игелекле, ярдәмчел кешеләр! Үз гомеремдә мин андыйларны берничәне генә күрдем. Шуларның берсе — син үзең, Исламетдин... Сиңа да аллаһе тәгалә озын гомер, бәхет бирсен, ярабби...

Ислам бабай дәшмәде, чокырдагы чәйне калагы белән шаулатып болгата-болгата, үзалдына карасына кабынып утырды һәм әледән-әле ухылдап, авыр сулап, тамак кырды.

— И-и, Исламетдин күрше, гомер дигәннән, безнең гомер узып бара шул инде, — дип, тагы сүз куертырга тырышып карады Зәмзәмбану карчык. — Дөрес әйтәләр: туй күлмәгеңне теккәндә, кәфенеңне дә хәстәрләп куярга онытма, диләр. Ходай әмер бирсә, әҗәлдән котылып булмый инде ул...

Ислам карт, чынаягын өстәл өстенә шапылдатып куеп, ян тәрәзә аша ишегалдына күз төшерде. Бакча коймасы буенда, күләгәдә, казлар сыенышып яткан иде.

— Бүген бер төш күрдем әле... Ык суында зур бер ак балык йөзеп бара, имеш... Нигә булыр икән бу? Ак булгач, бәхеткәдер инде ул, ә, Исламетдин?..

— Ә миңа бүген төшемә кызыл балык керде...— дип, карылдык тавыш белән аның сүзен бүлде Ислам бабай, сабыры төкәнеп. — Янгын чыгаргамы икән әллә?..

Зәмзәмбану үпкәләгән төстә авызын турсайтты, аннан:

— Һай, оныткванмын да, кечкенә мичемне кабызып кына кергән идем, күмерләнеп беткәндер инде, ходаем, — дип, урыныннан сикереп торды да авыр-юан гәүдәсен көчкә өстерәп, ишеккә таба юнәлде. — Аллаһе тәгаләнең рәхмәте киң, бернинди янгын чыкмас, аллаһы боерса... Нәгыймә, балыкка мин соңрак керермен инде, ярыймы?..

Шулай дип, Зәмзәмбану тутәй күздән югалды.

Ул чыгып китүгә, Ислам бабай карчыгы Нәгыймәгә ябырылды:

— Нишләп йөри монда бу җен карчыгы? Теленә тилчә чыккыры, лыгырдавыннан баш сызлый башлады. Кем хуҗа бу өйдә? Нинди яңа йорт ул тагын? Кем әйтте?

Карчыгы җавап бирмәде, болай да чиста-ак тәлинкәләрне тастымал белән сөртеп ялтыратуында булды.

— Монысы ни дигән сүз тагы! — дип, кинәт өстәлгә сукты Ислам бабай, ачуы кабарып. — Мин сорыйм, ә ул дәшми! Син дә аңлатмагач, Сөләйман патша кабереннән торып аңлатырмы әллә миңа боларны?.. Ярар, бераз миндә дә гаеп бардыр, кичәгенәк арттырыбрак җибәргәнмендер... Теге шайтан суының шаукымы... Каян беләсең, ул агуны мин, бәлки бүтән авызыма да капмам.. Уф-ф!.. Җитмәсә, бу эссесе миләрне кайната... Сулыш алыр хәл юк...

Ислам карт, урыныннан торып, бүлмәне әйләнеп килде, тагын утырды. Нәгыймә, әүвәлгечә бер сүз дәшмичә, аңа яңа чәй ясады. Тик бераздан гына шелтәле-үпкәчән тавыш белән:

— Кичә әйбәт килеп чыкмады шул,— дип куйды.

Карт, авыр сулап, башын түбән иде.

— Шәргыя әйтә, әтиңе гомер кичерәчәгем юк, ул шундый алтын кешене рәнҗетте, ди... кияүне әйтә...

— Минме?! — дип, янә башын күтәрде карт. — Мин аны түгел, ул үзе мине рәнҗетте!!

Мич буенда нидер эшләп маташкан Нәгыймә картының бу сүзләрен җавапсыз калдырды, Ислам бабайның күңеле тагы тынычланган-дай булды.

— Шәргыя миңә шулай диде. Мин аңа аңлаттым, әтиеңнең хасталанып йөргән чагына туры килдегез, мәйтәм. Хаста чагы булмаса, үзенең көймәсен шулай балта белән чапкалар идемени, мәйтәм.

— Мин аны йодрыгым белән сугып ярдым,— дип, мактаныбрак әйтеп куйды карт.

— Барыбер. Аны күптән сумалалап куясы булган сиңа! Көннәр бит әнә нинди — коргаксыгандыр. Соңгы вакытта йортта берни эшләмисең; бакча ишеге сыңар күгәндә асылынып тора; сарай сәндерәсенә менә торган баскыч черегән, яңасы кирәк. Тегү машинасының да ниндидер әйбере ватылган — җепне чуалта; үтүк кызмый; сарыкны суярга вакыт җиткән... чоланда сандыкларны күчереп урнаштырасы бар... Нажия

үзем күчерәм дигән иде дә, мин рөхсәт итмәдем... Аңа авыр күтәрергә ярамый...

Ислам бабай карчыгының бу зарларын караңгы чырай белән, дәшмичә тыңлады. Аннары ул, шулай ук бер сүз әйтмичә, түр өйгә кереп китте, анда улы Рөстәмнең электр бритвасын табып алып, хәсрәтле кара уйларына чумган бер халәттә, кырынырга тотынды.

Түр якта салкынча иде. Алисә, бүгенге уен-шаяруларыннан тәмам арып, шунда идәндә оеп йокыга киткән. Ислам бабай кырынып бетергәч, кызчыкны кулына күтәреп алды да караватына илтеп салды. Кытыршы учы белән аның маңгаеннан сыйпады, куркыныч төшләр күреп саташмасын өчен, өшкергәндәй, як-ягына «тфү, тфү» дип өреп куйды. Аннан яңадан болдырга чыкты.

Һаваның иң кызу чагы иде. Күк йөзе аксылланып, рәшәләнеп тирбәлә. Беркайдан бернинди тереклек авазы ишетелми. Хәтта Буран да, эсселеккә түзә алмыйча, бар нәрсәдән ваз кичкән бер кыяфәттә, аякларын сузып, телен чыгарып, күләгәгә кереп яткан.

Ислам бабай үзалдына мыгырданып куйды:

— Бүген әллә нәрсә артык ялкауландым әле мин. Күптән кузгаласы кеше — юкны бушка аударып һаман йөрим дә йөрим.

Ул абзардан атны алып чыкты, җигә башлады. Ат артыннан берәмберәм бөгәлчәннәр дә очып чыктылар. Озакламый алар кызыл атны бөтен яктан өерләре белән сырып алдылар.

— Син тагы кая җыендың? — дип, тәрәзәдән кычкырды Нәгыймә карчык.

— Кая булсын инде? Иске елга үзәненә. Китапханәгә китап укырга бармыйымдыр, шәт. Китап укып йөрергә түгел, эшләргә кирәк монда. Аңладыңмы шуны тавык миең белән?

Нәгыймә карчык, һәммәсен аңласа да, гадәтенчә, болдырга чыгып, картына юл үгет-нәсихәтләре әйтмичә булдыра алмады:

— Син инде, атасы, карап кына йөр, ярыймы. Атың-ниең белән бергә машина астында кала күрмә. Сакланганны алла саклаган, ди. Болыт-мазар күтәрелсә, шундук кире борыл, яшен сукмасын...

Ислам бабай бер сүз дә дәшмичә арбадагы җәтмәләрне рәтләвендә булды.

— Аннан, кешеләр белән юкка-барга бәйләнешмә, зинһар. Гадәтенне беләм. Соңгы вакытта син артык кызу канлы, бәйләнергә генә торасың. Сүземне тыңла, ярыймы?

Ислам бабай капкадан чыгып киткәнче ул шулай сөйләнүеннән туктамады.

— На-а! Йолдыз кашка!

Карт, зур урамны ябалап, иртән баргандагыча, тыкрык белән иске тимерчелек турысына — ике йөз метрлы биек яр башына чыкты да бәрәңге бакчалары артындагы читән койма буйлатып сузылган тар юлдан авыл очына таба китте; авыл очына җитәрәк, тагы сулга — тыкрыкка борылды һәм, каз көтүе тулы, яшел чирәмле тар урамны аркылыга кисеп, басу капкасына чыкты. Атын туктатты, бераз уйланып, исенә төшереп торды. Кайчандыр монда, авылның шушы очында, күнелгә якын бер кыз яши иде. Исеме ничек иде соң әле шуның?.. Юк, исеме картның хәтерендә сакланып калмаган иде.

Ислам бабай, уйламаганда-көтмәгәндә дигәндәй, атына чыбыркысы белән сыдырды — Йолдыз кашка, сискәнеп, кисәк кенә алга тартылды һәм сөзәк юлдан түбән таба элдертеп алып китте. Ул хәтта сикертеп, дулап чабарга да уйлаган иде, тик, дилбегәнең ныклы кулда икәнен тоеп, башын мәһабәт рәвештә чөеп юыртудан артыгына җөрьәт итмәде. Тиздән алар яшелләнеп торган елга үзәненә төшеп җиттеләр.

«Ә монда елга әле һаман үзенең иске юлыннан ага бирә, — дип уйлап куйды Ислам бабай. — Митькага гел мач килеп тора! Аның елга-

сы әнә үзенең юлын үзгәртмәгән. Әүвәл монда, елга буенда, ничек көймә ясап-тугып яткан булса, ул хәзер дә шул эше белән әвәрә килә. Митька дигәннән, аның ни хәлләре бар икән, күптән күргән юк үзен. Кереп чыгасы микән әллә? Бәлки минем белән бергә иске үзәнгә дә барыр?»

Карт, ел саен сабан туй үткәрелә торган киң мәйдан аша узып, елга яры буендагы муртаеп беткән ялгыз өянке агачлары янәшәсеннән ары таба — колхозның яшелчә бакчасына таба юл тотты. Бер башы белән елга ярына терәлеп торган һәм тәбәнәк тал-читән белән әйләндереп алынган бакчаның түрге башында каралты-кура караеп күренә иде.

Ислам бабай атын туктатты да, арбадан төшеп, читән аша гына эчкә атлап керде.

— Әй, Митька! Син кайда?

Аңа җавап бирүче булмады.

Эш кораллары саклана торган сарайның ишегендә — йозак; шулай ук Дмитрий Ивановичның даими эш урыны булган лапас астында да җан иясе барлыгы сизелми иде. Тик җир өстендә тупыл бүрәнәләр, кабыгы салдырылган юан юкә агачы аунап ята. Янәшәдә зур бер өем кирпеч; ә елга ярына таба ике рәт булып ярым сүнек учаклар тезелеп киткән: алар арасында материал пешекләнә... Шунда ук таш өстендә су җылыту өчен ике тимер мичкә куелган; хәзергә алар буш, шуна күрә алардан кайнар һава бөркелеп тора иде. Кыскасы, монда көймә ясау өчен кирәк булган бөтен нәрсә бар.

Болардан бер читтә кәкре борынлы, ян-яклары алсу төскә буялган озынча бер көймә йөзтүбән капланган. Митьканың әйтүенчә, мондый көймә каек дип атала, имеш; борынгы заманнарда кешеләр шундый каекларда йөзгәннәр, ди.

Заманында Митька Ыкта йөзәрлек кечкенә генә җилкәнле кораб ясарга да хыялланып йөргән иде. Хәзергә кадәр ясый алганы юк әле шуны. Вакыт тими, ди. Аннан, яхшы, яраклы агач табуы читен, ди; агачка үсәргә, нығырга ирек бирмиләр, яшьли кисеп харап итәләр, ди. Кирәкле агачны урманлы яклардан — Кама буйларыннан алып кайтсаң гына инде, ди...

— Митька! — дип, тагы эндәште карт; җавап булмагач, арбасына чыгып утырды да атны сулга, янәдән авылга таба борды. Бәлки Митька үзенең өендә утырадыр?

Авылның бу очында тоташ иске йортлар иде. Югары Бикташ белән чагыштырганда, монда яшелгә буялган калай түбәләр әллә нигә бер генә очрый, шулай ук радио тавышы да ишетелми, дуңгызлар исә бөтенләй юк иде... Әйтергә яраса, монда «чын мөселман» татарлары яши иде. Һәм шулар арасында әүвәл-әүвәлдән бер рус кешесе — озын, чандыр гәүдәле, башына, татар карты сыман, кара түбәтәй киеп йөргән Дмитрий Иванович Филиппов та гомер кичерә иде.

Дмитрий Ивановичның йорты, иске булса да, тышкы кыяфәте белән һәркемнең игътибарын җәлеп итәрлек: такта түбәнең урамга караган кыегы һәм кәрнизе, тәрәзә йөзлекләре ярым айга охшаш дулкынлы-дулкынлы бизәкләр белән челтәрләп эшләнгән; урыс капканың баганасына кугәргән дага кадакланган, ә өй почмагына беркетелгән тактада багор, балта һәм чиләк рәсемнәре ясалган иде.

— Митька! Бу мин — Ислам. Ник син җавап бирмисең? — дип янә кычкырды карт.

Филиппов колакка катырак кеше иде, шуңа күрә Ислам бабай, ниһаять, аны дәшеп чакырмыйча, туп-туры өенә барып керергә дигән карарга килде. «Йоклап ята торгандыр... — дип уйлады ул, атын читән казыгына бәйләп. — Эссе бит, хәле бетеп, кулмәксез-нисез идәнгә сузылып яткандыр да йокыга киткәндер... Урыс кешесенә нәрсә аңа, ястык кирәкмени!..»

Дмитрий Иванович Бикташтан сигез километр югарыда Ык буенда урнашкан Беляевка дигән рус авылында туып-үскән кеше иде. Ислам бабайдан бер ун яшькә кечерәк булып, ул утыз яшьләрендә сугышка киткән, шунда хәбәрсез югалып, туган авылында үлүчеләр исемлегендә йөргән, тик сугыш беткәч кенә күкрәгенә медальләр тагып һәм контузияләнеп өенә кайткан иде. Ул сугышта йөргән чагында аның хатыны бүтән кешегә кияүгә чыккан иде. Ләкин бу хәл Дмитрий Ивановичны артык пошындырмады; ул, бернинди гауга-мазар кузгатмыйча, барлыюклы әйберләрен биштәр капчыгына тутырып аркасына асты да күрше татар авылына — Бикташка юл тотты, шунда эшкә урнашып, озакламый Гөлчирә исемле бер тол хатынга йортка керде. Ислам бабай бик яхшы хәтерли әле — ходайның һәр бирмеш көненә шатланып яшәүче күндәм холыклы, тыйнак-сабыр бер хатын иде ул. Митька белән алар унике еллап тату гына гомер кичерделәр, аннан Гөлчирә, төзәлгесез авырудан әкрен генә сүнеп, дөнья куйды... Балалары булмады. Шул вакыттан бирле, менә унбиш еллап инде, Дмитрий Иванович ялгыз башы яшәп ята, өйдәге барлык эшләрне үзе башкара; тик ара-тирә генә Беляевкадан житкән кызы — озын буйлы, сары чәчле Настя килеп, аның кием ямау, кер, идән юу кебек эшләрен эшләп киткәли иде...

Ислам бабай, Дмитрий Ивановичның гыйбрәтле тормышы турында уйлый-уйлый әкрен генә ишегалды буйлап атлады. Бик сагынган иде ул аны. Ичмасам, иркенләп бер сөйләшеп күңелләрен бушатырлар иде. Ислам бабай аңа көймәсе белән булган хәлне аңлатып бирер, шулай сөйләшә-сөйләшә үзен бераз кызгандырып алыр иде. Ни әйтсәң дә, Дмитрий Ивановичның үз кулы белән ясалган көймә иде бит ул.

...Ислам бабай ишеккә килде һәм дөбердәтергә тотынды:

— Һей, Митька, син өйдәме?

Ләкин шул чак аның күзе ишек келәсенә төште: келә тишегенә тавык тәпие кыстырып куелган иде...

Кая олаккан соң бу Митька? Менә гөнаһ шомлыгы!

## 7

Ислам бабайның тәмам күңеле сүрелде. Ул, урамга чыгып, атны бәйдән чиште, дилбегәне тартып, арбаны бик текә рәвештә юлга таба борды.

— Н-на! Н-на!..

Ислам бабай Югары урамны кисеп узды. Югары урам — авылның иң котсыз, агачсыз урамнарыннан берсе. Анда күләгәле урын таба алмыйча аптыравың бар. Һавасы шундый коры, бер очкын төшсә, бөтен урамын-ниең белән янып бетәсене көт тә тор. Шуңа күрә монда көндезләрен бөтенләй мич якмыйлар иде диярлек.

Күзне камаштырып, юл кырыенда ак казлар чүмәшеп калды.

Аннан юл бәрәңге бакчалары арасына барып керде, борынга тузан катыш бәрәңге сабагы, көнбагыш исе килеп бәрелде. Ниһаять, алда авылның төньяк басу капкасы күренде.

— Һей, малайлар! Капканы ачыгыз! — дип кычкырды Ислам бабай.

Ләкин якын тирәдә бернинди ялан тәпи күренмәде. Карт арбадан төште, капканы үзе ачып, үзе япты. Капканың кызган чылбыры аның учын тәмам өтеп алгандай итте.

— Туктале, шундый ук хәл кайчан булган иде соң? — дип үзалдына мыгырданды карт. — Әйе, Бохарада бугай? Көндезге челләдә сакта торганда мылтык тимеренә яңагымны куеп йокыга киткәнмен дә битемне пешергәнмен... Әйе, әйе, битемне шулай пешергән идем...

Ул корыч чылбырга янә кулы белән орынды һәм, йөзен чытып, елмаеп куйды.

«Их, Митька, Митька! Тәки күреп булмады үзеңне!»

...Күгелҗем күк йөзе буйлап утлы шар тәгәри. Аның кызуы шул кадәргә җиткән ки, әйтерсең ул күк гөмбәзеннән көнбатышка таба түгел, бәлки, кирегә борылып, янә югарыга таба үрмәли иде.

Кояш артыннан исә, аның кайнар эзенә басып, җигүле арба бара. Арбада — бер өем җәтмә, җәтмә өстендә — сумалалы борынына чуар күбәләк ябышкан иске көймә, көймә кырыенда, аякларын түбән салындырып, Ислам бабай үзе утырган. Юл өстендә үскән һәм кояшта көеп-саргаеп беткән чүп үләне, әрем сабаклары аның аякларына ышкыла — күн итек башлары тәмам аксылланып калган иде.

«Миңа нишләргә икәнен белсә шул, бәлки Сөләйман патша гына белә алыр иде,— дип уйланды Ислам бабай.— Бик озын гомер юлы үтелгән шул, һәммәсен аңлап бетерүе дә кыен. Узган гомер — биек тау шикелле, түбәсендә басып торган җиреңнән аска карасаң, бөтен нәрсә бәләкәй булып күренә. Өйләре дә кеп-кечтеки, сарыклары, кешеләре дә... Саксыз кыланып, таш кыйпылчыгына орынсаң, тау өстендәге бөтен вак-эре кантарлар берьюлы шыбырдашып түбән тәгәрәрләр дә астагы кешеләргә зыян китерерләр төсле... Акылы камил булып житмәгән карт кешегә яшәү бик авыр. Митька — минем белән чагыштырганда, яшь, хыялый бер егет. Алтмыш яшь — яшьмени ул? Ә менә Арслан абый — ул ичмасам туксан яшьтәге кеше. Ул яшәүнең бөтен кадерен, серен белә булыр...»

Умарталыкка юл кояшта кызган, тузанлы калкулыклар өстеннән бормаланып бара, һәм монда, сугыш кырындагыча, арба артыннан тау-тау кара тузан болыты күтәрелә иде.

Арыш басуына кергәч, Ислам бабай атын туктатты да, арбадан төшеп, аркылы-торкылы ярыклар сызып үткән җир өстенә чүгәләде.

— Бичаралар...— диде ул, яшькелт-сары сабаклы, тәбәнәк-зәгыйфь арышларның башларыннан сыйпап.— Ничек кенә түзәсез икән, бәгырьләрем! Күзләрегез булса, сез яшь агызып җылар идегез! Авызыгыз булса, сөрән салып кычкырыр идегез! Ләкин сез бөтен хәсрәт-кайгыны эчегезгә йоткансыз. Мин, карт кеше, сезнең бу мөшкел хәлегезне яхшы аңлыйм, бичаракайларым!..

Арба сукаланып каткан коры, сикәлтәле юлга борылды. Болай да нык арыган бил сөякләре, башы сызлап торган Ислам бабай түзмәде, арбадан төшеп, җәяү генә китте. Бераздан ул борынын тартып сулыш алды һәм, кинәт авызы эчендә тозлы бер тәм тоеп, учы белән иреннәрен сыпырды. Учка кан ягылып калган иде.

— Аһ, шайтан! Шул гына җитмәгән иде!..— дип сукранып куйды ул.

Ислам бабай, күләгәрәк урынга китеп, башын артка ташлады, шул рәвештә минут чамасы кымшанмыйча басып торды. Ләкин канның туктарга исәбе юк иде. Шуннан, иелеп, мышный-мышный, кычыткан яфрагы өзәргә кереште; җитәрлек кадәр җыйгач, аны полиэтилен капчыкка салып, арба тактасында суы чыкканчы бик һәйбәтләп изде дә, чеметемләп, сусыл, зәһәр яшел кычыткан йомшагын борын тишекләренә тыгызлап тутырды. Ярдәме тиде шикелле — кан агудан туктады. «Бүген каян да булса балан табып ашарга кирәк булыр, ахрысы»,— дип уйлап алды ул.

Исәпсез-хисапсыз бөгәлчән, кигәвен өере озатуында ул, ниһаять, урман аланына килеп керде. Монда инде аны колакка ятыш, саф авазлы эшчән бөҗәкләр — бал кортлары каршы алды.

Умарталар күл буена, ачык җиргә тезеп куелганнар, ә Арслан картның үз өе урман күләгәсендә, салкын сулы чишмә ярында урнашкан иде.

Ислам бабай Йолдыз кашканы күләгәле урынга кертеп туктатты да, үзе чишмә янына ашыкты. Куш учы белән боздай салкын, саф суны чумырып алып, авызына якын китерде, күзләрен йомды һәм эчеп җибәрде. Тагын чумырып алып эчте, тагын, тагын. Маңгай сөяген бер мизгелгә генә нидер кысып, авырттырып куйгандай булды.

Чишмә артык тирән булмаган чокыр эченнән, ак һәм чуар төстәге ташлар арасыннан тибеп чыга иде. Монда кояш нуры үтми, шулай булса да чишмәнең зур көмеш табакка мөлдерәмә тутырылгандай түгәрәк өсте карасуланып ялтырап тора һәм, кемдер әлеге табакны астан бармагы белән төбенә бәреп селкеткәндәй, сизелер-сизелмәс кенә дулкынланып тирбәлә иде.

Ислам бабай, чишмә ярында буш чиләк табып, Йолдыз кашкага да эчәргә күлдән җылы су алып килде. Аннары, өс-башын каккалап, өйгә таба китте, күн итекләрен салды да болдырга күтәрелде.

— Исәнмесез-з! — дип эндәште ул, ишеккә эленгән марля пәрдәне бер якка этәреп.— Өйдә кеше бармы?

Өйалдына ялан аяктан гына Вахит — Арслан картның илле яшьләр чамасындагы сыңар күзле улы ашыгып чыкты.

— У-у, Ислам бабай! Әйдүк, хуш киләсең, уз әйдә! — диде ул, аннары түргә таба башын борып, кычкырыбрак әйтте: — Әти, кунак килде, Ислам бабай!

Балыкчы карт сүзсез генә эчкә узды. Зур бүлмәнең бер почмагында, идәнгә җәеп салынган түшәк өстендә, мамык юрганга төренеп, Арслан карт ята иде.

Ислам бабай аңа кыюсыз гына:

— Арслан абый... бу мин әле, Ислам,— дип эндәште.

Арслан картның күзләренә ак төшкән, ул бөтенләй диярлек күрми иде. Кәҗә сакалы өзлексез калтырап, дерелдәп тора. Беләүләнеп беткән кара түбәтәе, яшел чикләвек кәшәнкәседәй, такыр баш түбәсенә тәмам ябышып каткан кебек күренә иде.

— Бу мин, Ислам! Әхмәт Исламы!

— Ә-ә... Исламетдин...— Арслан картның бит мускуллары дерелдәп куйды.— Мин сине күрәм...

Шулай дип, ул кулы белән һаваны капшагандай итте. Ислам бабай, калтыранган күз кабакларын йомып, битен хуҗага таба суза төште, һәм тегесе ак бармаклары белән аны яңагыннан сыйпады.

— Әйе, таныйм... Сиңа күпме яшь хәзер?

— Җитмеш өч.

— Һм... Мине куа киләсең алайса. Нигә болай — сакалсыз йөрисең?

— Ни дим... үстереп булмады инде,— дип акланды балыкчы карт, уңайсызланып.

— Ярар, үстерерсең әле, вакыт бар... Әйдә, утыр, чәй эчәрбез.

— Рәхмәт.

Сыңар күзле Вахит кече якта шалтор-шолтыр самавар кабызып өлдереп маташкан арада, Арслан карт белән Ислам бабай, бер-берeнә йөзләрен текәп, дәшми генә, елмаешып утырдылар. «Таныды! Исенә төшерде! — дип шатланып уйлады Ислам бабай, хуҗаның чак кына нур чагылган сукыр күзләренә карап.— Ә ник исенә төшермәсен ди? Кайчандыр ул мине зур бәладән коткарып калган иде бит!»

Бик күптән, бала чагында ук, авыл тегермәнчесенең таза, юан ике малае, шаярышып, үзен ничек суга батыруларын Ислам бабай гомере буе хәтерендә саклый иде. Ыкның урта, тирән җирендә алар өчәүләп су коеналар иде. Шул вакыт тегермәнче малайлары, алмаш-тилмәш, аны суга батырып уйный башладылар. Кечкенә Ислам, алардан ничек котылырга белмичә, су астына чума да, аяк-куллары белән бөтен көченә ишеп, читкә тайпыла, аннан, тыны бетеп, өскә атылып чыга. Ләкин ул авызын ачып сулыш алырга да өлгерми, тегеләрнең әле

берсе, әле икенчесе учы белән башка басып, аны янәдән төпкә батыра. Бу «уен» күпме баргандыр, әмма Исламга ул коточкыч озак булып тоелды. Әйтерсең су өстендә меңләгән кул аның калкып чыгуын сагалап кына тора; малайларның шаркылдашып көлүләреннән колак шаулый, күз алдында әллә нинди утлы бөҗралар әйләнә. Ичмасам, кычкырырга, ярдәм сорарга да һич мөмкинлек юк: өскә калкып, кояш яктысын күреп өлгергәнче, тагы шул мәрхәмәтсез кул башка китереп бәрә. Ислам тәмам хәлдән тайды. Читкә тайпылырга аның инде бөтенләй көче юк, ул әллә никадәр су йоткан, тончыгып укшый һәм аңын югалта башлаган иде. Бер мизгелгә су өстенә калыкканда күзгә чалынып калган күпер шәүләсе, күктәге болыт кантарлары һәм янәшәсендә шаркылдашып үкерешкән коточкыч тегермәнче малайлары аңа инде ниндидер чит-ят дөнья күренешләре сыман тоела иде...

Шул чак кинәт ул үзенең әйләнәсендә ниндидер ыгы-зыгы сизде. Ул да булмады, кемдер аның кулыннан тотты:

— Йөзәрлек хәлең бармы? Әйдә минем арттан.

Тавыш таныш түгел иде. Ислам, буйсынып, кул-аякларын көчкә кыймылдатып, төштәгедәй аңлы-миңле бер халәттә, әлеге кеше артыннан әкрен генә йөзеп китте. Бераздан тезләре төпкә тиде, сайга чыгуын чамалап, аягүрә торып басты. Ул дер-дер калтырый, хәлсез аяклары сыгылып-сыгылып китә иде. Ярга чыгып җитүгә үк ул ком өстенә ауды. Аны укшыта иде. Аннан ул, елашып кычкырган тавышлар ишетеп, елгага таба борылып карады.

Анда, тез тиңентен суда, озын, зифа буйлы, таза бер егет — Арслан абыйсы басып тора иде. Ул тегермәнче малайларының берсен колагыннан эләктергән, икенчесенең кулын арка якка каерып тоткан. Авыртудан тегеләр үкерешеп кычкыралар:

— Ай, алла! Ай, алла! Абый, абыкаем...— дип ялваралар иде.

— Ник сез кечкенәләрне рәнҗетәсез! Менә сезгә шуның өчен! — дип, колакларын боргычлады аларның Арслан.

Тегермәнче малайлары, күз, борыннарын сөртә-сөртә шыңшып, яр буеннан авылга таба менеп киткәч, Арслан абыйсы Исламга әйтте:

— Курыкма. Тагын тия калсалар, үземә генә әйт. Кызлар күлмәге кигезеп хур итәрбез үзләрен. Ә вакыты җиткәч, ул тегермәнче байларны, мулла-мунтагайлары белән бергә, баганага асып куярбыз! Малайлары, кызларына да эләмәк кидерербез! — диде.

— Ничек инде алай?! — дип, куркып сорады Ислам.

Арслан, муены тирәли бармагын әйләндереп:

— Менә шулай! — дип өстәп куйды.

Революция елларында Арслан авылның зур кешесенә әверелде. Ул кесәсендә наган һәм печать йөртә иде. Авыл байлары берничә тапкыр аның йортына, мунчасына ут төрттеләр, хәтта үзенә дә һөҗүм итеп карадылар. Ләкин ул барлык хәтәр хәлләрдән исән-имин чыкты, кыенлыклар татып булса да, авылда совет власте урнаштыру эшенә үзеннән зур өлеш кертте...

— Сине күрмәгәнгә йөз ел булгандыр инде, Арслан абый,— дип, шаярту катыш ихтирам белән әйтеп куйды Ислам бабай.

— Әйе, күптәннән бирле күренмисең. Әйдә чәй эч. Бик кызу. Кызуда чәй эчәргә кирәк.

Вахит табынга ак фарфор кружка белән гәрәбәдәй сары яңа бал кертеп куйды.

— Менә бал белән эчегез...

— Рәхмәт.

Чәйне озаклап, тәмләп эчтеләр. Ислам бабай шыбыр тиргә батты, әмма күңеле күтәренке иде.

— Гомер бара, Арслан абый... Тегермәнче малайларын колакларыннан боргычлаганың әле кичә генә булган төсле, ә уйласаң, күпме

вакыт узып киткән,— диде Ислам бабай, малай чагындагы теге вакыйганы исенә төшереп.

Арслан картның уйчан йөзе берьюлы нурланып китте.

— Әйе, әйе! Соңыннан без ул тегермәнчене Себергә сөрдек. Ә малайлары... берсе чехлар белән качкан иде бугай, шуннан кайтмады. Атып үтергәннәрдер, күрәсең! Ә икенчесе... ахырда галим кеше булган дип сөйләделәр... Дөньяда нинди генә хәлләр юк, исең-акылың китәр...

Бер мәл тынып тордылар. Аннан:

— Әйе-е,— дип сузды Арслан карт, күрәсең, бөтенләй бүтән нәрсә турында уйлап; аннан өстәп куйды: — Янгырны әйтәм, һаман яумый, син бу хакта ни уйлыйсың, Исламетдин?..

— Игеннәр көя...— дип килеште Ислам бабай.— Син минә миннән озаграк яшәгән кеше, син шундый корылыкны үз гомереңдә хәтерлисеңме соң, Арслан абый? Шундый янгырсыз җәйнең синең гомердә булганы бармы диюем?

— Юк, мондый эссе җәйне мин хәтерләмим,— диде Арслан карт, ярым сукыр күзләрен челт-мелт йомып.

Ислам бабай беравык дәшми утырды, аннары, ниһаять, үзен борчыган төп мәсьәлә турында сүз башларга җөрьәт итте.

— Арслан абый, минем синең белән кайбер нәрсәләр хакында киңәш-табыш итәсем килгән иде,— диде ул.— Үз гомеремдә мин дә күпне күрдем. Тормышның ачысын да, шатлыгын да татыдым дигәндәй. Инде тәмам арылды. Чәчнең карасы, уңып, йөрәккә сауды. Шулай да минем әле үләсем килми, дөньядагы хәлләрне күреп, аңлап яшисем килә. Чөнки мин үз-үземне түгел, бүтәннәрне яратам.

Арслан аны тын гына тыңлады. Ара-тирә ул, чәчәкле юрган өстенә сузып салган ап-ак кулын кыймылдатып, бармаклары тирәсендә безелдәп очкан кигәвенне куып җибәрә иде.

Ислам бабай сүзне бик ерактан башлады. Төркестанның ком барханнарын, чүл бүреләре хакимлек иткән әремле далаларын, арчын урманнарын телгә алып узды, кан дошманы, басмачылар атаманы имам Дофар белән очрашуын, аның, ничек сукыр карт кыяфәтенә кереп, хикмәтле бер әкият сөйләвен әйтте, әкиятнең үзен дә тәфсилләп сөйләп бирде.

Аксакал дәшмәде. Ул ни дип әйтергә дә белми иде.

Кайчандыр юлында очраган дошман турында баш ватуның хәзер нигә кирәге бар? Дошман дошман инде ул, стенага терә дә ат та үтер — һич ялгышмассың!

— Башына ул чалма ураган идеме? Мин аны кинода күрдем,— дип куйды сыңар күзле Вахит.

Ислам бабай ризасыз төстә йөзен чытты.

«Яшь башы белән нәрсә картлар сүзенә тыгыла әле бу? Синең фикерне түгел, Арслан абыйның — революция арысланының фикерен ишетәсем килә минем!»

Күңеленнән генә шулай уйлап, Ислам бабай үзенең егерме дүртенче елда, басмачылар сугышыннан туган якларга кайткач, Минзәлә урамында Арслан белән истәлекле очрашуын күз алдына китерде.

Арслан ул чакта озын буйлы, таза, кырык яшьләрдәге мәһабәт бер кеше иде. Өстендә акка зәңгәр буй төшкән матрос күлмәге һәм изүе ачык күн куртка. Бүлтәеп һәм бераз ачылып торган иреннәре арасыннан җете ак тигез тешләре елтырап күренә. Гомумән, елмайганда да, кеше сүзен тыңлаганда яки берәр нәрсәгә игътибар белән караганда да ул шулай, тешләрен каты кысып, иреннәрен бүлтәйтә иде. Гүя, шул кысык тешләре арасыннан, матросларча «шик» белән, бер төкереп җибәрер кебек. Мөмкин булса ул хәтта тешләрен шытырдатып кыскан килеш сөйләшергә дә теләр иде шикелле.

— Әхмәтев! — диде ул. Исламны шундук танып алып.— Кереп чык әле, сөйләшик!

Шушы очрашуга хәтле берничә көн элек кенә Арсланның үз карамагындагы ике иптәшне атып үтертүе хакында Исламга хәбәр ирештергәннәр иде инде. Эш болай: Арслан әлеге ике иптәш дигәннән берсенең, хыянәт юлына басып, Суыксудагы иң әйбәт сигез комсомолецны кулаклар тозагына эләктертеп һәлак иттерүен белеп ала да, тагаен кайсысы сатлык җан булуын тикшереп-нитеп тормыйча, икесен дә үлемгә дучар итә.

Ислам бабайның әле дә хәтерендә, алар Арслан белән икәү аның эш бүлмәсендә сөйләшеп утырганда, кинәт ишек ачылды да, ничектер сәер рәвештә яны белән атлабрак, башына кара шәл ябынган яшь бер хатын килеп керде. Керде дә, түргә узып, стена буендагы зур асылма көзге астына барып сөялде. Аннары, өзек-өзек сулыш алып, ишетелеришетелмәс тавыш белән, әкрен генә болай диде:

— Иптәш Касыймов, мин беләм, сез минем иремнең хыянәтче булуына тәмам ышанмадыгыз... Минем инде җылап яшем кипте... Тик сездән сорыйсым килә: балаларга мин ни дип әйтим? Әтиләре дошман кеше иде дипме? Әллә чын, намуслы кеше дипме? Балаларның үсәсе бар бит әле,'Касыймов иптәш...

Хатын сөйләгәндә күз төпләрен сыпырып-сыпырып ала иде. Кинәт бу бүлмәгә ни өчен элеп куелганлыгы да билгесез әлеге зур, куе сары төстәге агач рамлы һәм яшькелт таплар төшеп чуарланган борынгы, авыр көзге хатын артында дәррәү чайкалып куйды. «Ава бит! — дип йөрәге кысылды Исламның. — Авырлыгы өч-дүрт пот бардыр, өстенә килеп төшсә, измәңне изәр...»

— Үсеп җиткәч, балаларыма мин ни дип аңлатырмын, әйтегез? — дип, янә кабатлап сорады хатын.

Арслан, гадәтенчә тешләрен кысып, хатынның йөзенә төбәлеп карады.

— Борчылуыгызны аңлыйм, бик нигезле борчылу, — диде ул, ниһаять, бөтенләй бүтән нәрсә хакында уйлагандай бер тавыш белән. — Балалар безнең кеше булып үсәргә тиешләр. Димәк, әтиләре турында да алар яхшы уйларга тиеш.

— Каюмовның балалары да шулай уйларга тиешме? — дип сорады хатын, чак кына көлемсерәп.

— Әйе, анысылар да! Ил өчен шулай файдалы. Әтиләре хыянәтче булганга балалар гаепле түгел! Балаларның һәркайсы кызыл сугышчы булып үссен. Моңардан революция отачак кына!

— Хыянәтче дип, гаепләнне дә, гаепсезне дә атып үтерү — бу да шулай ук файдалымы?

Стенадагы көзге янә тавыш белән чайкалып куйды. Хатын, куркудан читкә тайпылып, артына борылып карады һәм, ирекле-ирексез дигәндәй, көзге пыяласында үзенең кайгылы, сулган йөзен күрде.

— Өйрәнгәнсез кешене гел стенага каратып бастырырга! Өйрәнгәнсез! — дип кычкырып җибәрде ул, хурлыгыннан нишләргә белмичә, аннары: — Уй, уй... — дип үзалдына мыгырдана-мыгырдана, тизрәк ишеккә ташланды.

— Хатын-кыз шул, нишләмәк кирәк... — диде Арслан, артык исе китмичә.— Көзгедән үзен күрде дә оялып калды... Зарарсыз. Тагы кияүгә чыгар әле. Әйдә чыксын. Яңадан балалар тапсын. Аларның иң зур хезмәте — шунда.

Ислам үзен Арслан каршында әле һаман малай итеп сизә һәм шуңа күрә аңардан бик ятсына иде. Шулай да ул сорамыйча булдыра алмады:

— Аларның икесен дә шулай... хыянәтче итеп аттыгызмы?

— Әйе.

— Ә балалары... икесен дә хыянәтче булмаган дип санарга тиеш, дөрес әйтәмме?

— Дөрес әйтәсең. Хикмәт моментның файдалылыгында, энекәш. Моңардан ике файда күздә тотыла! Аттык, чөнки монысы бүгенге момент өчен кирәк иде. Инде, әйтик, балалары, этиләренең яхшы сугышчы булганлыгына ышанып, дөрес тәрбиядә үсә икән — бусы киләчәк өчен файдалы. Шундый арифметика, энекәш! Шактый четерекле арифметика диюем!

Бу вакытларда Ислам инде малай түгел, ә Сивашларны кичкән, басмачылар белән сугышып кайткан тәҗрибәле, курку белмәс егет кеше иде... Шулай да Арслан абыйсының әлеге төгәл-сабыр арифметикасыннан аның йөрәгенә нииндидер коточкыч бер шом йөгерде.

— Балалар аталары өчен гаепле түгел,— дип кабатлады Арслан.— Без гадел булырга, бөтен нәрсәгә чын хуҗаларча карарга тиешбез.

Шулай дип ул, ак тешләрен елтыратып, елмаеп куйды. Һәм Исламның күңелендә аңа карата янә соклану хисе уянды. Шуннан ул, дәртләнеп, сугыш кырларында үзе дөмектергән дошманнарны санап-тәфсилләп сөйләргә кереште. Инде, сөйләп бетереп, Арслан аны:

— Судан тартып чыгаруым юкка булмаган икән. Минем тирәдәрәк булырга тырыш...— ди-ди, тимердәй каты куллары белән кочаклап та алгач, Исламның тәмам шатлыгы эченә сыймады.

Ләкин аңа сугыш сукмагын дәвам итәргә туры килмәде, ул балыкчы көймәсенә күчеп утырды. Арслан белән тиңләшерлек түгел иде шул аның көче...

— Әйе-е...— дип сузды Ислам бабай, башын иеп.— Мин синнән тагы нәрсәдер сорамакчы идем. Әйе, кичәгенәк минә яңа көймәмне ваттым. Мурзин аркасында. Мурзинны ишетә беләсеңдер? Миңа кияү тиеш кеше ул. Мин аның белән бик каты ачуланыштым. Ни өчен икәнен сөйлимме?

Һәм Ислам бабай, бер көн эчендә кырыгынчы кат дигәндәй, тагы үзенең Минзәләгә кунакка баруы һәм кичәге хәлләр турында пошына-пошына сөйләп чыкты.

— Мурзин бик яман кеше,— диде ул, нәтиҗә ясап.

Арслан дәшми генә ятуында булды.

— Син әйтәсең, Мурзин корт чакканга ачуланды дисең,— диде Вахит, сүзгә катышып.— Ә минә мине шулай ук корт чакмый.

«Моны ничек аңларга икән? — дип уйлады Ислам бабай, кашын җыерып.— Ярар, соңыннан уйлармын әле...»

Шул чак бүлмәгә кара-чутыр бер малай атылып керде.

— Исәнмесез! — дип сәлам бирде ул һәм олы кешеләрчә бик житди кыяфәттә сүзен дәвам иттерде.— Тышта эсседән түзәрлек түгел. Иген көя. Яңгыр юк. Әти, мин авылга кайтам, анда бүген кино була.

Ислам бабайның күңел төбендә нииндидер томанлы бер теләк кыймылдап куйды. Аннан бу теләк, ачыклана барып, катгый бер карар рәвешенә килде.

— Карале, малай, син... утын яра беләсеңме?

— Әлбәттә!

— Алайса, авылга кайткач, безгә кер дә, Нәгыймә әбиеңә әйт: мине Ислам бабай җибәрде, диген. Балта сора. Аннан... утын яр. Ишегалдында... бер ярык көймә ята... Менә шушындый чыраларга ярып бетер үзен! Эшләрсеңме шуны? Мин кайтышка эзе дә булмасын! Моның өчен мин сиңа балык бирермен, ярыймы?

— Нәрсәгә балык! Болай да эшләр! — диде Вахит.— Бар, йөгер, үтә Ислам бабаң кушканны! Бер аягың монда, икенчесе анда булсын! Ә балыкны... ярар инде алайса... бирсәң бирерсең, Ислам бабай.

Күптән җүнле балык ашаган юк. Ничә күзле була икәнен дә оныткан-мын инде.

Малай, вак акчаларын чылтырата-чылтырата, ишектән чыгып йөгерде.

Арслан карт, түшәге өстенә ярым яткан килеш, аксыл бәбәкләрен бер ноктага төбәгән дә, ниндидер үз уйларына баткан иде.

— Рәхмәт, сине сау-сәламәт күреп бик шатландым, Арслан абый.

Шулай дип, Ислам бабай урыныннан торды һәм, Арслан үзе нәрсә әйтер икән дигән сыман, аның каршында таптанып басып тора башлады

— Ярый, хуш, сау бул, Исламетдин...— диде, ниһаять, Арслан карт, йөзенә зәгыйфь елмаю чыгарып.— Булган эшкә салават! Ә син үткәнне үзеңдә саклап йөртәсең икән. Болай булса, озакка бара алмассың син, егет.

— Үткәнне ничек онытмак кирәк? Болай да инде күп нәрсәне онытабыз. Әле биш елны, әле ун елны күңелдән сызып ташлыйбыз дигәндәй...

— Аның каравы, яшьрәк булырсың.

Картлар, бер-береннең күңел уйларын аңлап, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән кеткелдәшеп куйдылар, ә табын өстенә соргылт төстәге йомшак сөлге каплаштырып маташкан Вахит исә, картларга карап, бөтен өйне шаулатып көлеп җибәрде.

## 9

— На-а, Йолдызкай! Кызула! Юкса, барып та җитә алмабыз!..

Ислам бабай, янә яшькелт калкулыклар өстенә күтәрелеп, тәгәрмәч астыннан тузан болытлары очыра-очыра, үзенең юлын дәвам иттерде. Кояш инде көнбатышка таба шактый авышкан, ләкин кызуы әүвәлгедән һич тә ким түгел иде. Һәрхәлдә, кояш чыгуга, картның йөрәге берьюлы кысылып, шәрә бит-куллары чеметтереп авырта башлады.

— Әй, кемгә әйтәм! Тоякларыңда пичәт юктыр бит, нәрсә башыңны шул кадәр түбән бөгеп, аяк астыңа пошкырып барасың? Әйдә, кызула дим!

Ислам бабай шактый нык селтәнеп дилбегәне какты — ачык җирне тизрәк узып китәсе килә иде аның. Айгыр, ризасыз төстә әле сул, әле уң күзе белән артка караштыргалап, сикертеп юыртуга күчте.

Ерактагы бәрәңге басуында кеше шәүләләре күренә иде. Өя башлаганнар, димәк. Анысы да ярый. Ичмасам, йомшартылган туфрак төннәрен беркадәр дым тартыр... Ә Кол-морза артындагы басуда борчакка төшкән булырга тиешләр. Анда, мөгаен, Мәскәүгә кадәр дигәндәй тузан болыты асылынып торадыр.

«Миңа да эшкә тотынырга вакыт, бик вакыт! Бүген көне буе авызда сүз боткасы әвәләп, ял итеп йөрим. Әүвәл андый хәл булмый торган иде. Шулай да, Митька әйтмешли, борын салындырырга кирәкми. Борын белән җир сөреп чәчәрдәй орлыкның дөньяда булганы юк әле! Хәзер һәркемгә кыен. Илдарга да, Нәҗиягә дә. Митьканы инде әйтәсе дә юк — Гөлчирәсен, туган авылын сагынып тәмам пошаманга калган, картлач... Ә миңа хәзер бөтенләй кыен түгел дияргә мөмкин. Мин фәкать үз әйләнә-тирәмдә барган хәлләрне генә төшенергә телим. Мин, күрәсең, озакламый үләрмен — минем белән алар арасындагы аерма тик шунда гына. Һай, һәммәсе шул каһәр суккан көймәдән башланды. Инде менә үзе дә бетте — телгәләп яргач, ул хәзер утта чытыр-чытыр очкыннар чәчрәтеп яначак... Әйе, мин чынлап та картайганмындыр, күрәсең. Әнә Арслан абыйны гына кара. Туксан

яшенә житкән кеше миңа нәрсә киңәш итә алсын? Ул тагы да биегрәк тау түбәсендә тора, саксыз кыймылдаудан миңа караганда да күбрәк курка, юкса, түбәнгә ташлар тәгәрәве ихтимал! Әллә алай түгелме, ул басып торган тауның итәгендә инде ташлар да калмаганмы? Әйе, ул үз гомер юлын шөбһәләнмичә, жиргә шаулатып басып үткән, ак тешләрен күрсәтеп елмая-елмая, туктаусыз үргә күтәрелгән. Ул үз аягы астында кайчандыр изелеп, тапталып калган дошманны кызганып хәтеренә төшерәме соң?! Юк, әлбәттә. Тауга менешли, ул ташларны дәрьясы-дәрьясы белән түбән тәгәрәткәндер. Инде менә тау түбәсендә сыңар күзле улы Вахит белән бер ялгызы торып калган. Бәлки ул хаклыдыр, дөньяда шөбһәсез яшәү хәерлерәктер? Безнең гомер соңгы ноктасына якынлашты; мичтә дөрләгән ялкын телен Рөстәм бернинди буяуга буйый алмаган кебек, Мурзин да минем чиста-саф күнелемә бернинди кара тап төшерә алмаячак! Үз бәямне мин үзем беләм...»

Ислам бабай як-ягына жентекләп карый-карый барды.

Күк йөзе, жиләс мунча тәрәзәсе кебек, ничектер тоныкялтырау белән ялтырый. «Яңгыр юк та юк! Саңаклар тәмам кипшерде... Ичмасам, шул булыр-булмас жиле дә юнәлешен үзгәртми — һаман көньяктан исә дә исә, кайнарлыгыннан тының кысылыр. Тәмуг дисәң тәмуг...»

Соры-жирән үләнле юл сизелер-сизелмәс кенә булып түбән төшә башлады. Бу тирәләрдә чалгы йөрмәгән иде. Юл кырыйларындагы жиләк куакларын эт эчәгесе сарып алган. Картка аларның ак чәчәкләренең вак яфракчыклары ничектер ябыла башлаган сыман тоелды. Яңгыр яварга микәнни? Каян килсен икән ул яңгыр? Юк, шиңгәннәр генә бугай.

Күлләргә таба баш очыннан үрдәкләр очып китте.

Ислам бабай эшләпәсен салды — әллә инде жил көнчыгышка таба әйләнгәнме? Юк, юнәлеше һаман әүвәлгечә. Әнә ерактагы камышлы күлләр өстендә кара бер нокта асылынып тора. Тилгән бу. Димәк, ул күл буенда нәрсәнедер күреп алган. Бәлки яр кырыендагы яшел түмгәкләргә кунаклаган бакаларны күзлидер? Картның йөрәге татлы бер хистән тагы кысылып, сулкылдап куйды. Чынлап та, яңгыр яварга жыена микән әллә? Йолдыз кашка да пошкырып аваз бирде. Болын өстендә, әйләнә-тирәдә бүтән шылт иткән тавыш та юк. Ислам бабай эшләпәсен янә киде дә атны куалады...

Бераздан ул Югаргы күлләргә житеп, ике күл арасыннан сузылган камышлы тар муентыкка килеп керде. Монда суларга жиңелрәк — күлләрдән беркадәр су салкыны бәреп тора иде. Камышы да Ыкның теге як ярындагы күлләр буенда үскән кыяклы камыш түгел, бәлки көпшә сабаклы, биек жикән камыш иде. Аларның корыган һәм берберенә чуалып чорналган кызгылт-кара тамырлары, елдан-ел төпкә түшәлә барып, шактый калын түшәк хасил иткән; аның өстендә хәтта рәхәтләнеп ятып торырга мөмкин иде.

Ярты сәгатьләп шул рәвешчә баргач, Йолдыз кашка, ниһаять, Ислам бабайның сөзәк итәкле калкулык өстенә менгереп житкезде. Карт, бер кулы белән көймә кырына таянып, арбадан сикереп төште.

Кызыл тал куаклары арасында яшь бер имән агачы һәм ике карт өянке калкып тора; алардан ике генә адым ары, текә яр астында, мул сулы иске елга үзәне жәйрәп ята. Ул, тар тасма сыман, офык читенә кадәр дугайланып бара да, бер унике чакрымнар үткәч, Ыкка килеп кушыла. Аның яр читләре ифрат матур: югарыда буйдан-буйга ике яклап кара бөрлегән, эт жиләге куаклары сузыла, ә аста, ташлы су читендә, ак лилияләр һәм төнбоеклар үсеп утыра иде.

— Менә, ниһаять, без үз өебездә! — диде Ислам бабай, атны тугарып.— Бар, биләмәләреңне әйләнеп кил, тик ерак китмә, ярыймы?.. Монда сиңа азык житәрлек, үләнгә чалгы тиеп тә карамаган...

Шуннан соң ул, башта койрык яктан, аннан күбәләкле борын ягыннан тотып, ябышкак һәм кулны пешерердәй кайнар көймәне арбадан җиргә күтәреп төшерде; авызын өскә каратып әйләндерде дә, җир өстеннән чана сыман шудырып, ярга таба сөйрәп китте. Шулай азаплана-азаплана, көймәне яр астына, суга ук төшереп җиткергәч, ишкәк, дөмбе, җәтмә кебек нәрсәләрен дә арбадан көймәсенә ташыды. Аннары утырып йөзеп китте.

Иң элек ул җәтмәләрне салырга кереште. Ул, бер җәтмәне салуга, аның урынын саташтырмас өчен, якында үскән берничә камыш сабагын сындырып билге ясый да ары ишеп китә һәм чираттагы җәтмәне сала башлый иде.

Барлык җәтмәләрне шулай бер-бер артлы салып бетергәндә, Ислам бабай үзенең беренче килеп туктаган урыныннан шактый ерак киткән иде инде.

Шул чак ул аргы як яр буендагы куаклыклар арасыннан һавага учак төтене күтәрелүен күреп алды. Сизелер-сизелмәс кенә булып пешкән балык исе дә борынга килеп бәрелде. Кем булыр икән болар? Читтән килгән кешеләрме, әллә авыл малайларымы? Иң гаҗәбе, каршы як ярда бит. Йөзеп чыктылар микәнни?

Җентекләбрәк карый торгач, аның күзенә алсу төстәге палатка чалынды. «Чит илнеке,— дип уйлап алды Ислам бабай.— Юк, яннарына менеп, кемнәр икәнен белмичә ярамас, ахрысы».

Ислам бабай көймәне ярга китереп туктатты да, төшеп, агач тамырларына тотына-тотына югарыга үрмәләде.

Чытыр-чытыр учак яна, учак өстендә чиләктә нидер кайный. Шунда ук, ашамлыклы табын янында, үзара сөйләшә-көлешә, бер ир кеше белән башларына панамкалар кигән өч хатын-кыз утыра иде.

— Исәнмесез,— дип эндәште карт, яр астыннан калкып чыгып.

Хатын-кызларның берсе чәрелдәп кычкырып җибәрде, аннан, Ислам бабайны күргәч, шаркылдап көләргә тотынды.

— Ой, котны алдыгыз! Оясыннан зур йомран чыгып килә ме дип торам! — диде ул.

Карт, уңайсызланып, гафу үтенә башлады:

— Мин монда балык тотучы... Карыйм — төтен. Тикшерергә кирәк, мәйтәм.

— Ә безне нәрсә тикшерергә? — дип чәчрәп чыкты зур гәүдәле, калын иренле ир кеше.— Син кем буласың?

«Нигә әле ул минем белән болай тупас сөйләшә? Тәртипсез! Каян килгәннәр икән болар? Кемнең кунаклары икән?» — дип уйлады Ислам бабай.

Шул чак ул куаклар арасында торган кызыл төстәге җиңел машинаны күрде һәм шундук аңлап алды.

— Сез Минзәләдәнме?

— Анысы синең эш түгел! Бар, юлыңны кара.

— Ник әле минем эш булмасын? Мин монда...

— Бар, бар!

— Карт кеше белән алай тупас сөйләшергә кирәкми, Мәгъсүм,— дип сүзгә катышты бая карттан өреккән хатын.— Кызма алай. Борчылырга ярамый сиңа.

— Ә мин сезне беләм,— дип елмайды очлы борынлы, пляж костюмы кигән яшь хатын.— Сез — Әхмәтев дигән кеше, балыкчы, шулай бит? Бикташка Гыйлаҗ абыйларга кунакка баргач, без сезнең өйгә балык алырга дип килгән идек. Сезне анда бар кеше мактап сөйли.

Бу сүзләргә карт эчтән генә куанып куйды. Ләкин теге ачулы ир дорфа рәвештә аны һаман куалый бирде.

— Иә, анлашылдымы инде?! Нәрсә торасың? Эчәргә биргәнне көтәсеңме? Нурия, булмаса, салып бир үзенә. Юк, юк, анысыннан түгел... простоеннан сал...

Ислам бабай тәмам каушый калды.

— Мин аракы эчмим...— дип мыгырданды ул.

— Беләбез, беләбез... ничек эчмәгәнеңне! Син аны әнә йомраннарына сөйлә!

Картның ачудан күзләрендә очкыннар ялтырады. Ул эшләпәсен маңгаена батырыбрак киде дә, бер сүз дә әйтмичә, учак янына килде, чиләктә нинди балык пешерүләрен белү өчен, кайнап торган шулпаны аш чүмече белән болгатып-болгатып карарга тотынды. Анда бик күп кәрәкә һәм ике кило чамасындагы зур бер чуртан балыгы күзгә чалынды. «Гаҗәп, бу кадәр балыкны нәрсә белән тоттылар икән болар? Җәтмә салдылар микәнни?»

Калын иренле адәм картны нәрсә кызыксындырганын шундук аңлады һәм учак янына атылып килде дә, Ислам бабайның башы очында йодрыгын болгап:

— Синең ашка тыгылырга хакың юк! — дип кычкырырга тотынды.— Ишетәсезме, ул безне агуларга тели! Мин бу уханы ашамаячакмын! Бар, табаныңны ялтырат моннан!..

Ислам бабай, сабырын җуймыйча, тыныч кына:

— Кәрәкәләрне нәрсә белән тоттыгыз? — дип сорады.

— Анысы синдәй эт койрыгының эше түгел!

Карт кесәсеннән кызыл кенәгә чыгарды. Рыбнадзорның штаттан тыш инспекторларына бирелә торган вәкаләт документы иде бу. Ләкин калын иренле адәм документка күзен дә салмады.

— Анысы синең эш түгел! — дип кабатлады ул, бусарынып.— Исеңдә тот, моның өчен эләгәчәк әле сиңа! Карт ишәк, ахмак...

Хатыннар, сөйләшүнең болай артык тирәнгә китүеннән куркып, ирне тынычландырырга керештеләр, ләкин ул алар үгетләгән саен кыза гына барды.

— Җәтмә кайда? — диде карт баягыча сабыр тавыш белән.

— Нинди җәтмә? Без кармакка тоттык! Ишетәсеңме, кармакка тоттык дим, томана баш, черегән ми! Бар, исән чагында сыпырт моннан! Бу хулиганлыгың өчен без сине хөкемгә тарта алабыз...

— Кулың кыска,— диде карт, түземен җуеп.

— Ха-а! Кыска икәнен күрсәтермен мин сиңа? Менә хәзер бер кешене чакырыйм әле, аны күрүгә, син шундук аның аягына егылачаксың...

— Кирәкми... уятма, йокласын! — дип шаулаштылар хатыннар.

— Нинди җимгә — суалчангамы, ипигәме тоттыгыз? — дип, һаман сорашуын дәвам иттерде Ислам карт.

— Суалчанга,— диде очлы борынлы хатын, әлеге ир урынына җавап биреп, һәм елмаеп куйды.

— Күрсәтегез.

— Нәрсәне?

— Суалчанны.

— Калдыгын без ташладык инде,— дип, икеләнебрәк җавап бирде очлы борынлы хатын.

— Алайса, кармакларыгызны күрсәтегез.

Хатын палатка янында әле һаман ярсынып әйләнгән калын иренлегә таба карап кычкырды:

— Мәгъсүм, кармаклар кайда икән безнең?

— Хәзер... күрсәтәм мин аңа кармакны!..— диде теге, янап.— Хәсәныч! Торыгыз әле... Монда ниндидер бер карт хулиган бәйләнде... Чиләктәге шулпага тыгыла... Ниндидер җәтмә эзли...

Хатыннарның берсе Ислам бабайның колагына пышылдады:
— Тизрәк китегез... Мурзинның иң якын дусты ул... Үзегезгә яман булмагае...
Көтелмәгән бу хәбәрдән картның йөрәге сикереп куйды.
— Мурзин — минем киявем,— диде ул, кистереп.
Бу юлы инде хатыннарга хәйран калырга нәүбәт җитте.
— Сез ни сөйлисез?! — дип ахылдаштылар алар.— Мәгъсүм, Мәгъсүм! Ул Мурзинның каенатасы икән ләбаса!
Калын иренле, палатка эченә башын тыккан җиреннән кинәт тураеп басып, аптыраулы кыяфәттә артына борылып карады. Һәм шул ук мизгелдә палатка ишегеннән икенче берәү — теге вакытта Мурзин белән бергә Ислам бабайларда кунакта булган күзлекле кеше атылып чыкты. Чыкты да, кулларын җәеп, картка таба килә башлады:
— Ислам бабай, бу синмени! Исәнме, сау-сәламәтме, кадерле Ислам бабай! Менә бит, әкәмәт, шундый мөхтәрәм кешене дә танымаганнар! Бу һич ярый торган эш түгел, җәмагать. Әйдә, табын янына утыр, Ислам бабай, кунак булып китәрсең. Арыгансыңдыр. Йөзеңә дә әнә әллә нинди кайгы күләгәсе яткан...
— Вакытым юк минем. Өйгә ашыгам,— диде Ислам карт, авыр сулап.
Кара күзлекле кеше, сабый балаларныкыдай түгәрәк-мөлаем йөзен балкытып, картның хәлен аңлаган төстә баш кагып куйды. Ул инде шактый олы яшьтә булырга кирәк — чигә чәчләре чаларган, күз төпләренә тирән җыерчыклар яткан иде.
— Шулайдыр шул, шулайдыр, — дип такылдады ул. — Вакытыгыз юктыр. Карт кеше өчен вакытның һәр минуты — алтын ди бит. Ә безнең ишеләр өчен вакыт — көмеш кенә әле... Әйе, аңлыйм, бик яхшы аңлыйм...
Алар икесе дә, уңайсызланып, тынып калдылар.
Калын иренле сүз кыстырырга кирәк тапты:
— Мин аңа бер рюмка аракы тәкъдим иткән идем... чын күңелдән... Эчмәде.
— Эчмим шул,— диде карт.— Мин көймәдә. Гомумән, миңа эчәргә ярамый. Начар тәэсир итә, ахмаклыклар эшли башлыйм... Ә соңыннан үкенәм...
— Әй-е, — дип сузды күзлекле, янәдән балкып. — Мулланур Рамазановичны әйтәм, сөенәчәк инде... Алтын кеше ул... Сез дә алтын кеше. Алтын алтынга җилемсез ябыша диләрме әле?! Сәлам тапшырыргамы соң?
Ислам бабай, теләр-теләмәс кенә елмаеп:
— Бернинди сәлам тапшырулар кирәкми, — диде, аннары, күзлекленең чыраенда курыкканлык галәмәте күреп, өстәп әйтте:— Бу безнең ике арадагы эш, Мулланур да миңа гына кагыла торган эш.
Бу сүзләрнең асыл мәгънәсен аңламаса да, күзлекле килешергә кирәк тапты:
— Әйе, шулай шул, — диде. Ул, бабай белән сөйләшкәндә үзен ничек тотарга тиешлеген белмичә, әле як-ягына карана, әле күзлеген рәтли башлый иде. — Шулай шул. Минем дә вакытым бик кысан. Эш күмеп китте. Менә, әлегечә, ара-тирә табигать арасына чыкканда гына бераз иркен сулыш аласың...
Карт йөзен чытты.
— Җәтмәгез бармы?
— Җәтмә? Нинди җәтмә? Бездә бернинди җәтмә юк, Ислам бабай, — диде күзлекле.
— Ничек инде юк? Кәрәкәләрне нәрсә белән тоттыгыз соң?
— Кармак белән, Ислам бабай. Кармак салып, ягъни.
— Кәрәкә мондый эсседә кармакка капмый.

— Юкка бәйләнәсез, Ислам бабай!

— Кармакларыгыз кайда?

— Кайда булсын — ташладык, утка яктык! — диде күзлекле үтә куанычлы бер чырай белән.

«Нигә бу шул кадәр куана?» — дип гаҗәпләнеп уйлады Ислам карт. Чынлыкта, күзлекле һич тә куанмый, киресенчә, аның күңелендә әйтеп бетергесез ачу кайный; фәкать бу ачу аның йөзендә, чыраенда куанган вакыттагы сыман бертөрле галәмәт аша чагыла иде.

— Җәтмәне миңа китереп бирегез.

— Оһо? Нинди җәтмәне? Нәрсә шулай бәйләнәсең әле син, Ислам бабай, ә? Мулланур Рамазанович үзеңә рәнҗи күрмәгәе...

— Рәнҗи бирсен.

— Оһо? — дип, шулай ук гаҗәпләнеп кычкырды калын иренле һәм күзлекле кеше янына килеп басты. — Бу карт миңа баштук ошамаган иде.

— Әйе, бик тә рәнҗиячәк Мулланур Рамазанович, бик тә рәнҗиячәк,— дип кабатлады күзлекле, баягыча куанычлы елмаеп.

— Рәнҗесен.

— Кызыгыз Шәргыя дә рәнҗиячәк... Рөстәм дә, аның эш хуҗасы... безнең дустыбыз Сергей Иванович та рәнҗиячәк. Без аның белән күрше генә торабыз. Кара аны, Ислам бабай!

Карт, йөзен-кашын балаларча усал җыерып, күзләрен йомды һәм яңадан ачты. Күзлекле шаркылдап көлеп җибәрде.

— Ха-ха-ха! Куркыттың! Син һаман да әле әүвәлгечә мәзәк кеше икәнсең... кадерле Ислам бабай! Ярый, бар, өеңә кайт инде. Монда син барыбер берни таба алмассың. Юкса, әнә җил чыгарга тора...

Ислам бабай офык читенә төшеп барган зур, кызыл шарга таба йөзен борды. Чыннан да, ул яктан җил искәндәй иде.

Картның йөрәге шатлыклы хистән тагы сулыгып куйды. Явар микәнни?.. Ул күзләрен кысты. Аңа инде көнбатышта үтә күренмәле аксыл болытлар күтәрелеп килә, авыл һәм кырлар өстеннән җиңел күләгәләр йөгерә төсле тоелды.

Хушлашып та тормастан, ул су читенә, көймәсе янына төште. Һәм шунда гына елга өстенең шадраланып тирбәлүен, төнбоек чәчкәләренең җыела, ябыла башлаганын күрде.

Ислам бабай әйтерсең лә берьюлы яшәреп китте.

Ул биек ярлары арасына кысылып утырган иске елга үзәне буйлап бик тиз ишеп барды. Су читләрендә, сары утлы фонарьлар сыман, саз чәчәкләре балкып кала. Аларның да таҗ яфракчыклары, ябыла башлап, югары таба күтәрелгән иде.

— Ярар, сабыр итегез... Мин сезне болай гына җибәрер дип өметләнмәгез, — диде Ислам бабай, хәйләкәр төстә үзалдына көлемсерәп.

Аларның янауларыннан бөртек тә курыкмый ул. Дөрес, Рөстәмгә яисә кызга зыян итү ихтималлары бар барын... Ләкин карт үз дигәнен барыбер эшләячәк. Ахыр чиктә, аның өчен иң мөһиме нәрсә? Елга балыгын ике аяклы ерткычлардан саклап калу — менә шул! «Җәтмәләрен конфискацияләлим. Урлап китәм. Җәтмәне үз куллары белән бирергә мәҗбүр итә алмаганмын икән, димәк, миңа шул бер юл — җәтмәне урлап китү юлы гына кала... Өркеткән булалар бит әле: янәсе, малаең белән берәр күңелсезлек килеп чыкмагае! Мондый явыз халыкны ничек авызлыкларга икән? Алар белән ничек сөйләшергә? Миңа нишләргә икән? Бөтенесе шул кадәр буталган... Сөләйман патша үзе дә, мөгаен, моның очына чыга алмас иде... Ярар, урлыйм да китәм җәтмәләрен. Балык өчен иң хәерлесе, мөгаен, шул булыр!»

Агач яфраклары шыбырдашып куйды. Әле ярты сәгать элек кенә кул-битне уттай яндырып пешергән кояш нурлары, кинәт кенә сүрелеп,

клубтагы кинө яктысыдай, салкынаеп калды. Җил даими бер тизлек белән исә иде.

Ислам карт, көймәсен кирегә борып, янәдән теге Минзәлә кешеләре туктаган ярга таба ишә башлады.

Аларга җитәргә бер йөз метр кала, ул ярга төште һәм нелә-бөгелә куаклар арасыннан китте. Аның сак адымы җил шавында бөтенләй диярлек ишетелми иде.

Каяндыр бер өер карга пәйда булды. Алар, кар-кар кычкырып, елга өстендә зырылдап әйләнешергә тотындылар. Шул чак карт бер мизгелгә сулышын кысты — аның колагына күк күкрәве ишетелгәндәй булды. Ләкин күк гөмбәзе иң югары ноктасына кадәр чип-чиста, ачык шәмәхә төстә иде. Күрәсең, өлеге күкрәүне бик еракган җил алып килгән булгандыр...

Карт авыз эченнән ишетелер-ишетелмәс тавыш белән кеткелдәп, юлын дәвам иттерде. Үзен күрмәсеннәр өчен, ул гәүдәсен бөкрәйтеп, урыны-урыны белән хәтта чүгәләп диярдәй атлады. Ә инде учакның җиргә сыланып таралган зәңгәр төтене эченә килеп кергәч, бөтенләй дүрт аякланды. Аның хәтер күгендә әллә кайчан булып узган төрле хәлләр — Төркмәнстан, Вахш буйлары, шунда беренче мәртәбә фазан атып алуы, атлар һәм башка шундый хатирәләр бөтерелә иде...

Менә кешеләр сөйләшкән тавыш ишетелде. Ислам бабай машинаның борыны төбендә үк кычыткан арасына кереп ятты. Төтен күзне әчеттерә иде.

«Кызыл машина... Милициянекеме икән әллә? — дип уйлады ул, машинаны караштырып.— Юк икән, «шәхси» номер куелган...»

Кычытканнарны аралый-аралый, ул тагы алгарак үрмәләде. Бер кычыткан сабагы, терсәк астыннан ычкынып китеп, битне һәм колак яфрагын яндырып алды.

«Кара син аны, ничек усаллана,— диде Ислам бабай, үзалдына көлемсерәп.— Кайчандыр бик күптән, ачлык елында, без сине пешереп ашый торган идек, югыйсә!.. Кадерең шактый зур иде...»

Карт сакланып кына башын калкытты һәм тирә-ягына күз ташлады. Һәм кинәт аның үз-үзеннән шаркылдап көлеп җибәрәсе килде: шундый могтәбәр карт, ике сугыш батыры, кыю йөрәкле, тәвәккәл кеше, сугыш уены уйнаган малай-шалай кебек, куак арасында посып ятсын, имеш! Егерменче гасырның җитмеш ничәнче елы узып бара. Бавыр авырта, йөрәк чәнчешә, төтеннән күзне яшь каплый... Шулай да бу мизгелдә ул үзен барыбер малайча хис итте һәм, әгәр сөрән салып кычкырып җибәрә калса, тавышы, мөгаен, кыз баланыкыдай әче тавыш, чәрелдек тавыш булыр иде дип гөман кылды.

Куаклык артында исә аның гайбәтен чәйниләр иде.

— Тынгысыз карт... Теңкәне корыта торганы!— дип сөйләнде күзлекле адәм.— Ә бит үзе ахмак та түгел. Һәрхәлдә, Мулланур Рамазанович аны һич тә ахмакка санамый. Пенсионер карт шул, аларның һәммәсе шундый: гадел, сатылмас кеше булып кылана...

— Хәтта аракы да эчмәде, баш тартты.

— Сиңа, Мәгъсүм, аның өстенә эт кебек ташлану һич кирәкмәс иде. Андый чакта мөлаемрак, тәмле сүзлерәк булу кирәк. Сүз уңаеннан әйтим — аңа берәр төрле медаль бирдертү турында кайгыртасы иде, җәмагать.

— Ә нинди не?

— Теләсә ниндиен! Мәсәлән, суга батучыны коткарган өчен бирелә торганын!— дип шаркылдап көлде күзлекле.— Ә ник? Бу бик мөмкин эш. Мин Мурзин белән сөйләшермен, ә ул — Петряевка сүз катар. Петряевка бер медаль кызганыч булыр дисеңмени? Аның каравы, карт шундук тынычланыр, медален очраган бер кешегә күрсәтеп, мактанып йөри башлар. Күңеле йомшарыр — менә үзегез күрерсез...

Оялу, нәфрәт хисеннән Ислам бабайның йөзе бурлаттай кызарды.

«Һай, булыр икән шул кадәр җүнсез бәндәләр! Бернидән чиркан-мыйлар! Ярар, ярар, мин сезгә күрсәтермен әле... Ходай кушып, Илдар белән туганлашырга гына язсын...»

Карт, шым гына үрмәләп, машинаның икенче ягына чыкты. Авыр сулыш алды һәм шул чак үзенең бик нык арыган булуын тойды. Ерак та түгел, каршыда самавар җизе ялтырап күренде.

Җәтмә, мөгаен, машина багажнигындадыр. Карт тезләнде һәм шундук янәдән җиргә ятты. Җәтмә каршыдагы куаклар өстенә кибәргә элеп куелган иде.

Ул арада баш очында шартлап-чатырдап яшел ракета атылды.

— Ура! Ура!— дип кычкырдылар хатыннар.— Әйдә тагын, тагын! Карагыз әле, нинди ма-атур! Хуш, сау булыгыз, ямьле су буйлары!..

Ракеталарның кызылы... аннан җете сарысы һавага күтәрелде. Күзлекле аларны берсе артыннан икенчесен җибәреп кенә торды...

Ислам карт, җилнең көчәйгәнрәк вакытын чамалап, аягүрә торып басты да, күнегелгән өлгер хәрәкәтләр белән, җәтмәне сул беләге өстенә аркылы өя-өя, куаклык тирәли әйләнеп чыкты. Җиргә чүгәләде — ул-бу сизелми иде. Шуннан, мыек астыннан гына көлемсерәп, янәдән әрәмәлек арасына чумды.

Бер ун минуттан ул инде көймәсендә утыра иде.

Арка яктан көчле җил бәрә; ул хәзер шундый көчәйгән ки, саз үләненең суга ятып үскән тәлинкә зурлыгындагы яссы яфраклары кискен һава агымыннан югары таба каерылып күтәреләләр дә, бер мизгелдән су өстенә янә шапырдашып төшәләр. Ерактагы урман, кырлар өстендә күк күкри, бөтен тирә-як яңгыр алды эңгеренә өртелгән иде. Әнә яр карлыгачлары да күренде; алар, һаваны аркылы-торкылы сызгалап, тыз-быз уйнаклап очарга керештеләр. Югарыдан җил уңаена таба каерыла-каерыла кыр казлары тезмәсе узып китте.

Ислам бабай көймәне борыны белән сайга китереп тирәде, аннан аны камышлык аша яр буендагы таллык төбенә сөйрәп чыгарды. Нечкә таллар көчле җилдән сыгылып-сыгылып килә, көмешсу яфраклары шыбырдашып шаулый иде.

Нейлон җептән үрелгән авыр, юеш ГДР җәтмәсен Ислам бабай бик пөхтәләп төрде дә әрекмән арасына яшерде, читтән карап, аның күренү-күренмәвен тикшерде.

— Шулай...— дип мыгырдады ул.— Җәтмәләр салынды, көймә үз урынында. Берне көйрәтеп алыйм да, өйгә кайтырга да мөмкин.

Ул яр өстенә, арба янына күтәрелде. Шунда үлән чемченеп йөргән Йолдыз, хуҗасын күреп, кешнәп куйды.

— Хәзер китәрбез, Йолдызкай, китәрбез,— диде карт, атның кешнәвенә җавап биргәндәй.— Берне көйрәтергә рөхсәт итәрсеңдер ич?

Ислам бабай кесәсеннән «Прибой» тартмасын тартып чыгарды. Папиросларның һәммәсе диярлек яньчелеп, сынып беткән икән; кайберләренең тәмәке тутырылган өлеше, чабагач башы сыман, мөштеккә чак-чак кына эленеп торалар. Ниһаять, берәмтекләп эзли башлагач, арадан бер бөтене дә табылды. Карт аны авызына капты, шырпы сызу өчен, аркасын җилгә куйды. Папиросны кабызып, кире көнбатышка таба йөзе белән борылып басканда, шәфәкъ инде сүнгән — офык читенә кара болыт җәелә башлаган иде.

Болыт торган саен зурая, тоташ кара-күгелҗем тап сыман, офыкны инли барды. Аның өстендә нәфис ал төстәге киртләч-киртләч вак болытлар тезмәсе асылынып тора; тагы да югарырак, үзенә аерым бер тезмә рәвешендә, шикәрдәй ак һәм шакмаклы икенче төрле болытлар өере күренә. Әйтерсең лә кырыс табигать, кисәк кенә юмартланып китеп, дымга сусаган җиргә бар байлыгын берьюлы күрсәтеп бирим дигәндәй, күк йөзенә үзенең һәммә төр һәм төстәге болытларын өсте-

өстенә өеп-тезеп чыккан иде. Күз алдында кабара-кинәя барган шушы катлы-катлы чуар армаданы исә вакыт-вакыт буйга һәм аркылыга утлы сызыклар кискәләп уза; аларның һавадагы реактив самолет юлын хәтерләткән нәзек эзләре болыт өстендә зәңгәр-кызгылт нур чәчеп жемелдиләр дә, эреп, күздән югалалар иде. Бераздан болытның югарыгы өлеше, кепка козырегы сыман, алга таба бүлтәйде, ә түбәнге өлеше яшен сөңгеләреннән шартлап, кинәт балкып китте. Кара болыт кантарлары, бәйдән ычкынгандай, күкнең һәр тарафына ашыгып агыла башладылар. Күк гөмбәзе берьюлы соры, көлсу бер төскә керде, җил дә кисәк кенә туктап калды.

Тирә-якны тынлык басты.

Ислам карт башын чайкап куйды, папирос төпчеген суга ташлады (тын һавада папиросның суда чыжылдап сүнгәне ишетелде). Аннары, Йолдыз кашкага таба борылып, шөбһәсен белдерде:

— Йөрәк сикерә. Яңгыр булмый калыр, яумый узып китәр дип куркам...— диде.

Шәт, әле кичке җиде дә тулмаган булгандыр, шуңа карамастан, карт үзенең атын җиккәндә көн инде тәмам караңгыланып беткән иде. Ул арада якында гына күк гөмбәзен яшен чыбыркысы ярып узды, җирне һәм картның йөрәген дер селкетеп, күк күкрәде.

— Әйдә, бер коеп яу инде булмаса, көттермә, яу инде!..— дип пышылдады Ислам бабай, атын кайту юлына таба борып.

Аның ялваруын ишеткәндәй, кинәт түбәндә, яр астында, яшен яктысыннан бөтен үзәнлек, су өсте офык читенә кадәр бер мизгелгә балкып китте һәм күк күкрәве белән бер үк мизгелдә коеп яңгыр ява башлады.

Карт шатлыктан кычкырып җибәрде.

Ул эшләпәсен салды, йөзен югары чөйде — мул яңгыр тамчылары, тәнне иркәләп, бит-яңаклар буйлап түбән тәгәрәде. Күк йөзендә, күлләр, болын-кырлар, авыллар өстендә әйтерсең лә ниндидер тылсымлы галәмәт зур җан иләре ыгы-зыгы килә; алар яшерен рәвештә берберсенең кулларына нәрсәдер тапшыралар, ниләрдер бүләк итешәләр кебек; кайвакыт шушы ыгы-зыгы арасында шашынкы бәхет мизгеле кичергән җир өстен тоташ яктылык каплый һәм, барлык авазларны күмеп, әтрафны мәгърур күк күкрәү яңгырата иде.

## 10

Яшен сугудан шүрләп, карт эшләпәсен янәдән башына киде. Аның бер генә чыланмаган җире дә юк, шулай да ул шат һәм бәхетле иде.

Алтын кармак ла салдым зур суларга,
Ак балыгын алдым кулларга,

— дип җырлады ул.

Күк гөрелтесе бере артыннан икенчесе яңгырап кына торды, кара болыт кантарлары өсте-өстенә өелеште — алар һәммәсе тизрәк бушанып калырга тырыша иде. Аяк асты караңгы, тәгәрмәчләр су ерып бара, әмма пычракка бату куркынычы юк, чөнки чуендай кибеп каткан җирне җебетергә бу яңгыр суы гына түгел, океан суы да җитмәс кебек иде. Шуңа күрә камыш араларыннан узганда да Ислам бабайның күңеле тыныч булды.

— Һәй, һәй, әйдә! — дип ашыктырды ул атны.

Йолдыз кашка исә, үзалдына пошкырынып, артык ашыкмады. Өстәвенә, юлы да түмгәкле, арба әле бер якка, әле икенче якка авыша, аны тартып баруы шактый авыр иде. Шулай да карт, атны куалаудан бигрәк, бу караңгы әрәмәлекләр арасында җанлы кеше барлыгын — ул үзе, Ислам бабай, барлыгын белгертү өчен, Йолдыз кашкасына

— Һәй, һәй, әйдә атла! — дип кычкырынды.

Бара-тора су арба күчәренә кадәр күтәрелде, тәгәрмәчләр шарлама суда әйләнгән чыгырдай шупырдашып тәгәрәделәр. Әмма сунын төбе әле һаман каты-тыгыз, арба, таш юлдан баргандай, батмый-нитми алга тәгәри бирде.

«Менә бит ничек коя... — дип шатланды карт. — Бөзлы да түгел үзе. Тагы шунысы әйбәт: тигезле-тигезсез, иген кырларына үткәреп ява торган яңгыр, димәк, игеннәрне екмаячак, агызып китмәячәк...»

— На-на, атла, Йолдыз! — дип янә кычкырды Ислам бабай. — Син нәрсә, шушында гына төн кунмакчы буласыңмы әллә?

Яңгыр астында камышлар шыбырдашып шаулыйлар. Яшен камчысы күкнең бер кисәген кыеклап кисеп алганда, ул камышлар өсте берьюлы яктырып китә һәм очлы, тырпайган сабаклары офык читенәчә урман сыман агарып күренә иде.

Кинәт картның күңеленә шом төште:

«Көймәне яр өстенә менгеребрәк куймаганмын! Ай-яй-яй, ай бу яңгыр булмаудан начар гадәт кереп калган. Су күтәрелсә, соңгы көймәмнән колак кагуым бар лабаса... Ничек инде шуны уйларга башым җитмәде икән? Картаям, димәк. Үләр вакытым җитте микәнни?.. Үлсәм, мине кызганып сөйләрләр микән? Мөгаен, сөйләрләр. Мине яраталар бит. Мине бөтенләй яратмаулары һич мөмкин түгел!..»

Арба тигез, чирәмле юлга чыкты, ахрысы — сикертми башлады.

Ислам бабай, күкрәген киереп, сулыш алды: борынга шалфей, бөтнек, тукранбаш һәм кибеп көйгән җир җиләгенең тәмле, исерткеч исе килеп керде.

— Алтын кармак ла салдым зур суларга... Әйдә, малкай! Кызула!

Ат юыртуга күчте, карт күзләрен йомды.

«Яңгыр явып бик шәп итте әле бу... Игеннәр рәтләнер.. болында икенче кат печән өлгерер... Димәк, саулык та булыр...»

Ат, умарталыкка борылмыйча, үз белдеге белән, туры юлдан авылга таба китте. «Онытмый бит, каһәр. Хәтере безнекеннән шәбрәк. Нигә шулай икән ул?»

Ислам бабай төтен исен сизде. Аннан яңгыр пәрдәсе аша алда пыскып янган учак һәм аның янәшәсендә куыш күләгәсе күзенә чалынды.

— Һей! — дип сөрән салды ул.

Яшен яшьнәгәндә, куыш пыяла сыман тоташ ялтырап күренде — ул полиэтилен пленка белән капланган иде. Заманы яңа булгач, төзү материаллары да яңача шул.

— Кем ул? — дип сорады малайлар тавышы.

— Мин, мин бу... Ислам бабаң. Зер гут, — диде карт, кеткелдәп.

Ул, яңгырга чыланган башын селки-селки, караңгыдан куыш эченә керде. Тәбәнәк, кыйшык өстәл өстендә керосин лампасы яна, шунда ук озынча электр фонаре да бар; өстәл кырыендагы бүрәнәдә исә, күзләрен кулындагы ачык китабы өстенә якын ук китереп, бер малай утыра. Аның кара-кучкыл йөзе һәм чәчләре юеш — күрәсең, ул да күптән түгел яңгыр астында булып кергән иде.

Картны күргәч, малай китабын япты да урыныннан сикереп торды.

— Әти кайдамы? — дип, сорауга җавап биргәндәй, куыш ишеге төбендә дәшмичә басып торган картка төбәлеп катты ул. — Әти а-ан-да, көтү белән авылга китте... Ашыйсыгыз килмиме, Ислам бабай? Чәй эчмисезме? Суынып җитмәгәндер әле. Чишенегез... Су бастымы? — дип, тагы баягыча үз-үзенә сорау бирде малай, маңгаен җыерып. — Әйтәсегез бармы! Аның каравы, игеннәргә әйбәт булды — иген уңачак хәзер, үкереп уңачак... Чишенегез, Ислам бабай...

Картның өс киеменнән туктаусыз тамчылар тама иде.

— Юк, чишенеп тормыйм, рәхмәт, — диде Ислам бабай, елмаеп. — Син үзең утыр, утыр, укуыңны дәвам ит!

Малай борыны белән тагы китабына кадалды. Ара-тирә ул, башын калкытып, йомры кара күзләре белән картка карап ала иде.

Ислам бабай куыштан яңгыр астына чыкты, дөм караңгыда жигүле арбасы янында бераз вакыт уйланып торды. Яңадан куышка керде.

— Малай, карале, — диде ул ничектер уңайсызланган кыяфәт белән, — син мине... яратасыңмы?

Малай, сәерсенеп, картка күтәрелеп карады:

— Әйе, яратам.

Аннары алар икесе дә елмаешып куйдылар. Малай гаҗәеп кызык китап укый, карт та күңеленнән шундый ук гаҗәеп тормыш китабы сәхифәләрен актара иде...

Ислам бабай жигүле аты янына кире чыкты, арба төбенә җәеп салынган һәм моңарчы утыру өчен генә хезмәт иткән брезент плащын алып, өстенә бөркәнде дә, инде бераз зәгыйфьләнә төшкән яңгыр тамчыларының шыбырдашуына колак салып, җилле, очсыз-кырыйсыз караңгылык эченнән юлын дәвам иттерде...

«Малай мине яратып дөрес итә, — дип уйланды ул. — Ә ник мине яратмаска? Мин гомерем буе үземне кайгыртмадым, гел кешегә яхшы булсын дип яшәдем. Төркмәнстанда юл йөргәндә турсыктагы суны иң соңгы кеше булып эчә идем. Тире исе килеп торган лайлалы, болганчык су була иде ул. Ә менә атакага һәр вакыт беренче булып кердем. Тезбашларым атның сәләгәенә каткан була, чөнки куркак атым алдан бармас өчен киреләнеп башын боргалый, артка каерылып карарга тырыша иде... Кырык беренче елны сугышта мин өлкән улымны югалттым. Шул ук елны җәй көне сөйгән командирым да һәлак булды. Ул мине шаяртып «Крючок-рыбачок» дип атый торган иде. Балыкчы-кармакчы ягъни... Аны дошман пулясы яралаганда...»

Лейтенантны дошман пулясы яралаганда, Ислам Әхмәтев әрәмәлек артындагы елга буенда иде. Немецлар контратаканы кире кагып, безнекеләрнең кире чигенеп барган чагы. Аяк атларга да хәле калмаган Ислам ничек кирәк алай үз окопларына кайтып керде һәм шунда гына лейтенантның хәтәр яра алганын күрде. Командирның чыраеннан кан качкан, өске ирене зәңгәрсуланып, күгәреп тора иде.

— Сиңа әйтәм, Әхмәтев... Крючок-рыбачок, — дип елмаерга тырышты лейтенант. — Син миңа алай кызганыч итеп карама, ярыймы. Юкса, мин ырымнарга ышана торган кеше...

— Мин алай карамыйм, иптәш командир...

Ләкин лейтенантны кызганудан Исламның бөтен чыраена кайгы билгесе яткан иде. Ничек кызганмыйсың ди, шундый яшь командир үләргә ята бит.

— Без синең белән балык тотарга барырбыз әле... — дип пышылдады лейтенант. — Тик син миңа алай карама, яме. Әллә минем белән балыкка барырга да теләмисеңме?..

— Боерык бирсәгез, мин хәзер үк барам! — диде кинәт Ислам. — Боерык кына булсын! Балыгын тотабыз аның! Тәмләп ашарсыз бер... Әйе!

Башка сугышчылар көл гына селтәделәр:

— Нинди балык булсын монда, юкны сөйлисең, Ислам! Күптән тончыгып беткәннәрдер инде! Йөрмә юкка!

— Әйдә барсын.... — дип, күгәргән иреннәрен кыймылдатты лейтенант һәм күзләрен йомды. — Крючок-рыбачок... Әйбәт кеше...

Елга буенда әле һаман сирәк-мирәк мылтык тавышлары яңгырый. Урман өстеннән җан суыргыч шомлы бер аваз белән снарядлар улап уза; алар кайдадыр биң еракта, фронт сызыгы артында төшеп ярылалар иде.

Болганчык сулы бу елгада күп егетләр һәлак булган иде бүген...

Ислам тышлыгына музыка язу билгеләре төшерелгән трофей блокнотның тимер чыбык беркеткечен суырып алды да, аны кармак сыман бөгеп, бер очына элмәк ясады, аннары шул элмәккә озын ак җеп бәйләде. Тирә-ягына күз йөртеп, шомыртка охшаган бер агач күрде; шатлык катыш гаҗәпсенү белән, агачның метр ярым чамасындагы нәзек бер ботагын кисеп алды, иснәп карады — чыннан да, бу шомырт иде. Ботак артык төз булмаса да, кармак сабы сымаграк бер нәрсә килеп чыкты... Ислам, эшләгән эшенә эченнән сөенеп, чүгәләп атлый-атлый, әрәмәлектән яр читенә төште. Аның аркага аскан винтовкасы түтәсе белән җир өстеннән сөйрәлеп бара иде.

Елганың суы бик болганчык, ләм төсендә иде. Ислам, елга яры буйлап күзен йөртә-йөртә, балык яшеренеп ятардай урынны эзләде. Ниһаять, татлы-рәхәт бер дулкынлану рәвешендә күңел төбеннән күтәрелгән әүвәлге аучылык һәвәсе аңа бу урынны төгәл чамаларга ярдәм итте — әнә ул, балык булса шул куаклык артында, елганың камыш белән уратып алынган тугай сыман култыгында булырга тиеш.

Ислам, түше белән шуа-шуа, яр кырыена килде. Ул ашыга иде. Терсәк астында үле кысланың кипкән кабырчыгы чыртлап ватылды. Үләнгә төтен исе сеңгән иде.

Ислам кесәсеннән җебетелгән сохари кисәге чыгарды һәм, күзләрен су өстенә текәгән хәлдә, сохарины төкерекли-төкерекли учында бик озак әвәләп торды. Эчке дулкыннан аның куллары калтырый иде. Ни әйтсәң дә, сугыш башланганнан бирле аның балык тоту түгел, бу турыда уйларга да чамасы юк иде бит...

Ниһаять, Ислам кармак җебен сакланып кына суга ыргытты. Камыштан телеп ясалган һәм бер очы кармак җебенә беркетелгән озынча калкавыч суга төшүгә үк, тартылып, пулядай югарыга карап ятты.

— Ягез, балыккайларым, ашый башлагыз җимне! Анда сезне командир абзагыз зарыгып көтә, — дип пышылдады Ислам.

Инде эңгер төшә башлаган, су өсте караеп ялтырый, теге як ярда, бер өч метрда, учак уты күренә иде. Ваемсызлык? Әллә саташтыру өчен юри якканнармы?

Калкавыч селкенергә уйламый да. Ислам кармакны чыгарды, җимен тикшерде, аны ике бармагы белән суырып алып, авызына капты, аннан яңа йомарлам ясап, янәдән кармак очына куйды.

Камыш калкавыч су өстендә хәрәкәтсез ятуында булды.

— Ягез, кабыгыз инде... Анда командир үлеп ята...— дип, бөтенләй күз яше белән ялварды Ислам.

«Бәлкем бу суда чынлап та балык калмагандыр, ә? Кысыр судыр,— диде Ислам, күңеле сүрелеп.— Чикерткәгә каптырып карарга иде дә, тик ул чикерткәне хәзер кайдан тапмак кирәк?»

Ислам кармак сабын яр кырыена беркетте дә кире әрәмәлеккә таба үрмәләде. Колак салып тыңлый башлады.

Колакның үз чыңыннан башка бернинди тавыш юк иде. Кинәт Исламга аягы янында нидер үләнне кыштырдата кебек тоелды. Ул яшендәй тизлек белән учын әлеге кыштырдаган җиргә каплады һәм шундук аны җирәнүле рәвештә кире тартып алды — үлән арасыннан шуышып баручы салкын, шома тәнле елан иде бу. Әгәр ул агулы елан булса, бер дә юкка дөнья куюың ихтимал бит! Ләкин Ислам андый хәтәр нәрсәләр турында уйламады, шулай ук ул теге як ярда немецләр барлыгын да хәтереннән чыгарды... Читтән карап торучы бу минутта Исламны, куаклар арасында үрмәли-үрмәли, ниндидер күзгә күренмәс җен-пәриләрне аулап йөри дип уйлаган булыр иде, мөгаен...

Юк, бернинди чикерткә, бөҗәк тә тота алмады Ислам. Кем белә, бәлки алар монда бөтенләй булмаганнардыр да, фәкать әсәрле Исламга гына бар кебек тоелганнардыр.

Ул яңадан яр астына, кармагы янына үрмәләде. Һәм күпмедер вакыт су өстендә калкавычны күрми торды — калкавыч яр читенә үк кагып чыгарылган иде. Кармакта җим юк. Исламны дулкынлану биләп алды. Ул, яңа җим куеп, кармакны тагы суга ыргытты. Күзен йомды, бераздан кире ачты.

Һәм шул ук мизгелдә көзгедәй тигез су өстендәге калкавыч сикереп куйды. Ислам кискен хәрәкәт белән кармак сабын югары күтәрде һәм, һавада ярым түгәрәк ясап, яр читенә бармак озынлыгы җимбалык шыпылдап килеп төште. Теләсә нинди җимгә һәм кармакка эләгә торган шундый ахмак балык инде ул! Суга сикереп качмасын өчен, Ислам солдат аның өстенә бөтен авыр гәүдәсе белән капланды дияргә мөмкин. Шулай гимнастеркасын инә очыдай вак тәңкәләргә буяп, ул аны түше астыннан тартып чыгарды һәм тере килеш кесәсенә салды. Әйдә, шунда тыпырчынсын, янәсе! Салкын тере балыкның кесәдә ярсып тыпырчынуы балыкчы кеше өчен иң гүзәл ләззәтләрнең берсе ул!..

Ислам бер-бер артлы тагы биш җимбалык эләктерде. Һәм бөтенләй көтмәгәндә — шактый зур чабак тартып чыгарды. Кичке әнгердә көмеш тәңкәләрен ялтыратып, ул зур итеп авызын ачкалап ята иде. Бер мәртәбә хәтта ишетелер-ишетелмәс кенә чыелдап та куйды шикелле.

Ислам солдатның күңеле шат, кесәсендә әнә күпме тере балык тыпырчына иде.

Шул чак аның күз алдына яралы командир килеп басты. Йа ходай, болар барысы да командир хакына эшләгән эшләр ләбаса!

Ислам кармакны шунда яр буена ташлады да, кесәсендәге балыкларны измәс өчен сул янтыгына ятып шуыша-шуыша, окопларга таба ашыкты, хәтәр урынны узгач, бөтенләй аягүрә торып, йөгерә башлады.

— Кем килә?

— Мин, Әхмәтев! Балык алып кайтам... командир сорады... Күп итеп тоттым!

Ләкин беркем шатланмады, беркем мактау сүзе әйтмәде. Һәммәсе башларын түбән иеп, боек чырай белән басып торалар иде.

Ислам якынрак килде: лейтенант, аксыл, кырыс йөзен кичке күк йөзенә таба юнәлткән хәлдә, урынында хәрәкәтсез ята иде.

— Их, өлгерә алмадым бит,— дип пышылдады Ислам. Аның яңаклары буйлап кайнар яшь тәгәрәде.

Кабер казылып, мәетне гүргә куйгач, Ислам Әхмәтев сугышчыларны аралый-ера алга узды да бая үзе тоткан балыкларның һәммәсен берәм-берәм караңгы кабер эченә ташлады. Берме-икеме балык әле һаман тере иде, алар лейтенантның күн итеге өстендә тәңкәләре белән елкылдап, сикерешеп куйдылар.

«Әйдә, бергә ятсыннар, лейтенант минем балыгымнан бәлки теге дөньяда авыз итәр»,— дип уйлады Ислам. Ул асылда теге дөньяның булуына ышанмый, шулай да үлем белән яшәү мәсьәләсендә аның ул вакытларда ук инде томанлы үз карашы яралып килә иде...

Сугышчылар аның бу эшен гаеп итмәделәр.

Менә шулай, тере балыклар белән бергә җирләделәр алар үз командирларын. Кырык беренче елның август ахырларында, фронт сызыгында булган бу кайгылы кич Исламның хәтеренә мәңгегә сеңеп калды.

Балыклар нәрсә? Шул ук сугышта, иң беренче көннәрендә үк әле, чик буе окопларының берсендә Ислам бабайның өлкән улы — ул вакытта унҗиде яшьлек бер малай — үзенең бөтен взводы белән бергә немец танклары астында калып, терелэй җиргә күмелеп үлде... Бу хәбәр Ислам бабайда сугыш уртасында, безнең гаскәрләр инде көнбатыш чикләргә якынлашып килгәндә генә барып иреште. Улының һәлак булган урынын ул үзе дә эзләп карады, ләкин таба алмады —

мәгълүматлар артык каршылыклы булып чыкты. Карт сугыш вакытында да, сугыштан соң да төрле җирләргә хатлар язды, белешмәләр җыйды, әмма улының һәлак булган урынын билгеләү мәсьәләсе аның саен катлаулана барды. Улы сугышып үлгән окоп хәзер көнбатыш чикнең буеннан-буена сузыла кебек иде...

Ислам бабай әле булса төшендә бу улын тере итеп күрә. Ул, имеш, әлегәчә исән, шунда, җир астында һава җитмәүдән газаплана, кычкыра, ярдәмгә чакыра, ләкин аны беркем дә ишетә алмый, имеш; чөнки ул күмелеп калган окоп өстендә хәзер тимер-бетон, таш һәйкәлләр тора. Бөтен чик буенча тезелеп киткән бит хәзер андый һәйкәлләр... Ә бәлки ул анда, җир астында, йоклап кына ятадыр? Сөйлиләр бит, кеше унар ел, алай гына түгел, егермешәр ел буена уянмыйча йоклый ала, диләр. Мондый йокыны мәрткә китү дип атыйлар. Шул, йоклыйсың-йоклыйсың да, ничәмә-ничә еллардан соң әүвәлге рәвешендә яңадан уянасың. Тик сакалың гына аяк табанына кадәр үскән!.. Ислам бабайның улы шулай мәрткә киткән булса ни гаҗәп?. Уянадыр да, кычкыра-кычкыра арыгач, яңадан йокыга таладыр... Бу могҗиз заманданиләр генә булмас дисең?

Еллар узган саен картның бу төш күрүләре ишәя һәм сәерләнә барды. Кайчакны ул үзенең улын төштә чик буенда үскән агач итеп күрә иде. Ләкин бу агачта яфраклар урынына күзләр эленеп тора, имеш; коңгырт төстәге чын тере күзләр — яктыда алар нурлар чәчеп елтырыйлар һәм барысы да бер тарафка — Ислам бабайга таба төбәлеп карыйлар, имеш.

Карт шулай, улын сагынып гомер кичерде... Азык-төлек, киемсалым һәм уку әсбаплары сатыла торган авыл кибетенә кергәндә ул, мәсәлән, зур масштаблы Европа яисә СССР карталарын өстәлгә җәеп сала да, алардан илнең көнбатыш чикләрен эзли башлый һәм, һәркайсында эзләгәнен тапкач, монда минем улымның кабере дә бар бит дип, шатлыклы-көенечле бер хис белән сабый балаларча гаҗәпләнеп куя иде...

Менә хәзер ул көчле яңгыр астында өенә кайтып бара.

Малай нәрсә диде? Яратам диде.

«Гомерем буе гади, намуслы тормыш белән яшәдем шул мин. Озын гомер итүемнең дә сәбәбе үз-үземне сакларга тырышып яшәүдән түгел. Аның сәбәбе бүтәндә — икенче сугышка чаклы, ягъни кырык яшемә җиткәнче, мин тәмәке тартмадым, авызга аракы алмадым. Хәзер дә мин көнгә нибары бер папирос тартам, ә эчүем — елга бер мәртәбә... Әмма эштә мин үземне жәлләмәдем. Мин бит бөтен нәрсәне үз кулларым белән ясыйм. Галәм корабларында минем бармак эзе юк югын, аның каравы, җирдә һәммә кеше минем хакта гадел сүзен әйтә ала! Бураны үз кулым белән торгыздым. Җәтмәсен үрдем, кар базларын казыдым... Аннан да битәр, кешедән берни жәлләмәдем, бөтен дөньясыннан миңа кунакка килеп йөрделәр. Кунаклар килгәнне күргәч, тавыгым үзе теләп пычак астына керә, сыерым шат, ахмак тавышы белән мөгри-мөгри сөтен саудыра торган иде. Кунакларга каймагын, маен ашаттым, үзем әйрәнен эчтем мин бу сөтнең... Үземнеке дигән бердәнбер нәрсә — ул да булса минем күләгәм. Хәер, анысы да әссе чагында миңа түгел, хатыныма хезмәт итте...

Баштан кичергәннең, дөньяда күргәннең барысына мин дөрес бәя бирә бардым. Маңгаемдагы җыерчыклар кайбер яшь картларныкыннан азрак икән — анысы минем гомер буе беркемгә, бернәрсәгә хәтер калдырмыйча, ялгансыз, бердәмлекле, бөтен тормыш белән яшәвемнән килә. Минем җаным беркайчан да акка-карага аерылмады, юха елан кебек бөргаланмады. Бу хак сүз!

Әгәр ниндидер мәсьәләдә шөбһәләнсәм дә (андый очраклар да булмады түгел), мин ул шөбһәмне сөрән салып кычкырыр өчен тел очына салып куймадым, пычак сыман уч төбенә салу турында инде — әйтәсе дә юк. Балыкчы кешенең вакыты күп — шөбһәле һәр нәрсә турында иркенләп баш ватарга мөмкин... Күзеңне суга текә дә тик уйлый бир...

Ватан сугышында командирымның мине яратуы, үз күрүе тикмәгә генә булгандыр дисеңмени... Мескенне балык белән сыйлый алмадым — шунысы үкенечкә калды...

Ә Илдар соң? Быел җәен үзе җыйган яшерен киңәшмәгә иң беренче булып мине чакырды бит!»

...Илдар ул чакта колхозның иң акыллы, иң могтәбәр картларын җыеп алган иде. Әгәр анда җыелган аксакалларның җыерчыкларын бергә кушсаң — бөтен бер диңгез өстен каплар, ә сабырлыклары дөньяның барлык тауларына җитәр иде.

Илдар, гадәтенчә, көлмәде, шаяртмады. Арка ягыннан көчле электр лампасы яктырткандай, аның җитди йөзе күләгәләнеп кенә төсмерләнә иде.

Ул болай диде:

— Уҗымнар янды. Язын чәчкәннәр дә күеп бетте... Үзегез күрәсез — яңгыр юк. Инде нишләргә? Икенче кат сөреп чәчәргәме? Чәчсәк, күпме мәйданга чәчәргә? Яртысынамы? Ярты мәйдан белән уңыш шәп булды дигәндә дә әллә ни мактанырлык нәтиҗәгә ирешә алмаячакбыз. Алдан ук әйтеп куйдым: ярты мәйданнан алынган икмәк тулысы белән дәүләт амбарына кереп бетәчәк. Ә үзебезгә нәрсә кала? Инде икенче юл — булган запасның бөтенесен чәчеп чыгарга... Әгәр иген уңса, ул чакта... Әгәр иген уңмаса ничек? Минә шушы мәсьәлә хакында сезнең киңәшегезне ишетәсе килгән иде.

Картлардан кайсыдыр сакланып кына егерме беренче елны телгә алды.

Икенче берәве: тиздән яңгыр яварга тиеш, чыршыларның салынкы ботаклары күтәрелә башлады, диде.

Фикерләр аерылышты.

Ислам бабай һаман дәшмәде. Алдан ук борынны тыгу нигә кирәк аңа? Ул — балыкчы, аңардан кипкән балык исе аңкый. Ләкин минә Илдар аңа таба күләгәле, җитди йөзе белән борылды:

— Син ни әйтерсең, Ислам бабай?

— Ни әйтерменме? Сөрергә кирәк. Язмыштан узмыш юк. Игеннәр икенче кат көйсә дә — беркем безне гаепләмәс. Ә инде көйгән кырлар өстенә шушы атна-ун көн эчендә яңгыр явып үтсә, без үзебезнең кул кушырып ятуыбыз өчен коточкыч хурлыкка калачакбыз. Тагы бер юл бар — нефтьчеләр ярдәме белән Кол-морза янындагы Таштауны шартлатып, Ыкны бөяп кую. Ул чакта безнең колхоз кырлар уртасында утырачак.

Әлбәттә, картның соңгы тәкъдимен беркем дә якламады: ул тәкъдимне кабул иткәндә Ыкның түбән агымындагы барлык авыллар сусызлыктан һәлак булырлар иде... Киңәшмә чәчү мәйданнарын янадан сөрергә дигән бердәнбер нәтиҗәгә килде.

Кырлар, басулар өстендә тузан болытлары күтәрелде, хәтта саесканнар да тузаннан сорыланып калдылар...

*
* *

«Кызганыч, көймәне яр башынарак менгереп куймадым. Тәки хәтердән чыгарганмын. Яңгыр суы алып китәр инде... Картайганмын, димәк. Әҗәлем якынайган, димәк. Үләргә була анысы, тик минә ма-

лай белән нишләргә? Илдар белән ничек туганлашырга? Ә Митька? Ә Мурзин белән нишләргә? Шулай да хатны язмамдыр! Их, хәл итәсе күпме эшләр бар... Җитмәсә, нинди эшләр бит әле — иң кыен, иң төп дигәннәре! Аларны уйлагач та чәчең үрә тора. Ә уйламыйча булмый, чөнки әҗәлем якынлашканын сизәм... Ә бәлки алай түгелдер, мин әле яши генә башлый торганмындыр? Их, күп нәрсәне аңламыйм шул әле мин? Әйтик, кеше нәрсә өчен яши? Үзе өченме, әллә бүтәннәр өченме? Әйбәт, яхшы кешеләрне ничек үзара туганлаштырырга икән? Бәлкем бу турыда махсус закон чыгарыргадыр, аны Конституциягә язып куяргадыр? Әгәр бүре сарык тиресенә яшеренгән булса — нишләргә? Сарыгы бүре тиресенә ябынса — ни кылырга? Кичерергә ярыймы аны? Менә сез, балалар, бик күп китап укыйсыз. Монысы бик әйбәт. Әмма, миңа калса, чын хакыйкать, чын акыл китапның эчендә, ике катыргысы арасында түгел, ә аның өстендә, әйләнә-тирәсендә. Мин, карт кеше, моның шулай икәнен күреп торам! Аннан тагы шуны күрәм: саф җанлы кешеләр гаделсезләргә караганда күбрәк... тик алар кеше күзенә артык керергә генә тырышмыйлар... Әнә малай әйтте, мине яратам, диде».

Еракта эт өргән тавыш ишетелде.

Өйалды бүлмәләренең төннектәй кечкенә тәрәзәләрендә утлар җемелдәп күренде — карт бәрәңге бакчалары ягыннан кайтып килә иде.

Көпчәкләр пычрак ерып бара, Йолдыз кашканың тояклары астыннан баскан саен су чәчри иде.

Ислам бабай, башын алга ташлап, караңгылык эченә күзләрен текәде.

Басу капкасы ачык. Кайдадыр гармун уйнап җырлаган тавышлар ишетелә. Бүген яңгыр яуган көн бит — халык бәйрәм итә!

Кырый йорт турысында ниндидер күләгә күзгә чалынды. Якынрак килгәч, йөзен ачык күрмәсә дә, бөкрәеп атлаган йөреше буенча карт аның карчык кеше икәнлеген шәйләде. Ул биләмгәме бара, әллә биләмнәнме кайтып килә иде, күрәсең.

— Һей, ә син мине яратасыңмы соң?..

Кортка, читкә тайпылып, башын түбән иеп калды. Нишләмәк кирәк, карчыкларның көзгесе — җир, шуннан да югарырак кутәрелеп карый алмый алар.

— Яратасыңмы дим?.. Ә?..

Бөтенләй үк яратмавы, юк, мөмкин түгел. Мөгаен, ишетмәгәндер. Ишетсә дә, Ислам карт икәнен абайламагандыр, карт үзе дә аны танымады бит. Ләкин аның Ислам бабайны бер дә яратмавы мөмкин түгел, анысы — мөхаль нәрсә...

Ислам бабай шулай, төн уртасына авышкан бер вакытта, җәй буе зарыгып көтелгән шифалы яңгырдан җеп бөртегенәчә чыланып, әмма көр күңел белән, авылга килеп керде.

**РӘИС ДАУТОВ** тәрҗемәсе

# Роберт Миңнуллин

## Шундый минем туган ягым...

Акчәчәкләр чыңлап тора,
Җырлап тора әйләнәдә.
Аккаеннар сылу-сылу
Яшь кызларга әйләнә дә,
Җыйнаулашып, тезелешеп
Төшеп китә Сөн буена,
Яп-ялангач калып кына
Су керергә төн буена.

Ә малайлар шундый монда:
Хикмәт кенә уйлап йөри,
Япь-яшь кенә яшеннәрне
Камчы итеп уйнап йөри.
Шул камчыны шаяртып бер
Шартлатсалар болгый-болгый,
Баш очында утлар уйный,
Күкләр күкри ургый-ургый...

Тайлар монда бер урында
Чыдый алмый биеп тора.
Ә басулар шундый биек —
Офыкка ук тиеп тора...

Менә шундый инде минем
Туган җирем, туган ягым.
Мин төзәлә алмам, ахры —
Мактанылды менә тагын.

## Безнең авылдан да узган сугыш...

Авылдан бик ерак йөде диләр
Фронт сызыгын,
Комсыз сугышны...
Алай икән, ник соң ул сугышны
Уйласаң да кыса сулышны?
Йөздән артык солдат
Өйләренә
Ни сәбәпле кайтмый калган соң?
Яшь хатыннар — ирсез,

Ә малайлар
Ник әтисез калган аннан соң?
Нигә соң ул сугыш
Авылдагы
Һәрбер йортны мең кат тетрәткән?
Хирурглар
Ярчыкларны һаман
Чүпләп бетералмый күкрәктән?
Яудан соң да
Ник солдатлар түгел,
Үлем кәгазьләре агылган?
Я, кем әйтә ала
Ул сугышны
Узмаган дип безнең авылдан?!

## Тургай

Н. Н.гә

Җир белән күк арасында
Талпына гашыйк тургай...
— Икесенең берсен сайла,
Алданма, ашык, тургай!

Йолдызга да меналмыйча,
Гөлгә дә куналмыйча,
Мәхәббәттән кала күрмә,
Кайсына булалмыйча...

Ишетми...
Нишләсен тургай:
Күк чакыра, җир тарта.
Гашыйк җанда торган саен
Моң ургыла, җыр арта.

Җыр хакына, моң хакына,
Онытып янасын да,
Сайрый, сайрый, сайрый тургай
Ике ут арасында.

Гомерлеккә сайлаганмы
Күк белән җир арасын?
... Тургай җанын кем аңламый,
Тургай булып карасын.

## Син борчылма, Туган илем!

Күптән инде
Төн бит инде,
Бераз гына
Ял ит инде,
Туган илем!

Син борчылма —
Төнлә син ял иткән чакта
Солдатларың һәрчак уяу,
Солдатларың тора сакта!

Күптән вакыт
Ятырга да,
Ял кирәк бит
Батырга да,
Туган илем!
Син борчылма —
Төнлә син ял иткән чакта
Гашыйкларың уяу синең,
Гашыйкларың тора сакта!

Безнең алда —
Хезмәт таңы,
Бөек эшләр
Көтә тагы,
Туган илем!
Син борчылма —
Төнлә син ял иткән чакта
Шагыйрьләрең төн йокламый,
Шагыйрьләрең тора сакта!

## Бураннарым белән барам...

Ак урамнар буйлап киләм
Ак бураннар аркылы.
Урамнарга сыймый буран,
Җанга тула аркылып.

Кышның утлы бураннары
Ярсып уйный канымда.
Кызу канлы бураннарны
Тыялмый бер канун да.

Бураннарга буйсынам мин...
Буйсындыра да алам.
Торган саен якыная
Бураннар белән арам.

Күңел булмый — бураннарга
Бер чыгып бәйләнмәсәм.
Җанда — буран. Ярый инде,
Буранга әйләнмәсәм...

Кышларымнан канәгать мин,
Бик риза язганына.
Бураннарым белән барам
Мин якты язларыма.

## Янарга икән янарга...

Янарга икән янарга!
Янарга азаккача:
Иң азаккы ләззәткәчә,
Иң соңгы газапкача.
Әгәр шулай янмый икән,
Нигә ул андый йөрәк?
Ул йөрәкнең януыннан
Янмавы хәерлерәк.

Яшьнәргә икән яшьнәргә
Йөрәкләр көл булганчы.
Мизгелгә генә булса да
Төннәрең көн булганчы.
Кемгә кирәк аҗагандай
Тонык кына яшьнәвең.
Яхшырактыр яшьнәмәвең,
Яхшырактыр дәшмәвең.

Яшәргә икән яшәргә!
Үзеңне жәлләмичә.
Безгә диелгән гомерләр
Түгел бит әллә ничә.
Әгәр шулай яшәмәсәң,
Яшәвең кемгә хаҗәт.
Ә бит яшиләр андыйлар,
Яшиләр — шунсы гаҗәп.

## Шундый инде без менә...

Әле без әллә кем түгел,
Кешедән дә ким түгел!
Безгә артык җебегәннәр
Һәм әрсезләр тиң түгел.

Тыйнак шул без. Тыйнаклыклар,
Белмим, каян киләдер?
Шуның белән мактанабыз,
Хурланабыз, нигәдер.

Көрәштә, гадәттәгечә,
Җиңәбез тыйнак кына.
Батырларны җиргә алып
Салабыз җыйнак кына.

Каравыл кычкырмыйбыз без,
Түзәбез тыйнак кына.
Мәҗлесләрдә — уйнап-көлеп,
Өйләнсәк — туйлап кына.

Җырласак та, туйласак та,
Йөрмибез уйнап кына.
Уйнап йөрер заманмы соң?
Карагыз уйлап кына.

Тыйнак кына яшибез дә,
Китәбез тыйнак кына.
Без бу җиргә хуҗа да бит,
Дөньяда — кунак кына.

Аптырыйсыз. Әйтерсең лә
Андыйлар бер без генә.
Әйбәтме, әйбәт түгелме? —
Шундый инде без менә.

## Агыйделдә

Агыйделдән ак пароход
Кайтып китте Казанына.
Ә мин кайтмыйм, кайтмыйм әле,
Калам әле азга гына.

Бүген якты Агыйделнең
Патшасы да, колы да мин.
Бүген бәхет — минем кулда,
Бүген бәхет кулында мин.

Белмим, печән исеннәнме,
Белмим, сөю хисеннәнме? —
Рәхәт итеп исергәнмен,
Изрәп китеп исергәнмен.

Яшь таллар да минем кебек
Мәхәббәттән исергәндер.
Бәхетлеләр.
Алар монда
Ул хисне күп кичергәндер...

Сүнә калса, хисләреңне
Агыйделдә яңарт икән.
Бөек гашыйк булыйм дисәң,
Агыйделдә ярат икән.

Сөюдән шашкан йолдызлар
Монда күпме ташлангандыр!
Мәхәббәт дигәннәре дә
Агыйделдән башлангандыр.

Шушы төнем кабатланса,
Мин бәхеттән үләр идем.
Миннән соңгы гашыйкларга
Шушы төнне теләр идем.

Ә җанымда ялкынланып
И дәрли җыр,
И яна җыр...
Ул — Агыйдел турындагы
Иң соңгы җыр,
Иң яңа җыр!

## Салисә Гәрәева

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

●

Баскан җирем — илем хәзинәсе:
Алтын, тимер, уран.
Зәңгәр ахак кебек күл буенда
Ташка басып торам.

Борынгы көй аһәңедәй, күлдән
Ишетәм ят авазлар.
Борынгыча, баш очымнан үтә,
Каңгылдашып, казлар...

Дулкыннарның телен аңлыйм кебек,
Таныш алар моңы,
Үткәннәргә илтә уйларымны,
Алда — тормыш чыны.

Баскан җирем — илем хәзинәсе:
Алтын, тимер, уран.
... Хәзергедән матур киләчәккә
Кыю план корам...

## Сварщик егет

Зур бер цехның бетон идәнендә
Йолдыз чәчә берәү тырышып.
— Узарга да юл бирмисең,— диеп,
Көлә-көлә киттем орышып...

Ул да көлә: — Яуган очкын аша
Үт елмаеп, сиңа килешә!
— Җәлләмим,— ди,— ал шул йолдызларны,
Кесәңә сал кайнар килешкә!..

Зәңгәр ялкын белән тиз арада
Торбаларны ялгап куя ул;
Цехка кергән саен юлларыма
Көлә-көлә йолдыз коя ул!..

●

Ул көн килде. Җиле, кары белән
Өшетте дә мине, туңдырды;
Өмет белән тулы күңелемнең
Канатларын килеп сындырды...

Еламадым. Бәгырь каткан иде.
Үксемәдем — яшем юк иде.
Суына барган хисләр давылында
Суга торган яшен юк иде.

... Тәрәзәдән тышка карадым —
Якынлашкан кышка карадым...

●

Син күрдеңме — ап-ак карлар уйнаганны?
Син сиздеңме — минем нилэр уйлаганны?
Минем уйлар син булганга ак канатлы —
Минем бәхет иярләде ап-ак атны.

... Ак атларда без киләбез, җилә-җилә,
Ах! Кайгы да арттан килә, көлә-көлә...

## Әнкәем

Газиз әнкәм!
Алты карлыгачың
Алты якка очты, талпынып.
Алты балаң алты йөрәк итеп
Алды синең сөю ялкынын...

Һәр йөрәктә бер үк лалә үсте,
Һәр чәчәккә кунды бал корты.
... Бал кортлары кебек эшчән, тату,
Хөр кешеләр тулы ак йортың!..

●

Гаҗәп уйлар кайчак башка килә,
Гаҗәп тойгы ала бөтереп...
Берәү кинәт яулый күңелеңне,
Ә икенче — тарта көттереп.

Бер карасаң, беркем кирәк түгел,
Дөнья иркен, рәхәт, күңел көр;
Сөенәсең: эшем гөрләп бара,
Сәламәтмен, шатмын — и шөкер!..

Ә бер таңда... — салкын мендәреңне
Кочкан килеш күзең ачыла;
Һәм басасың, төрмә соткыныдай,
Ялгызлык һәм картлык каршына!..

## Без килештек

Без килештек кабат. Рәнҗүләрне
Онытырга булдык — күпкәме?
Бер үпкәне генә җиңми калмас
Бергәлекнең матур үткәне...

Ә рәнҗүләр кайтыр: гел кояшлы
Булып тормый көннәр, бәхәссез.
Сәгадәтле көннәр! Үпкә, рәнҗү
Һәм килешү белән рәхәт сез!..

Без килештек кабат — кулларыбыз
Кайнарырак хәзер — иркәрәк.
Үпкәләшмик! — Син дә чын күңелдән
Юат, җылыт, елмайт, иркәләп!..

## Машбюрода

Машинкалар чират бирә пулеметтан,
Ак кәгазьләр шуа тора чуарланып.
Минутына өч йөз удар хәреф төшә —
Ашыгудан машинистка чыга янып.

Саннар ява, ак юлларга тезелешеп
Баса алар, чиратлашып, сабыр гына...
Шулай гөрләп, үз аһәңе-җыры белән
Җиргә ява язгы ләйсән яңгыр гына.

Чират бирә машинкалар пулеметтан,
Яңа сүзләр, яңа саннар туып тора.
Кара юллар буйлап яткан линейкалар
Үз җаена юлдан-юлга шуып тора.

Ә чибәр кыз, чәч дулкынын артка ташлап,
Клавишларга басып гүя уйнап тора.
Дистәләгән кеше өстәл артларында
Ак кәгазьгә басар сүзне уйлап тора.

# САДРЕТДИН АЙНИНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

*Таҗик совет әдәбиятына нигез салучы, таҗик һәм үзбәк әдәбиятларының күренекле вәкиле Садретдин Сәетморат улы Айни 1878 елны элекке Бохара әмирлеге, Гиҗдөвән төмәне, Соктара авылында туа. «Соктара күп милләтле зур авыл. Монда элек-электән таҗик, үзбәк, иранлы мараканнар һәм кайчандыр шунда торып калган гарәпләр бергә, дус яшәде. Нигездә, авыл халкы ике телдә сөйләшә: гарәпләр белән үзбәкләр — үзбәкчә, калган күпчелек таҗик теләндә аңлаша-аралаша иде. Авыл һәм дин башында — таҗиклар, алыш-биреш, сәүдә өлкәсендә үргәнечлеләр хөкемлек итәләр. Башлангыч мәктәп һәм югары классны мәдрәсә кышын да, җәен дә эшли. Шуңа күрә безнең авыл кебек гыйлемле авыл әмирлектә бик сирәк очрагандыр», — дип яза әдип соңыннан.*

*С. Айниның да ата-бабалары гыйлемле була. Бабасы Сәетгомәр хаҗи, мәсәлән, күршедәге ярлырак авылда байтак еллар муллалык вазифасын башкара.*

*«Минем балалык чорым ике авылда үтте. Җәй айларында без Соктарада, дәү әти йортында яшибез. Кышка икенче төмәнгә караган Югары Мәхәлләгә кайтабыз. Авылларның икесе дә Бохарадан төньяккарак, кырык чакрымнарда иделәр», — дип искә ала әдип.*

*Ни сәбәптер, Садретдинны алты-җиде яшьләрендә абыстай мәктәбенә генә бирәләр. Әмма аның «зур мәдрәсәләрдә белем алу» теләген бу мәктәп кенә канәгатьләндерә алмый. Бер җәйне Бохарадан килгән бер зур түрә кечкенә Садриның хәтер сәләтенә исе китеп, шул табында утырган абыйсына «аны укытырга» киңәш итә. Абыйсы аны Бохарага җибәрергә сүз бирә.*

*Садретдинга иҗат юлы, шулай итеп, Бохара мәдрәсәләрендә ачыла. Айни өчен бу данлы кала бәхет, шатлык кына алып килми. Алдынгы карашлы мөгаллим һәм шагыйрь әмир зинданнарының тарлыгын да, әмир җәлладларының камчысын да татып карый. Бөек Октябрь көннәрен ул рухланып, хөрриятькә дан җырлап каршы ала. Айниның зур таланты бары тик Ленин идеяләре белән сугарылган хөррият көннәреннән соң гына чын-чынлап чәчәк ата.*

*С. Айни әсәрләрен ике телдә — таҗикча һәм үзбәкчә язган.*

*Аның автобиографик «Бохара» исемле роман-эпопеясы, илебез чикләрен үтеп, дөньякүләм бәя алды. Галим С. Айниның таҗик әдәбияты тарихын тасвирлаган хезмәтләре, «Мангытлар династиясе» дигән китабы әле дә үз кыйммәтләрен югалтмыйлар. Әдипнең гыйльми хезмәтләре дә илебездә югары бәяләнде, аңа академик дәрәҗәсе бирелде, Таҗикстан Фәннәр академиясе ачылгач ул аның президенты, ә Үзбәкстан Фәннәр академиясенең мактаулы әгъзасы итеп сайланды.*

*Бу хезмәтләре өчен ул ике мәртәбә Ленин ордены белән бүләкләнә. Ул СССР Верховный Советына һәм Таҗикстан ССР Верховный Советына депутат итеп каткат сайлана.*

*Бу санда китерелгән өзек язучының «Бохара» романының бала чакны тасвирлаган өлешеннән тәрҗемә ителде.*

## Садретдин Айни

# БЕРЕНЧЕ ТӘЭСИРЛӘР

хикәя

Шәфрикан төмәненә[1] караган Югары Мәхәллә авылы яныннан Шәфрикан елгасы ага. Ә бу авыл Кызыл Ком чүленең янәшәсендә үк утыра иде. Бер җәйне бу елганы көчле җил белән чүлдән күчкән ком өеме томалап китте. Бу хәл минем күз алдында булды. Без ул көнне көтүче малай Ергаш белән елга аръягында, көтүдә уйный идек. Көн урталарыннан исә башлаган эссе җил икенче көннең иртәсенә безнең авылны басу-кырсыз да, бакчасыз да, сусыз да калдырган иде.

Иртән иртүк әтиләр, капчык һәм китмәннәр алып, бабам бакчасын карарга киттеләр. Мин дә аларга иярдем. Кеше биеклегендәге саман койма белән уратылган бабам бакчасын танымаслык булган, җимеш агачлары бил тиңентен комга күмелгән иде. Ә коймасыз бакчалар, басулар? Аларны табарлык та, танырлык та түгел. Иң аянычы — басуларга да, бакчаларга да бик кирәк суның ком астында калуы иде. Бакчалардан комны читкә дә түгәрсең, ә сугарасы су кайда?

Тиздән белдек, бу хорафат бер безнең Югары Мәхәллә халкына гына кагылмаган икән. Күрше Рубахо, Тезгузар, Карагач, Абдуллаҗан, Мөхәннәд Баки, Качехуран авылларына да житкән. Ком бураны Гиждөвән төмәнендәге дәү әти авылы Соктара күршесендәге Саидато чигендә туктаган булып чыкты. Боларны ишеткән әтием ачынып:

— Бөтен Шәфрикан төмәне бер төндә җирсез дә, сусыз да калды, ком чүленә әйләнде,— диде.

Буш вакытларында ул сату өчен тегермән ташлары ясый, әле шушы көннәрдә генә күрше авыл тегермәнчесенә дип яңа таш төгәлләп килә иде. Әни, әтинең соңгы көннәрдә ком белән булашып эшен ташлавын искә төшерде дә:

— Минем әтиләргә ярдәмләшәм дип бөтенләй эшегездән аерылдыгыз,— диде.— Бик ашыгыч эш дигән идегез ич!

Моңа каршы әти башын чайкап көлемсерәде дә:

— Әйе, бик ашыгыч иде. Тик бу ташның аңа кирәге юк хәзер. Әле генә карап кайттым, су буендагы тегермән дә ком астында калып җимерелгән...— диде.

Җәй айларын без гадәттә дәү әтидән калган йортта — Соктара авылында уздыра идек. Монда безнең җирләр, бакчалар. Әтинең туганнары. Быел исә әти безнең барыбызны да кышка да биредә калдырырга ниятләде. Бабайдан калган иске агач өйне сүтеп, яңа корылмалар өстәп яңа өй өлгертте.

Менә яңадан язлар да житте. Бөтен тирә-як күкрәп, язга шатланып утыра, бакчаларда туктаусыз кошлар сайрый. Билгеле, без, бала-чага, урамнан да кермибез. Шундый якты, кояшлы көннәрнең берсендә бик пошаман хәлдә Югары Мәхәлләдән әти кайтып керде. Бу вакыт мин

---

[1] Төмән — өяз, хәзерге район.

тыкрыкта этем Хайбар белән уйный идем. Әти күренүгә бу хакта башта әнигә кереп әйттем. Әти ана әби-бабайларның исәнлеген әйтте дә, әледән-әле уфылдап, уфыргалап:

— Чәй куй... Биштәрдәге итне алып яшер, мәче алмасын...— дип, өзек-өзек кенә сөйләшеп, әни хәстәрләп өлгергән мендәр өстенә сузылып ятты. Ул никтер бик боек, моңсу иде. Әни түзмәде, читләтеп кенә:

— Әллә берәр хәл булдымы? Тегермән ташларыңны сата алмадыңмы? — диде.

— Ташларны саттым,— диде әти сабыр гына.— Акчасына ике карагач алдым, аларны тураклап, өеп куйдым. Ә менә Шәфрикан...

Әти, үз уйларына чумып, тагын тынып калды. Тагын уфылдап куйды. Әмма инде әнинең кулына «җеп очы» эләккән, ул Шәфрикан елгасын чистарта башлаганнарын белә иде. Әңгәмәне өзмәс өчен:

— Шәфриканны ачалар диләр, хакмы ул? — дип сорады.

— Дөрес. Тик аннан ни файда?! Тотынмаган булсалар әйбәтрәк булгандыр. Су бирәм дип дәһканны бөтенләй малсыз, җирсез калдыралар, имансызлар...

Әти ник болай дип әйткәнен башта аңлашмый тордык. Ничек инде ул елганы арчып су җибәргәч тә халыкка файдага булмасын, ди?

Шәфрикан буенда утырган авыллар былтыр көз көне үк аны комнан арындыру эшенә тотынып караганнар иде. Көч җитмәү сәбәпле бу эш уңышсыз чыкты. Су үтәрлек кенә итеп ачылган тар үзәнне яр буе комнары тагын күмә барды. Шуннан соң мир башлыклары ярдәм сорап әмиргә мөрәҗәгать иттеләр. Әмирлектән елгага яңа үзән ачтыруны сорадылар. Әмир, әлегәчә җыела торган налогтан тыш халыкка өстәмә салым салып, бу эшне башкарып чыгуны Шәфрикан төмәненең дүрт олысына — рәис, казый, салым җыючы һәм караул башлыгына тапшырды.

Бу дүрт түрә башта елганың булачак үзәнен билгеләп, аннары җыен җыеп күпмегә төшәсен, салымның күләмен әйтә дә, әкренләп эшкә керешә.

Инде атабыз Сәетморат хаҗины борчыганы шул икән — сугару көннәре якынлашып килүгә дә карамастан, эшнең очы да, кырые да күренми ди. Алты айга нибары дүрт чакрым ара үтелгән икән. Монда кайтыр алдыннан гына әти анда булган, боларны үз күзе белән күргән.

— Карасаң — кыр тулы халык. Тик алар кемнәр диген? Мир җилкәсен кимерүчеләр. Түрәләрнең аш пешерүче, йомышка йөрүче, куйчы, сакчы, итчеләре генә дә ике йөзгә җыела икән. Эш башындагылар көннәр буе ышыкта, чатырда ята ди. Ник ятмасыннар, үзләре тук, атлары алдыннан солы өзелми. Җир казучыларны көн сүрелгәч кенә эшкә алып чыгалар да, ике-өч аршин буй үтүгә, «бүгенгә җитәр, иртәгә калсын» дип әйтәләр икән.

— Нишләп соң ул алай сузалар? — диде әни.— Нигә ашыктырмыйлар?

— Аларга кая ашыгырга. Халыктан һәр бирмеш көн ун мең таңкә салым кереп тора ич. Бу акчаның яртысы түрәләр корсагында, яртысы кесәсендә калып бара. Нигә сузмасыннар!

Әти борчылып бу хакта безгә сөйләп, аңлатып бетергәндә инде чәйдән кузгалыр чак җиткән иде. Менә ул соңгы йотым чәен уртлап куйды да, әйтергәме-әйтмәскәме дигән кебегрәк бер хәлдә утырганнан соң, әнинең күзенә төбәлеп карап:

— Бер нәрсә эшләдем әле мин. Отышкадырмы, оттырышкамы, белмим. Тәвәккәлләп, әмирнең үзенә яздым әле бу хакта. Бәйнә-бәйнә барсын да яздым. Суның вакытында булмавы халыкка гына түгел, казнага да зыян, уңышлар булмагач, әмир өлеше дә бермә-бер кимиячәк, дидем. Эш башына намуслы кешене куеп, суны тизрәк җибәрәсе иде, дидем. Сезгә моны ул тирәдә үз җирләре булмаган, бары тик дәүләт

һәм халык өчен кайгырткан кеше язды, дидем. Имзамны куймадым, Сез дә бераүгә дә әйтмәссез,— диде.

— Инде ул хатны әмир укыдымы? Кем тапшырды? — дип сорады әни.

— Бохарага энең Корбан Ниязны җибәрдем. Ул тапкыр егет. Әмир ( җомга мәчетенә килгәч аның берәр якынына тапшырырсың, дидем. Иншалла, шәт ул хат хәзер әмир кулындадыр,— дип әти дога кылды. Аннары, бүген беренче тапкыр елмайган сыманрак итеп: — Файдасы тияр, дим. «Сезнең байлыкны кайгыртучы» дип юкка гына өстәмәдем бит мин ул хатка. Аңлар...

Әтинең күңеле язылып киткәндәй күренде. Бераз хәл алгач ул торып остаханәсенә юнәлде. Тиздән без аның киндер тукып утыруын ишеттек. Безнең өйдәге бар нәрсә әтинең үз кулы белән тукылган иде. Күлмәк, ыштаннар да, сөлге, ашъяулыклар да үзебезнеке. Буятырга гына кайбер әйберләрне әти буяучыларга биреп эшләтә, ә күп вакытта җепләрне дә үзе буйый иде. Мөхетдин абыйны Бохара мәдрәсәсенә озатканда гына ул фабрикада эшләнгән тукыма алып чапан-җиләннәрен шуннан тегеп кидерде.

Берәр атнадан җәйге каникулга Сәет Әкбәр белән абыем кайтты. Сәет Әкбәр Һидият хаҗиның зур улы иде. Безнең авылда Һидият хаҗины Оста хаҗи гына дип йөртәләр. Чөнки бездә бераү дә ишек-капка булсын, башка кирәк-яракны булсын аның кебек оста итеп эшли алмый иде.

Тиздән әниемнең Бохарада белем алучы энесе дә килде. Ул Гиждәвән төмәне казые Абдул Вахид улы белән бергә укый иде. Каникулга чыккач та ике-өч атна шуларда кунакта булган икән. Хәл-әхвәл сораштыра торгач Абдул Вахид казый исеменә Бохара әмиреннән әмере ирешүен дә ишеттек. Шулай итеп әти Шәфрикан елгасын ачу эшенең башына Абдул Вахид казый билгеләнүен белде. Моны ишеткәч ул бик тә сөенде. Инде бер-ике көн кунак булган Дәһкан абый әти-әнисе янына ашыккач, ул да, Югары Мәхәлләгә барып, эшнең торышы белән танышып кайтырга ниятләде. Бик үтенгәч әти үзе белән мине дә алды.

Ике авыл арасы унбиш-уналты чакрым иде. Шул көнне үк Югары Мәхәлләгә барып җиттек. Анда үзебезгә кермичә, бабайларга гына тукталырга булдык. Дәһкан абый белән әтинең кайтуын ишетеп, тиздән бабам йортына авыл картлары җыелды. Алар беравыздан Гиждәвән казыеның эшне кызу тотуын, халыкны иртәдән-кичкә чаклы эшләтүен, болай барса бер-ике көннән авылга су киләсен сөйләделәр. Түрә янында нибары ике генә кеше — хезмәтчесе белән йомышка йөрүчесе генә икән. Ул анда симез куйлар суйдырып, сыйланып ятмый, үзенә кирәк ашамлыкны өеннән китертә, староста белән старшиналарга да халыктан туенуны тыйган ди икән. Шуңа күрә ул абруйлы, элгәреге түрәләр биш-алты айда башкара алмаган эшне атна-ун көндә төгәлләп килә ди.

Бу хәбәрләрне ишеткән әти тагын да куана төште. Шундук абыйны үзе белән әйдәп:

— Бүген үк барып күрик. Бу уңышлар сәвабына урында дога да кылып кайтырбыз, — диде.

Без бу юлы да өчәү киттек. Халыкның күрше Рубахо авылы янәшәсендә эшләгәнен белә идек. Бу авыл бездән күренеп үк тора. Без килгәндә билен яшьләрчә буган, кулындагы озын таягына таянган түрә яр буенда иде. Абдул Вахид казый кечерәк ак сакаллы, ачык, карачкыл йөзле, какча гәүдәле тәбәнәк карт иде. Кашлары минем бабам кашы кебек куе һәм озыннар.

Аның белән әүвәл, мәдрәсә шәкертләренә хас булганча, гәүдәсен билдән бөгеп Дәһкан абый исәнләште. Аннары әтигә ымлап:

— Бу минем җизнәм, сезнең алда баш иярга килде, — диде.

— Алайса, ул сезнең беренче мөгаллимегез дә буладырмы?
— Әйе, тәкъсир, ул миңа хәреф танытты, Бохара мәдрәсәсенә укырга урнаштырды,— диде абый.
Әтигә ике кулын сузып күреште казый.
— Беләм, алайса, беләм мин сезне. Дәһкан белән укучы улым сезнең хакта күп сөйләде. Ә бусы кем була?
— Улым,— диде әти.
Казый кулына алып мине чөйде дә, янадан җиргә бастыргач:
— Шушылай зур булып үсәрсең, укымышлы мулла булырсың,— диде. Аннары кызыл кәгазьле конфет алып кулыма тоттырды.— Укыймы?
— Мәктәпкә бу көздә барачак.
Шул вакыт безнең әнинең Корбан Нияз, Раушан Нияз һәм Ниязхан атлы туганнары килеп бастылар. Алар да бирелә эшлиләр иде.
— Ә болары сезнең кемнәрегез? — дип кызыксынды казый.
— Минем туганнарым,— диде Дәһкан абый.
— Әйбәт эшлиләр. Бигрәк тә Корбан Нияз ошый миңа. Тапкыр да, батыр да егет. Андыйлар күп түгел.
Казыйның аяклары арыды, ахрысы, ул утырды. Башкалар да утырыштылар. Карт сүзен дәвам итеп:
— Энегезгә сокланам. Акыллы да, тәвәккәл дә. Юкса бит бик күпләргә моның я берсе, ә икенчесе җитешми. Я ул артык дуамал, яисә акылы җитеп килеп тә, юаш холыклы була. Моның икесе дә яман.
Шулай диде дә Абдул Вахид түрә, Дәһкан абыйга таба борылып:
— Рөхсәт ит Корбан Нияз энеңә миндә хезмәттә калырга. Миңа ул ошый. Гыйлеме бармы? — диде.
— Укымаган шул.
— Зарар юк. Акылы, тапкырлыгы булсын. Башкасына өйрәнер.
Бу сүзләр белән казый Корбан Нияз абыйга борылып:
— Ярый, сез эштә булыгыз,— диде. Аннары ялчысына чәй китерергә кушты. Хезмәтче агач ботагына эленгән хурҗынны алып, аннан бакыр чәйнек белән бер чынаяк чыгарды. Чынаякка чәй агызып башта аны хуҗасына сузды. Аннары безгә өләшеп чыкты.
— Гаеп итмәгез, башка сый-хөрмәт юк,— диде казый. Без дә сауны баскач, кузгалып:
— Әйдәгез, башкарылган эшкә дога кылыйк,— дип халык янына алып китте. Һәр авыл, артель үзенә билгеләнгән җирдә эшли. Алар белән авыл старшиналары һәм старосталар җитәкчелек итә. Без якынлаша башлау белән бу түрәләр ашыгып агач ышыгыннан күтәреләләр дә кычкырып-кычкырып халыкка әмер бирергә керешәләр иде. Абдул Вахид казый шундый «каты тырышкан» бер иләмсез юан старшинаны туктатып:
— Тәкъсир, китмән алып эшләп тә күрсәтсәгез икән,— диде.
Бу хәлдән соң инде безне һәр урында авыл башлыклары халык белән бергә китмән тотып каршы ала башладылар.
Без Шәфриканга Истамсу елгачыгы кушылган төшкә юнәлдек. Бу урында инде буа буылган, балта осталары буа авызына соңгы такталарын кагалар иде. Елга үзәне дә буадан өс якка ачылган, жир казучылар инде буа астына күчкәннәр иде. Абдул Вахид карт старшинаны чакыртып, буачылар артеленә дә түбәнгә күчәргә боерды.
— Монда суны җибәрегез,— диде. Аннары әтигә мөрәҗәгать итеп:— Эшне мин арттан су куып килерлек итеп оештырдым. Бүген без монда, иртәгә су... Кеше үз эшенең нәтиҗәсен күреп торсын. Су иртәгә Рубахо авылына җитәчәк.
Менә елганың югары башыннан, йомычка һәм башка чүп-чарларны куып, болганчык су килүе күренде. Менә беренче көчсез дулкын буа киртәсенә килеп төртелде. Аның артыннан инде зурайганнан-зурая бар-

ган икенче, өченче дулкыннар агыла иде. Бер мәлне су, такта ярыклары арасыннан әз-әзләп саркып торуга да карамастан, буа кырына ук күтәрелде. Елга мөлдерәп тулган иде. Хәзер үк инде бу дулкыннар, буа өстеннән агып, безнең Югары Мәхәллә елгачыгына барып кушылыр сымак тоелды. Менә ул сөенеч! Әйтерсең бу дулкынны ияртеп хәзер үк авылга алып кайтачакбыз!

Әйе, бу көннәрдә авылда Абдул Вахид казыйның мактаулы исеме телдән төшмәде. Әти дә әледән-әле исе китеп:

— Җитмеш алты яшьлек карт бит, ә нинди житез, уңган, эшчән,— дип куйгалый иде.

Тагын берничә ел үткәч кенә мин аның әле күренекле шагыйребез булганлыгын да белдем. Шагыйрь Абдул Вахид Садрый Сарир булган икән ул.

Моны мин очраклы гына белдем.

Өч-дүрт ел укыганнан соң мин авылыбызның кызлар мәктәбен тәмамладым. Әмма остабикәдә күпме укымыйк — хәреф танудан башкага өйрәнә алмадык. Икенче кул беләнрәк язылган булса әле ул китапны да укырлык дәрәҗәдә түгел идек. Язуга бөтенләй тотынмадык та.

Шуннан соң әти мине авыл мәдрәсәсе мөгаллименә алып килде. Мөхетдин абыем белән Сәет Әкбәр хаҗилар да аңардан белем алганнар иде. Иң әүвәл «Белем башы» исемле китапка керештек. Бу китапны бер ай укыдык без. Сүзләрнең мәгънәсенә төшенмәсәм дә, мөгаллим артыннан кабатлап, ятлап барырга тиеш идем. Шуннан «Белем» китабын кулга алдык. Бу китап таҗик телендә иде, тик гарәп язма кагыйдәләрен тасвирлый, анда бик күп гарәпчә мисаллар китерелгән иде. Бу мисалларны, шулай ук, аңламый-нитми ятлап кына бардык. Мөгаллим үзе аларның эчтәлеген белгәндерме, тик һич вакыт миннән «бу ни аңлата» дип сорамады, кызыксынмады. Мине тагын да уйга калдырганы шул, Бохара мәдрәсәсендә укыган әтине дә бу мәсьәлә борчымый иде. Ул минем көндәлек дәресне ничек ятлаганымны тыңлый да:

— Бик әйбәт, улым. Һәрчак шулай укы! — дип мактый иде.

Авыл мөгаллиме сабакларыннан мин ике нәрсәгә өйрәндем. Берсе — әбҗәд санына, ягъни гарәп алфавитындагы аерым хәрефләрнең кайчан, нинди санга тиң икәнен белдем. Икенчесе — шигырьне яратырга өйрәндем. Борынгы газәл, рубаятларның чын мәгънәсен төшенеп җиткермәгәндә дә мине аларның яңгырашы ук әсир итә иде. Өстәвенә, кайбер шигырьләрне инде без абыстай мәктәбендә дә ятлаган идек.

Бу вакытта әле мин үзебезнең тирәдә шагыйрьләр яшәгәнен белми идем. Белү түгел, хәтта ул хакта башыма да килми иде. Шигырьне бит изге җаннар язып калдырган. Бармыни ул хәзер андый изгеләр...

Бер көнне әти ни өчендер мәчеткә мине дә үзе белән алып китте. Мәчет алды тулы халык иде. «Юкса күрмәссең» дип, әти мине биек койма башына атландырды.

— Карап тор, хәзер мәчеттән абыеңның хәлфәсе чыгар. Ул бөек затлардан булыр, галим ул, шагыйрь ул,— дип кисәтте.

Мин аптырап калдым. Халык алдына чыгып баскан кеше бер дә андый изге рухлы затларга охшамаган иде. Үзе ябык, сары гына чырайлы, кечерәк буйлы. Иңендә гадәти ак чапан, ә башында безнең мөгаллим-муллаларныкыннан да кечкенә ак чалма. Гаҗәпсенеп, бу хакта әтигә әйттем.

— Шулай ул, балам,— диде әти.— Кемнең башы буш, шул зур итеп чалма урый, ә акыл иясен болай да таныйлар.

— Нинди шагыйрь соң ул?

— Газәл, рубаятлар яза,— диде.

Бу вакыт намаз башланасы иде. «Бар кайт, улым, өйдә сөйләшербез»,— дип эти мине җибәрде.

Өйдә ул үз кулы белән күчереп язган язма китабын алып минем янга утырды. Китапның соңгырак битләрен ачып берничә шигырь укыды.

— Болар аның газәлләре,— диде. Сүзнең ни хакта баруын төшендерде. Һәр газәл «иса» дигән сүз белән тәгәлләнә. Бу ни дип сорадым.

— Бу аның шагыйрь буларак алган исеме: Иса. Менә бу шигырен ул утыз яшьтә язган. Шуңа анда киләчәгенә якты өметләр нык чагыла. Ә болары соңрак, кырык, илле яшьләрендә иҗат ителгәннәр. Хәзер аңа алтмыштан ашкан, ә яшьлек өметләре әле дә акланмаган,— диде эти.— Ул да ярлы баласы. Гомере буе иске китапларны күчереп яза, хәлфәлек хезмәте белән көн күрә.

Шул чак этинең йөзендә ниндидер ямансулык билгеләре чагылып үткәндәй тоелды. Ул хәтта көрсенеп, тирән сулап куйды.

— Мин дә, хәллерәк булсам, тагын да укыр идем. Туры килмәде. Бәлки миннән дә берәр затлы адәм чыгар иде. Инде син тырыш. Бөтен өметем сездә.

Ул кичне без, эти бик ихтирам иткән Саиб баба Исфахани, Хафиз, ерак Һиндстан илендә яшәгән Бәдел шигырьләрен укыдык. Бу мизгелдә этием, яшереп ширбәт капкан бала сымак, эчке бер яктылык, рәхәтлек кичерә сыман иде.

— Бүгенге көндә дә шигырь язып буламы? Изге дә, галим дә булмаган кеше дә яза аламы аны? — дип төпченүемне дәвам иттем.

— Билгеле, сәләте булган һәркем яза ала,— диде эти. Аннары китабының тагын бер битен ачып куйды.— Бу шигъри дүртьюллыкны мин яздым. Оста хаҗи туганымның мәчет ихатасын матурлап, бизәп яңартуына багышланган ул. Аның мәгънәсе шунда ки, шигырьдәге тавык, богдай һәм су сүзләренең хәрефләрен санга күчерсәң, 1303 килеп чыга. Һиҗрият хаҗи абыең ул ихатаны нәкъ шул мең өч йөз өченче елны башкарган икән.

Бу сөйләшүдән соң минем күңелне әллә ниткән якты нурлар балкытып җибәргән кебек булды. Димәк, хәзер дә матур-матур газәлләр, рубаятлар иҗат итүчеләр бар икән бит! Әнә бит минем эти дә шигъри юллар төзгән!

— Шагыйрь булу өчен, улым, күп укырга, бик күпне белергә кирәк, күп хезмәт куярга кирәк. Безнең Иса хәлфәләр, борынгы Саиб баба, Бәдел, Хафизлар нәкъ шундый акыл ияләре. Үрнәк ал...

— Ә Иса хәлфәдән башка кем дә булса яшиме соң хәзер?

— Әлбәттә. Күп алар. Син белгән Гиждәвән казые, мәсәлән.

Бу сүзләрне ишетү миңа сөенечле дә, көенечле дә тоелды. Нигә мин моны элегрәк белмәгәнмен соң? Теге чакта, очрашканда ук белгән булсам!?

— Яза белсәң икән,— дидем мин.

Эти мине юатып:

— Тырышсаң булдырырсың, улым! — дип өметләндерде. Һәм киләсе көннәрнең берсендә үк үзе язарга өйрәтәчәген әйтте. Әмма ул ышандыргач та әле тагын берничә көн үтте. Мин түзмәдем, кабат исенә төшердем.

— Кәкре-бөкрерәк язам шул мин. Миннән отсаң синең дә язуың эшкә ашмас. Тиздән абыеңнар кайтыр. Сәет Әкбәр матур яза, сине дә ул өйрәтер,— диде эти.— Ә без синең белән киләсе базарда язу әсбаплары ала торырбыз.

Әлбәттә, бу сүздән соң минем түбәм күккә тиде.

**ЛИРОН ХӘМИДУЛЛИН** тәрҗемәсе.

**Усман Алиев,**

Социалистик Хезмәт Герое

# ГОМЕРЛЕК САБАК



Кичтән бик арып кайтсам да, эреп кенә йоклап китә алмадым. Төне буе җаным уйнады. Йокыга гына китәм, тагын уянам. Минем иң яратмаганым: йокламыйча урында яту. Тордым да ишегалдына чыктым. Көнчыгыштан таң сызылып килә. Күкрәкне тутырып-тутырып салкынча саф һава сулыйм. Келәләрне артык шалтыратмыйча гына капканы ачтым, урамга атладым. Безнең өй авылның иң биек җирендә диярлек. Көндезен моннан караганда Зур Чынлыбыз уч төбендә кебек. Әле алай гынамы, аръяктагы басулар да шактый ачык күренә. Йортларны, культура йортын, мәктәпне, терлекчелек биналарын шәйлим. Ерак-ерак басулардан трактор гөрелтесе ишетелеп куя. Эшлиләр. «Язның көне ел туйдыра» диләр, төнне дә әрәм иткән юк. Техника ике сменада эшли. Өлгергән һәр басуны никадәр тизрәк эшкәртеп, никадәр тизрәк чәчеп бетерсәң, шул кадәр файдалы.

Төнге сменадагы агрегатлар авазы бер көчәя, бер тыныклана. Мин аларны тавышларыннан таныйм. Бусы әнә аның тракторы, дим. Тегесе — тегенеке. Кишәрлек башына җитеп, кайчан борылуларын да абайлыйм. Әгәр дә берәрсенең гөрелтесе үзгәреп, колакка ят авазлар ишетелсә, йөрәгем урыннан куба, тавышының тигезләнүен көтеп газизләнәм. Үзем дә сизмәстән, шыпырт кына көлеп җибәрдем. «Кара инде моны» дим үземә үзем. Космик корабльләр очышы белән идарә итүче үзәкмени. Минем тәнемә-җаныма да ниндидер сихри җепләр белән барлык басулар, агрегатлар тоташтырылганмыни. Минем ничек тын алуыма, йөрәгем тибешенә карап бу минутта кырларда ни дә булса үзгәрәме. Нишләтәсең бит?! Барысын да үзең теләгәнчә, җаның теләгәнчә итәсе килә. Күп нәрсәгә өйрәндем бу тормышта, әмма битарафлыкка өйрәнә алмадым. Кайберәүләр мине «кызу канлы» дип тә әйткәлиләр. Бәхәсләшмим, кайнарланып киткән чакларым да буладыр, ә бит артык «салкын канлы» кешеләр дә дөньяны җылытмый, сүрән мичтә икмәкнең дә йөзе килми.

Таң нурлары офык буйлап җәелә. Урамнарның әле берсеннән, әле икенчесеннән машиналар, җигүле атлар узганы ишетелә. Әнә колхоз председателе Алимҗан Әмирхановның да «УАЗ»ы выжлап капка төбенә килеп туктады. Авылда көн кояш чыкканчы ук башлана. Бигрәк тә язгы чәчү, урак өсләрендә.

Ашап-эчтем дә үзем дә кырга ашыктым. Иртәнге сәгать алтыда сменалар алмашына. Аңынчы төнлә эшләүчеләрнең җирен тикшереп, кабул итеп алырга кирәк. Бездә гадәт шундый: һәр механизатор, эшен тапшырмыйча, кырдан китми. Бергәләп һәммәсен ачыклагач, хезмәт паспортларына билге куясың. Эштә бернинди кимчелек табылмаган икән, барысы да технологик карталарда күрсәтелгәнчә үтәлгән икән, «бик яхшы» дип бәялисең. Кайчакларда «дүртле» генә бирәсең. «Өчле», «икелеләр» бездә юк. Уртача, начар дип бәяләрлек эшләрне бөтенләй кабул итмибез, яңадан эшләтәбез, бөтен чыгымнарны гаепленең үзеннән күтәртәбез. Бер тапкыр моны татыган кешенең күзе ачыла. Күңелсезлекләр килеп чыкмасын өчен алдан ук ярыш шартларын һәркемгә җиткерәбез, хезмәт паспортларына ук язып куябыз. Үпкәләргә урын калмый.

Унынчы бишьеллыкта кырчылык өлкәсендә бер яңалык туды: безнең күршеләребез — Буа районы уңганнары «Һәр басуга — сыйфат билгесе!» дип республикабызның барлык игенчеләренә мөрәҗәгать иттеләр. «Һәр басуга — сыйфат билгесе!» Хәзерге этапта икмәк өчен көрәшнең пароле ул. Буалыларның яңа башлангычын бөтен йөрәгем белән кабул иттем. Хәер, бер мин генә дә түгел. КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы да аны бик яхшы дип тапты, җиргә, икмәк үстерүгә бәйле һәр кешенең бурычларын аңлатып карар чыгарды. Бик вакытлы, бик мөһим документ. Сигезенче, тугызынчы бишьеллыкларда без моның хакында әле сүз дә кузгата алмый идек, көчебез җитенкерәми иде.

1964 елның башында Буада үткәрелгән киңәшмәне хәтерлим. (Ул чагында безнең «Ирек» колхозы Буа районына керә иде, 1967 елда Чүпрәле районы яңадан оешты.) Анда республика күләмендәге бер җитәкче катнашты.

— Гектардан 12 центнерда уңыш җыеп ала алмагач, ничек яшәрсез?! — диде ул. — Сез яхшы игенчеләр түгел, ә үзегез яхшы җирләрдә утырасыз, — дип «канга тоз салды».

Райкомның беренче секретаре утырган җиреннән сикереп торды.

— Быел унике центнердан да ким үстермәбез, — дип, бөтен район җитәкчеләре, танылган игенчеләр, терлекчеләр алдында вәгъдә бирде.

— Карарбыз, бу сүзеңне онытма! — диде Казан кунагы. — Унике центнер! Бер уйласаң, әллә ни зур сан да түгел. Ә бит Татарстан буенча шундый уңышны тотрыклы итә алсак, без мәнә болай яшәр идек, — дип баш бармагын күрсәтте.

Унынчы бишьеллыкның беренче елында республикада бөртеклекузаклы культураларның һәр гектарыннан 17,2 центнер уңыш җыеп алынды. Илебез амбарларына бер миллион 640 мең тонна, ягъни йөз миллион пот ашлык салынды. Боларны өч орденлы республикабыз тарихы белми иде. Шулай да хәзер берәү дә баш бармагын күрсәтми.

Мин үзем унике центнер дип хыялланган җитәкчене дә гаепләмим. Заманасы шул булган, мөмкинлекләр шундый булган, аягыңны түшәгеңә карап сузасың. 1961—1965 елларда Татарстанда уртача уңыш нибары 9,4 центнер гына иде бит. Алтмышынчы еллардан башлап безнең «Ирек» колхозы игенчеләренең уңышлары турында республика матбугатында, радио-телевидение тапшыруларында аз

язылмады, аз сөйләнмәде, хәтта үзәк газеталарда да хәбәрләр күренгәләде. Ә уңыш алай шаккатырырлык идеме?! Хәтта әйтергә дә оят. 1950 елда һәр гектардан өч центнер ярым уңыш амбарга кергән. 1960 елда ул 16 центнерга җитте. Егерме центнерның югары ягына беренче тапкыр 1967 елда күтәрелдек. Хәзер дәрман башка, хәзер дәрт башка, хәзер уй-теләкләр башка. Тотрыклы рәвештә гектардан кимендә утыз центнер ашлык җыеп алырга!—Бу бишьеллыкка безнең максат шундый.

«Һәр басуга — сыйфат билгесе!» Бер әйтү белән аңа тел җайлашты. Бер әйтү белән ул тормышыбызның аерылгысыз күренешенә әверелде.

Юк, юк, промышленностька сукырларча ияреп, «түбә астындагы, стена эчендәге» шартларны зәңгәр күк астындагы иксез-чиксез кырларга ясалма рәвештә күчерү түгел бу.

«Һәр басуга — сыйфат билгесе!» Ул минем өчен мода да, күрсәтмә дә түгел, ул минем инануым, ул минем кыйблам, ул минем вөҗданым. Мин аны ничек аңлыйм, ничек күз алдына китерәм?

Көзен дә, язын да җир иң кулай срокларда ничек кирәк шулай эшкәртелсен. Басуына карап алымнары билгеләнсен. Басу өстендә өзеп алып күкрәккә кадарга бер чәчәк дә табылмасын. Сөрү җирендәни чәчсәң, шул гына үсәргә тиеш. Юл читләрендә, багана төпләрендә чүп үләннәре тырпаеп утырмасын. Кирәкле-кирәкмәс урыннардан сукмаклар да салынмасын. Болар берсе дә табигатьнең капризларына бәйләнмәгән. Чынлап-чынлап елагач, сукыр күздән яшь чыга, диләр. Ә безгә еларга кирәк түгел, эшләргә генә кирәк. Тракторга да, тагылма коралларга да аптырамыйбыз. Җаның теләгәнчә эшкәрт җирне, һәр кырны «картинкә» ясa, сыйфат билгесе өчен көрәш җирне эшкәртүдән башлана. Бик тә борынгы нәрсә үзе җир сукалау, тырмалау, йомшарту, ә серләре һаман да бихисап.

Җирне ашлый белү үзе бер фән.

Кайда, кемнән ишеткәнемне хәтерләмим, әмма яшь чагымда бер җыр колакка кереп калган.

«Су сорасам, ут салалар
Янган йөрәкләремә»,

— диелә анда.

Җир-ана да, туфрак та җанлы. Ә без аңа теләгәнен бирәбезме, әллә үзебез дә белмичә «янган йөрәгенә ут өстибезме?!» Минераль ашламалар елдан-ел күбрәк кайтарыла. Ә бит алар төрле: азотлы, фосфорлы, калийлы. Кайсы җиргә кайсын кертергә икәнен белеп эш итмәсәң, каш ясыйм дип күз чыгаруың да бар.

Минераль ашламаларны белмичә куллану врач рөхсәтеннән башка үз белдегең белән дәвалану белән бер ул. Туфракның үзенчәлекләрен, елның ничек килүен (яңгырлымы, корымы) исәпкә алып эшләсәң, ашлама җиргә сый була, уңышны да күтәрә.

«Һәр басуга — сыйфат билгесе!» дибез икән, чәчүне үрнәк төстә үткәрү мәҗбүри шарт. Хәзер гадәттә орлык беренче-икенче класска җиткереп чәчелә. Минемчә, инде гел беренче класска күчәргә вакыт. Дөрес, җиңел бурыч түгел бу. Тулысынча беренче класслы орлык булдыру өчен агрономга да, җитәкчеләргә дә җиде кат тир түгәргә кирәк. Икмәк үстергәндә тирләми дә булмый шул. Чәчү нормасын, орлыкны күмдерү тирәнлеген дөрес билгеләү — барысы-барысы беренче карашка гади генә кебек үзе, ә төптән уйласаң, гаҗәеп тә четрекле иҗади эш.

Орлыклар борын төртеп чыккач, елның-елында басуларны кабул итү оештырыла. Бик тантаналы да, бик җаваплы да йола бу. Колхоз

идарәсе, ревизия комиссиясе членнары, халык контролерлары, ветераннар, механизаторлар җыйналып кырдан-кырга йөри, карыйлар, тикшерәләр. Һәр квадрат метрда күпме орлык тишелгән — берәмтекләп санайлар. Монда кечкенә генә гаебеңне дә яшереп калдыра алмыйсың. Басу өсте, күзгә сыман, эшкә мөнәсәбәтеңне дә, намусыңны күрсәтеп тора.

Сүз дә юк, үсемлекләрне кабул итү — бик тә үтемле тәрбия чарасы. Бөтен авылдашлары алдында кемнең йөзен кызартасы килсен. Тик шунысы да бар: орлыклар тишелеп чыккач, механизатор хезмәтендәге кимчелекләрне тапсаң да, соң була инде. Атын урлаткач, сараен бикләгән агай кебегрәк хәлдә каласың. Моңа юлыгырга теләмәсәң, чәчү барышында һәммәсен дә энә күзеннән үткәреп торасың...

Мин кырга килеп җиткәндә бригаданың учетчысы Кәшшаф җир өстендә иде инде. Карашы шундый үткер, бар дөньясын онытып, җир өстенә төбәлгән.

— Энә югалттыңмы әллә? — дип шаяртып алам үземчә. — Зурайткыч пыяла кирәкмиме?

Ул башын күтәрде. Елмая. Без бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз. Күптәннән икебез дә бер бригадада.

Участокның икенче ягыннан безгә таба культивация агрегаты килә. Без икәүләп туфракны тикшерәбез. Учка алып йомарлап кысып карыйм. Чем-кара туфрак ул безнең җирләр. Элек-электән аны мактап нинди гыйбрәтле сүзләр генә әйтмәгәннәр. «Тәртә утыртсаң, тарантас үсәрлек», «икмәккә сылап ашарлык», «гөл туфрагы» дигәннәре бигрәк тә киң таралган. Мин аларның берсенә дә каршы чыкмыйм. Шулай да үзем тапкан сүзләрнең мәгънәсе икенчерәк: «Тиреңне агызсаң, шатлык үсә торган җир» дим. Эшкәрткәч, ул каз мамыгыдай кабарып-күпереп китә, ятып ауныйсы, тәгәрисе килгәндәй чаклар була. Бу җир өстенә каты-каты басып йөрергә дә җаным ытыргымый.

Кәшшаф белән икәүләп туфракның ничек эшкәртелүен карыйбыз, бармаклар белән казый-казый тирәнлеген үлчибез, үзебезчә берсен дә күздән ычкындырмаска тырышабыз. Егетләргә бәйләнергә сәбәп таба алмыйбыз. Яхшыны яхшы димичә булмый. Тракторчыларның хезмәт паспортына да бишле билгеләре куябыз.

Смена алышыну вакыты бик тә әһәмиятле. Элекке елларда механизаторлар туктап торган арада тракторларны карау белән чикләнәләр иде. Хәзер тәртип үзгәрәк. Тырма, культиватор, чәчкеч, катоклар җентекләп тикшерелә. Тырмаларның һәр теше, культиваторларның һәр кискече күздән үтә. Шунсыз җир эшкәртү культурасын күтәреп булмый, шунсыз басуга чыгарга рөхсәт юк.

Бөтенесе дә тәртиптә кебек иде, техника төзек, һәркем нәрсә эшләсен белә, бернинди өзеклек юк, рәхәтләнеп эшлә дә эшлә генә инде. Нәкъ менә шушы көнне оятка калдым. Таңнан торып кырга чыкмасаң, тырышып йөрмәсәң, эшнең рәтен белмәсәң, бер хәл иде.

Туфрак кибеп китмәсен дисәң, культивация артыннан ук басуны чәчеп, катоклап та куярга кирәк. Участок башына чәчү агрегатлары килеп җитмичә җирне культивацияләргә керешмибез.

Җир эшкәртү һәм чәчү агрегатларын кирәгенчә көйләп бодай чәчеләчәк басуга озаттым да шикәр чөгендере участокларына ашыктым. Анда эшләр технологик карталарда каралганча бара иде. Әллә ни артык юанмадым, ниндидер күңелсезлек барын сизенгән шикелле кире борылдым. Мотоциклда бара идем, миңа якынлашып килүче машинаны күреп, туктап калдым. Шунда ук танып та алдым: райком секретаре машинасы.

Ишектән чыга-чыга ук секретарь:

— Исәнмесез! — диде коры гына. Әллә кулын бирде, әллә бирмәде, хәтерләмим.

Әчем жу итеп китте, президиумнарда бергә утырган, күп нәрсәне уртага салып сөйләшкән, сине тиң күреп киңәшкән секретарь танымаслык иде.

—Миннән дә яшерә-яшерә эксперимент ясыйсыз, ахры,— диде ул.

— Юк, юк, бернинди экспериментка тотынганыбыз юк, — дидем үземчә беркатлылык белән.

— Алайса, нигә культивацияләнмәгән җиргә бодай чәчәсез? — диде секретарь шактый кыза төшеп.

— Сез бәлки күрше колхоз җире белән саташтыргансыздыр, — дим.

Ул күзенең агы белән карап алды.

— Сез нәрсә? Ун ел райкомның беренче секретаре булып эшләп «Ирек» колхозы чикләрен дә белмидер дип уйлыйсыз мәллә?

Үземнең нинди ялгыш җибәрүемне аңладым. Кирәгеннән артык беркатлы булуым өчен үкенеп тә куйдым, әмма барыбер бирешергә теләмәдем.

— Кайсы кырда? — дип сорадым.

Секретарь бодай чәчелергә тиешле урынны әйтте.

— Булмас, — дидем мин кырт кисеп. — Культиваторлар таккан тракторны да, чәчү агрегатларын да анда мин үзем озаттым.

— Әйдә, киттек. Юл өстендә сүз көрәштереп торыр вакыт түгел.

Машина борылып алга ыргылды, мин мотоциклда аның артыннан.

Басуга килеп җиттек.

Җир эшкәртүчеләр дә, чәчүчеләр дә тик тора.

— Менә карагыз, — диде секретарь, культивация ясамыйча чәчелгән җирләрне күрсәтеп.

Телем тотлыкты. Маңгаемнан тир бөртекләре бәреп чыкты, нәрсәгәдер сөртенеп, чак егылмадым.

— Мин бит аларга болай эшләргә кушмадым, — дидем акланырга теләгәндәй.

— Социалистик Хезмәт Герое җитәкләгән бригада кырында мондый хәлгә юлыгырмын дип уйламаган идем. Дан, хөрмәт сезне дә боздымыни инде?! — диде секретарь ачынып. — Беркем белән дә үпкәләшәсе килми, безнең нервлар да тимердән түгел, мәҗбүр итәсез бит, мәҗбүр итәсез бит... Их, сезне... Әллә инде саубуллашып та тормады, шап иттереп машинасының ишеген япты, колхоз үзәгенә таба китеп барды.

Мактаулы кыз туйда сыната, дигәндәй, хурга калдым. Тракторчыларга, чәчүчеләргә нидер әйтергә телӘдем — тавышым чыкмады. Башыма гөнаһлы шом килде. Әллә, мин әйтәм, Усманны кызык итәргә җыенганнармы, чәчүчеләрнең агротехника таләпләрен бозуын белеп, кемдер райкомга хәбәр иткәнме?! Ике-өч тапкыр әйләнергә дә өлгермәгәннәр — өсләренә беренче секретарь килеп чыккан! Юк-бар уйларым өчен үземне ачуланып аттым.

Мин бала-чага түгел, чәчү, урак өсләрендә мондый «кайнар коймак»ның нинди ризык икәнен аңлыйм. Минутында-сәгатендә райком бюросы җыеп, утлы табага бастырулар, учет карточкасына кертеп каты шелтә бирүләр, кайбер җитәкчеләрне, белгечләрне эштән алулар, хәтта партиядән чыгарулар да ерак йөрми. Бер кырын эшнең күләгәсе колхоз председателенә дә, партия оешмасы секретарена да, авыл советы председателенә дә, агрономга да, бригадирларга, механизаторларга да төшә. Берсе дә өлештән читтә калмый.

Ни хикмәттер, үз-үземне тынычландырырга көч таптым.

— Ни булса, шул булыр, анысы алар эше, — дидем. — Башны ташка орып булмый хәзер. Яңадан чәчүгә тотынырга кирәк. Кояш әнә никадәрле күтәрелгән. Иртәнге күңелсезлекләр өчен үз-үзеңне битәрләп, көнне югалтсаң, тагын да зуррак зыян китерерсең.

— Нәрсә булды? — дип механизаторлардан сорыйм.

Дәшмиләр. Арада беренче, икенче класслылары бар. Өлкәннәре, яшьләре. Алар белән җирне, икмәкне кадерләү турында бер тапкыр гына сөйләшкәнме. Бөтенебез бергә киңәшеп «һәр басуга — сыйфат билгесе!» алыр өчен көрәш җәелдердек. Менә сиңа сыйфат билгесе... Культивацияләмичә чәчәргә ярамаганын белмиләрме?! Бу бик гади нәрсә. Моны аңларга әллә ни белем дә, тәҗрибә дә кирәкми. Нишләтәсең бит, белә-белә бөлгәннәр.

— Нәрсә булды? — дип кабатлыйм. — Кемгә үч иттегез?!! Җир бит ул уенчык түгел, аның белән шаярырга ярамый.

Өлкәнрәк яшьтәге чәчүче алга чыкты.

— Килеп җиткәндә генә культиваторның нәрсәседер ычкынган. Механизаторлар аны төзәткән арада чәчә торыйк мәллә? — диген идек. — Көне бигрәк тә алтын ич. Эшләми торуы җинаять кебек. Туфрак та каты түгел. Секретарь күзенә чалынмасак, үзең дә сизми кала идең әле. Иртә таңнан райкомнан килеп җитәрләр дип кем уйлаган бит аны.

Бергәләп культиваторны көйләдек. Эшкә тотындылар. Тик күңелемне яңадан хәвеф билəп алды.

Колхоз председателе Алимҗан Әмирханов, партия оешмасы секретаре Шамил Йонысов, агроном Шамил Сәләхов күзенә ничек күренермен, дим. Аларны да уңайсыз хәлдә калдырдык бит. Райкомның беренче секретаре берсенә дә рәхмәт әйтеп китмәгәндер. Эшне зурракка җибәрсә дә, үпкәли алмыйсың. Ни булса да, җаваплылыкны үз өстемә алачакмын, башка берәүнең гаебе юк монда. Чәчүчеләр ашыккан икән, бусы да безнең эштәге кимчелек лә. Димәк, бөтен кешенең күңеленә барып җитәрлек итеп аңлата белмәгәнбез. Бер үк сүзне төрле кеше төрлечә кабул итә, кешесенә карата сүзен дә табарга кирәк. Кайчакта һәммәсен дә бер аршин белән үлчибез, бик күп җитешсезлекләрнең нигезе шунда яшеренгән.

Кайсы гына кырга барсам да, ни генә эшләсәм дә, бодай кырындагы «ЧП» башымнан чыкмады. Уйламаган уем, искә төшермәгән көнем калмады. Башка чакларда уйланып-уйланып та тәгаен генә аныклап бетермәгән нәрсәләргә карата үз билгеләмәләремне таптым.

Колхоз җыелышларында, район, республика күләмендәге гыйльми конференцияләрдә, газета-журнал битләрендә, радио-телевидение тапшыруларында уңышның төрлелеге хакында әледән-әле сөйләнелә, языла. Нинди генә анализлар ясалмый.

Унынчы бишьеллыкның беренче елында республикабызда бөртеклекузаклы культураларның һәр гектарыннан моңарчы күрелмәгән уңыш алынды. Татарстан игенчеләрен зур җиңү белән КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев котлады.

Шатланырлык эшләребез бар. Монысы бәхәссез. Әмма без әле бөтен мөмкинлекләребезне дә файдалана беләбез дип тә әйтә алмыйбыз. Республикабыз хуҗалыкларында уңыш күләме нәкъ кое сиртмәсе сыман тирбәлеп тора, төрлелек зур. Шундый саннар хәтердә калган. Татарстанның унике колхозында һәм совхозында уңыш утыз центнердан югарырак. 173 хуҗалык 20—30 центнер дәрәҗәсендә. Безнең колхоз да шуларның берсе. Без гектардан 26 центнер

бөртек җыйнап алдык. Ә бит егерме хуҗалыкта уңыш ун центнердан да түбәнрәк булган. Сарман районының «Петровка» совхозында уртача уңышның 41,5 центнерга җитүен белгән кешегә уйланырлык, бик уйланырлык. Барлык колхозларда, совхозларда да шул ук тракторлар, шул ук тагылма кораллар, шул ук комбайннар. Минераль ашламаларны бүлүдә, яңа сортлар белән тәэмин итүдә дә зур аерма юк. Ә уңышта аерманы аңлатып бетерә алмаслык. Дөрес, төрле зонада туфрак төрле, тик шунысын танымыйча булмый, республикабызның төньягындагы кайбер хуҗалыклар гомер-гомергә икмәк үстерү белән дан тоткан районнарны да узып киттеләр. Бер үк хуҗалыкта да бригада белән бригада арасында аерма бар.

Мин бу саннарны тикмәгә генә хәтерләмәдем. Мондый чуарлыкның каян килеп чыгуын аңлатырга исәп. Әлеге дә баягы, кешеләрнең икмәк үстерүгә мөнәсәбәте чагыла монда. Кемдер җир эшкәртү кагыйдәләрен боза, кайсыдыр начар орлык чәчә, өченчеләре ашламаларны дөрес кулланмый, дүртенчеләре урып-җыю барышында бөртекне югалта. Икмәк үстерү өчен мең дә бер шөгыль башкарырга кирәк дисәм, арттыра дип гаепләмәгез. Ел буена эшләнгән эшләрне берәмтекләп санасаң, чыннан да шуңа җыйнала ул. Шушы «мең дә бер шөгыльнең» берсен аннан-моннан башкарсаң да, калган меңенең кадере китә. Һәр басу «сыйфат билгесе» таләпләренә җавап бирсен дисәң, һәр эшне үрнәк төстә эшлә. Җир сукалаганда киткән хатаны чәчү вакытында төзәтеп булмый ла...

Колхоз председательләре, белгечләр авызыннан «күрше колхозда яңгыр күбрәк яуды», яисә «урак өстендә аларда аяз көннәр күбрәк булды» дигән сүзләрне аз ишетмәдем. Берәүнең дә «без туңга сөрүне тәмамлый алмадык», «без чәчүдә сыйфат бозуларга юл куйдык», «без урып-җыюга әзерлексез керештек» дип чыгып кычкырганы юк әле. Райком секретаре күреп калмаса, без дә «культивация ясамыйча бодай чәчтек» дип сөйләп йөрмәс идек.

«Без коммунистик хезмәтнең җиңүенә килербез», дип әйткән Владимир Ильич Ленин. Без бу юлда аз казанышларга ирешмәдек, әмма көрәш әле дә туктамаган. Моны һич кенә дә үз көенә, үз агымына куярга ярамый. Сүз уңаенда шуңа тукталасы килә. «Фәнни-техник революция чорында җитәкчеләр нинди булырга тиеш?» дигән темага соңгы вакытларда еш кына бәхәсләшәләр. «Ул киләчәкне күрә белергә, перспектив мәсьәләләрне оста чишәргә, көндәлек мәшәкатьләр белән күмелеп калмаска тиеш» дигән фикерләр көннән-көн көчлерәк яңгырый. Мин дә бу тезис белән бәхәсләшмим. Әмма ачыклыйсы килгән нәрсәләрем бар. Минемчә, бүген белән киләчәкне беркайчан да бер-берсенә капма-каршы куярга ярамый. Чөнки бүген белән киләчәк арасында сызып куйган чик юк. Бүген агач тамыр җибәрмәсә, иртәгә җимеш бирә алмый. Бүген кабул ителгән акыллы план иртәгә дә комачаулык тудырмый. «Мин зур проблемалар турында кайгыртам» дип, председатель чәчү барганда яисә урак урганда үз бүлмәсенә бикләнеп утырса, мондый хыялыйны тормыш дулкыны бик тиз ярга бәрәчәк. Һәр көннең үзенең җитди проблемалары, ашыгыч эшләре бар. Алардан читтә икәнсең, киләчәкне дә күрә алмыйсың. 1976 нчы елның бай уңышын урып-җыйганда, әйтик, тактиканы көненә берничә тапкыр үзгәртергә туры килде.

Комбайннар тезелмнәрне суктырырга гына керешә, шунда ук коеп яңгыр явып китә. Ә икенче басуга болытның канаты гына тиеп үткән. Әгәр дә председатель хәлне белеп тормаса, оператив карар кабул итә аламы?! Юк! Ә без нишләдек?! Кайсы басуда яңгыр булмаган, комбайннарны шунда куабыз. Кайда корырак — шунда эшлибез. Урып-җыю транспорт звеноларының эшен маневрлаштыру өчен үзеңә дә

кырда булырга кирәк. «Чапаев» кинокартинасын караучылар игътибар иткәннәрдер, һөҗүм барышында командирның урынын Василий Иванович бик ышандырырлык итеп сурәтләп күрсәтә. Икмәк өчен барган көрәштә дә шулай ук, һәркем үз урынында булырга тиеш. Райкомның беренче секретаре иртә таңнан торып, кырга чыккан икән, бу да табигый күренеш. Ул сводкаларны анализлап үз бүлмәсендә генә утырса, кырларны күз алдына китерә алыр идеме соң? Машинаңны, мотоциклыңны юлда калдырып, басуларны җәяүләп әйләнсәң, тагын да күбрәк күрәсең, күргәч, фикер дә туа, кешеләргә әйтер сүзеңне дә табасың.

Леонид Ильич Брежневның «нәтиҗәлелекне күтәрү өчен нәтиҗәлерәк көрәшергә кирәк» дигән сүзләрен бик киң мәгънәдә аңлыйм мин. Белемеңне, осталыгыңны арттыру, тәҗрибәңне баету, туктаусыз эзләнү, кешеләрне ышандыра, ияртә белү, каршылыклар белән аяусыз көрәшү ул.

Көрәшергә чыннан да мәйдан киң. Данлыклы Кубань якларында түгел, ә Татарстан җирендә һәр гектардан уртача 41 центнердан артык уңыш җыеп алучы хуҗалыклар барында ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, тынычланып калырга хакыбыз юк. Әйе, әйе, хакыбыз юк! Иртәгә, берсекөнгә уртача уңышны илле центнерга җиткерү максаты куелыр. Бу — безнең өчен хыял түгел. Үзебез үк яңа культура — тритикаленең һәр гектарыннан 51 әр центнер бөртек суктырып алдык. Ул арыш белән бодайны кушылдырудан туган. Тритикалене беренче ел игүдә үк шундый уңышлар яуладык, аның мөмкинлекләре тагын да зуррактыр дип уйлыйм.

Без аны «Казан-38» сортлы борчактан бушаган биләүле пар җиренә 2 нче сентябрьдә чәчтек. Бу, безнеңчә, соңрак булды. Чәчүлек орлык кайтып җитмәгән иде. Борчакны җыеп алуга участокны 2 нче августта 23—25 сантиметр тирәнлектә сукаладык. Чүп үләннәре баш төртү белән культивация үткәрдек. Чәчүгә ике көн кала туфракны 7—8 сантиметр тирәнлектә яңадан культивацияләдек, бер үк вакытта гектарга ике центнер исәбеннән туфракка минераль ашламалар керттек. Чәчүлек орлык суперэлита иде, гектарга ике миллион 400 мең бөртек туры килерлек итеп чәчтек, әлбәттә, чәчүлек орлыкны агуларга да онытмадык. Чәчүдән соң өстәмә рәвештә туфракны катоклау үткәрдек. 6—7 сантиметр тирәнлеккә күмдерелгән орлыклар бердәм тишелеп чыкты. Тритикале көзгә бодайга караганда да куәтлерәк тармакланды, гәрчә, әйткәнемчә, чәчү белән бераз соңарсак та, үсемлекләр кышка бик матур керде.

Кышын щитлар ярдәмендә кар тоттык, аларны күчерә-күчерә, карның тигез ятуына ирештек. Язын гектарга өч центнер исәбеннән туфракка минераль ашламалар керттек һәм участокны диагональ буенча тырмалап чыктык. Үсемлекләрнең тармаклануы гаҗәпләнерлек иде. Бер төптән хәтта унар сабак киткәнен дә күзәттек.

Тритикале көзге бодай белән бергә өлгерде. Үсемлекләрнең биеклеге 110—120 сантиметр иде. Бик яңгырлы ел булуга карамастан, бу культураның сөрлекмәве безне бигрәк тә сөендерде. Уңышны аеры ысулы белән җыйнап алдык.

Беренче елны без аны тугыз гектар гына чәчкән идек, шуннан 459 центнер бөртек суктырдык.

Яңа культура — тритикале җиребезнең мөмкинлекләренә бөтенләй икенче күз белән карарга мәҗбүр итте. Моңарчы күнеккән саннар күләгәдә калды. Гектардан — 51 центнер. Моннан да ышандырырлык пропаганда кирәкмидер. Тормыш үзе уйларга, фикерләргә, омтылышларга тәэтмә кертә.

Алдагы елда без инде тритикаленең мәйданын уналты тапкыр арттырдык. Үзебезне генә дә кайгыртып калмадык, яңа культура орлыгын «Путь Ленина», «Дружба», «Авангард», «Йолдыз», Ленин, Бауман, Фрунзе исемендәге колхозларга да бирдек.

Соңгы елларда үзләштерелгән тагын бер сорт турында әйтәсе килә. Сигез гектар мәйданда беренче тапкыр «Мәскәү-35» сабан бодаен чәчкән идек, уңышы 36,2 шәр центнер чыкты. Ул да өметле күренә. Аның мәйданын да 100 гектарга җиткердек.

Уңдырышлы яңа сортларны үзләштерү, районлаштыру шулай бертезлексез бара ул.

Республикабызның төрле районнарында, төрле зоналарында рекордлы уңыш җыеп алулары турында ишетергә, укырга туры килә. Болар безгә кабат-кабат искәртеп тора: эшкә җигәсе чыганакларыбыз бихисап. Шулай булырга тиеш тә: галимнәребез яңадан-яңа сортлар чыгара, яңадан-яңа машиналар иҗат итә, ә без аларның эшен кырларда дәвам иттерергә бурычлы. Үзебез дә үзгәрмәдек түгел, куәтле тракторларга, комбайннарга утыручыларның күбесе урта белемле, беренче-икенче класслы механизаторлар.

Партиябез һәм хөкүмәтебез авыл хуҗалыгын күтәрү турында даими кайгырталар, унынчы бишьеллыкта бу максатларга 170 миллиард сум капиталь салым каралган. Җирләрне мелиорацияләүгә 40 миллиард сум бүленгән. Моны әйтергә генә җиңел. Тотылган чыгымнар, күрелгән чаралар рекордлы уңыш булып ил табынына кире кайтырга тиеш тә. Без шул чагында гына Илгә, Көнгә ачык йөз белән карый алабыз.

... Сәгать уннарда бодай басуына колхоз председателе Алимҗан Әмирханов, партком секретаре Шамил Йонысов килде. Икесен бергә күргәч, үземчә уйлап та куйдым. «Кыздырырга җыенганнар». Исәнләшүләреннән, йөзләреннән ул-бу сизелмәде. Алар икесе дә миңа караганда күпкә яшь, күз алдымда үскән җитәкчеләр.

— Эшләр барамы, Усман абый? — диде Алимҗан гадәтенчә бер якынлык белән.

— Райком секретаре безнең хакта бернәрсә дә әйтмәдемени? — дидем.

Тегеләр сагаеп киттеләр.

— Шул дәрәҗәдә сүз куптарырлык нәрсә эшләдегез? — дип гаҗәпләнде Шамил.

Аңлашылды: райком секретаре «вакланып» тормаган. Барысын да үзем сөйләп бирдем.

— Гомерлек сабак булды бу миңа, — дидем авыр сулап. — Гомерлек сабак.

Күңелсез хәлне бригаданың партия-комсомол группасында тикшердек. Һәр нәрсәне үз исеме белән атап әйттек. Гаепләләрне үз иптәшләре «мунчага кертте».

Һәр басуга сыйфат билгесе алу җиңел түгел, озын чылбырның бер генә буыны да йомшак булмасын, югыйсә, ул өзелә, күпме хезмәтнең кадерен җибәрә. Баланы матур язарга күнектергән кебек, игенчеләр сафына кушылган һәр егетне, һәр кызны матур эшләргә өйрәтергә кирәк.

Бу уңайдан бер яңалык турында әйтәсем килә. Колхозыбыз урта мәктәпкә трактор, кирәкле тагылма машиналар бирде. Малайлар, кызлар игенче һөнәренә укыганда ук өйрәнә башладылар. Балалар арасына ашкынып барам, үзем белгәннәремне, кичергәннәремне алар күңеленә салып калдырырга тырышам, җирнең чын хуҗалары, җирне матурлаучылар матур язарга өйрәнгәндә үк тәрбияләнсә, алар без-

нең өметләрне дә аклар, илнең мәшәкатен, илнең язмышын да үз иңнәренә салыр.

Яшәгән саен тормыш мәгънәсен тирәнрәк ачасың. Менә мин Владимир Ильич Ленин кул куйган беренче Совет декретлары турында торып-торып уйланам.

Җир, Икмәк, Тынычлык. Дөньяда беренче социалистик дәүләт беренче адымнарын шушы сүзләр белән башлады. Алтмыш елдан соң кабул ителгән яңа Конституциябездә дә җирне һәм тынычлыкны саклау иң изге бурычыбыз санала.

«Хәзерге һәм киләчәк буыннар интересларында СССРда җирне һәм җир асты байлыкларын, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясын саклау һәм фәнни нигездә рациональ файдалану өчен, һаваны һәм суны чиста тоту, табигый байлыкларны кабат җитештерүне тәэмин итү һәм кешене чолгап алган мохитны яхшырту өчен кирәкле чаралар күрелә» дип белдерә безнең Ватаныбыз. Кайсы илдә яшәүче хезмәт иясенең хыялы түгел икән бу?! Күрә дөнья, белә безнең нәрсәгә йөз тотуыбызны.

Мин тагын бер статьяны искә төшерәм. «Колхозлар били торган җир аларга бушлай һәм сроксыз файдалануга беркетелә». Безгә бушлай бирелгән бу җиргә гасырлар буена кан-яшь түгелгән. Безнең яклар турындагы «Чынлы бәете»н генә искә төшерик. Бу җирдә без бары тик матурлык, муллык тудырырга, икмәк үстерергә генә хаклы.

«Кылыч ача алмаганны икмәк ача» ди халык. Икмәк илнең иминлеге дә, киләчәге дә ул. Икмәк игүчеләрне үстерә белсәк, илнең көне якты булыр.

Икмәк кылычтан үткер булмаса, икмәк кылычтан өстен булмаса, икмәк кылычтан гомерлерәк булмаса, без бүген «кылычлардан сабан ясаучыга» табыныр идекме!..

Язманы журнал өчен **МИДХӘТ МИНШИН** әзерләде.

**Шамил Рәкыйпов**

# ДНЕПР ЯРЛАРЫНДА ТАЛЛАР БАР



Кояшта янган, зифа буйлы чибәр кыз каядыр ашыга иде. Күзләрендә чагылган шатлык, бөтен төскилбәте, җил-җил атлавы аның чиксез бәхетле, тормыштан канәгать булуы турында әйтеп тора. Аңа ничә яшь? Мөгаен, уналтыдыр. Яки унҗиде. Кызлар хәзер, «Комсомол» сортлы җир җиләге сыман, тиз өлгерә, зур булып үсә.

Яр өстендә кызны егете көтә икән. Ул, кояшта җемелдәп көмешләнеп яткан суга карап, әрле-бирле йөренә. Өстенә кыска җиңле челтәр майка кигән, ак чалбардан. Калку буйлы, киң җилкәле егет. Ул, мин шулай мәңге яшь, тәннән көч ташып торган килеш яшәрмен дигәндәй, дөньяга хуҗа булып, ашыкмый гына атлый, куерып үскән агачлар күләгәсеннән килүче ак сумкалы кызны күрми әле. Кыз талпынып куйды: егетне күрде. Ләкин шунда ук тынычланды. Көттерә төшсәм, кадерлерәк булырмын, дип уйлады, күрәсең. Ул назлы итеп елмая-елмая атлый. Килүләре карап туймаслык. Матурлыгы йөрәккә ут ягарлык. Менә ул нечкә биленнән ашып киткән, башын чайкагач алга күчкән калын толымын, комачауламасана дигәндәй, ак сумкасы белән күкрәгенә кысып юлын дәвам итте.

Толымнар... Алар йөрәккә нык уелган хатирәләрне яңарттылар.

Сугыш башлангач, туган илне саклаучылар сафына тизрәк басу өчен ничаклы кыз, көзге алдында иренен тешләп, яшьтән тулып, озын чәчен кискән, аны истәлеккә сандык төбенә салып калдырган яки үзе белән ут эченә алып киткән. Дау тынып торган араларда землянкаларда сагыну җырлары яңгыраган, солдат капчыгы төбендә бөгәрләнеп яткан калын толымнар кыска чәчкә тагылган.

Ә бераздан кызлар сөеклесе белән күрешергә түгел, мәрхәмәтсез дошман белән очрашуга — һөҗүмгә киткәннәр. Туплардан атканнар, сугыш кырында яралыларны бәйләгәннәр, самолетта очып барып, фашистны дөмбәсләгәннәр... Мәңгелек йокыга талганнарның кабереннә назлы толымнарын да салып калдырганнар.

Днепр ярына сөйгәне белән кавышырга килгән чибәр кыз мондый гыйбрәтле хәлләрне ишеттеме икән?

Кыз, толымы белән уйный-уйный, егетенә таба бара. Алсу битләрендә, әле сулмаган иреннәрендә пакь елмаю. Әйтерсең ул шау чәчәккә төренгән яшь алмагач...

Алар очраштылар. Салават күпере калыктымени: тирә-юньгә нур сирпелде. Кулга-кул тотынуны чиксез хуплагандай, талгын җилгә таллар баш иде, табигать иркәләре — назлы чәчәкләр хуш ис бөркеде.

Алар яр буйлап киттеләр. Дөнья зур куаныч, тәкатьсез шатлык белән мөлдерәмә иде.

...Монда нәкъ утыз биш ел элек кичү булган.

Монда Украинаны тизрәк азат итү өчен дошман белән бугазга-бугаз килгәннәр.

Монда ничаклы кешенең чәчәктәй гомере өзелгән... Шуларның берсе — якташым Рамил Әбдершинга, сөйгәне белән киткән әлеге егет кебек үк, нибары унсигез яшь булган. Боларга аның турында сөйләсәм, геройның каберен эзлим дисәм, юл күрсәтерләрме?

Аста чал Днепр ага да ага... Яр читендә суга иелгән тузгак таллар, сугыштан соң да дистә еллар сөйгәнен көтеп сагыш йоткан тол хатыннар күк, тирән уйга чумганнар. Бу таллар дәһшәтле көннәрне, кан, вәхшәт тулы төннәрне хәтерлиләрдер әле.

Ул чакта да сентябрь шундый кояшлы булган...

## Ышаныч ул канат бирә

*«Мин Совет Армиясендә хезмәт итәм. Апам миңа авылыбыздан Советлар Союзы Герое чыгуын язып җибәрде. Ул — Рамил Әбдершин. Авылдашыма нинди батырлык күрсәткән өчен Герой исеме бирелде икән?*

*Ш. Габбасов.»*

Өченче танк армиясенең 69 нчы механикалаштырылган бригадасы, ничә урында вәхшиләрчә үтерелгән совет кешеләренең мәетләре каршында тын калып, дошманнан үч алырга, чиксез җәберзолымга түзгән Украина җирләрен бәдбәхетләрдән тизрәк азат итәргә ант бирде һәм Киев юнәлешендәге каты сугышларның беренче эшелонында булды.

Фронт сызыгын тигезлибез дигән сылтау белән немецлар Днепрның уң ягына ычкындылар. Текә ярларда тимер-бетоннан коелган ут нокталары, түшәме бүрәнәләрдән катлы-катлы итеп ясалган блиндажлар, бер-берсенә тоташтырылган тирән окоплар, алар алдындагы чәнечкеле тимер чыбык киртәләр, миналы кырлар — һәммәсеһәммәсе Днепрның уң ярларын чыпчык очып та үтә алмаслык крепость хәленә китергән иде. Болары — ярсу дулкынлы дәрьяны кичкәч җимерәсе каршылыклар. Кичү үзе ничаклы көч сораячак. Чөнки көн-төн күзәтә фашист елганы. Агып килгән күбек чалмаларына да, гаскәр чыга дип шикләнеп, ут яудыра. Күктә очкычлар кизү тора. Төнлә сакчылар аеруча уяу. Елга өстен әллә ничә җирдән прожекторлар яктырта, пулеметлар трассирлы пуляларны кызганмыйча сибә. Ара-тирә, ямьсез чинап, мина төшеп ярыла, яки снаряд шартлап күккә су кибәнен чөя...

Таң алдыннан гына тирә-юнь беразга тына. Оборона тотучыларның күпчелеге татлы йокыга тала. Анда-санда сакчылар гына бер-берсенә тавыш бирәләр.

Киев ягыннан чистартылган түгәрәк җиз тасны хәтерләткән кояш чыгып килгәндә елга өстенә күксел әрфия пәрдә япкандай була: җиңелчә томан төшә, судан бу күтәрелә. Шуны гына көтеп ят-

кан сержант Рамил Әбдершин отделениесе каударланып эшкә керешә. Солдатлар камышлыкка яшерелгән бүрәнәләрдән, такталардан сал әмәллиләр, аңа руль һәм ишкәкләр беркетәләр. Аннары салны, дошман күзе күрмәсен өчен, камыш сабаклары белән күмеп, батальонга кайтып китәләр.

Урман эче тын. Сугыш авазларыннан котлары алынып, туган каенлыкларын, каштанлы иңкүлекләрне, орчыктай очлы булып күккә ашкан көяз тирәкләрне ташлап киткән сайрар кошлар әле бирегә кайтмаганнар. Озакламас, кайтырлар алар бу төбәкләргә, кайтырлар.

Урманда рәхәт. Һава сулап туймаслык. Үлән өстендә кызларның тамчылы көмеш алкаларын, калфак энҗеләрен хәтерләткән чык бөртекләре җемелди, вакыты җитеп коелган эре-эре грушалар тәгәрәшеп ята.

Печәнне чабучы булмаган. Табигать җимешләре, ник шулай кадерсезгә әйләндек дигән кебек, үпкәләп, рәнҗеп, җиргә сыенганнар. Ә бит болай булырга тиеш түгел. Тормыш үз матурлыгын саклап, мәңгелек юлыннан дәвам итәргә тиеш.

Грушаларны җыеп алдылар һәм, батальонга кайткач, кухняга илттеләр.

Рамил майор Чубарьга заданиенең үтәлүен белдерде.

— Яхшы, сержант,— диде майор.— Хәзергә ял итегез. Көндез батальон Днепрны кичү инструктажын үтеп бетерә. Отделениең сынатмас дип уйлыйм. Аннары, пожалуй...— Майор, мәгънәле итеп, кичү буласы якка ым какты. Командирның нәрсә әйтергә теләвен Рамил яхшы аңлады. Димәк, кем белә, алар батальоны бәлки кичүне беренче булып башлар. Монысы инде аның хәзергә сер... Сугыш сере.

...Алда сине зур сынау көткәндә тиз генә йоклап китәрмен дисеңме? Күзләр шар күк. Куыш колгаларын басып торган печәндә ничаклы чәчәк! Эреләре, бик тә матурлары бар. Орлыкларын җыеп, үстерәсе иде үзләрен тутәл-тутәл итеп. Яшьтән үк чәчәк яратты ул. Өзмәде, кисмәде. Бүләк итәргә кирәк булса, нәни чүлмәкләргә күчереп утыртты. Әх, ул көннәр... Кадерле хатирәләр яңара күңелдә. Һәрвакыт мөлаем әнкәсе, чак кына кырыс, ләкин искиткеч гадел һәм намаз картыдай пакь, пөхтә әтисе, пешкән чиядәй кара күзле, һич тиктормас сеңелләре Нурия белән Раушания, нәни Равил күз алдына килә. Мәктәп, күрше кызлары... Ничаклы сагынылган үзләрен!.. Ә бит нибары җиде ай үтте. Каттәкурганда хәзер хөрмә пешкәндер, йөзем җитешкәндер: Алмалар инде күптән җиргә тып та тып коелгандыр. Авызда эреп китә торган карбызларны олауларга төяп озаталардыр. Болар барчасы, үзбәкләр әйткәнчә, адәм михнәте, ягъни кеше хезмәте белән үстерелгән нигъмәтләр. Каттәкурган диңгезе яр буйларындагы бакчалар да җимеш биргәндер инде. Элек ул җирләр, суга сусап, кысыр яткан. Дымсыз яшәүгә күнеккән таштай каты, әбиләр бармагыдай кәкре-бөкре саксаул да рәтләп буй тартмаган анда. Тавык күкәе пешәрлек кайнар комда кәлтәләр һәм еланнар гына кызынган.

— Менә күрерсең, Рамил, өч ел дигәндә бу үсентеләр виноград бирә башлар, — дигән иде класс җитәкчесе Нәҗия апа Йосыпова яраткан укучысының өмәләрдә ифрат да тырышып эшләвен хуплап. Чын диңгез ясалып беткәч, бүләкләүгә Рамилне ул тәкъдим иткәндер, мөгаен. Бик ярата иде шул аны Нәҗия апасы. Укырга кызыклы китаплар биреп тора иде. Рамил, аның киңәшләрен тотып, ничаклы шигырьне күңелдән ятлады, ничаклы хәтер дәфтәрләре — кызыклы мәгълүматлар теркәлә барган конспектлар булдырды. Мондый мөстәкыйль эзләнү, тәгаллек техникумда укыганда ярап куйды тагы. Рамил һәр фәнне җиңел үзләштерде һәм педагогия техни-

кумын отличнога тәмамлады. Диплом алганның икенче көнендә хәрби комиссариатка юнәлде. Унсигез яшь тулмаган иде әле ул чакта аңа. Гаризасын кулына тоттырып кайтарып җибәрделәр.

Рамил күзгә якта хәрби комиссар ишеген кабат шакыды һәм кабат «Вакыт җиткәч, чакырып алырбыз», дип юатып озаттылар. 1943 елның 18 февралендә, үзенә унсигез яшь тулганның икенче көнендә генә аның үтенечен канәгатьләндерделәр. Озатырга Нәҗия апасы да килде. Истәлеккә дип бик матур куен дәфтәре бирде. Дәфтәргә иң-иң әһәмиятле булган фикерләрне генә терки барырга кушты. Рамил беренче биткә Туган илнең бер генә һәм бик газиз булуы турындагы әнисе яраткан җырны күчереп язды.

Гомель пехота училищесын тәмамлап фронтка җибәрелгәч, состав ни сәбәптәндер Волоколамск шоссесына җитәрәк юлда туктап калды. Батальон командиры вагоннарның ишеген ачарга боерды һәм үзе җиргә сикерде. Калкурак урын сайлап баскач, яңгыравык тавышлы комиссар әңгәмә башлады. Гаҗәеп дәрәҗәдә матур итеп, дулкынланып сөйләде ул.

— Моннан ерак та түгел Бородино — бабаларыбыз Наполеон гаскәрләрен тар-мар иткән данлыклы җир, — диде. — Ә менә каршыбызда, күкселләнеп торган урман артында, батыр комсомолка Зоя Космодемьянскаяны фашистлар җәзалап үтергән Петрищево авылы. Аның кабере дә шунда... Сул ягыбызда — Дубосеково разъезды... Панфиловчы егерме сигез каһарман фашистларны каршылаган җир...

Рамил, йоклый алмаячагын аңлап, куыштан чыкты. Кояш төшлеккә таба күтәрелеп килә иде. Бар тереклек алтын сыман нурлар эчендә рәхәтләнә. Яфраклар талгын җилдә сак кына лепердәшәләр. Нәрсә турында сөйләшәләр икән соң алар? Рамилнең үзәкләре өзелерлек булып сагынуы, йөрәгенең нигәдер хәвефләнеп тибүе турындамы? Ул тыныч, ләкин бөтен әйләнә-тирәдә ниндидер әрнүле моң бар сыман. Ни дип саргайган әнә теге каенның тәңкә-тәңкә яфраклары? Күкрәге җәрәхәтләнгән аккоштай, соңгы сулышларын ала икән инде ул: мина кыйпылчыклары аның үзәгенә чаклы умырып, чәрдәкләп киткәннәр. Каусәсенең ак тузы яшькә чыланган күк. Ул сөялгән яшь имән дә нык җәрәхәтле икән. Табигать күрке булган бу ике яшь агач хәлсезләнеп егылудан бер-берсен саклап торалар лабаса. Ләкин озак дәвамлы булмас шул болай ярдәмләшү... Күз тидеме әллә югыйсә?! Урман авызыннан җил исеп куйды. Каен бөтен гәүдәсе белән тетрәнде, сылу гәүдәне игелекле туфрак белән тоташтырып-туендырып торган ап-ак каеры тузы шул чак өзелде һәм каен, сөйгәне куеныннан ирексез аерылганга һуштан язган яшь кәләштәй аһылдап, җиргә бөгелеп төште. Назлы чибәремнән башка нигә миңа бу тормыш дигән сыман, имән дә каен янына гөрселдәп ауды. Аларның кипшенә башлаган яфраклары җирдә соңгы тапкыр кавыштылар...

Рамил, бу күренешкә чиксез әсәрләнеп, баскан урынында тын калды. Ул әле берәүне дә яратырга өлгермәгән иде. Әмма мәктәп елларында ук кемгәдер ихлас омтылуын аңлады. Кем иде ул? Розамы, Лаләме яки Сөмбелме? Моңа төгәл җавап юк. Тик шунысы хак: бу кызлардагы сокландыргыч камиллек акрын-акрын Рамилгә күчә барды — алар егетне рухи баеттылар, алардагы юмартлык, җәбер-золымга нәфрәт, гадилеккә, гаделлеккә чакыру мәңге тере табигатьнең үзеннән көчкәндер сыман тоелып, кызлар үзләре Рамилгә Ватан-ана җылысын бөркеп тора сыман иде...

Алда Днепр күкселләнеп ята. Еракта-еракта тонык гөрелте ишетелә башлады. Кояш ягыннан безнең очкычлар килеп чыкты һәм яшеллеген җуярга өлгермәгән уң як яр буйларында җиргә өзеп ташланган кыңгырау чәчәкләргә охшаган зәңгәр нокталар хасил булды.

Аннары яшеллек төтен катнаш тузан болытына күмелде. Самолетлар китүгә артиллерия эшкә кереште. Немецлар да тик ятмады: еракка ата торган туплар кайдандыр арттан аваз салды. Җир авыр көрсенде, урман сыкранып ыңгырашты. Агачлар ауды, күзләрне чагылдырып яшеннәр яшьнәгәндәй, ут биеде.

Үсеп торган чәчәкне өзгән өчен дә сабакташларын тиргәгән Рамил: «Ике яклап атышалар, ике як та урманны көйдерә, тереклекне гарипләндерә. Фашистларны кумый торып, бу мәхшәр туктамаячак!» — дип үз батальонына чапты.

Кайтса, почта килгән. Ашкынып хатны ачса... Сөекле әнкәсе, Сәмаркандтан балаларга кием-салым юнәтеп кайткан да, ике көннән соң, вафат булган. Илгә-көнгә фашист афәт китермәсә, авыру ана шулай юл газабы чигеп йөрер идеме?...

Майор Чубарь Әбдершин отделениесенә Днепрны беренчеләрдән булып кичәргә рөхсәт бирде.

Караңгы төшкәч, су читендәге камышлыкка килделәр. Рамил майлап-көйләп куйган пулеметын көймә борынына урнаштырды. Отделениедәге сугышчылар күңелләренә хуш килгән командирның үз яннарында салда булуын телиләр иде, ахры. Рамил аларга:

— Сал акрын йөзәчәк. Ә көймәдә без теге якка тизрәк чыгып, кичүдәге батальонны ут белән ышыклап торачакбыз, — диде.

— Күктән төштеме әллә ул көймә?! — диде кайсыдыр.

Рамил чүпрәк уралган ишкәкләрне рәтләп:

— Партизаннар бүләге бу! — дип җавап кайтарды.

Теге як ярга күз текәп тын калдылар. Гаскәр килә дә килә. Менә караңгыда майор тавышы ишетелде:

— Вакыт, егетләр!

— Киттек!..

— Теге як ярда очрашканга кадәр!

Рамил, көймәне этеп, койрыкка сикерде. Пулеметчылар ишкәкләргә ябыштылар. Көймә җиңел барды. Беренче утраучыкны үттеләр. Икенчесенә җитәрәк, прожекторлар кабынды. Камышларга елышып, көймә төбенә яттылар. Салкын нурлар, су өстен айкап, янәшәдән генә уздылар да, арттарак килүче салларны яктырттылар. Дошман ярсып атарга кереште.

Хәзер инде сакланып торудан бернинди файда юк иде.

Көймәдәгеләр ныгытып ишә башладылар. Уч төпләре янып чыкты, биттән өзлексез тир акты, гимнастерка аркага ябышты. Тизрәк! Тизрәк!..

Яр өстендәге куе караңгылыкта, каршыда гына, арпа кылчыкларыдай үткен нур сирпеп, зәһәр ут бөркелә башлады. Боз явуны хәтерләтеп, тирә-юньгә пулялар сибелә иде. Көймә чалышая төште.

— Тагын чак кына, егетләр!..

Ниһаять, дошман уты куркыныч булмаган яр ышыгына килеп керделәр. Кыз урлап кайтучылар кебек тетрәнеп һәм ашыгып, пулеметны кадерләп җиргә төшерделәр.

— Сашко! Давай тизрәк әрҗәләрне!..

Сашко җавап бирмәде. Аның каны белән чыланган патрон әрҗәләрен эләктереп, Рамил икенче номер янына килде.

— Башына тигән...

— Эх, Сашко... Синең өчен дә үч алырбыз, туган!

— Давай!..

Көндез безнең самолетлар астын-өскә китергән ныгытманың читкә каерып ыргытылган бетон түшәме астына кереп, елгага туктаусыз ут яудырган фашистларны яннан кисәргә тотындылар. Кичүдәгеләргә куркыныч кими төште. Шулай да өстенлек дошман ягында

иде эле. Кичүдәгеләр, бернинди югалтулар белән исәпләшмичә, бу якка ыргылалар иде.

Салдагылардан берничә сугышчы гына пулеметчылар янына килде.

— Су! Су!— дип кычкырды Рамил пар бөрки башлаган кожухка ымлап.

Батальон Днепрны зур югалтулар бәрабәренә кичте. Немецлар Зарубенцы авылына чигенделәр. Таң алдыннан майор Чубарь командирларны үз янына җыйды.

— Батальон сугышчан бурычны намус белән үтәде, — диде ул.— Без аз калдык. Ләкин өстәмә көчләр килгәнче биредә кичүдәгеләрне каплап торырга тиешбез. Ә ничек? Таң аткач фашист һөҗүмгә күтәреләчәк. Бездә ярты сәгатькә җитәрлек сугыш кирәк-яраклары калды. Аннары ни кылырбыз? Ярый ла өстәмә көчләр килеп җитсә. Әгәр өлгермәсәләр? Менә шуңа күрә, нәкъ Курск дугасындагы кебек, һөҗүмне немецлардан алдарак башларга кирәк. Кинәт, нык кысылган йодрык булып маңгаена бәреп миңгерәүләткәч, ул каршы тора алмаячак. Момент куып чыгарырбыз. Һәм — трофейлар безнеке. Хәлиткеч бу һөҗүмдә мин коммунистлар һәм комсомолларның башкаларга үрнәк булачагына нык ышанам. Һөҗүм хәстәрен күрү өчен ун минут бирелә.

Коралларны барладылар, пулемет тасмаларына соңгы патроннарны тезделәр.

— Кыю безнең командир, — дип уйлады Рамил. — Әткәй әйтмешли, тәвәккәл таш яра. Мондый очракта бүтән җайлы юл юк. Фашист авылга зур көчләр һөҗүм итте дип уйлаячак. Бөтен олавын, коралын ташлап йөгерәчәк. Аны үз коралы белән кисәчәкбез.

Иң алдан разведчиклар китте. Алар төн караңгылыгына кереп чумгач, укчылар һәм пулеметчылар кузгалды. Пулемет көпчәкләре күзгә шома юлдан иплә генә тәгәриләр. Дошман сизәрлек бернинди шау-шу юк. Ара-тирә генә сугышчылар авыр сулап куйгалыйлар. Саллы йөк бер җилкәдән икенчесенә күчә, тонык кына булып котелок зыңлап куя. Андый солдатны командиры пышылдап кына әрләп ала. Юл дәвам итә.

Авылга җитәрәк тукталдылар. Разведчикларны көтәргә кирәк икән. Бераздан алар бер унтерны сөйрәп кайттылар. Аңардан тиз-тиз сорау алдылар. Майор командирларны кабат үз янына җыйды. Ул:

— Беренче рота авылның сул ягыннан бара, икенчесе — уңнан, калган көчләр олы урам буйлап үзәк мәйданга үтә. Сигнал — яшел ракета, — дип, сәгатьләрне дөресләргә боерды. — Егерме минуттан һәркем үз урынында булырга тиеш.

Беренче һәм икенче роталар, илаһи зур кош канаты сыман якякка сузылып, дегеттәй караңгыга сеңделәр. Бүтән сугышчылар сабыр гына үз нәүбәтләрен көттеләр. Көньякта күк чите алсулана башлады. Ә озын мәһабәт гәүдәле майор Чубарь, авылга күз текәгән килеш, һәйкәлдәй хәрәкәтсез килеш бер урында тора бирде.

Егерме минут үтмәдемени әле? Майор авылны ни өчен өч яклап кына камарга исәпли икән соң?

Авылда тынлык. Фашистлар безнең һөҗүмне бу тирәләрдән көтмәгәннәр, ахры. Фронт сызыгы тоташ түгел. Днепр ярларына берәгәйле ныгытмалар ясаганнар да менә Зарубенцы белән ике арада бернинди ут нокталары юк. Бирешмәслек «Көнчыгыш вал» дип исемләнгән оборонаблагын кисеп кергән «чөйне», иртән тирә-яктан өстәмә көчләр тарттырып, елгага бәреп төшерергә исәплиләрдер, күрәсең.

— Кузгалырга!— дигән шыпырт команда булды. Су буена төшә торган казлар кебек тезелешеп дүрт-биш минут баргач, басу капкасы каршына яттылар. Авызына хәнҗәр капкан өч сугышчы постларның

эшен бетерергә китте. Бераздан ябалак кычкырып куйды. Бу — юл ачык дигән сүз иде. Майор, Рамилгә шунда калырга ишарәләп, башкаларны үзенә ияртте. Төркем каралтылар алдындагы агачлар ышыгыннан үзәк мәйданга ашыкты. Киң урам ярыйсы ук ачык күренә иде. Таң ата. Йокының иң татлы чагы. Кайсы ишек алдындадыр әтәч, батыраеп, аваз салды. Рамил елмаеп куйды.

Авылны азат итү сәгате сугуын белдерәсеңме әллә, әтәч җаным? Элек шулай сызылып таң атканда синең гайрәтле җырыңа алсу киркрикле ничаклы агай-энең кушылгандыр. Ә хәзер син әнә бер ялгызың калгансың. Фашисттан шүрләмичә батыраеп, яңа көн тууын хәбәр итәсең икән, димәк, безнең эшләр ал да гөл булачак!..

Каты шартлап, чыжлап күккә яшел ракета атылды һәм авылның өч ягында, иртәнге тынлыкны чәлпәрәмә китереп, «ур-ра!» тавышлары яңгырады. Гранаталар гөрселдәде, автоматлар тырылдады.

Кырыйдагы өйләрдән чыгучы булмады.

Рамил, отделениесендәге икенче пулеметны засадада калдырып, үзе алга чапты. Олы урамның түренә, әчкәрәк кертеп салынган озынча йортның алдына туктап ашыга-ашыга пулеметын борды. Ишек-тәрәзәләрдән сикергән солдатлар күренде.

«Мәктәп бинасыдыр бу, — дигән уй башыннан үтте Рамилнең. Тапканнар урын... Укучыларны мәхрүм итеп...»

— Та-та-та-та-та!.. — Пулемет, иртәнге салкында күшеккән әгъзаларын җылытырга теләгәндәй, башта иренгән сыман атты. Анна-ры ишектән ябырылып койма буйларына таба йөгерүче гитлерчыларны кургаш яңгыры белән коендыра башлады.

— Ленту! Ленту приготовь, Митя!..

Яңа тасма куйган арада бер төер фашистлар, койма аркылы сикереп, бакчага кача башладылар. Әх, ычкындырырга ярамый бит аларны. Ярамый! Граната ыргытыргамы? Мәктәпкәме? Ут капса?.. Хәзер... Хәзер...

Пулемет янә дәртләнеп атарга керешкән иде, койма янындагы солдатларның берсе граната томырды. Рамилгә, җиңелчә контузияне исәпкә алмаганда, зыяны тимәде, икенче номер, җиргә йөзтүбән капланган килеш, тынып калды. Рамил атты да атты.

Ярты сәгатьтән урамнарда бәрелешләр тынды. Илбасарларның исән калганнары безнең гаскәрләр камавы булмаган тыкрыклардан Григоровкага шылдылар.

Батальон сугыш кирәк-яракларын җыярга кереште. Үзебезнең соңгы патроннарны туганнар кабере янында бирелгән залпларга файдаландылар. Майор шуны теләде. Чыннан да, полкташлар белән соңгы хушлашу өчен үз халкыңның көче кергән сары җиз патроннар кирәктер ул.

Лапастагы базларга, идән асларына яшеренгән авыл халкы курка-курка гына урамга чыкты. Күршесенә йомыш белән кергән булып, тирә-юньне күзәтте. Авыл кем кулында, ганс-явыз үкчәсен күтәргәнме, әллә баздан чыгарга иртәрәкме әле?.. Кинәт чырайлар бердән яктырып китә, шатлыклы авазлар яңгырый:

— Ксенья әбекәй! Мәрхәмәтле күршеләр! Чыгыгыз! Үзебезнекеләр килгән! Үзебезнекеләр!..

Капкалар шалтырап, тупсасына хәтле киереп ачыла. Аларны ябып та тормыйча, мәктәп һәм авыл советы биналары урнашкан үзәк мәйданга йөгерәләр.

— Фашист-канәчкечтән йолып алуыгыз өчен рәхмәт, балакайлар!

Бина өстендә колгада, элек бәйрәмдәгечә очынып, талпынып комач җилферди. Сагындырган, һай сагындырган ул җанны! Карасана инде хәр һәм мәһабәт ул!

Үзеннән-үзе митинг башланды. Кай арада өр-яңадан киенеп өлгергән киң җилкәле, ялтыравык каешлы, кобуралы, күкрәге тулы орден, медальләр җемелдәгән пәһлевандай гәүдәле майор Чубарь, болдырга чыгып, якташларын сәламләде. Алкышлар тынгач, совет гаскәрләренең партия һәм Башкомандующийның зирәк акылы җитәкчелегендә, җиңү арты җиңү яулавын сөйләде. Озакламыйча Киевның һәм бөтен Украина җирләренең азат ителәчәгенә ышандырды.

Гаскәрләр ялга урнашты, чат саен поход кухнялары төтенли иде.

Рамил мәктәп ихатасында койма буенда пулеметын сүтеп, майлап җыйды да, тузан кунмасын өчен аны телогрейкасы белән каплап куйды. Аннары, гашеткага аркасын терәп, җиргә утырды. Ике кулы белән чигәләрен тотып, күзләрен йомды. Юк, черем итәргә исәпләми иде ул. Ялгызы калып уйланасы килде аның. Шулай онытылып күпме утыргандыр, күзләрен ачса, 9—10 яшьлек кыз бала аның башыннан шуып төшкән пилоткасын киертеп азаплана. Рамилнең куе кара чәчләре пилоткага сыешырга теләмиләр. Кыз аларны нәни йомшак кулы белән сыпыра иде.

Башта Рамил төш күрәм дип уйлады. Йомшак кулны тотканнан соң, аның хуҗасы чырылдап читкә тартылгач, айнып киткәндәй булды.

Рамил елмаеп:

— Курыкма, сеңелем, — диде.

— Үзебезнекеләрдән курыкмыйм мин, — диде кыз.

— Ничәнчедә укыйсың син? Икенчедәме? — Рамил бу сорауны урынсызга бирүен тиз сизенеп, иренен тешләде.

Кызның тавышы калтырады, озын кара керфекләре түбән таба сирпелде.

— Укымыйм, абый. Беренчедә дә укымыйм әле. Немец мәктәпне үзенә алды.

— Хәреф тә танымыйсыңмы? — диде Рамил кызны янына утыртып, сумкасыннан кәгазь-каләм алып.

— Хәрефләрне таныйм... Күрше кызы Оксана өйрәтте.

— Ә Оксананы кем укытты? Кайда хәзер ул укытучы?

— Аны... өйдә укыткан өчен немец асты. Икенче укытучыны өч көн генә әле окоп казырга куып киттеләр.

Рамил окоп казучыларны, шул исәптән укытучы Дарья Петровнаны да, бүген-иртәгә азат итәчәкбез дип кызны тынычландырды. Ябык ак чырайда канәгать елмаю хасил булды. Нәни йөрәккә сыймаган шатлыгын уртаклашырга теләптер, ахры, кызчык өенә ашыкты.

Разведка Зарубенцы авылы алдындагы биеклектә тирәнгә казып ясалган ныгытмалар барлыгын һәм бу эшне башкарган халыкның амбарларга бикләп куелуын белдерде.

Майор Чубарь ашыгыч төстә полк командиры янына китте. Озакламый һөҗүмгә күтәреләчәкләре һәр сугышчыга ачык иде.

Рамил, хуҗалык взводыннан кызыл буяу алып кайтып, туганнар кабере өстендәге агач пирамиданы буяды. Эше беткәч тә китәргә ашыкмады, хискә бирелде.

Сашко Днепр ярында ятып калды. Дмитрий мәңгегә бирелдә мәңгегә күзләрен йомды. Нинди сабыр, акыллы егет иде ул. Бакчачы булу иде аның теләге. Шуны белгән кебек, хәзер менә баш очында яфраклар серләшә. Нәрсә турында серләшәләр икән соң алар?

Сезнең моң, сезнең сагыш гомерлек түгел, дуслар. Киләсе елга ук мул итеп җимеш бирерсез. Пешми торып ул җимешләрне бераү дә өзмәс. Җиргә тып та тып итеп алма төшә башлагач кына бакчада кызлар җыры яңгырар. Сагышлы, сагынулы булыр ул җыр. Йөрәкләрне сызлатыр ул. Ләкин батырлар кабердән барыбер чыга алмас шул, чыга алмас..

ШАМИЛ РӘКЫЙПОВ ◆ ДНЕПР ЯРЛАРЫНДА ТАЛЛАР БАР ◆

Рамил мәктәп ихатасында кабызылган учак янына килеп утырды. Кипкән өректәй бөрешкән сары битле хатыннар мәктәп эчендә фюрерның «цивилле» солдатлары калдырып киткән чүп-чарны утка ташыйлар иде. Хатыннарның берсе, кисәү таягы белән учакны актара-актара, гитлерчыларны ләгънәтли иде.

## Күңел дәфтәренә чаткы төште...

*«Геройлар эзеннән» китабыгызның ахырындагы исемлектән Р. Х. Әбдершинга Советлар Союзы Герое исеме бирелүен белдек. Ул безнең авыл егете булырга тиеш. Нигә аны Сәмарканд өлкәсеннән дип яздыгыз? Әллә ул бүтән кешеме?*

*Оренбург өлкәсенең Яңа Муса авылы гражданнары».*

Учак ягучы хатын бәләкәй дәфтәренә нәрсәдер язып утырган солдат белән кызыксынып:

— Кайсы якныкы соң син, солдатик-касатик? — дип сорады. — Нинди ата-ананың йөрәк җимеше буласың?

Әнкәсе әйтмешли, җыру көйләгәндәй итеп сөйләшкән өлкән яшьтәге бу мөлаем хатынга ни дип җавап бирергә дә аптырады Рамил. Тумышы белән ул Оренбург якларыннан. Хәйрулла абзый, олы улы Рамилгә сигез яшь тулар-тулмас, Кәттәкурган каласына күчеп килгән. Колхоз төзүдә катнашкан, озак еллар аның баш хисапчысы булып эшләгән. Хәер, болар һәммәсе Рамилнең күз алдында башкарылган эшләр ләбаса. Әтисе үз-үзен һич аямады. Рамилне дә шуңа өйрәтте. «Сине, улым, мөгаллимлеккә укытырмын. Кешенең күзен ачтыру — олы бәхет!» — диде. Һәм, җае чыккан саен, үзбәк халкының уңганлыгы, зирәклеге турында тәмләп сөйли иде. Бөек галим Олугбәк турында да Рамил беренче булып әтисеннән ишетте. Озакламыйча М. Горький исемендәге җидееллык мәктәпне Мактау грамотасына тәмамлаган һәм шул елны ук Кәттәкурган сусаклагычын төзүдә җиң сызганып эшләгән комсомол егет Бохара, Сәмәрканд калаларындагы могҗизаларны үз күзләре белән күреп йөрде. Бохарада Олугбәк салдырган таш мәдрәсәнең ишеге өстендә галимнең: «Белемгә омтылу — һәр мөслим һәм мөслимәгә фарыз»,— дигән сүзләрен укып куанды...

Кипкән өрек җимешедәй җыерчыклы, сары йөзле өлкән хатын Рамил күңелендә әнә шундый хатирәләрне кузгатты. Сорауларга җавапны да бик уйчан кыяфәттә бирде, ахры. Немец гранатасыннан алган контузия кызган мәлдә генә беленмәгән икән ул: баш чатный, күз алдында кызгылт, сары түгәрәкләр уйный иде.

Хатын кисәү таягы белән учакны актара башлады. Чүп-чар эчендә фашист тамгалы сәмруг кош сурәте төшерелгән катыргы дөрләп яна иде. Дулап бөтерелгән ялкын очкынлы ялын тузгытты. Бер чаткы, зәһәр чыжлап, Рамилнең куен дәфтәре битенә очып кунды. Кәгазь үтәдән-үтә янып чыкты.

Кичә Рамилнең күз алдында ике яшь агач ауды. Бүген бакчада җимешсез агачларга тап булды. Инде менә янган фашист сурәтеннән очкан чаткы... Китегез, китегез күңелдән шомлы уйлар! Ул яшәргә тиеш әле...

* * *

Кояш төшлеккә җиткәндә безнең туплар һаваны тетрәтте. Баш очыннан сызгырып очкан снарядлар, миналар ике авыл арасындагы калкулыкта туфрак бураны күтәрделәр. Ныгытмаларга куелган юан

бүрәнәләр чәрдәкләнеп һавага очты, корыч янып, балавыздай йомшап төште, әйләнә-тирәгә теткәләнгән мундирлар сәләмәсе чәчелде...

Аннары дөнья тынды. Тузан басылды. Батальон һөҗүмгә китте. Фашист шуны гына көтеп торган икән. Бакчалар эченнән төрле калибрдагы туплар ата башлады. Япан кыр ут эчендә калды. Ятарга мәҗбүр булдылар. Ләкин урын бик җайсыз иде: сафлар сирәкләнгәннән-сирәкләнде.

Немецлар өч тапкыр һөҗүмгә ташландылар, өчесендә дә чигенергә мәҗбүр булдылар. Батальон ачык кырда ята бирде. Нишләргә? Каршыңдагы гаскәр саны үзеңнән өч-дүрт тапкыр артык икәнлеген белә торып һөҗүмгә күтәрелергәме, әллә өстәмә көчләр килүен көтәргәме? Кайчан килер ул? Фашист атакасын янә кабатласа?

Майор Чубарь әнә шулай баш ватып дошманны күзәтә иде.

Мондый уйлар Рамилне дә борчыды. Ул — гади бер сугышчы. Батальон язмышы турында кайгыртучы командир бар, комиссар бар. Ләкин Рамил уйламый булдыра алмый. Ул шулай тәрбияләнгән. Хәлеңнән килгәнне эшләргә омтылу — бөеклек түгел, кешенең көндәлек бурычы. Бүген, бу минутта, бәлки хәтәр тәвәккәллектер ул. Пулемет щиты ышыгында атарга боерык көтеп яту куркынычсызрак икәне көн кебек ачык... Башкалар ничәмә-ничә тапкыр хәтәррәк адымнарны атламаганнармы?..

Рамил майор Чубарь янына шуышты.

— Иптәш комбат, миңа, әнә теге калкулыкны урап үтеп, флангтагы камышлыктан ут ачарга рөхсәт итсәгезче, — дип мөрәҗәгать итте ул. — Ялгызым гына барам. Дошман сизмәс...

Авылдан фашистлар чыга башлаган иде. Майор икеләнеп тормады: «Барыгыз!» — диде.

Әбдершин пулеметына ташланды. Пулемет рамына дилбегә бәйләп, дилбегәне, малай чакта ат-ат уйнагандагыча муенына киеп, култык астыннан үткәрде дә кәлтәдәй шуышып китте.

Сугышчылар аны тын да алмыйча күзәттеләр. Сержант әнә теге камышлыкка барып җитәргә өлгерерме? Бәдбәхетләр, безнең көчнең чамалы икәнен белгәнгә, әнә ничек күкрәк киереп киләләр! Сержант, чак кына ашыга төшсәңче, туганкай! Чак кына, тагын чак кына. Күп булса, йөз метр... Аннары син камышларга чумачаксың.

— Булды! Өлгерде! — Күкрәкләр бердән җиңел сулап куйды.

Немецлар Рамил яшеренгән камышлык яныннан саф-саф тезелеп үттеләр. Һавада, дуга ясап, яшел ракета кабынды.

— Майор ут ачарга боера, — дип уйлады Рамил. Тиз-тиз пулеметын борды, әрҗәне ачты. Таныш такылдау, рәхәтлек биреп, бөтен тәненә таралды. Гитлерчылар ике ут арасында калдылар. Әле кайчан гына төз басып килгән тигез сафлар буталды, болганды. Шунда камышлыкка мина ява башлады. Рамил бернәрсә сизмәде. Атты да атты. Муеныннан, күкрәгеннән җылы нәрсә акты. Куллары хәлсезләнде, башы чамадан тыш авырайды. Шул чак үзе иртән кәгазь-каләм бүләк иткән кечкенә кызның өмет тулы күзләрен күргәндәй булды. Әнә ул: «Немец кабат борылып килмәсме?» дип сорый. Колак төбендә фәкать шул тавыш кына яңгырап тора.

— Килмәс! Килмәс! — дип пышылдый Рамилнең уттай кайнар иреннәре.

Сугыш кыры мәетләр белән чуарланган иде. Исән калган ике йөзләп гитлерчы, корал ташлап, кул күтәрүне хәерлерәк күрде. Аларны тылга үткәреп, авылга ыргылдылар. Урамнарда кыска вакытлы бәрелешләр булып алды. Укчылар ротасы, фашистлар амбарларга бикләп терелэй яндырырга өлгерми калган йөз илледән артык кешене азат итеп, юлларга, җәмәгать биналарына куелган миналарны зарарсызландырырга кереште.

Ә пулеметчылар бу чакта камышлыкта кычкыра-кычкыра Рамилне эзлиләр иде. Аны һушсыз килеш табып алдылар. Ашыгыч рәвештә кыр госпиталенә илттеләр. Операция өстәлендә егет аңына килде һәм хәлсез тавыш белән: «Немец авылга үттеме?» — дип сорады.

Бу аның соңгы сүзләре була...

Күзләре чиксез ялварып тәрәзәгә текәлә. Сестра кыз, Рамилнең теләген аңлап, хирургка карый. Хирург тәрәзәне ачарга рөхсәт итә. Рамил ерак та түгел җәелеп аккан Днепрны, шанлы елганы кичә торган гаскәрләрне күздән кичерә, аннары моңлы карашы яр читләрендәге бөдрә талларга тукталып кала. Тирәндә, тирәндә нурлар акрынлап сүнә. Күз кырыена каяндыр күңел түреннән саркып җыелган ике бөртек ачы күз яше ак җәймәгә тәгәрәп төшәргә өлгерми, җәрәхәтләр белән телгәләнгән тән яшәүдән туктый.

Туганнар кабере казыла. Хушлашу залплары яңгырый. Майор Чубарь матәм митингысын тәмамлап: «Туган җир куенында тыныч йоклагыз. Ватан сезне мәңге онытмас!» — ди.

СССР Верховный Советы Президиумының 1943 ел, 17 ноябрь Указы белән Әбдершин Рамил Хәйруллаевичка Советлар Союзы Герое исеме бирелә.

## Барыбер кайтты

*«...Абыебыз Рамил Әбдершинның Советлар Союзы Герое булуы белән без бик горурланабыз. Ләкин бу хакта бездә берникди документ юк. Аның Геройлык Грамотасы ичмаса укыган мәктәбенә тапшырылсын иде.*

*Клара, Нурия, Раушания һәм Равил Әбдершиннар.*
*Сәмәрканд өлкәсе, Кәттәкурган каласы.*

Рамил Әбдершинның якты истәлеген мәңгеләштерү буенча җитәрлек эш алып барылмаган. Яңа Муса авылында ул бездән яшьли үк киткән, дип тынычланганнар. Кәттәкурганда да ниндидер сәбәпләр табылган. Мәскәүдән җибәрелгән Грамота да хәтта эзсез юкка чыккан. Шулай ел артыннан ел үткән.

Ә хәзер?

Кәттәкурганның герой укыган 10 нчы мәктәп бинасына (элек ул татар мәктәбе булган) алтын хәрефләре кояшта җем-җем итеп торган мемориаль такта куелган. Күк йөзедәй зәңгәр коридор сине кояш ягындагы киң ишекле якты иркен класска алып килә. Алдагы рәттәге парталарның берсе башкаларына һич охшамаган. Аның буявы гына яңа. Такталары иске, тупсалы капкачлары бик үк туры тормаса да, бу парта күпләрне үзенә тарта. Ләкин күпләргә эләкми. Аңа утыру өчен һәр фәннән чирек саен «бишле» билгесе алырга кирәк.

Заманында бу партада Рамил укыган.

Хәзер Рамил бу мәктәпкә гомерлеккә кайткан. Аның монда үз бүлмәсе бар. Зурайтылган фоторәсеменнән игътибар белән карап тора. Күзләрендә чак кына шаянлык һәм моң сибелә сыман. Шаянлыгында тиктормас балачагының дәртле ашкынуы, моңында чәчәктәй гомеренең бик иртә өзелеп, башкарасы зур эшләренең үтәлми калуы өчен әрнү-яну бар шикелле. Әх, яшисе иде хәзер сезнең белән! — ди ул гүя һәркемгә.

Аның сурәте астындагы чүлмәкләрдә эре-эре матур чәчәкләр үсә. Тынгысыз эзтабарлар Рамил холкының барлык үзенчәлекләрен өйрәнгәннәр һәм һәрьяклап аңа охшарга тырышалар.

Түрдә иң кадерле урында Рамил Әбдершинга Советлар Союзы Герое исеме бирелү турында алтын хәрефләр белән язылган Грамота. Унсигез яшьлек гомернең хак бәяләмәсе ул.

Монда сабыйлар октябрят йолдызчыгы тага.

Монда пионерлар тантаналы вәгъдә кабул итә.

Монда үсмерләргә тышына бөек Ленин сурәте төшерелгән комсомол билеты тапшырыла.

Музейда олылар да даими кунак.

Көннәрнең берендә, төштән соң, чал чәчле, тоташ карадан киенгән чибәр бер ханым Герой бүлмәсенә керде. Акрын гына атлап түргә узды. Төрле истәлек әйберләрне, язуларны күздән үткәргәч, Григоровкадагы туганнар каберенннән китерелгән туфракка озак кына карап торды. Аннары яшьле күзләрен Рамилнең рәсеменә төбәде. Иреннәре тетрәде. Нәрсәдер пышылдады. Азрак тынычлангач, шунда үзен сурәткә төшерергә теләсәләр дә, риза булмады.

Ханым зифа буй-сынлы укучы кызга сокланып карап куйды.

Аның бөдрәләнеп торган кара авыр толымнарын сыйпады. Аннары ул, Рамилнең шушы мәктәптә укыган чакларын исенә төшереп һәм алардан моңсу рәхәтлек табып булса кирәк:

— Рамил мондый толымнарны бөдрә талларга охшата иде, — диде. Киткәндә соңгы кат карап калыйм дигән сыман, чигенә-чигенә ишектән чыкты. Һәм шәһәр халкы яратып ял итә торган җиргә — Үзбәкстан диңгезенең яр буена юнәлде. Көзгедәй су өстендә көмеш чабаклар уйный, акчарлаклар оча иде. Йөзләрчә арыклардан дөге, мамык басуларына мөлдерәп чайпала-чайпала игелекле хәзинә ага иде...

Яр читләрендәге бакчаларда менә ничә ел инде йөзем пешә. Пионерлар карап үстергән аллеяларда берсеннән-берсе матуррак чәчәкләр тезелешеп тора. Аларны өзмиләр. Чәчәкләр җилдә тирбәлешеп, Герой истәлеге алдында баш иялəр сыман...

**Шәмси Хамматов,**
*тарих фәннәре кандидаты, доцент*

# ДӘҺШӘТЛЕ ЕЛЛАР АВАЗЫ

*«Мин, үз фронтыбызның бөтен почмагында булып, шактый нәрсә күрергә, шактый хәлләр баштан кичерергә өлгердем инде. Зур батырлыклар күрсәтеп, орден-медаль алган байтак татар егетләрен дә күрдем. Алар турында «Кызыл Татарстан»га язам, шулай ук әдәби әсәр язарга җыенам. Шулай итеп, монда чын-чынлап, шигырьдә әйткәнчә, бер үк вакытта каләм һәм автомат белән сугышырга туры килә»* [1].

*Муса Җәлил*

Ватаныбызның зур сынаулар алдында калганы бар. Ил халкы шундый чакта сынала. Сәләте нинди? Үз өстенә төшкән авырлыкны, ул авырлык йөкләгән бурычны үти аламы? Үти алса — нинди көч белән?

Халык рухы белән көчле. Кеше рухының көче ил куәтеннән килә, ил куәте — кеше рухыннан. Бөек Октябрь революциясе колониаль милли изү баскычын сүтеп, барлык халыкларны тигезлек, какшамас дуслык мәйданына чыгарды. Социализм һәм коммунистик идеалыбызның явыз дошманы — фашизм Германиясе әнә шул баскычның таралмаган булуына исәп тотып, Ватаныбызны сугыш фаҗигасына тартып кертте, ләкин үзенең шул черек идеологиясе сазлыгында батып калырга дучар ителде.

Рух көче оранжерея яки теплицаларда үстерелмәде. Халкыбыз аны үз идеалы коралы итеп үз каны белән сугарылган изге азатлык көрәшләрендә яулап алды. Шуңа күрә бөек Тукаебыз әйткәнчә:

**Без сугышта юлбарыстан көчлебез,**
**Без тынычта аттан артык эшлибез.**

Беренче карашка гап-гади тоелган инанганлык — халыкларыбызның тирән гасырлардан килгән гаделлек һәм бәхет идеалының чагылышы ул. Ленинның бөек партиясе көрәш байрагына шушы идеалны язып куйды һәм җиңүгә иреште. Коммунистлар партиясе үзе алып барган көрәшнең халыклар теләге хакына булуы белән көчле иде. Халыклар бу теләкне бәетләрендә, хикәятләрендә, язучыларының әсәрләрендә җырлаган. Җырланган сүз, җырланган уй, җырланган идеал күңел байлыгына, рух коралына әйләнә.

Шуңа күрә безнең партия әдәбият һәм сәнгатькә, яңа кеше, коммунизм идеологиясенә бирелгән патриот һәм интернационалист тәрбияләүдәге гаять зур көч була-

[1] «Казан утлары», 5 сан, 1976 ел, 146 бит.

рак, киң игътибар һәм тирән кайгыртучанлык белән карады һәм карый. Ил өстенә төшкән иң зур сынау — Бөек Ватан сугышы вакытында әдәбият-сәнгать тә үз бурычын намус белән үтәп чыкты һәм бу тугрылыкны, ил, халыклар алдындагы җаваплылыкны какшамас төстә дәвам иттерә.

Бөек Ватан сугышы чорында газета һәм журналлар, партия, иҗат оешмалары органнары буларак, Ватан азатлыгы хакына көрәштә пропаганданың төп рупоры булды. Әдәбият-сәнгать тә үз эшчәнлеген газета-журналларның күп миллионлы трибунасында сугышчанрак, һәр кешегә барып җитәрлек төстә алып барды. «Кызыл Татарстан» газетасы һәм «Совет әдәбияты» журналы бу елларда әдәбият-сәнгатьнең үзәк мәйданына әверелде. Бу ике милли матбугат редакцияләренә төрле фронтларның татар газеталары алмаш битләр, республикабыз хезмәт ияләренең тормышы, фронтка ярдәме турында материаллар оештыруны үтенеп мөрәҗәгать иттеләр. Үз чиратында алар фронт газеталарына батыр солдатлар һәм офицерлар турында язучылар, журналистлар язган кыска-кыска очерк, хикәя, нәсер, язма, шигырь, публицистик мәкаләләр җибәреп тордылар.

Сугыш еллары матбугатында татар совет язучыларының патриотик иҗаты — фундаменталь тикшеренүләрдә яктыртылырга лаеклы тема. Бу мәкаләсендә исә автор әнә шул изге көрәш көннәрендә «Кызыл Татарстан» газетасында әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә булган игътибарны яктыртырга омтылыш ясый, иҗат эшенең һәм журналистиканың совет халкын фашистларны җиңәргә рухландырган көч булганлыгын күрсәтергә тырыша.

*

* *

«Кызыл Татарстан» Бөек Ватан сугышы башлануның беренче көннәреннән үк мәкерле дошманны җиңү өчен халкыбызны изге көрәшкә чакырды. Газетаның 1941 ел, 24 июнь санында төрле митинглардан откликлар бирелде. Татар совет шагыйрьләре Әхмәт Фәйзи «һәркем үзенең көчен барласын!», Гадел Кутуй «Коммунизм өчен», Кави Нәҗми «Фашизмга үлем!», Салих Баттал «Җиңү бездә! Җиңү безнеке!» исемле шигырьләрендә фашизмга үзләренең нәфрәт сүзләрен белдерделәр.

Газетаның 25 июнь санында Татарстан Язучылар союзында булган митингтан отчет басыла. Митингта Муса Җәлил, Мөхәммәт Садри, Кави Нәҗми, Шәйхи Маннур, Гадел Кутуй, Әхмәт Фәйзи, Афзал Шамов һәм башка әдипләр чыгыш ясыйлар, үзләренең ялкынлы шигырьләрен укыйлар. Көчле алкышлар белән кабул ителгән резолюциядә болай диелә: «Без, Татарстан язучылары, кулларыбызда каләм һәм корал тоткан килеш, данлыклы Кызыл Армия сафларына кушылырбыз һәм барлык энергиябез, талантларыбыз һәм белемебез белән, сөекле Ватаныбыз өчен тормышыбызны да кызганмыйча көрәшербез. Без үзебезнең большевистик партиябез, Совет хөкүмәтебез тирәсенә тагын да тыгызрак тупланырбыз» [1].

Бераз соңрак газетада «Язучылар практик эш белән җавап бирәләр» дигән хәбәр басыла. «Язучылар һәм шагыйрьләр арасында патриотик хис көчле,— диелә анда.— Алар үзләренең иҗат планнарын бик тиз яңадан төзеп, аларны оборона таләпләренә буйсындыралар... Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләре белән вакытлы матбугатта актив катнашалар. Антифашистик, патриотик ике махсус әдәби җыентык чыгарыла. Шәһәр күләмендә антифашистик әдәби-художество кичәсе үткәрүгә хәзерлек алып барыла».

«Кызыл Татарстан» газетасының 25 һәм 26 июнь саннарында К. Нәҗми «Беренче удардан соң», Г. Кутуй «Озату җыры», М. Садри «Бөтен халык сәламе», Г. Хуҗиев «Коммунист Шакир Зариповның район хәрби комиссариатына язган гаризасы» дигән үткен, дулкынландыргыч шигырьләре, И. Туктар «Батырлыкта матурлык» исемле нәсере белән катнаша. Ә 2 июльдә Муса Җәлилнең «Дошманга каршы» дигән шигыре басыла. Анда мондый юллар бар.

**Котырган эт безнең корыч сафка**
**Таш маңгаен бәреп ярачак.**

---

[1] «Кызыл Татарстан», 25 июнь, 1941 ел.

**Безнең өскә аткан утларының**
**Ялкынында үзе яначак.**

Бик күп язучылар, шул исәптән М. Җәлил, «Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе заданиеләрен намус белән үтиләр. Мәсәлән, М. Җәлил Татар дәүләт опера һәм балет театры дирекциясенә, шул театрның әдәби бүлеге мөдире буларак, 1941 елның 9 июлендә мондый гариза белән мөрәҗәгать итә:

«Кызыл Татарстан» газетасы редакциясе мине, язучы һәм журналист-пропагандист буларак, күп кенә чаралар үткәрү һәм тылда оборона-производство эше буенча әдәби сәхифә оештыру өчен, 3—4 көнгә Арча районына командировкага җибәрә.

Яңа обстановка уңае белән, бу эшнең әһәмиятен искә алып, миңа бу сәфәрне рөхсәт итүегезне һәм, театр хезмәткәре буларак, мине иҗади эш тәртибендә халык арасында әдәби чыгышлар ясау өчен җибәрүегезне сорыйм. Мин 1941 елның 12 июлендә кайтырмын» [1].

«Кызыл Татарстан» газетасының иң актив авторы санап, М. Җәлил дусты Г. Кашшафка 1942 елның 3 апрелендә, аңа язучы «Фадеев тәкъдим иткәнчә», үзен «Кызыл Татарстан» газетасының «спец. хәрби корреспонденты итеп билгеләүләре турында газета редакциясе белән сөйләшүен үтенеп» яза, «милли татар частена тизрәк эләгер идем һәм «Кызыл Татарстан», «Красная Татария» газеталары өчен бик кирәкле күп нәрсәләр эшләр идем»,— дип белдерә. «Юкса ачу килерлек,— дип яза аннары,— янында гына якташларың, фашист хәшәрәтләрен кырып, әллә нинди могҗизалар эшләсеннәр, ә мин, аларның үз шагыйрьләре, шуның өстенә журналист, алар белән бәйләнеш тотмыйча, аларның батыр эшләре турында бер сүз дә язмыйм... Газета бу нәрсә белән кызыксынырга тиеш»[2].

Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Гали Динмөхәммәтовка 1942 елның 2 июнендә язган хатларының берсендә дә Муса Җәлил «Кызыл Татарстан» газетасының «Махсус военкоры булып, милли частьларда йөрергә, татар геройлары турында язарга теләр идем»,— дип күрсәтә. Шул хатында М. Җәлил шулай ук, хәрби корреспондент буларак, үзенә фронтның алгы позицияләрендә «боевой походта йөреп үткәрергә туры» килүен әйтә, чөнки «шунсыз газетаны оператив һәм боевой итеп чыгарып булмый. Фронтның чын геройларын, шулай ук командир һәм сугышчыларны газетада яктырту, анализ ясау өчен, боевой эпизод һәм боевая операцияне бары фронтның алгы сызыгында гына күреп була»[3].

Ватан язмышы хәл ителгән киеренке көннәрдә патриотизм хисе бер Муса Җәлилне генә түгел, башка язучыларның да күңелен били. Алар аны әсәрләрендә чагылдыралар. «Кызыл Татарстан» газетасының 5 июль саны халыкны гадел сугышта җиңүгә өндәүче әдәби бит белән чыга. Анда Т. Гыйззәтнең «Ватан өчен бөек сугышка», Л. Җәләйнең «Фашизмны юк итәргә!» дигән публицистик мәкаләләре, Ә. Исхак, Ф. Басыйров шигырьләре урын ала. Әдәби биттәге әсәрләрнең һәр җөмләсе, һәр сүзе үткен, сугышчан булуы белән аерылып тора. Таҗи Гыйззәт, мәсәлән, «Ватан өчен бөек сугышка» дигән мәкаләсен шигъри юллар белән тәмамлый:

**Масаймасын фашист маэмайлары**
**Искәрмәстән булган уңышка.**
**Юлбасардай бүген керсәгез дә,**
**Без җиңәрбез соңгы сугышта.**
**Кешелексез, хаин, хыянәтче**
**Башыгызга тиздән җитәрбез!**
**Үле гәүдәгездән күпер ясап,**
**Марш белән таптап китәрбез.**

Күренекле драматург Таҗи Гыйззәтнең «Финанс комиссарына» дигән шигыре дә моңа аваздаш. Анда авторның Ватанны саклау фондына мең сум акча бирүе «Гитлер башына нәләт бомбалары» булып явачаклыгы әйтелә.

---

[1] «Социалистик Татарстан», 22 декабрь, 1965 ел.
[2] Муса Җәлил. Әсәрләр, дүрт томда, 3 т., Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976, 581—582 битләр.
[3] «Казан утлары», 5 сан, 1976, 146 бит.

Татар халкының классик язучысы Шәриф Камал сугыш башлангач та үзенең тирән патриотик тойгыларын чагылдырып, «Кызыл Татарстан» газетасына «Әлбәттә җиңәчәкбез» дигән публицистик мәкалә яза. Автор анда илбасарларны «чирканыч, зәһәр аждаһа», ә үз иреге, азатлыгы өчен көрәшүче халыкны «батыр егет» белән чагыштыра һәм, халык әкиятләренә ишарә ясап, батыр егетнең җиңүен тасвирлый. «Без үзебезнең эшебез хаклы икәнлеккә нык ышанабыз. Бездә гаделлек, бездә хаклык, бездә аңлы җанлы көч, бездә алдынгы техника һәм корал бар... Әлбәттә без җиңәчәкбез»[1],— ди ул.

Дошманнарның явыз хыянәте үз башына булачагын шигъри гәүдәләндерү халыкның рухи ныклыгын арттыруга ярдәм итә. Кави Нәҗминең «Фашизмга үлем» шигырендә бу шактый калку чагыла.

...Котырган эт — Гитлер безгә каршы
Сугыш ачты, ләкин бу сугыш —
Үз башына булыр бу этнең.
Фашизмга үлем — бу сугыш!

Югарыда телгә алынган бу мәкалә һәм шигырьләрнең иң характерлы ягы — дошманны җиңүгә ышаныч тойгысының көчлелеге. Гадел Кутуй «Коммунизм өчен!» шигырендә гитлерчыларның Совет иленә һөҗүмен бәхетле киләчәккә — коммунизмга каршы һөҗүм итеп сурәтли һәм дошманнарның җиңелүгә дучар булачагы турында нык ышаныч белдерә.

Тора-бара газета битләренең тематикасы акрынлап үзгәрә. Ш. Маннур, Н. Баян, Ә. Исхак, Г. Кутуй, Ф. Кәрим һәм башка авторлар иҗатында конкрет сугыш вакыйгалары чагылыш таба. Менә «Кызыл Татарстан» газетасының 1941 ел, 25 октябрь саны. Өченче биттә «Бөтен көчебезне һәм иҗат эшебезне фашизмга каршы көрәшкә берик» дигән гомуми баш астында махсус сәхифә бирелә. Ул художник Р. Сәйфуллинның «Бөтенесе фронт өчен, бөтенесе җиңү өчен!» дигән плакат-картинасы белән ачыла. Сугыш чорында бу художник иҗат иткән әсәрләр газетада зур урын ала.

Әхмәт Исхакның «Бер адым да чигенмәбез», Гадел Кутуйның «Батыр каберендә», Кави Нәҗминең «Анасы һәм улы», Шәйхи Маннурның «Син нәрсә бирдең?», Әхмәт Юнысның «Сынау» шигырьләре һәм поляк шагыйре Леон Пастернакның Ә. Исхак тәрҗемәсендә «Антифашистлар җыры» — барысы да авыр сугыш көннәрен, совет халкының сыгылмас характерын ачалар. Бу тема Гази Кашшафның «Канга — кан, җанга — җан» дип исемләнгән публицистик мәкаләсендә калку күренә. Аны дулкынланмыйча укып булмый. Автор фашистларның ерткыч җанварлардан да явызрак булуын, аларның «кеше газапларын күреп ләззәтләнергә, кан агуыннан рәхәт табарга тырышуларын» фаш итә.

«Кызыл Татарстан» газетасында иң актив чыгыш ясаучыларның берсе Гадел Кутуй була. Аның дошманга үч-нәфрәт белән сугарылган шигырь, мәкаләләре, спектакльләргә рецензияләре атна саен диярлек басыла. Менә аның «Москва» шигыре. Ул публицистик җырга тартым. Мәскәүне шагыйрь рус иленең тарихи үткәннәре белән бәйләп сурәтли:

Күз алдында тора Суворовлар,
Кутузовлар килә хәтергә.
Һәм кабердән чыгып алар
Әзер
Москва өчен утка керергә[2].

Татар шагыйре рус халкының батырлыкка тиң тарихы белән хаклы горурлана, җиңүләрнең ата-бабадан килүен искәртә.

Газета битләрендә күренекле рус, украин һәм башка халыклар язучыларының, публицистларының мәкаләләре дә урнаштырыла. Александр Корнейчук, Емельян Ярославский, Всеволод Иванов, Ванда Василевская һәм башка авторларның публицистикасы татар укучысын тирән дулкынландыра.

---

[1] «Кызыл Татарстан», 8 июль, 1941 ел.
[2] «Кызыл Татарстан», 31 октябрь, 1941 ел.

«Кызыл Татарстан»ның 1941 ел, 6 ноябрь санында төрле ил язучыларының язмаларын туплаган махсус сәхифә бирелә. Анда немец язучысы Вилли Бредель, испан язучысы Сесар М. Арконада, итальян язучысы Дж. Джерманетто, татар язучысы Гомәр Бәширов мәкаләләре, немец шагыйре Клара Блюм һәм рус шагыйре Александр Сурков шигырьләре урнаштырыла.

Шунысы игътибарга лаек: бу сәхифәгә кергән мәкаләләр Казанда языла.

«...Германиядә гитлеризм килеп чыккан вакытта аерым кешеләрнең өстенә төшкән сынау, бүген бөтен дөнья өстенә һәм, башлыча, азат Советлар Союзының ике йөз миллионлы халкы өстенә төште. Һәм бу сынау нинди генә дәрәҗәдә каты һәм рәхимсез булмасын, совет халкы ул сынаудан җиңү белән чыгар»,— дип яза Вилли Бредель һәм мәкаләсе астына «Казан, 28 октябрь» дип куя[1]. Итальян язучысы Дж. Джерманетто мәкаләсе дә шулай тәмамлана.

Мондый сәхифәләр «Кызыл Татарстан»да шактый еш бирелгән.

1941 елда композиторларыбыз күп кенә яңа җырлар иҗат итәләр. Шуларның берсе — Ф. Яруллинның М. Җәлил сүзләренә язган «Кискен көрәшкә» җыры. Ул фашизмга каршы сугышта сафларны ныгытырга, Ватанның ялкынлы патриоты булырга чакыра. Күп тә үтми, газетада М. Мозаффаровның Әхмәт Исхак сүзләренә язылган «Поход җыры» басыла. Мәсгуть Латыйпов белән шагыйрь Гадел Кутуй «Ватан сугышы» дигән кантата язалар.

Композитор Н. Җиһанов Г. Кутуйның «Партизанка» дигән шигыренә көй иҗат итә. Әнә шулай җыр жанры үсә. Ул халыкны изге сугышка күтәрелергә чакыручы иң үтемле, иң сугышчан форма итеп карала.

Редакция фронт белән тыгыз элемтәдә тора. Фронтка киткән язучылар, журналистлар сугыш кырыннан якташларыбызның батырлыгы турында очерклар, шигырьләр җибәреп торалар. Ара-тирә үзләре дә кайткалыйлар. Ул елларны Гадел Кутуй, Шәрәф Мәдәррис, Әсгать Айдар, Мәхмүт Хөсәен һәм башкалар редакциядә булалар. Казан госпиталендә яткан Фатих Кәримнең шигырьләре газетада басыла.

Фронтовик язучылар, журналистлар республикабыз партия, совет оешмаларына, редакцияләргә, Язучылар союзына, әдипләргә хатлар язып торалар, Татарстан хезмәт ияләренең тормышы белән кызыксыналар, иҗат планнары белән уртаклашалар. Ватан сугышы елларында, мәсәлән, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Председателе Г. Динмөхәммәтов исеменә М. Җәлил, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Ш. Маннур, Б. Корбанов, М. Бубеннов һәм башка әдипләрдән, журналистлардан хатлар алына.

Үз чиратында Г. Динмөхәммәтов фронтовик язучыларны, журналистларны иҗат эшчәнлегенә рухландыра.

Г. Кутуйга 1943 елны язган җавап хатында Г. Динмөхәммәтов татар әдәбияты торышы турында аның фикере белән кушылып болай яза: «Сез хаклы, безнең республикада әдәби әсәрләр язу эше бик шәп тормый. Бу өлкәдә беренче адымнар, кем әйтмешли, яралгылар гына бар. Нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, бүгенге көнгә кадәр геройларыбызны сурәтләгән заманча, капиталь әсәрләребез юк, ә геройларыбыз хәзер бик күп. Якын көннәрдә бу мәсьәләне директив органнар каршына куярга уйлыйбыз, гонорар мәсьәләсе дә төзәтелер һәм Татарстан Язучылар союзына мәгълүм юнәлеш бирелер дип ышанам»[2].

1942 елның җәендә татар телендә уналты фронт газетасы чыгарыла башлый. Аларда күренекле әдипләр, шагыйрьләр, публицистлар, журналистлар, редакторлар, әдәби сотрудниклар, хәрби корреспондентлар булып Г. Кутуй, М. Максуд, Ә. Ерикәй, Р. Ишморат, А. Шамов, Х. Усманов, Г. Әпсәләмов, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, И. Гази, Г. Бакиров, А. Әхмәт, Ә. Исхак, Г. Галиев, Г. Хуҗиев, Г. Насретдинов, Ш. Мәдәррис, М. Мазунов, Ә. Юныс, К. Әхмеров, М. Шәйми, З. Шәһиморатов, А. Әхмәдиев, Б. Корбанов, Г. Хәбиб, Р. Баһау, М. Гыймадиев, Г. Гыйльманов, Я. Ярмәкиев, М. Савельев һәм башкалар эшләделәр. Татарча чыга торган фронт газеталары редакцияләрендә сугыш елларында 40 тан күбрәк язучы һәм журналист хезмәт итте. Бөек Ватан сугышында 50 дән артык язучы һәм журналист батырларча һәлак булды.

---

[1] «Кызыл Татарстан», 6 ноябрь, 1941 ел.
[2] «Казан утлары», № 5, 1976, 151 бит.

Фронт газеталары үтенечен канәгатьләндереп, аларга тылдагы редакцияләр, Татарстан Язучылар союзы республикабыз хезмәт ияләренең, әдәбият, сәнгать, фән эшлеклеләренең фидакарь эшләре турында материаллар, партия һәм совет органнары җитәкчеләренең мәкаләләрен җибәреп тордылар. Г. Бәширов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Х. Хәйри кебек язучылар фронт газеталарына турыдан-туры ярдәм итү өчен командировкаларга бардылар. Алар анда Ватан сугышы каһарманнары турында мәкаләләр язып бастырдылар.

Сугыш чорында «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә генә дә татар совет язучыларының 400 дән артык очерк һәм хикәяләре, шигырьләре, төрле темага язылган мәкаләләре һәм башка әдәби әсәрләре басыла.

Ватан сугышы елларында газетабызда бигрәк тә егерменче-утызынчы еллар шагыйрьләренең активлашуы үзен бик нык сиздерә. М. Җәлил, К. Нәҗми, Ш. Маннур, Г. Кутуй, Ф. Кәрим, Ә. Ерикәй, Ә. Исхак һәм башка шагыйрьләрнең халкыбызның дошманга каршы гадел көрәшенә багышланган, җиңүгә өндәгән 115 тән артык әсәре басыла. Боларга фашистлар тоткынында һәлак булган М. Җәлил, Р. Саттар, Х. Мөҗәй кебек әдипләрнең сугыштан соң табылган патриотик әсәрләрен дә өстәргә кирәк.

Публицистик рух сугыш елларында газетада аеруча көчәя. Бу табигый, чөнки публицистика патриотик көчләрне фашизмга каршы көрәшкә туплауда куәтле йогынты ясаучы жанрларның берсенә әверелә. Газета бу коралның тагын да үтемле булуы өчен үз тирәсенә байтак әдипләрне туплый.

Шундыйларның берсе — шагыйрь Нур Баян.

Республика партия матбугатының, шул исәптән Нур Баянның публицистикага «юл боруларында» күренекле совет язучысы Илья Эренбургның йогынтысын күрмичә мөмкин түгел. И. Эренбургның Ватан азатлыгы өчен барган утлы көрәш сызыгында торып иҗат ителгән язмалары бу елларда «Правда», «Красная звезда» һәм күп төрле фронт газеталарында гына түгел, «Кызыл Татарстан» битләрендә дә бик еш дөнья күрә. Аның «Талаучылар», «1943 елгы яз», «Июнь» һәм башка публицистик мәкаләләре, Татарстан хезмәт ияләрендә рухи күтәренкелекне уяту белән бергә, татар язучыларын да бу сугышчан жанрда активрак иҗат итәргә этәрә. Рус язучысының бу өлкәдә үрнәк күрсәтүен Нур Баян Ибраһим Газига язган хатында ачыктан-ачык әйтә, Эренбург мәкаләсенә охшатып, укучыларга һәм дусларга проза белән хат язарга җыенуын белдерә [1]. Һәм озакламый 1942 елның 26 сентябрендә «Кызыл Татарстан» газетасында шагыйрьнең «Йөрәктә нәфрәт, ачу кайный» дигән мәкаләсе басылып чыга.

Бу чор публицистикасы белән танышканда шуңа игътибар итәсең: сүз осталары фашизмның ерткычлыгын бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бастыралар. Бу Нур Баянның «Йөрәктә нәфрәт, ачу кайный» мәкаләсенә дә хас. «Гитлерчылар йөргән урыннарда — туганнарыбызның үлек гәүдәләре, сугышка кадәр гөрләп торган шәһәр урамнарында, авыл буйларында, аланнарда — дар агачлары, — дип язды шагыйрь, — телеграф баганаларында — безнең белән бергә сулыш алган, социалистик тормыш өчен бергә янган дусларның гәүдәләре асылынып тора...»

Документаль нигезгә корылган, патриотик рух һәм публицистик аһәң белән сугарылган киң колачлы бу чыгышта Нур Баянның идея, әхлак, поэтик декларациясе тагын да көчлерәк яңгырый. Ул фашистлар тарафыннан мәсхәрә ителгән унҗиде яшьлек кызның, дошманнан үч алырга чакырып, бер сугышчыга язган хатына, гитлерчыларның җинаятьчел боерыгына һәм башка документларга таянып, һәркемнең күңеленә ирешерлек публицистик гомумиләштерүләр ясый, Татарстандагы ватандашларын көрәшкә чакырып: «Дусларым! Немец бандитларын изге җиребездә юк итү өчен, сез безгә күбрәк снаряд, мина, граната, самолет, танк бирегез. Без Ватан өчен биргән антыбызны үтәрбез»... — ди.

Газетаның публицистик мирасында Шәриф Камалның өлеше зур. Бу җәһәттән шуны әйтеп үтәргә кирәк, 1942 елның 22 декабрендә, язучы вафат булгач, аның публицистик эшчәнлегенә газета югары бәя биреп: «Гомеренең соңгы минутына чаклы Шәриф Камал кулыннан үткен каләмен ташламады һәм фашизмга каршы юнәлдерелгән утлы мәкаләләр... язуын дәвам иттерде» ди.

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы, 11—12 сан, 1942 ел.

«Дошман бирелергә тиеш» — татар әдәбияты классигы Шәриф Камалның «Кызыл Татарстан» газетасында басылып чыккан иң соңгы мәкаләсе шулай дип атала. Сәнгатьчә камиллек һәм эпик колач белән иҗат ителгән бу сугышчан язмада әдипнең патриотик рух белән сугарылган ялкынлы сүзе бар тавышка яңгырый: «Дошман актыккы көчләрен куеп, безнең кулыбыздан бөек революция казанышларын тартып алырга омтыла. Советлар Союзының барлык туган халыклары ныклы дуслык, бердәмлек нигезендә оешкан хәлдә, дошман һөҗүмнәрен кире кайтару, канга манчылып котырынган бандаларның көчән муеннарын сындыру һәм аларны җир йөзеннән бөтенләй юк итү өчен Кызыл Армиягә зур тырышлык белән булышлык итәләр. Булышлыкны, әлбәттә, тагын да көчәйтергә кирәк. Бөтен көчләрне туплап, фронтка һәртөрле чаралар белән ярдәм итү һәрбер намуслы гражданның бурычы. Дошман бандаларының тар-мар ителүен безнең һәртөрле булышлыгыбыз, һичшиксез, якынайтыр»[1].

Сугыш вакытында фронт һәм тыл бердәм омтылыш, бер сулыш белән яши. Бу «Кызыл Татарстан» газетасы битләрендә дә чагылыш таба. Еш кына фронттагы сугышчы якташларыбызның каһарманлыклары турында сөйләүче язмалар белән янәшә үк тылдагы тормыш хәлләре киң яктыртыла. Газетаның 22 сентябрь (1943 ел) санында урта битләрдәге язмалар, шигырьләр шушы берлекне күрсәтүгә багышлана. Анда сөекле шагыйребез Г. Тукайның «Без сугышта юлбарыстан көчлебез, без тынычта аттан артык эшлибез!» дигән сүзләре барлык материаллар өчен эпиграф итеп алына. Менә Ш. Маннурның «Хәрәкәттәге армия» дигән кайтарма адрес белән килгән «Исәнме, туган җир» исемле шигыре. Ул ут эчендә Ватан өчен көрәшүче сугышчының туган җиргә кайнар мәхәббәтен ачып бирә:

> **Солдат яши туган иле өчен,**
> **Солдат үлә туган җир өчен,**
> **Саф күңелдән сине сөючең ул**
> **һәм билгесез батыр җиңүчең.**

«Мин татарларны бик яхшы беләм: алар вөҗданлы халык, батыр йөрәкле халык, һәртөрле каһарманлыкларга сәләтле халык». Бу — Максим Горький сүзләре. Әлеге сәхифәдә аны зур горурлану хисе белән кабат укырга мөмкин.

Куш биттәге махсус сәхифәдә тылдагы халыкның хезмәт батырлыгын чагылдырган язмалар да күп. Язучы Мирсәй Әмир «Бабайлар» турында яза. «Колхоз бабайлары. Алар арасында алтын бабайлар нинди күп! Сугышка кадәр картлыкка чыгып,... аннары сугыш башлангач, үзләре теләп яңадан колхоз эшенә кайткан бабайларның намусы каршында, аларның патриотик көче каршында җаннарың эреп китәрлек...» ди автор.

Тылдагы язучылар редакция заданиесе белән авылларда, колхозларда еш булалар. Нәтиҗәдә күп кенә очерклар, хикәяләр, этюдлар иҗат ителә. Г. Кашшаф, Ф. Хөсни, Г. Иделле, Г. Бәширов, К. Нәҗми 1944—1945 елларда аеруча актив эшли. Гази Кашшафның «Ютазы хатлары» циклы, Ф. Хөснинең Буденный районы эшчәннәренә багышланган этюд-зарисовкалары, Гомәр Бәшировның Арча районы колхозларыннан язылган очерклары — шуның мисаллары.

Гази Кашшафның «Татар әдәбияты яңа борылышта»[2] дигән мәкаләсе аерым игътибарны сорый. Чөнки ул сугыш чорында язучылар эшчәнлеген раслаган кыйммәтле документ булып тора. Мәкалә татар совет язучыларыннан Т. Гыйззәт, Н. Исәнбәт, К. Нәҗми һәм Г. Кашшафның СССР Совет язучылары союзы президиумы чакыруы буенча Мәскәүдә булып кайтканнан соң языла. «Москвага фронттагы язучылардан Г. Кутуй, Ә. Ерикәй, Г. Галиев һәм М. Садри иптәшләр дә җыелган иде», ди Г. Кашшаф үз мәкаләсендә. Аннары сугыш чорында каләм осталарының эшчәнлегенә тукталa. «Мәскәүдә татар совет язучыларының иҗатларын тикшергән вакытта, татар әдәбиятының бай традицияләре, үткән мирасы искә алынды, — дип дәвам итә автор. — Русның мәшһүр язучысы Александр Фадеев, татар әдәбияты тарихында проза әсәрләренең зур урын тотуын, аның реалистик юлда бик нык алга киткәнлеген, язучыларның тел сафлыгына, әдәби композициягә аеруча игътибар биргәнлекләрен әйтеп, татар әдәбиятының Союзда иң зур әдәбиятлардан берсе булуын күрсәтеп үзды... Иптәш

---

[1] «Кызыл Татарстан», 24 декабрь, 1942 ел.
[2] Карагыз: «Кызыл Татарстан», 23 ноябрь, 1943 ел.

А. Фадеев, А. М. Горькийның татар әдәбиятына югары бәя биргәнлеген, аның белән кызыксынуын һәм татар язучыларының әдәби осталыклары турында сокланып сөйләвен белдерде һәм барлык татар совет язучыларына да әдәби осталыкка ирешү бурычын куйды».

Мәскәүдә Татарстан язучылары А. Фадеев белән ВКП(б) Үзәк Комитетында булалар. Анда Үзәк Комитет «Совет әдәбияты» журналының тиражын 3 меңнән 10 меңгә кадәр арттырырга рөхсәт бирә һәм кәгазь белән тәэмин итүдә ярдәм итә. «Без Үзәк Комитеттан канатланып һәм яңа эшләргә рухланып чыктык»[1], дип яза ул көннәр турында Г. Кашшаф. Әлеге факт татар әдәбияты өчен күңелдә урынлы горурлану хисе уята. Ул утлы елларда да партиябезнең әдәбият-сәнгать мәсьәләләрен һәрвакыт игътибар үзәгендә тотуы хакында сөйли.

Мәскәүдә булып кайтканнан соң, татар язучыларының шактый активлашуы сизелә. Газета әдәби әсәрләр белән бергә, Татарстан сугышчылары турындагы очерк, зарисовкаларга зур урын бирә. Әлеге язмаларның рубрикасы «Ватан өчен сугышларда безнең якташлар» дип атала. Хәрәкәттәге армиядән Абдулла Әхмәт, мәсәлән, «Кызыл Яр егете» дигән зарисовка җибәрә, анда Шаһгали Солтановның батырлыгы турында сөйли. Ә Риза Ишморатов һәм Гали Хуҗиев «Татарстан, ишет!» дигән очерк язалар. Ул күләме белән әллә ни зур булмаса да, сугыш эпизодларын күрсәтү, совет солдатының теләсә нинди батырлыкка әзер булуын раслау ягыннан бик көчле әсәр. Авторлар аны фронтның алгы сызыгыннан җибәрәләр. «Татарстан, ишет! Каһарман улларың, Ватан өчен каннарын һәм җаннарын да кызганмыйча сугышып, синең азатлыгың, Идел-йортны менә шулай саклыйлар,— диләр алар.— Татарстан кызлары, ишетегез! Сөйгән ярларыгыз сезнең намусыгыз өчен, шатлыклы кавышу һәм бәхетле семья өчен, якты киләчәк өчен менә шулай сугышалар».

1943 елның 17 декабрендә ВКП(б) ның Татарстан өлкә комитеты бюросы, Татарстан совет язучылары союзы правлениесенең эшен тикшереп, махсус карар кабул итә. Карарда язучыларның эшенә гомуми бәя бирү белән бергә, алар алдында торган бурычлар да ачык билгеләнә. ВКП(б) өлкә комитеты бюросы язучыларга сугыш чоры өчен хас булган, массаларны шул чордагы идеяләр белән баета торган әсәрләр тудыру эшен йөкли. Бу исә язучылардан барлык көчләрен эшкә җигүне, халыкка тагын да якынаюны, әдәби осталыкны үстерүне таләп итә. Карарда язучыларның тормыш белән нык бәйләнгән булуларына, марксизм-ленинизм тәгълиматын ныклап өйрәнергә тиешлекләренә, совет кешесенең рухын тоеп, аны аңлый белеп иҗат итәргә кирәклегенә аеруча басым ясала.

Партия Үзәк Комитеты «Татарстан партия оешмасындагы масса-политик һәм идеологик эшнең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» (1944 ел) карар кабул итә. Анда Татарстанның рухи тормышында ирешелгән зур казанышлар белән бергә, сугыш елларында политик-масса эшендә, татар халкының тарихын яктыртуда, шулай ук татар әдәбияты һәм сәнгате өлкәсендә гәүдәләнгән идеологик характердагы җитди ялгышлар да күрсәтелә[2].

Партиябезнең Татарстанда әдәбият-сәнгатьнең дөрес юлдан үсүе турында кайгыртуына җавап итеп, язучылар, идеология фронты работниклары җиң сызганып эшкә тотыналар.

М. Әмир «Миңлекамал» дигән сәхнә әсәре иҗат итә. Тәнкыйтьче Л. Җәләй әлеге пьесага багышланган рецензиясендә «Миңлекамал» партия тарафыннан «куелган югары таләпкә җавап була ала торган әсәрләрнең берсе һәм беренчесе дип саналырга хаклы»[3],— ди.

Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә куелган бу әсәрдә гади татар хатынкызлары образлары аша совет патриотизмы күрсәтелә. Гомумән, матбугат М. Әмирнең «Миңлекамал»ын уңай яктан билгеләп үтә, аның тәрбияви роленә басым ясап, авторның һәм театр коллективының уңышларын ачык күрсәтә.

Бу елларда совет язучыларының иҗаты белән таныштыруның күп төрле алымнары кулланыла. Музейларда күргәзмәләр оештыру, түгәрәк даталар уңаеннан газетада мәкалә-истәлекләр оештыру — менә шундый алымнарның берничәсе. «Кызыл

---

[1] «Советская Татария», 25 декабрь, 1971 ел.
[2] Карагыз: «КПСС в резолюциях...», Изд. 8-е, т. 6, М., 1971, 119 бит.
[3] «Кызыл Татарстан», 14 май, 1944 ел.

Татарстан» газетасының 8 октябрь (1944 ел) саны М. Горький музеенда Г. Тукайга багышланган экспозиция ясалуы турында хәбәр итә. Хезмәт ияләре Тукай күргәзмәсен зур кызыксыну белән карыйлар, шагыйрьнең иҗат һәм тормыш юлын өйрәнәләр, андагы уңай сыйфатларны үзләрендә дә булдырырга тырышалар. 4 нче Украина фронты сугышчылары һәм офицерлары күргәзмәне караганнан соң болай дип язып калдырганнар. «Без, 4 нче Украина фронтының командировкага килгән бер группа сугышчылары, бүген татар шагыйре Г. Тукайга багышланган күргәзмәне карадык. Күргәзмә бөек татар шагыйренең тормышын һәм иҗатын ачык күрсәтә» [1].

Бөек мәсәлче И. Крыловның үлүенә 100 ел, А. Грибоедовның тууына 150 ел, бөек фикер иясе һәм революционер Н. Чернышевскийның үлүенә 55 ел тулу, татар галиме Каюм Насыйриның тууына 120 ел тулу уңае белән урнаштырылган мәкаләләр, махсус битләр тылда һәм фронттагыларны патриотик рухта тәрбияләүдә зур роль уйный, язучыларның иҗаты һәм тормышы белән киң таныштыра.

1943 елның 6 мартында «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталарында «Фронтовик татарларга татар халкыннан сәлам хат» басыла. Ул бер көн алда — 5 мартта «Правда» һәм «Известия» газеталарында чыга. Шушы хатка җавап итеп, «Кызыл Татарстан»ның 1943 ел, 3 апрель санында «Ленинград фронтындагы татар сугышчыларының татар халкына хаты» басыла. Хатта аларның Ленинградны дошманнан нык саклаячаклары белдерелә: «Безнең өскә данлы бурыч — Ленин шәһәрен — революциянең бишеген саклау бурычы йөкләнде. Барлык сугышчылар белән — руслар һәм украиннар, белоруслар һәм грузиннар, казахлар һәм үзбәкләр белән бер сафта торып көрәшкән хәлдә без фашист кабәхәтләрне туктаусыз кырабыз, дошманның техникасын җимерәбез, дошман яуларын Ленинград яныннан куабыз» [2], — дип языла анда.

«1 нче Украина фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хат» игълан ителә. Ә шанлы җиңү яулап алынгач, 1945 елның 17 июлендә, газетада «2 нче Белоруссия фронтының татар сугышчыларыннан татар халкына хаты» басылып чыга.

Җиңүгә зур өлеш керткән бу мөһим документларның иҗат ителүен безнең язучыларыбыз һәм шагыйрьләребезнең публицистикадагы зур казанышы дип тә карарга кирәк. Мәсәлән, 1 нче Украина фронтының татар сугышчылары хатын язуда фронт газетасы редакторы булып эшләгән Риза Ишморат белән Гали Хуҗи актив катнаша. 2 нче Белоруссия фронты татар сугышчылары хатын иҗат итүдә Шәрәф Мөдәррис зур роль уйный. Р. Ишморатның сөйләвенә караганда, фронтовик татарларга татар халкының хаты һәм шул хатка җаваплар тыл һәм фронтның какшамас аерылгысызлыгын раслап кына калмый, бәлки совет халкының, шул исәптән батыр татар халкының рух бердәмлеген чагылдыра, аның партия тирәсенә корычтай ныклык белән тупланганлыгын дәлилләп тора.

**Рух бирде безгә сугышта ныгыган, үскән Союз,**
**Бөек халыклар дуслыгы, сынауны үткән Союз.**
**Без бер семья, таза йодрык, бергә килеп береккән —**
**Рус, татар, казах, молдован, үзбәк, әрмән, төрекмән.**
**Бер үк безнең, аерылгысыз — һәммәбезнең теләге,**
**Уртак безнең Ватаныбыз — бөек дуслык терәге** [3], —

диелә 2 нче Белоруссия фронты сугышчыларының җавап хатында. Гомумән, хатларның проза белән язылганнарыннан аермалы буларак, соңгысының шигырь белән язылуы кайнар хис, йөрәк авазы, героик халыкка хас булганча, рух күтәренкелеге белән сугарылган. Каһарман генералларыбыз Я. Чанышев, Ф. Булатов, Х. Ганиев, Советлар Союзы Геройлары Г. Булатов, Х. Гыйззәтуллин, Ф. Хәбиев, С. Сәетвәлиев, Дан орденнарының тулы кавалерлары Х. Гарипов, Д. Булатов һәм фронтның дүрт меңнән артык батыр татар сугышчысы кул куйган бу хат патриотик хис белән тулы. Бу хатка шулай ук язучылардан һәм журналистлардан Х. Госман, Ш. Мөдәррис, Г. Насрый, Г. Гыйльманов, Н. Гобәйдуллин һәм башкалар кул куйган. Ул гражданлык поэзиясенең меңнәрчә, миллионнарча кешегә барып ирешкән гүзәл бер үрнәкләреннән санала ала.

---

[1] Карагыз. «Кызыл Татарстан», 8 октябрь, 1944 ел.
[2] «Кызыл Татарстан», 3 апрель, 1943 ел.
[3] «Кызыл Татарстан», 17 июль, 1945 ел.

Татар халкының фронтовик татарларга язган хатына, халыкның данлы тарихына бәя биреп, бу шигъри документта болай диелә:

**Килде синең сәлам хатың күңел күген нурлатып,**
**Саф йөрәктән, пакь намустан, ант иттек без шул вакыт:**
**Ант иттек без туган җирне явызлардан сакларга,**
**Соңгы тамчы канга чаклы Ватан хакын хакларга...**
**Үтәп чыгып көрәшләрдә сугышчанлык бурычын,**
**Төгәлләдек җиңү белән Бөек Ватан сугышын!..**
**Торды безгә сугышларда рух, куәт, илһам салып,**
**Рәсәйдә үткән тарихың синең дә, туган халык!**
**Торды хәтердә борынгы — Идел-Йорт лачыннары —**
**Данлы Ливон, Бородино, Перекоп батырлары** [1].

Кайнар патриотик хисләр белән иҗат ителгән бу бердәмлек антлары татар совет журналистикасын һәм әдәбиятын өйрәнүче галимнәребез белән белгечләрнең җитди игътибарына лаек.

Бу чорда газета спектакльләргә, басылып чыккан әдәби китапларга рецензияләр биреп баруны дәвам иттерде.

1941 елның июнь башларында хөкүмәт комиссиясе һәм җәмәгатьчелек Н. Җиһановның М. Җәлил либреттосына язылган «Алтынчәч» операсын тыңлады. Ул сәхнәгә куелгач, матбугатта, шул исәптән «Кызыл Татарстан» газетасында да, бик күп мәкаләләр басылды [2], яңа опера хаклы рәвештә культурабыз тормышында зур вакыйга дип бәяләнде. «Алтынчәч» операсы, — дип язды өлкән әдибебез Шәриф Камал, — мондә гүзәл һәм көчле тәэсир калдырды. Монда халыкның ирек сөючәнлек, батырлык һәм күмәк омтылучанлык кебек матур сыйфатлары тамашачыларга музыка аркылы җанландырылып бирелә» [3].

Татар дәүләт академия театры 1941 елның 26 июлендә Т. Гыйззәт әсәре буенча «Таймасовлар» спектаклен куйды. Шул ук көннәрдә Г. Кутуй «Кызыл Татарстан» газетасына рецензия дә язып өлгерткән. «Театрның төп режиссеры иптәш Ш. Сарымсаков, пьесаның художество кыйммәтен, андагы характерларның төрлелеген табигый ачып бирү белән бергә, совет халкының туган илгә булган мәхәббәтен, халык улларының батырлыкларын сәхнә сәнгате аша күрсәтүгә нык игътибар биргән» [4]. Газетада Т. Гыйззәт әсәре белән С. Сәйдәшев музыкасы нигезендә куелган «Наемщик» музыкаль драмасының премьерасына Г. Кашшаф [5] рецензиясе дә басыла.

Ул елларда чыккан әдәби җыентыклар тәнкыйтьчеләр күзеннән читтә калмый. Мәсәлән, М. Максудның «Үч һәм нәләт җыры», Ш. Мөдәррїснең «Тупчы Ваһап» дигән шигырь һәм поэмалар җыентыкларына карата язылган рецензияләр моңа мисал булып тора. «Дошманны җиңү өчен төп шарт — аны дошман күрә белү, үч алу, нәфрәтләнү, баштанаяк көчле нәләт тойгылары белән кораллану. М. Максуд иптәшнең «Үч һәм нәләт» җыентыгында әнә шушы идея самими йөрәктән чыккан лирик шигырьләр эченә салынып бирелгән» [6], — ди үзенең рецензиясендә галим, әдәбият белгече Л. Җәләй. Ә Фатих Хөсни «Ш. Мөдәррїснең бу җыентыгы шагыйрьнең Ватан сугышы көннәрендә күзгә күренеп үсканлеген билгеләүче якты һәм шатлыклы бер истәлек булып кала» [7], — дип бәяли.

* * *

«Кызыл Татарстан» газетасы һәм «Совет әдәбияты» журналы фронтта татар солдатларының яратып укый торган басмалары була.

Фронтовик-шагыйрь Зәки Нури үзенең бер язмасында Бөек Ватан сугышы елларының «гомергә онытылмаслык бер вакыйгасын хәтерлим», — дип исенә төшерә: —

---

[1] «Кызыл Татарстан», 17 июль, 1945 ел.
[2] Карагыз: «Кызыл Татарстан», 11, 20 июнь, 20 июль, 1941 ел.
[3] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы. «Кызыл Татарстан» редакциясенә хат, 4921 фонд, 1 нче тасвирлама, 6 нчы эш, 59 бит.
[4] Карагыз: «Кызыл Татарстан», 31 июль, 1941 ел.
[5] Шунда ук, 22 ноябрь, 1941 ел.
[6] «Кызыл Татарстан», 22 март, 1944 ел.
[7] Шунда ук, 18 апрель, 1944 ел.

«Зур җирдән» фронт сызыгы аша очып килгән самолет партизаннар зонасына йөк ташлады. Парашютларның берсендә Татарстан бүләкләре дә бар иде. Шулай туры килгәне өчен рәхмәт яугыры: арадан бер төргәк «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» газеталары килеп чыкмасынмы шунда! Мех бияләйләр, җылы шарфлар, Казан кызлары матурлап чиккән кульяулыклар һәм тәмәке янчыклары белән бергә, алар да кулдан-кулга бик тиз таралды. Безгә, Татарстанның өч егетенә, якташ газеталарны көрәштәш дусларга өләшүе чиксез-чамасыз бер куаныч булды. Кайберләрен агач кәүсәләренә дә бик тиз ябыштырып өлгердек. Барыбыз да шуларны йотлыгып укый...

Без алардагы информацияләрнең муллыгына һәм сугышчанлыгына сокландык. Һәр полосадан, әйтерсең, безнең Җиңү кояшыбыз ялтырап күренде, ә пулемет лентасын хәтерләткән колонкалар исә дошманны кыра торган кургаш юллардан төзелгәннәр төсле иде. Җан тетрәткеч очрашу димичә нәрсә диярсең моны!» [1].

Язучыларның, журналистларның фронт газеталарында, матбугатта эшләүләре әдәбиятыбызны, журналистиканы баетты, үзләренең ялкынлы сүзләре, шәхси батырлыклары белән алар сугышта дошманны җиңүгә, тылда фидакарь хезмәткә рухландырдылар.

Муса Җәлил «Отвага» газетасы сотрудникы буларак, язучының фронттагы роле турында болай дип язган: «Бары тик алгы сызыкта гына кирәкле геройларны күрергә, материал табарга, сугыш хәрәкәтләрен күзәтергә мөмкин. Шуның өчен мин гади күзәтүче булып кына йөрмим, канкойгыч сугышларда үзем дә катнашам» [2].

Язучы-журналист Абдулла Әхмәт «Кызыл Татарстан»га сугыш кырыннан язып җибәрә. «Хәрби журналист — оборона вакытында да, һөҗүм вакытында да алгы сызыкта. Дошман обороналарын беренче булып өзүче, аңа беренче ударлар ясаучы батырларны күреп, алар белән сөйләшә һәм әле генә булып узган вакыйгалар турында фронт газетасы өчен материаллар оештыра. Мондый кайнар көннәрне ул сугышчы да, оештыручы да, кирәк булса, командир да булып китә...» [3]

Язучы Габдрахман Әпсәләмов фронт газетасында эшләвен горурланып искә ала. «...Чын-чыннан журналистика мәктәбен, — дип яза ул, — фронт газетасында үттем. Газета эшенең ашыгычлыгы, материалның көненә генә түгел, сәгатенә кирәк булуы — мине тиз һәм кыю эшләргә өйрәтте. Мин уйлыйм, газета мәктәбен үтмәгән кешегә язучы булу бик кыендыр» [4].

Шулай итеп, Татарстан матбугаты, шул исәптән «Кызыл Татарстан» газетасы кайнар сугыш көннәрендә дә үзләренең публицистик сүзләре, язучылар, журналистлар, иҗат интеллигенциясе, авыл һәм эшче хәбәрчеләрнең актив ярдәме белән партия өлкә комитеты җитәкчелегендә халкыбызны гадел көрәшкә туплыйлар. Әлбәттә, матбугат органнарының сугыш елларында әдәбият-сәнгать, публицистика аша халыкка йогынты ясавы уңай нәтиҗә бирә.

Совет кешесе тылда һәм фронтта да батырлык күрсәтте. Икенче Балтик буе фронтының «Суворовчы» дигән газетасында күренекле полководец, Икенче Балтик буе фронты командующие армия генералы А. И. Еременко: «Татар халкының бик күп уллары фронтта үзләренең исемнәрен дан белән бизәделәр» [5], дип яза, татар халкының дан казанган улларына, Совет Ватанының дошманнарына каршы куркусыз сугышучы батырларга мактау сүзләре әйтә.

Фронт белән тылның нык элемтәдә булуы, Бөек Ватан сугышы елларында тылда да, фронтта да газета-журналлар чыгу — күпмилләтле совет кешеләрен, совет солдатларын Ватанга бирелгәнлек хисендә, совет патриотизмы рухында тәрбияләде. Хәзер инде совет публицистлары сугыш елларында матбугатта тупланган тәҗрибәне өйрәнәләр, аны үзләренең көндәлек эшләрендә файдаланалар.

---

[1] «Социалистик Татарстан», 4 апрель, 1968 ел.
[2] «Литературная газета», 9 май, 1973 ел, шулай ук «Казан утлары», № 6, 1975 ел, 133 бит.
[3] «Кызыл Татарстан», 21 июль, 1944 ел.
[4] «Казан утлары», 1975 ел, 4 сан, 119 бит.
[5] «Суворовчы» газетасы, 13 октябрь, 1944 ел. Карагыз: «Казан утлары», № 5, 1975 ел, 152 бит.

Әбрар Кәримуллин

# ГӨЛНАР ХАНЫМ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының Бөек Ватан сугышыннан соңгы беренче сезоны М. Гали һәм Х. Уразиковның «Каюм Насыйри» драмасы белән ачылды. Татар тамашачылары сәхнәдә беренче тапкыр Гөлнар ханым образы белән очраштылар. Драмада атаклы татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның Гөлнар ханым белән иҗади хезмәттәшлеге, аларның Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыятендә бергә эшләүләре, Гөлнар ханымның Каюм Насыйри эшчәнлеген кайнар рәвештә яклавы сурәтләнә иде.

Бу әсәр белән танышкач, «реаль тормышта Гөлнар ханым образының прототибы булганмы соң?» дигән табигый сорау туа. Булган гына түгел, мәгърифәтчелек хәрәкәтендә күренекле урын тоткан гаять үзенчәлекле шәхес, тормышы һәм эшчәнлеге өйрәнелүгә лаек культура эшлеклесе ул. Рус һәм шәрык, рус һәм татар культуралары арасындагы бәйләнешләрне өйрәнүче галимнәребезгә дә ул таныш.

Чын исеме аның — Ольга Сергеевна Лебедева. Кем соң ул бу кадәр күңелле рус хатыны? Кайда туып, кайда яшәгән, ниләр кылган? Ниһаять, ни өчен аны Гөлнар ханым дип атаганнар?

Эзләнүләрне башлауга, Казан университеты типографиясендә басылган китаплар каталогында шундый мәгълүмат очрады: К. Насыйри, татар балалары өчен рус «Әлифба»сын төзегәндә, рус теленә О. С. Лебедева тарафыннан тәрҗемә ителгән «Кабуснамә» китабыннан мисаллар алган. О. Лебедева аны татар теленнән тәрҗемә иткән, ә татар теленә исә әсәрне фарсыдан Каюм Насыйри үзе күчергән һәм 1882 елда китап итеп бастырып чыгарган булган. О. Лебедева тәрҗемәсе 1886 елда, ягъни әсәрнең татарча тексты басылып дүрт ел үткәч дөньяга чыга. Ольга Лебедева зур тырышлык белән гарәп, фарсы, төрек телләрен, гарәп графикасын өйрәнә. Татар сөйләм телен яшьтән үк белгән булса да, гарәп һәм фарсы сүзләре белән чуарланган китап теле аңа әле авыр бирелә. «Кабуснамә»не ул шәрык телләрен тагын да тирәнрәк үзләштерү максатын күздә тотып тәрҗемә иткән булырга мөмкин. Чөнки татар теленнән русчага О. Лебедева тәрҗемә иткән бердәнбер әсәр ул. Шәрык телләрен өйрәнгәндә О. Лебедева Каюм Насыйридан да дәресләр алган.

Ольга Сергеевна татарның башка мәгърифәтче галим һәм әдипләре Шиһабетдин Мәрҗани, Мөхәммәтгази Мәхмудов һәм башкалар белән дә яхшы таныш була. Гомум мәгърифәтчелек идеяләре, дөньяви мәктәпләр төзү, татар яшьләре алдында рус һәм Европа культурасы ишекләрен ачу, вакытлы матбугат булдыру, татар балаларына рус теле укыту максатлары аларны бер-берсенә якынайткан. Татарларның тормыш-көнкүреше белән якыннан таныш булуы, халыкның мохтаҗлык һәм хокуксызлыгын күреп тирәнтен ачыну тойгысы Ольга Сергеевнаны татар һәм башка мөселман халыкларының ихлас күңелле дустына әверелдерә. Ул татар мәгърифәтчеләренең фикердәше, ә миссионерлар каршында «еретик» булып китә.

О. С. Лебедева хакындагы биографик мәгълүматлар аз. Ул 1854 елда Казанда яисә шул тирәдәге бер авылда туып үсә. Аларның монда үз утары булган булырга тиеш. Яшь туташның кайда югары белем алуы турында нинди дә булса мәгълүмат очрамады. Шәрык культурасын, телләрен өйрәнү максаты белән ул шактый еллар Төркиядә яши. Анда төрек галимнәре, әдипләр, җәмәгать эшлеклеләре белән элемтәгә керә, төрек әдәбияты, матбугаты һәм мәктәпләре белән таныша, тарихын өйрәнә. Ул гына түгел, О. С. Лебедева, җиң сызганып, төрек җәмәгатьчелеген рус әдәбияты, аның алдынгы вәкилләре иҗаты белән таныштыру эшенә керешә. Төрек власть ияләре аның бу эшчәнлегенә шик белән карый, хәтта аны яшертен агент дип саныйлар. Шәрык белгечләренең 1889 елда Стокгольмда үткән Сигезенче халыкара конгрессында Лебедева күренекле төрек мәгърифәтчесе, галим һәм язучы Әхмәд Мидхәд белән таныша. Әдип төрек әдәбият сөючеләрен рус әдәбияты казанышлары белән таныштыруны кайнар хуплый. Төрек вакытлы матбугаты битләрендә О. С. Лебедеваның рус язучылары иҗатына багышланган мәкаләләре еш басыла башлый. Лебедева шулай ук рус язучыларының әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итеп бастыра. 1890—1892 нче елларда Истамбулда А. С. Пушкинның «Буран», «Пиковая дама» әсәрләре, шагыйрь турындагы биографик очерк басыла. М. Ю. Лермонтовка багышланган күләмле мәкалә, «Демон»нан тәрҗемә ителгән өзекләр китап булып чыга. Тәрҗемәләр арасында Лев Толстой әсәрләре зур урын алып тора. Шушы елларда аерым китап булып Толстойның «Ике карт», «Гаилә бәхете», «Ильяс», «Иван Ильичның үлеме» һ. б. әсәрләре дөнья күрә.

Рус әдәбияты белән киңрәк таныштыру максатын күздә тотып, Ольга Сергеевна рус әдәбиятының беренче чорларыннан алып үз заманына кадәр булган тарихын бәян иткән аерым китап яза. А. С. Пушкинның төрек телендә биографиясе дә аерым басма булып чыга. Аның барлык тәрҗемәләре диярлек шул заманның төрле журналларында бирелә бара, соңыннан аерым китаплар рәвешендә басыла.

Тәрҗемәләрен, мәкалә һәм монографияләрен О. С. Лебедева «Гөлнар ханым» псевдонимы белән чыгара. Россиягә кайтканнан соң ул матбугатта шул исем белән чыгышлар ясый һәм танылып китә.

Төркиядә Гөлнар ханымга карата булган төрле шик-шөбһәләр тиздән юкка чыга, галим-голәмә, әдипләр арасында ул хөрмәтле кеше санала башлый.

О. С. Лебедеваның эшчәнлеге шул чор рус матбугатында да югары бәя ала, аны рус әдәбиятының Төркиядәге тулы вәкаләтле вәкиле дип атыйлар. Гөлнар ханым төрек әдәбиятын рус теленә тәрҗемә итү эшен дә башлап җибәрүче. Рус телендә бастыру өчен ул күренекле төрек әдипләре Әхмәд Мидхәд, Касыйм Әмин әсәрләрен әзерли. Әмма патша цензурасы төрек әдәбиятының бер генә үрнәген дә Россиядә дөньяга чыгарттырырга теләми.

Гөлнар ханым, шәрык телләреннән тыш, борынгы грек, испан, итальян, француз телләрен яхшы белгән, Көнбатыш Европа телләренә төрек язучыларының әсәрләрен тәрҗемә иткән. Аның эшчәнлеге белән Европада кызыксына башлыйлар, һәм бу хәл Россиянең үзендә дә эзсез калмый. 1893 елда, Гөлнар ханымның Россиягә кайтуы хакында ишеткәч, «Санкт-Петербургские ведомости» үз корреспондентын Одессага җибәрә. Одессада чыга торган газетада Гөлнар ханымга багышланган «Рус хатыны төрекләр арасында» дигән сенсацион исем белән интервью басылып чыга.

«Ул — Ольга Сергеевна Лебедева, — диелә интервьюда, — Россиядә әлегә бик популяр булмаган бу исем, хәлбуки, Америка, Англия, Бельгия һәм өлешчә Франция журналларын урап чыгарга өлгергән инде.

Төркиядә безнең Ватаныбызга карата яшәп килгән ялгыш карашны бетерү теләгеннән тыш, Лебедева ханымның Константинопольдә шактый озак вакытлар яшәвенең икенче бер максаты да бар.

— Мин анда укыйм, корьән һәм шәригатьне, төрек, гарәп, фарсы телләрен өйрәнәм...

Лебедева ханым газета репортерына әнә шулай ди.

— Сез бәлки боларның миңа нинди хаҗәте бар дип тә сорарсыз,— дип дәвам итә ул сүзен. — Болай җавап бирәм: тәмам онытылган, читкә тибәрелгән кавем — русь татарлары арасында цивилизация тарату өчен. Аларны мин ирем белән Казанда яшәгән чакта бик якыннан өйрәндем... Татарлар — яхшы күңелле, ягымлы, акыллы ха-

лык — русларга нисбәттә хәзер ниндидер ялган, нормаль булмаган хәлдә торалар, минем максатым исә: аларга руслардан аерылып тормаслык дәрәҗәдә мәгърифәт бирү.

—Ә сез моңа ничек ирешергә уйлыйсыз?

— Махсус татар мәктәпләре ачып һәм ярым русча, ярым татарча чыга торган газета оештырып... Безнең мәктәп һәм университетларга керү татарлар өчен мөмкин түгел»[1].

Илгә кайтуга, Ольга Сергеевна туры Петербургка юнәлә һәм үзенә хас дәрт белән ниятләрен тормышка ашыруга керешә. Ул Матбугат эшләре буенча баш идарә начальнигы Е. Феоктистов белән очраша, татарлар өчен газета оештыру планын аңлатып бирә һәм яклау да тапкан кебек була. Ләкин тиздән Гөлнар ханымга кыска һәм төксе генә язылган рәсми кәгазь килә, анда, «Чишмә» исемле русча-татарча газета чыгару проектын Эчке эшләр министры кулай дип тапмый, диелгән була[2].

Газетаның программасы нидән гыйбарәт булган, ни өчен патша хөкүмәте аны чыгарырга рөхсәт бирмәгән?

О. С. Лебедеваның матбугат идарәсенә җавап хатындагы аңлатмада болай диелә: «Русча-татарча әдәби-тарихи гаилә газетасы. Атнага бер тапкыр чыга, мөселманнарга аң-белем бирүне, рус тарихы, әдәбияты белән таныштыруны максат итә. Газета ике телдә чыга: русча тексты һәм татар теленә тәрҗемәсе. Цензура аша үткән мәкаләләр генә басыла ала. «Правительственный вестник»тан һәм халык мәгарифе министрлыгы тарафыннан хупланган тәрбияви журналлардан күчермәләр булыр»[3].

Шул ук хатында Ольга Сергеевна газетаның шактый чикләнгән программасын тагын да тарайтырга әзер булуын белдерә, бары тик рөхсәт кенә бирелсен. О. С. Лебедева үз ниятенең патша самодержавиесе политикасына да, татарлар арасында мәгърифәт тарату максатына да бердәй туры килүенә ышаныч белән эш итә. Башка халыкларны алдынгы рус культурасы белән әдәбиятына якынайту буенча элек башкарган эшләренең Төркиядә һәм Көнбатыш Европа илләрендә хуплап каршы алынуыннан соң, шундый ук характердагы эшчәнлек үз илендә катгый рәвештә тыелыр дип ул күз алдына да китерми. Царизм политикасына карашында ул, әлбәттә, иллюзияләрдән тулысынча арынмаган була, «яхшы күңелле, акыллы һәм ягымлы халык»ларның русларга нисбәттә ни өчен «ниндидер ялган, нормаль булмаган хәлдә» калуын төшенеп җитми. Күрәсең, миссионерларның татарлар үзләре дәртсез, иҗтиһадсыз дигән уйдырмалары аңарга да азмы-күпме тәэсир итми калмаган.

Мәгълүм булганча, татар матбугаты өчен көрәш XIX йөзнең беренче елларыннан ук башлана. Татарча газета булдыру өчен алдынгы рус культурасы эшлеклеләре И. И. Запольский, М. Г. Никольский һәм Н. Г. Чернышевский даирәсе кешеләреннән П. И. Пашино, Вл. С. Курочкин, татарларның үзләре арасыннан, О. С. Лебедевага кадәр үк инде, Каюм Насыйри, Таҗетдин Котлыяров, Мөхәммәтвәли Яхин, Г. Ильяси, Ш. Әхмеров һ. б. бик күпләр тырышып карыйлар. Аларның берсенә дә газета яки журнал чыгарырга рөхсәт бирелми. Патша самодержавиесе татарларга карата аеруча явыз политика үткәрә, аларның иң элементар ихтыяҗлары белән санашуны да кирәк тапмый, бары тик бөек рус культурасы һәм фәне йогынтысыннан читләштерергә тырыша.

Татарча газета чыгару омтылышлары турында Гөлнар ханым да белгән дип уйларга кирәк. Бу юлда үзенең нинди чаралар күргәнлеген аңа Каюм Насыйри да сөйләгән булырга тиеш. Матбугат идарәсенә юллаган хатларында Лебедеваның властьлар тарафыннан куелган теләсә нинди таләпләргә риза икәнлегенә басым ясавы да шул хакта сөйли. Әмма татарлар өчен газета чыгару, мөселманнарга дөньяви белем бирү, рус һәм Европа культурасына юл ачу царизмның милли-колониаль политикасы белән сыеша алмый. О. С. Лебедеваның шушы юнәлештә кылган гамәлләре хакым даирәләргә мәгълүм булганнан соң, «Санкт-Петербургские ведомости»ның хәбәрчесе алган интервью басылмый кала. Башкала газеталары арасыннан «Новое время»ның «Хроника» бүлегендә генә 1893 елның 22 октябрендә Лебедеваның Төркиядән кайтуы хакында кечкенә хәбәр күренеп ала. Анда Гөлнар ханымның рус әдәбия-

[1] «Новороссийский телеграф», 1893 ел, 30 октябрь саны.
[2] ЦГИАЛ, 776 фонд, 8 тасвирлама, 728 эш, 60 бит.
[3] Шунда ук, 65 бит.

тын пропагандалау буенча башкарган эшләре телгә алынса да, Россиядә нинди эш белән шөгыльләнәчәге турында берни әйтелми. Югарыда күрсәтеп үтелгән «Новороссийский телеграф» газетасының Лебедева интервьюсы басылган саны Эчке эшләр министрлыгының III бүлегенә алдырыла. Шул рәвешчә, Гөлнар ханым «ышанычсыз кешеләр» исемлегенә эләгә. Менә Лебедеваның планнары татар китабы цензоры В. Д. Смирнов аша христиан миссионерлары идеологы Н. И. Ильминскийга да килеп җитә. Ул шунда ук синод обер-прокуроры Победоносцевка хат яза һәм ислам дине империядә хакимлек итүче динне җиңә башлады, православный хатын-кызлар арасында да Мөхәммәт дине ягына күчүчеләр бар, дип зарлана. Татарларны рус культурасы һәм мәгарифенә тартырга тырышуы белән Гөлнар ханым үзе дә, татар халкы кебек үк, «ялган, нормаль булмаган» бер хәлдә кала. Алда әйтелгән ике кечкенә хәбәрдән башка рәсми рус матбугатында О. С. Лебедева исеме телгә алынмый.

Газета чыгару планнарының җимерелүен Гөлнар ханым авыр кичерә. Ул Казанга кайта һәм Спасс өязендәге утарына китә. Шулай да кайнап торган энергиясе аңа туктап калырга ирек бирми. Ул Л. Толстойның «Хуҗа һәм ялчы», Пушкинның «Бакчасарай фонтаны» әсәрләрен төрек теленә тәрҗемә итә, төрек телендә «Россиядәге чувашлар турында» дигән хезмәт яза. Гөлнар ханым татарлар өчен югары дөньяви мәктәпләр ачу турында хыяллана, Россиядә шәрыкне өйрәнү җәмгыяте оештыру хакында уйлана. Петербургка барып, алдынгы рус галимнәре белән киңәшә, үзенә идея тарафдарлары эзли. Ниһаять, мөселманнар өчен дөньяви мәктәпләр ачу планы да тормышка ашарлык булмагач, Гөлнар ханым тактикасын үзгәртә, ул рус җәмәгатьчелегендә мөселман халыкларының тарихы, мәдәниятенә объектив караш урнаштыруны максат итеп куя. Моның өчен исә озак гасырлар дәвамында пайтәхет, христиан чиркәве, самодержавиегә ялланган тарихчылар, официоз пропаганда тарафыннан мөселман халыклары культурасына карата тудырылган уйдырмаларны фаш итәргә кирәк була.

1890 нчы елларда Гөлнар ханым Петербургта яшәүче алдынгы рус укымышлылары белән эшлекле элемтә урнаштыра, атаклы шәрык белгечләре В. В. Бартольд, И. И. Березин, Н. И. Веселовский, К. Г. Залеман, П. М. Мелиоранский, В. В. Радлов, Ю. И. Крачковский, Н. И. Конрад, Семенов-Тянь-Шанский һ. б. лар белән аралаша. Россиядә шәрык җәмгыяте оештырырга чакырып, аларга мөрәҗәгать итә. Бу җәмгыять алдына ул «шәрык халыклары арасында Россия турында хак һәм төгәл мәгълүматлар тарату, шулай ук рус җәмәгатьчелеген Шәрыкнең материаль ихтыяҗлары һәм рухи тормышы белән таныштыру — Россияне шәрык илләре белән якынайтуга булышу, Россиянең үз эчендә һәм аннан читтә яшәүче шәрык халыклары арасында рус культурасын һәм житештерүчәнлек рәвешен пропагандалау» максатларын куя[1].

Шактый еллар үткәч, 1900 елның 29 февралендә императрица Александра Федоровна карамагында «Шәрыкне өйрәнү император җәмгыяте» төзергә рөхсәт бирелә. Җәмгыять үз эшчәнлеген промышленность-сәүдә, фән-культура, мәгариф өлкәләрендә җәелдерергә тиеш була, шуңа нисбәтле рәвештә анда өч бүлек төзелә. Ләкин җәмгыять үзенең төп максатына ирешә алмый. Алдынгы җәмәгатьчелек басымы астында гына рөхсәт бирергә мәҗбүр булган патша хөкүмәте «дини һәм милли дошманлык хисеннән арыну һәм акыл, мәгърифәт, үсеп килүче фән күрсәткән хакыйкать юлыннан бару» урынына җәмгыятьне самодержавие политикасы һәм практикасының көндәм ялчысына әверелдерә. Җәмгыятьне төзүгә иң зур хезмәт куйган О. С. Лебедева «почетлы председатель» булып кына исәпләнә, ә председатель итеп генерал-лейтенант Н. К. Шведов билгеләнә. Җәмгыятьне җитәкләүчеләр һәм аның почетлы әгъзалары арасында без Столыпин, Витте, генерал Куропаткин, генеральный штаб начальнигы Палицын, патша гаиләсе члennарын күрәбез. Җәмгыять тик промышленность-сәүдә өлкәсендә генә активлык күрсәтә, чөнки ул эре буржуазиянең шәрыкта үткәргән политикасына җавап бирә. Фән-культура бүлеге докладлар уку, шәрык белеме буенча берничә хезмәт бастыру белән чикләнә. 1912 елда җәмгыять В. В. Бартольд җитәкчелегендә «Мир ислама» дигән журнал чыгара башлый, ләкин анда шәрык тарихы һәм культурасына кагылышлы җитди хезмәтләр күренүгә, редактор итеп реакционер Д. М. Позднеевны билгелиләр, журнал исә кычкырып торган

[1] О. С. Лебедева. Об эмансипации мусульманской женщины. Спб., 1900 ел, 26 бит.

монархия органына әверелдерелә. Аның элекке хезмәткәрләре журналда эшләүдән баш тарталар һәм ул яшәүдән туктый. Мәгариф өлкәсендә җәмгыять бернинди дә эш башкармый. Шул рәвешчә, патша самодержавиесе куйган киртәләр Лебедева-Гөлнар ханымның бу хыялын да тормышка ашырырга ирек бирми.

О. С. Лебедева эшчәнлегенең тагын бер тармагы шәрык белгечләренең халыкара конгресслары белән бәйләнгән. Аның 1889 елда Стокгольмда, 1897 елда Парижда, 1899 елда Римда, 1902 елда Гамбургта, 1905 елда Алжирда узган VIII, XI, XII, XIII, XIV конгрессларда катнашканлыгы мәгълүм. XII конгресста ул Казан һәм татар халкы тарихы буенча доклад ясый, тиздән ул доклад Римда аерым китап булып басыла[1]. Китапта Лебедеваның шәрык белеме өлкәсендәге эшчәнлеге хакында очерк бирелә һәм аның хезмәте югары бәя ала.

Гөлнар ханым үзенең докладында Болгар чоры һәм Казан ханлыгы тарихын яктырта, Мәскәү һәм Казан мөнәсәбәтләрен тасвир итә. Анда татар халкының культурасы, татар хатын-кызлары тормышы, балалар укыту, патша администрациясе үткәргән көчләп чукындыру политикасы мәсьәләләренә дә зур урын бирелә. Докладчы шулай ук халык мәгарифе, аң-белем тарату бурычларына тукталa. Татарларга дөньяви мәктәпләр ачарга, вакытлы матбугат органнары булдырырга рөхсәт бирүнең зарури мәсьәлә икәнлеген, Россиягә файда гына китерәчәген басым ясап күрсәтә.

Хезмәтнең кыйммәтле ягы тагын шунда, автор татар халкын монгол баскыннары белән бутап карамый, китапта шовинизм шаукымының әсәре дә юк, автор тарихны, татарларның культура дәрәҗәләрен объектив яктыртырга омтыла. Көнбатыш Европада чыккан китаплар арасында хәлкыбыз тормышы һәм мәдәнияте объектив тасвир ителгән беренче хезмәт бу.

О. С. Лебедева бу хезмәтен Россиядә, үзенең туган телендә бастырырга тырыша. Әмма цензура киртәләре аркасында ул рус укучысына барып ирешә алмый.

Шул ук конгресста Гөлнар ханым мөселман хатын-кызларының тормыш әхвәле турында да доклад белән чыга. Бу хезмәт 1900 елда Петербургта басылган. Автор монда хатын-кызларның ислам диненә кадәрге һәм дин кабул ителгәннән соңгы беренче чорларда чагыштырмача хөр яшәеше, җәмгыять тормышында җитди урын тотуы, әдәбият-сәнгать, мәдәни үсештә зур роль уйнаган мөселман хатын-кызлары хакында сөйли, хатын-кызларның урта гасырларда ислам дине тарафыннан ничек изелү-җәберләнүен, мөселман илләрендә хатын-кыз азатлыгы өчен барган көрәшне күрсәтә. Брошюраның дөньяга чыгуы Россия җәмәгатьчелегенең бер өлешендә ачу тудыра, миссионерлар һәм кайбер әдипләр авторны ислам динен православиегә каршы куюда гаеплиләр, алар христиан илләрендәге хатын-кызларның тормыш шартлары һәм хәле асылда мөселман хатын-кызларыныкыннан аерылмый дип раславы белән Лебедева, имеш, хаклы түгел дип кычкыралар. Шушындый һөҗүмнәргә җавап итеп булса кирәк, О. С. Лебедева шул ук темага 1902 елда Гамбургта, 1905 елда Алжирда үткән конгрессларда да чыгышлар ясый. Конгресс материаллары белән бергә, ул чыгышлар чит илләр матбугатында басыла. Чыгышларында Гөлнар ханым Европа хатын-кызларының да азатлыкка мохтаҗ булуларын кабат исбат итә. Лебедеваның XIV халыкара конгресста ясаган доклады Россиягә дә килеп ирешә. Аны французчадан рус теленә Петербургта хатын-кызлар өчен югары курсларны тәмамлаган врач Әминә Батыршина тәрҗемә итә һәм 1905 елда «Баку» газетасында бастырып чыгара. Тиздән хезмәт татар теленә дә тәрҗемә ителеп, 1906 елда Казанда «Бәянел-хак» газетасында күренә, ә тагын бер елдан (Рәкыйб Рәкыйбов тәрҗемәсендә) китап булып тарала[2].

Петербургта яшәгән чорда да О. С. Лебедева татар мәгърифәтче галимнәре белән араны өзми, һәр җәйдә диярлек Спасс өязендәге утарына кайта.

90 нчы еллар ахырында Гөлнар ханым утарына Әлмәт районы, Миңлебай авылыннан Кәрим Гыйлманов исемле берәү килеп керә. Ул гаиләсе белән шәһәргә күчеп, балаларына дөньяви белем бирергә, ә үзенең калган гомерен халыкка чын аңбелем тарату, татар матбугат органы оештыру эшенә багышларга карар иткән. Бу хакта К. Гыйлманов иң элек Шиһабетдин Мәрҗани белән очрашып сөйләшкән, хатлар язышкан. Ш. Мәрҗани бу эшнең зур түземлек сорый торган, гаять четерекле

---

[1] M-me Olga de Lebedeff. Abrege de e' Histoire de Kazan. Рим. 1899, 97 битле.
[2] Гөлнар ханым (Лебедева). Мөслимәләр хөррияте. Казан, 1907 ел.

һәм авыр эш икәнлеген искәртеп, Спасс өязендә яшәүче бер күренекле кеше, күп илләрдә булып кайткан, күпне күргән, татар халкын чын күңелдән ярата торган һәм аңа аң-белем бирүдә күп көч куйган галимә, рус хатыны Ольга Сергеевна Лебедева белән киңәш корырга кушкан.

Гөлнар ханым Кәрим Гыйлмановны ачык йөз белән каршы ала, планнарын хуплый, дәртләндерә. Гыйлмановка язган хатларында да ул күп кенә файдалы фикерләр әйтә, эшлекле киңәшләр бирә. Мәсәлән, ул Кәрим Гыйлмановка Казанга түгел, ә Оренбургка күчәргә киңәш итә. Европа белән Азия арасында урнашкан бу шәһәрдә Европа культурасын халыкка җиткерү, китаплар басуны җайга салу, газета-журналлар чыгарырга рөхсәт алу ансатрак булыр дип саный ул[1]. Эш шунда ки, Ольга Сергеевна Казанның ул чорда татар мәдәнияте үзәге генә түгел, христиан миссионерлары оясы да булуын үз тәҗрибәсеннән бик яхшы белгән. «Инородец»ларга дөньяви белем бирүгә каршы торучы самодержавие ялчылары анда аеруча күп була.

Шушы киңәшне тотып, Кәрим Гыйлманов бөтен гаиләсе белән Оренбургка күчеп килә, дини дәрәҗәсеннән баш тарта һәм фидакарь эш белән халыкны агарту юлына баса. Бик зур кыенлыклардан соң ул типография ачарга рөхсәт ала һәм 1900 елда татар китаплары бастыра башлый. Ләкин тиздән, 1902 елда, ул фаҗигале рәвештә һәлак була. Әтисе башлаган эшне чит илдә укып кайткан улы Фатих Кәрими дәвам иттерә.

Кызганычка каршы, Казан университетының Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсе, Пушкин йорты, СССР Фәннәр академиясе шәрык белеме институтының Ленинград бүлегендә саклланган берничә хаттан гайре, О. С. Лебедеваның нинди дә булса кульязмалары безгә мәгълүм түгел. Гөлнар ханымның кайсы елда һәм кайда вафат булганлыгы хакында да хәбәр күренми.

Бөек Ватан сугышыннан соңгы чорда Лебедева фамилиясен тарихчылар еш телгә алсалар да, алар аның Төркия белән бәйләнештәге эшчәнлеген күрсәтүдән ары узмыйлар. Без архив документларына таянып һәм шул чор рус матбугаты хәбәрләрен, татар телендәге кайбер документларны файдаланып, бу гүзәл рус хатынының тормышын һәм эшчәнлеген тулырак күз алдына бастырырга тырыштык. Ул бөтен гомерен халыклар арасында үзара дуслык элемтәләрен ныгыту, татар һәм илебезнең башка мөселман халыклары мәгарифен дөньяви нигезгә кору өчен көрәшкә багышлаган. Рус хатын-кызлары арасында беренче шәрык белгече, гаять киң белемле һәм эрудицияле кеше, рус шәрык белеменең чын горурлыгы да ул. Патша Россиясе шартларында аның алдында меңнәрчә киртәләр корыла, күп планнарын тормышка ашырырга мөмкин булмый. Әмма һәртөрле тыю-кысуларга түзеп, барлык киртәләр аша үтеп, башкарып чыга алган кадәресе өчен дә без аның тормышын һәм эшчәнлеген ныклап өйрәнергә, алдынгы рус интеллигенциясенең гүзәл бер вәкиле булган ул гадел җанлы, фидакарь хатын алдында рәхмәт хисе белән башыбызны иярга бурычлы.

---

[1] Бу хат К. Гыйлмановның кызы Закира ханым Шәрәфтә саклана.— Автор искәрмәсе.

# ШАГЫЙРЬ КИТАПХАНӘСЕ

1955 елның башында Татарстан Дәүләт музее фондына күренекле татар совет шагыйре Һади Такташның шәхси әйберләре: язу өстәле, тирбәлмә урындык һәм култыксалы урындык, кара савыты, пресспапье, шәхси печать, шахмат, кәгазь тишкеч, шахтер лампасы, китап шкафы, күп кенә китаплары алына. 1967 елны Казандагы А. М. Горький музеенда саклланган әйберләре (кепка, эшләпә, акча янчыгы, портфельләре) дә безнең музейга күчерелә. 1970 ел ахырында шагыйрьнең 70 еллык юбилее уңае белән аның кульъязма мирасын күп санлы фото-документаль материалларны берләштергән архивы алынды. Хәзерге көндә Такташ фонды музейдагы әдәбият бүлегенең зур байлыгын тәшкил итә.

Музейга алынган шәхси әйберләр шагыйрь тормышындагы күп вакыйгалар белән бәйләнгән. Кайберләренең шагыйрь архивындагы документлар белән раслангаң кызыклы тарихы да бар. Киләчәктә аларга аерым-аерым да тукталырга мөмкин булыр. Ә бу юлы сүз шагыйрьнең китаплары хакында барачак.

Китапханә 220 китаптан тора. Күңелгә килгән беренче сорау: шагыйрь китаплары тулысынча саклангнмы?

Такташ турындагы монографик хезмәтләрнең берсендә бу хакта болай диелә: «Такташ, «күңел ачуларга» күп вакыт бирүдән үзен чикләп, бөтен көчен укуга, эшкә, иҗатка биргән. Ул үзенә бай китапханә әзерләгән. Тик, кызганычка каршы, ул китапханә тулысынча сакланмаган». (Х. Хәйри. Һ. Такташ. Казан, 1949, 134 б.)

Шагыйрьнең якыннары әйтүенчә, китапханәнең зур өлеше сатылган. Китапларны Такташның адвокат булып эшләгән бер танышы алган. Исемен хәтерләмиләр.

Музейга алынган китапларны карап чыккач та аларның бүлгәләнгән булуы ачык күренә. Мәсәлән, даһи Ленин образына шагыйрь иҗатында зур урын бирелә. Ул юлбашчының әсәрләрен дә, биографиясен дә, аның турындагы истәлекләрне дә күп укыган, әлбәттә. Кызганычка каршы, ул китаплар сакланмаган. Такташ 1926 елның 4 декабрендә да В. И. Ленин әсәрләренең 2 томын сатып ала. Шагыйрь китаплары арасында шулай ук И. В Сталинның «Вопросы ленинизма» («Госиздат», М., 1926), «Воспоминания Н. Крупской о Ленине» (Изд-во «Правда», 1925) кебек китаплары бар. Шәхси китапханәдәге бер китап эченнән Ленинның рәсеме дә табылды. Такташ аны юлбашчының үлүенә дүрт ел тулу уңае белән басылган нинндидер газета яки журналдан кисеп алган булырга тиеш.

Шагыйрь китаплары арасында дөнья әдәбияты классикларының әсәрләре юк дәрәҗәдә булу табигый хәл түгел. Сакланганнарыннан Мольерның «Избранные комедии» («Гослит», М.-Л., 1929), Мигель Де Сервантес Сааведраның «Хитроумный Идальго Дон Кихот Ламанчский», («Академия», М., 1929), Джек Лондонның «Путь морозных солнц» («Всемирная литература», Петроград, 1920) кебек берничә әсәрне генә күрсәтергә мөмкин.

Иҗатының башлангыч чорында ук дөнья әдәбияты белән яхшы таныш булган, 1921 елда «Җир уллары» трагедиясен язган шагыйрь китаплары арасында Мильтон, Гете, Лермонтов һ. б. классикларның китаплары булмауга ышанасы килми. 1921 елда ук «Миндә көчле Байроннар җаны» дип әйткән Такташның бөек инглиз шагыйре иҗатын яхшы белүенә һәм аның китапларын шул елларда ук сатып алган булуына да шик юк. Такташ китаплары арасында Байронның нибары «Сатира һәм лирика» («Госиздат», М.-Л., 1927) диген китабы гына сакланган. Китап күп укылудан, кулдан-кулга йөрүдән таушалып беткән. Такташ үзе

яраткан китапларны дусларына укырга бирә торган була. Байрон китабы исә озак еллар буе шагыйрь китаплары арасыннан китеп торган. Илленче еллар тирәсендә генә букинистлар аша ул үз хуҗасы йортына яңадан әйләнеп кайта.

Такташның кульъязма архивында биш биттән торган дәфтәр-көндәлек саклана. Анда шагыйрь 1928—29 елларда укыган китапларын, алардан алган тәэсирләрен язып барган. 1929 елның январь аенда ул Стефан Цвейгның биш томын укып чыга. Көндәлегенә «матур тәэсир калдырды» дип яза. С. Цвейгның 12 томлык сайланма әсәрләре рус телендә 1927—32 елларда М. Горькийның кереш сүзе белән, автор катнашында чыгарыла. Такташ барлыгы 1000 биттән артыкка җыелган биш томны бер ай эчендә укый. Шагыйрьнең уку темпын күзәллау өчен дә бу кызыклы факт.

Ул гына да түгел, шул ук айның 27—30 көннәрендә «Правдивое жизнеописание». Кытай хикәяләре. («Молодая гвардия», 1929, 360 бит) исемле китапны укый. 31 январь көнне америка язучысы Эптон Синклерның «Нефть» («Госиздат». М.-Л. 1928, 300 бит) романын укый башлый. Февраль аенда Синклерның тагын «Ад», «2000 год», «100%» дигән әсәрләрен укып чыга. Көндәлегендә бу язучының «Джимии Хиггинс» һәм башка әйберләрен укып чыккан идем» дип тә күрсәтә. Шагыйрь китапханәсендә югарыда саналган китапларның бары икесе — «Нефть» романы һәм кытай хикәяләре генә сакланып калган. Дөрес, көндәлектә күрсәтелгән һәр китапның шагыйрь китаплары арасында булуы шарт түгел. Шагыйрь аларны башка җирдән алып та укыган булуы мөмкин.

Китапларның сакланып калган өлеше дә, аларда шагыйрь ясаган язмалар-инскриптлар, төрле билгеләре аның уку зәвыгын күзалларга, рухи дөньясын ачарга ярдәм итә һәм, ниһаять, шагыйрьнең фәнни биографиясен эшләүчеләргә кыйммәтле чыганак була ала.

1929 елның 10 августында бер төркем язучылар һәм культура эшлеклеләре белән берлектә Такташ тугандаш республикалар буйлап сәяхәттә катнаша. Аннан шагыйрь күп кенә белешмә характерындагы китаплар алып кайта.

Китап сатып алгач та Такташ аларның тышына яки титул битенә үзенең имзасын һәм алыну датасын куя. Кайберләренә исем-фамилиясен яки үз рәсеме төшерелгән печать суга. Соңыннан, китапны укыгач, тагын имзасын һәм укып чыгу датасын куя, кайчак китаптан алган тәэсирен дә яза. Шагыйрь китаплары арасында әрмән совет язучысы Аксель Бакунцинның «Темное ущелье» («Гослит, М.-Л., 1927) исемлесе бар. Анда революциягә кадәрге әрмән крестьянының хезмәтен, тормышын яктырткан повесть һәм хикәяләр тупланган. Аңа, мәсәлән, Такташ болай яза: «Мәскәү бүләге 25/IX. 29. Такташ». «Укый башладым 25.IX.29. Такташ». Ике хикәяне укып чыга да «26.IX. 29. Такташ» дип имза куя. Китапны ахырынача укымавы турында исә көндәлегенә түбәндәгечә өсти. «Хикәяләрне укып тормадым. Бер төрле, ләкин русчага тәрҗемә итәрлек әйберләр түгел. Табигатьне тасвир яклары яхшы булса да, сюжет, содержание балаларчан». Кайбер китапларының кырыйларына да ул үз фикерләрен яза барган, аерым билгеләр куйган. Үзенә ошаган яки ошамаган урыннарын сызып, квадрат белән әйләндереп алган.

Такташ прогрессив немец язучысы Бернхардт Келлерман әсәрләрен яхшы белгән. Бигрәк тә фантастик планда язылган «Туннель» романын яратып укыган. Бу әсәр Атлантик океан төбеннән Европа белән Америка материкларын тоташтырыр өчен үткәреләчәк туннель вакыйгасына нигезләнгән. 1923 елда немец телендә басылып чыккач та ул зур уңыш казана, күп телләргә тәрҗемә ителә. Кеше акылының көченә, иҗади хезмәткә дан җырлаучы роман буларак Такташка да ошаган булса кирәк. Шагыйрьнең көндәлегендәге «28 нче ел. Келлерманның «Туннель»ен икенче кат укып чыктым» дигән сүзләр шул хакта сөйли.

Шагыйрь китапханәсендә Б. Келлерманның «Событие в жизни Шведенклея» («Мысль», М., 1927) исемле китабы саклана. Китапның титул һәм соңгы битләрендәге язулардан күренгәнчә, Такташ аны 1929 елның 3 мартында укып чыга. Немец язучысының революция проблемаларына багышланган бу әсәре Такташта зур кызыксыну уяткан. Китапның күп битләрендә карандаш белән сызылган урыннар бар. Шунысы әһәмиятле, ул абзацларның эчтәлекләре шагыйрь биографиясендәге кайбер моментлар белән туры килә. Мәсәлән, 170 биттә: «Бывают люди, которые без особых потрясений переносят сердечные удары, — их немного; другие плачутся на судьбу и поднимают шум, а третьи — те просто вытаскивают вина, откашливаются

и закуривают сигару» дигән абзац калын итеп сызылган.

1929 ел шагыйрь тормышында авыр кичерешләр белән бәйле. Аның шул елда обыватель-мещаннар тырышлыгы аркасында «Азат хатын» журналы редакциясеннән чыгарылуы билгеле. Шагыйрь бу чорда укыган китапларында үз кичерешләренә тәңгәл килгән җирләрне билгеләп барган. Ул сызыкларны шагыйрьнең рәнҗетелгән хисләрен саклаучы шаһитлар дип карау дөрес булыр.

172 биттә ул хатын-кызны тискәре тасвирлаган урынга да игътибар иткән. «Усевшись на террасе казино он мрачно и презрительно смотрел на гуляющих. Какие ужасные женщины. Толстые, бесформенные, смешные, бесстыдно много о себе воображающие, нелепо-тщеславные, с накладными щеками, в большинстве кривоногие... Шведенклей порой женщин не щадил» — дигән абзацны шулай ук квадрат сызыклар эченә алган.

Такташ үз гомерләрен пролетариат азатлыгы өчен көрәшкә багышлаган күп кенә шагыйрьләр иҗаты белән яхшы таныш була. Мәсәлән, аның китаплары арасында немец шагыйре, К. Марксның дусты, фикердәше Ф. Фрейлигратның «Вопреки всему» (Изд-во «Красная новь», М) исемле җыентыгы бар[1].

Такташ аны 1929 елның 24 декабрендә сатып ала. Битләрдә аерым билгеләнгән урыннар, язулар булмаса да, шигырьләрне Такташ кат-кат укыган дип фараз итәргә мөмкин, чөнки китап нык таушалган.

Шагыйрь гомеренең соңгы көннәренә кадәр авыл белән тыгыз бәйләнештә яши. Җәй айларында ул туган авылы Сыркыдыга кайта. Еш кына авылларда командировкада була. Бу турыда аның архивында сакланып калган күп санлы белешмә-язулар сөйли. Авыл темасына караган теоретик хезмәтләрне дә даими рәвештә укып бара, үз китапханәсендә булдырырга тырыша. Мәсәлән, А. Нестеровның «Как организовать хозяйство коммуны» («Книгосоюз», М., 1928) китабы шундыйлардан. Аны шагыйрь 1929 елның 24 маенда укып чыга һәм ахырына «Колхозларга барыр алдыннан» дип язып куя.

Әдәбият һәм сәнгать теориясенә караган китапларга шагыйрь китапханәсендә урын аеруча зур бирелгән. Бу җөмләдән «Искусство и литература в марксистском освещении» («Мир», М., 1924), В. Фриче «Социология искусства» («Госиздат», М-Л, 1930), П. Коган «Очерки по истории новейшей русской литературы» («Госиздат», 1929, т. 2, 4) һ. б. санарга мөмкин. Китапханәдә сакланган «Проблемы литературной формы» («Академия», Л. 1928) исемле җыентык аеруча әһәмиятле. Җыентыкка әдәбият теориясе һәм немец әдәбияты тарихы өлкәсендә эшләүче бер төркем немец галимнәренең хезмәтләре кергән. Аны Такташ 1929 елның 4 апрелендә больницага керер алдыннан сатып ала. Мәкаләләр 4—8 апрельләрдә «Клиникада ятканда укылды» дип күрсәтә. О. Вальцельнең «Сущность поэтического произведения» һәм «Грамматические и психологические формы в языке» дигән мәкаләләрен ул кулына карандаш тотып укый. Беренче мәкаләдә (2—3 битләр) «Что такое содержимое?», «Что такое облик?» дигән абзацларны билгели. 23 биттә «... в словах заключен лишь смысл стихотворения, душа же его — между слов. Ритмическое движение и звуковая окраска стиха должны как бы переложить стихотворение на музыку и тем самым выразить настроение, из которого оно родилось» дигән абзацны шулай ук билгели һәм битнең кырыена гарәп хәрефләре белән «Минем «Җир уллары»ндагы контексттагы настроениенең симфониясе мәсьәләсе» дип яза.

Такташ яшьлек, семья һәм мәхәббәт мәсьәләләренә зур игътибар иткән язучы. Ул яңа моральне, яшьләр арасындагы мөнәсәбәтләрне аеруча кызыксынып өйрәнә. Шушы темага багышлап язылган китапларны җыя. Шундыйлардан А. Луначарскийның «Мораль с марксистской точки зрения» («Пролетарий», М. 1925) китабын күрсәтергә мөмкин.

Югарыда Такташның Э. Синклерның «Нефть» романын яратып укуы турында әйтелгән иде. Шагыйрь бу әсәрдә яшьләрне эгоистик максатлар белән генә яшәргә өндәгән урыннарга игътибар итә. Мәсәлән, 300 биттә «Пользуйся молодостью, — кричал каждый. — Для чего вам возлагать на свои плечи тяжесть всего мира. И, главное, не беритесь за то, чего вы не можете переделать, и не ломайте себе голову над всевозможными жизненными противоречиями» дигән юлларның астына дулкынлы сызыклар белән сызып, бит кырыена плюс билгесе куйган.

---

[1] Маркска язган бер хатында Ф. Фрейлиграт үзен «Я был певцом революции и пролетариата» дип атый.

һ. Такташ мораль-этик темаларга багышланган әдәби әсәрләрне дә күп укый. Ф. Гладковның «Цемент» («Земля-фабрика». М.-Л. 1927) романын укыганда ясаган тамгалар аның бу җитди мәсьәләләргә мөнәсәбәтен шактый ачык күрсәтә. Китапны Такташ 1928 елның 15—26 апрель көннәрендә укый, ә 16 майда ул аңа яңадан әйләнеп кайта. Шагыйрь игътибарын нинди урыннар җәлеп иткән соң? Беренче чиратта, үзен бу чорда өзлексез борчыган бала тәрбиясе, ана вазифасы һәм әхлак мәсьәләләре, әлбәттә. 249 биттә билгеләнгән абзацларда тулысынча әхлак мәсьәләсе куела. Мәсәлән, «Цемент» романының төп геройларыннан берсе Даша үзенең бәләкәй кызы Нюрканы балалар йортына тәрбиягә бирә. Көн саен аның янына кереп йөрсә дә, баласының ябыгуын, читләшүен сизә. Шул абзац ике яктан да сызыклар эченә алынган һәм бит кырына «дөрес» дип язылган.

Такташ рус классикасы белән яхшы таныш була. Көндәлегендә 1928—1929 елларда гомумән Чеховның 5, 9, 10, 11 томнарын, Л. Толстой, А. Пушкин әсәрләрен укуы турында әйтелә. Шунда ук ул Толстойның «Воскресение» һәм «Анна Каренина» әсәрләрен икенче кат укуы турында яза. 1929 елның 10 маенда, мәсәлән, Толстойның «Воскресение»сын төнге сәгать бердә укып бетердем. Роман бу юлы яхшы тәэсир калдырды. Толстой үз классын яхшы белгән. Без үз классыбызны яхшы беләбезме? Аның «Война и мир», «Хаджи Мурат» һәм башка вак-төяк брошюраларын, драмаларын укыган идем, — дип күрсәтә.

Такташ китапханәсендә рус шагыйрьләре И. С. Никитин һәм Кольцовның тулы сайланмалары да булган. Аларның кайбер томнары гына сакланган. Чехов әсәрләренең 15 томы безнең көннәргә килеп җиткән («Полное собрание сочинений», Петроград, 1918). Такташ М. Горький иҗатын да яхшы белгән. Мәсәлән, аның 1929 елның 30 маенда «Жизнь Клима Самгина» романын укый башлый.

Шагыйрь рус совет әдәбияты яңалыкларын аеруча зур игътибар белән күзәтеп бара. Мәсәлән, 1929 елның 1—10 июль көннәрендә ул М. Шолоховның «Тын Дон» романын укый. Ә А. Толстойның «Хождение по мукам» трилогиясен тәрҗемә итеп тә карый. Кульъязмалар архивында романнан тәрҗемә ителгән кыска бер өзек саклана. Такташ китапханәсендә Октябрь революциясеннән соң әдәбиятка килгән күпчелек рус язучыларының китаплары (С. Кирсанов, М. Голодный, И. Молчанов, Я. Сельвинский, Н. Тихонов һ. б.) саклана. Ул А. Безыменский иҗатына карата аеруча мөгамәләдә булган. «А. Безыменскийның бөтен нәрсәләрен укып барам», — дип яза ул көндәлегенә дә. А. Безыменский үзенең әсәрләрендә яңа эпоханың иң актуаль мәсьәләләрен яктыртуы, яшьлек җырчысы булуы белән Такташка аваздаш шагыйрь. Бу шагыйрьнең башлангыч иҗаты Казан белән бәйләнгән булу да билгеле бер роль уйнаган булса кирәк. Такташ китапханәсендә аның дүрт китабы: «Ордер на мир» («Молодая гвардия», М., 1926), «Шахматы» («Московский рабочий», М., 1928), «Выстрел». Комедия в стихах. (Госиздат, М.-Л. 1930), «Поколение социализма» («Молодая гвардия», М, 1931) исемле җыентыклары сакланып калган.

Арада А. Жаровның «Стихи и поэмы» («Молодая гвардия», М., 1928) китабы да бар. 1929 елның маенда ул көндәлегенә дә: «А. Жаровны яратып укыйм», дип яза.

Шагыйрь китапханәсендә киңрәк тукталуга лаеклы китап — М. Светловның «Книга стихов» («Госиздат», М.-Л., 1929) исемле шигырьләр җыентыгы. Такташ аны 1929 елның 15 сентябрендә Мәскәүдә сатып ала. Шигырьләрне 20, 25 сентябрь көннәрендә укып чыга һәм: «Светлов миндә матур тәэсир калдырды», дип китапка да, көндәлегенә дә язып куя. Соңыннан китапны Ф. Кәримгә бирә. Китапның соңгы битендә шундый язма бар: «Укып чыктым. Яраттым. «Ночные встречи» дигән шигырь Кутуйның «Тукаена» түгел, Кутуйныкы моңа охшаган[1]. Ф. Кәрим. 11.V.30 ел».

М. Светлов китабында 32 юл кызыл кара белән сызылган. Шунысы кызыклы, китапларга Такташ ясаган билгеләрнең бер үзенчәлеген күрергә була. Такташ үзенә ошаган китапларга тамганы бик сак һәм пөхтә генә төшерә, ә инде ошамаганнарының тетмәсен тетә. М. Светлов китабында билгеләнгән шигъри строфаларның эчтәлекләре дә, билгеләренең ясалу формалары да аларны Такташ эшләгән булуына шик калдырмый.

Китапханәдә Такташ һәм Ф. Кәрим исемнәрен берләштергән тагы бер китап бар. Ул — Джек Алтаузенның «Безусый энтузиаст» («Московский рабочий», М. 1930) исемле лирик поэмасы. Китапның иясе — Ф. Кәрим: тышлыгына «Кәримов» дип, ә

[1] Сүз Г. Кутуйның «Тукай кабере янында» исемле шигыре турында булса кирәк.

соңгы биткә: «Укып чыктым. Яраттым. Ф. Кәрим. 4.V.30 ел», дип язылган.

Поэмада социалистик төзелешнең энтузиастлары, беренче буын комсомолларның романтик пафос белән сугарылган образлары сурәтләнә. Матбугатта ул гаять югары бәяләнә. Ф. Кәримнең үзе укыгач аны Такташка бирүен шуның белән аңлатырга мөмкин. Монда ике шагыйрь характерындагы бер үзенчәлек тә күренә. Такташ китабына (М. Светловныкы) Ф. Кәрим дә рәхәтләнеп үз фикерләрен язып куя. Такташ кеше китабына яза алмаган, күрәсең. Ул хәтта бүләк итеп автограф белән бирелгән китапларга да кагылмаган.

Такташ зур игътибар белән укыган китаплар рәтенә рус совет шагыйре М. Кузьминның «Форель разбивает лед» (Изд-во «Писателей», Л., 1929) исемле шигырьләр җыентыгын да кертергә була. Такташ җыентыктагы 47 шигъри юлны үз кулы белән билгеләгән.

Татар язучыларының китаплары шагыйрь китапханәсендә бик аз калган. С. Сүнчәләйнең «Шигырьләр, поэмалар» («Яңалиф», Казан, 1929) җыентыгы, Г. Ильясовның «для отзыва» дигән штамп куелган «Получка» («СССР халыкларының үзәк нәшрияты», М., 1929) исемле китабын, А. Таһировның колхоз төзелеше темасына «Үрнәк» («Яңалиф, Казан, 1931) исемле пьесасын һәм Ф. Кәримнең «Электр фонарьлары» (Казан, 1930), «Улак белән ерakka» (Казан, 1930), «Башлангыч җыр» (Казан, 1931) исемле җыентыкларын гына күрсәтергә була. Көндәлектә дә татар язучыларының әсәрләре турында әйтелми диярлек. 1929 елның 10 мартында: «М. Галәүнең «Төеннәр» дигән нәрсәсен карап чыктым. «Югалган матурлык» белән охшашлык бар», дип кенә язып үтә. Һәм «Безнең юл» журналын даими рәвештә укып барам», дип берничә тапкыр яза. Шагыйрь архивында журналның 1922—29 нчы елларда чыккан саннары саклана. Такташ аларны төпләтеп тә алган.

Китапханәдә «Дәрдмәнд әсәрләре» («Яңалиф», Казан, 1929) саклана. Китап эчендәге билгеләр Такташның шигырьләрне зур игътибар белән укыганын күрсәтәләр. Шагыйрь китапханәсендә тетмәсе бик каты тетелгән китап — Г. Теләшнең «Ударлы көннәр» исемле (Татиздат, Казан, 1930) җыентыгы. Китап битләре шагыйрь язмалары, сызыклары белән чуарланып беткән. Китапны Такташ үзенең «Партиясез» һәм партияле шигырьләр» турындагы мәкаләсен язганда укыган. Теләшнең «Ударлы көннәр» китабына 25 шигырь урнаштырылган. Шуларның 13 нә карата Такташ үзенең фикерен әйтә. Ә матбугатта басылган мәкаләсендә исә Такташ Теләшнең дүрт шигыренә генә туктала. Аның да берсе — «Большевиклар язы» шигыре «Ударлы көннәр» җыентыгында юк. Шушы дүрт шигырь мисалында, китап битләрендә язылган кыска фикерләрен киңәйтеп, мәкаләдә Теләш иҗатына тулы анализ ясый.

Шагыйрь китапханәсендә автографлы китаплар күп түгел. Рус совет шагыйре Михаил Юринның «Половодье» («Тифлис», 1924) һәм «Путь человека» («Баку, 1929) исемле шигырь җыентыкларын гына күрсәтергә була. Аларны М. Юрин Бакуда 1929 елның августында татар язучыларының ил буенча сәяхәте вакытында бүләк итә. «Бакинский рабочий» газетасы редакциясендә очрашу вакытында булса кирәк. Бу газетаның 1929 ел 22 санында «Татарстан язучылары Бакуда» исеме белән Гомәр Гали һәм портретлары белән Һади Такташ, Гадел Кутуй мәкаләләре урнаштырыла.

«т. Такташ!
Жизнь нужно любить так, чтобы голова кружилась от влюбленности! Только пройденный жизненный путь дает нам право утверждать, что будущее наше! Стойко держись за пролетарскую литературу.

Эта книжка пусть будет памятью о моем любимейшем Баку», дип яза М. Юрин «Путь человека» исемле китабында.

Бакуда очрашу истәлек булып кына калмый, ул иҗади дуслыкка да әйләнә. Алар арасында хат алышу башлана. М. Юрин Такташ шигырьләрен русчага тәрҗемә итәргә дә алына. Бу турыда без М. Юринның «Бакинский рабочий» газетасы бланкларына язылган хатларыннан беләбез: «Такташ, я очень виноват перед тобой, что до сих пор не мог перевести твоих стихов, но даю слово, что переведу и думаю, получится не плохо»... «Твой «Мокамай» мне чертовски нравится—я его постараюсь сделать на «це»[1], — ди Юрин 1929 елның 12, 13 октябрьларында язган хатларында.

Такташның гаилә членнары әйтүенчә, алар икәү рәсемгә дә төшкән булырга тиеш. Кызганычка каршы, М. Юрин 1966 елны вафат була. Бәлкем аның якыннарында

[1] «Це» — бик яхшы итеп дигән мәгънәне аңлата.

ул рәсем саклангандыр да. Эзләнүне дәвам итәбез.

Шагыйрь китапханәсендәге «Альманах татарской литературы» («Московский рабочий», М., 1930) китабы шулай ук Такташка бүләк итеп бирелгән. Анда: «Үзем чыгарып та, үземне сүктерүдән башка хезмәте булмаган китапны шагыйрь Такташка бирәм. Төзүче. 12.VIII. 1930 ел. Казан», дигән сүзләр язылган. Әмма китапта төзүченең фамилиясе күрсәтелмәгән. Җыентыктагы кайбер хикәяләрне русчага тәрҗемә иткән һәм шигырьләргә сүзгә-сүз тәрҗемә ясаган Фуад Саллави әйтүенчә, автографны язучы Ә. Ерикәй булырга тиеш.

Шагыйрь китапханәсендә әле ачыклауга мохтаҗ тагын бер автографлы китап бар. Ул «Ташкын» («Яңалиф», Казан, 1928) исемендәге әдәби хрестоматия. Анда: «Такташ дуска. Әмирхан. 2.XI. 1928», дигән сүзләр язылган. Хрестоматияне төзүчеләр Сафа Борһан, Г. Нигъмәти, Ф. Әмирхан. Китап 1928 елны Ф. Әмирхан үлгәннән соң басылып чыга. Димәк, ул Фатих Әмирхан бүләге була алмый. Такташның Әмирхан исемле тагы нинди дусты булган? Киләчәктә бәлкем ачыкланыр. Язулы китапларга «Исламда вә шура хөкүмәтендә хатын-кызлар хокукы» (Ташкент, 1925) китабының авторы Н. Хәкимов, «Октябрьның ун еллыгына безнең бүләк» (Казан, 1927) җыентыгын төзүче Г. Минский автографларын өстәргә була. Соңгы елларда автографлы китапларга Такташның үз автографлары да өстәлде. Такташ үзенең «Сайланма әсәрләр»ен (Казан, 1931) Ф. Кәримгә һәм Татарстанның халык артисты Хәким Сәлимҗановка түбәндәге язулар белән бүләк итә: «Кәрим! Синең белән үткән көннәрнең бик күп хисләре монда. Укыганда алар шул үткәннәрне җанландырсыннар. 12.X.31. Такташ»... «Сәлимҗан! Сиңа — «Камил»емнең режиссерына — дуска. 13.IX.31. Такташ».

«Такташ һәм татар театры» дигән теманы әле махсус өйрәнәсе бар. Гомеренең соңгы елларында Такташ хәтта кино сәнгате белән дә кызыксына. «Камил» пьесасын киносценарий итеп тә эшли. Кинорежиссер Дубровский белән иҗади элемтәгә керә. Шул елларда басылган театр һәм кино буенча махсус әдәбият белән дә танышып бара. Шагыйрь китапханәсендә Л. Мурның «Азбука киномонтажа» (М. 1930), А. Клепиковның «Первые уроки грима» (М., 1923) китапларының булуы Такташ иҗатының шушы яклары белән бәйле. Боларга тагы Б. Ефимовның «Карикатура на службе обороны СССР» («Огиз-Изогиз», М.-Л., 1931), С. Ярославскийның «О парт. этике» («Кубуч», Л., 1925) һ. б. китапларны өстәсәк, шагыйрьнең уку диапазонының киңлеге шигъри-әдәби рамкалар белән генә чикләнмәгән булуы ачык күренәдер.

Китапханәдә шагыйрьнең гомере өзелгән 1931 елда алынган китаплар аеруча әһәмияткә ия. Соңгы китаплар — шагыйрьнең соңгы шаһитлары!.. Алар китапханәдә күп түгел: «Сборник еврейской поэзии» (ТИХЛ, И., 1931), «Сборник армянской поэзии» (ТИХЛ, Л.-Л., 1931), Ю. Инге «Эпоха» (ТИХЛ, Л.-М., 1931), Л. Борисов «Галка» (Изд-во «Писателей», Л., 1931), Д. Гарибальди «Мои мемуары» («Огиз», М., 1931). Бу китапларга шагыйрь имзасын яки язулы печать кенә куеп калган. Укып чыгарга өлгермәгән булса кирәк. «Соңгы китаплар»дан Такташ билгеләре салынган тагын ике китапны күрсәтергә була: С. Леоновның «Антрацид» (М.-Л., 1931) романы һәм Б. Соловьевның «Люди нашей страны» (Л-М. 1931) исемле драматик поэмасы. Б. Соловьевның пролетариат әдәбияты сериясендә чыгарылган бу әсәрен ул 1931 елның 27 октябрендә укып бетерә һәм: «... Укып чыктым. Җиңел һәм талантлы язылган», дип соңгы имзасын куя.

Шагыйрь китапханәсе, шагыйрь китаплары! Күңел хисләрен саклаучы шаһитлар! Китапларның күбесе реставрациягә мохтаҗ. Безнең бурыч — аларны киләчәк буыннар өчен, озак елларга барып җитәрлек хәлгә китерү, кадерләп саклау.

**ДАНИЯ БАҺАУТДИНОВА,**
**Татарстан музееның әдәбият бүлеге мөдире.**

Нил Юзиев

# ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ МЕТОДОЛОГИЯСЕНӘ — КАМИЛЛЕК!

Галимнең яки тәнкыйтьченең әдәби әсәргә, әдәби күренешкә якын килү һәм аны өйрәнү коралы булып фәнни фикерләү ысулы, тикшерү алымнары, принциплары хезмәт итә. Шуңа күрә дә әдәбият хәзинәләрен барлауда, тикшерүдә фәнни фикерләү «механизмы»ның — әдәбият фәне методологиясенең камиллеге гаять зур роль уйный.

1976 елның 12—13 ноябрендә СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында хәзерге татар әдәбият белеменең һәм әдәби тәнкыйтенең актуаль методологик мәсьәләләренә багышланган фәнни-теоретик киңәшмә булып узды. Бу сөйләшү хәзерге әдәбият фәненең үсеш тенденциясен чагылдыруы ягыннан аеруча гыйбрәтле булды. Анда төп игътибар хәзерге татар әдәбият белемендә фәнни фикерләү методларын камилләштерүнең зарурлыгына юнәлтелде һәм шуның белән киңәшмә билгеле бер эз калдырды.

Хәзерге татар әдәбият белеменең һәм әдәби тәнкыйтенең казанышлары шөбһәсез. Бу уңышлар әдәбият тарихының төрле чорларына караган күләмле һәм җитди тарихи-теоретик хезмәтләрнең дөньяга чыгуында да, әдәбият теориясенең актуаль проблемаларына багышланган монографияләрнең иҗат ителүендә дә, аерым әдипләрнең тормыш юлы һәм иҗаты турындагы китапларның ишәюендә дә, төрле тематик җыентыкларның басыла торуында да күренә. Әдәбият фәне һәм әдәби тәнкыйтьбезгә багышланган мәкаләләрдә ул хезмәтләрнең исемнәре еш телгә алына — шуңа күрә аларны биредә кабатлап тору артык булыр. 60—70 нче еллар әдәбият фәненең 40—50 нчы еллар белән чагыштырганда, бер адым алга атлавы, җитди яңа уңышларга ирешүе, сан ягыннан да, сыйфат ягыннан да үсүе — бәхәссез. Әмма шул ук вакытта заман таләпләре югарылыгыннан чыгып, бөтенсоюз критерийлары белән якын килгәндә, әдәбият фәне өлкәсендә эшләүче көчләрнең шактый гына артуын да искә алсак, тынычланырга урын юк. Әдәбият турындагы китапларның, язучыларның иҗаты турында якланган диссертацияләрнең саны елдан-ел ишәя барса да, газета-журналларда әдәбият мәсьәләләрен яктырткан мәкаләләр саны өзлексез арта торса да, язучы һәм шагыйрьләрнең әдәбият фәненең торышына карата әйткән тәнкыйть сүзләре һич тә кимеми. Шагыйрьләр поэзия тарихы һәм тәнкыйте өлкәсендә эшләүчеләрдән, драматурглар — драматургия һәм театр белгечләреннән, балалар язучылары — балалар әдәбиятын өйрәнүче галимнәрдән, аларның хезмәтләреннән ризасызлык белдерәләр. Мисал өчен шундый фикерләрнең берсен китереп узыйк. Прозаик һәм шагыйрь Әхсән Баянов «Төп кыйбла — фәннилек» дигән мәкаләсендә[1]

[1] «Социалистик Татарстан», 1977, 25 январь.

хәзерге әдәби тәнкыйть турында болай дип яза: «Нихәтле генә гаҗәп тоелмасын, күп кенә мәкаләләрне укыгач, тәнкыйтьченең үзе тикшерә торган предметны белмәве, якынча гына сиземләве күренеп тора. Мондый тәнкыйтьче әсәр үзенчәлекләренә, технология катламнарына кермичә, дөресрәге, керә алмыйча, образлар системасы тирәнлегенә төшенмичә, язучының сүзне ничек әйткәнен тикшереп тә тормастан, аның нәрсә әйткәнен генә аңлатып, сөйләп котыла һәм судан коры чыга».

Әдәбият белгечләре ишәя, аларның хезмәтләре арта — ә язучыларның ризасызлыгы кимеми. Әлбәттә, язучыларның әдәбиятчыларны һәм тәнкыйтьчеләрне шулай кискен итеп, хәтта вакыт-вакыт дорфарак рәвештә бәяләүләрендә хакыйкатьтән читләшүгә илткән субъективлык та юк түгелдер. Әмма әдәбиятчылар адресына әйтелә килгән әлеге тәнкыйтьне тик субъектив факторга, язучылар белән галимнәрнең арасында булырга мөмкин аңлашылмаучанлыкка гына кайтарып калдыру да дөрес булмас иде. Аларның сүзләрендә өлешчә хакыйкать булуын тану әдәбият фәненең киләчәге өчен файдалы гына булачак. «Язучы белән тәнкыйтьче арасындагы кайбер аңлашылмаулар бер бүген генә тумаган — андый ситуацияләр 20—30 нчы елларда да, 40—50 нче елларда да булган, хәзер дә бар, киләчәктә дә булыр, ул — котылгысыз», — дип акланырга да булыр иде, әмма бу мәсьәләдә аклану урынсыз. Әдәбият тарихына мөрәҗәгать итсәк, чыннан да, андый мисалларны күпләп китерергә була. Әйтик, 20 нче елларда Такташ үз чорының һәртөрле узгынчы тәнкыйтьчеләре белән генә түгел, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти кебек күренекле әдәбиятчылары белән дә бәхәсләшкән, аларның аерым хезмәтләреннән ризасызлыгын белдергән. Бу турыда Х. Хәйринең Такташ турында язган мәкаләсендә шактый кызыклы һәм гыйбрәтле мисаллар китерелә[1]. Такташның ул мәкаләләрендәге, хатларындагы эмоциональ буяуларны бер читкәрәк алып куйсак, шагыйрьнең нигездә хаклы икәнлеген тану авыр булмас. Мисал өчен шагыйрьнең хатларыннан бер өзек китерик:

«Минем ике-өч ел язган шигырьләремне тәнкыйтьләүгә күз төшерсәк, иң күп чәйнәлгән нәрсә:

— Такташ ата казлар турында гына яза.

— Такташ тавыклар, мәчеләр турында гына яза, — дигән сүзләр.

Дөрестән дәме шулай? Минем шул өч ел эчендә язган шигырьләрем эчендә ата казлар, тавыклар турында язган шигырьләр өч-дүрт мең юл эченнән чүпләп алганда йөз юлга тулар микән? (Җитмеш юллар чамасы).»

Шушы рухтагы тәнкыйтьне 20—30 нчы елларда башка әдипләргә дә еш ишетергә туры килә. Әсәрдәге аерым бер образның үзен генә алып, аны контексттан һәм шигъри эчтәлектән, шагыйрь мөнәсәбәтеннән аерып карау һәм шул аерым хәлдә бәяләү вульгар-социологик тәнкыйтьнең яратып кулланган ысулларыннан булды. Шушы юнәлештәге тәнкыйтьнең схематизмын Такташ үз дәверендә үк күреп, аларның методологик хаталарын ачып салды: «Бу иптәшләр шигырьдәге төп мотивлар белән иярчен настроениеләрне, яки әсәрдәге декорацияне бутыйлар. Алар минем шигырьләрдәге декорацияләргә шулкадәр әһәмият бирәләр ки, хәтта үзләре дә сизми формализмга, схематизмга биреләләр».

Шагыйрь иҗат принцибы һәм эзләнүләренең характерын аңлатып болай дип язды: «Укучы ненормальный шаблоннан ялыкты. Бүгенгене ялангач килеш җырлаудан туйды. Шуның өчен дә мин соңгы вакытларда төп мотивларымны матур декорацияләр, күп вакытта көлке элементлар белән урап яза башладым. Мәчеләр, казларны көлке позаларга куеп, урталарына авылның бәхетле киләчәген җырлаучы тракторны китереп куям».

Такташның бу фикере шул чор тәнкыйтендәге хаталарны ачуы белән генә түгел, ә гомумән шигырьне тикшерүгә дөрес килүе белән дә бүгенгә кадәр дә әһәмиятен югалтмаган. Шигъри эчтәлекнең төрле дәрәҗәдәге мотивлардан, катламнардан төзелү мөмкинлеген күрсәтү шигырьне, әдәби әсәрне өйрәнүдә гаять отышлы ысул, «рациональ орлык» иде. Практик буларак Такташ шигъри әсәрнең гаять катлаулы организм булуын тирән тойды һәм аңарга бер яссылыктагы үлчәү белән генә килергә ярамаганлыкны күрсәтте. Күрүебезчә, бәхәснең асылында поэзия һәм әдәбият фәненең аерымлыгы түгел, ә әдәби әсәрләрне бәяләүдә эстетик принципларның

[1] Х. Хәйри. Шагыйрьнең эзләнүләре һәм бәхәсләре. — «Татар совет әдәбиятында социалистик реализм мәсьәләләре», Казан, 1960, 84—115 битләр.

аерымлыгы, тикшерү ысулларының үзгәлеге ята. Ә бу — методологиягә кагылышлы мәсьәлә. Такташ шул чордагы тәнкыйтьнең әдәби әсәрләрне бәяләү алымнары белән килешми, шул нигездә лирик шигырьне җиңел генә ботарлап ташлаган тәнкыйтьчеләр белән каршылыкка керә.

Әдәби әсәрне тикшерү методларының, эстетик бәяләү принципларының камил булмавыннан туган мондый бәрелешүләр, фикер аерымлыклары, әлбәттә, язучы белән тәнкыйтьче арасында гына түгел, әдәбиятчы белән әдәбиятчы арасында да табигый рәвештә очрый тора. Хикмәт — аерымлыкта да, каршылыкта да түгел, ә әдәбиятчыларның үз өлкәләрендәге әнә шундый йомшак һәм зәгыйфь урыннарны күрә алуларында, күреп төзәтә алуларында яки төзәтә алмауларында.

Язучыларның хәзер дә тәнкыйтьче һәм әдәбиятчылар адресына тәнкыйть сүзләре әйтә торулары исә әдәбиятчыларны нык кына уйландырырга, тикшерү ысулларындагы, алымнарындагы йомшак урыннарны эзләүне активлаштырырга тиеш. Тәнкыйтьче һәм әдәбиятчы традицион ысуллар белән генә эш итеп, бөтенләй яңа принципка нигезләнеп оешкан әдәби әсәрне аңлатуда аптырап калмыйммы? Яңа дип уйлаган тикшерү алымы әсәрнең эчке рухын тирән итеп ачарга булышамы, әллә, киресенчә, комачаулыймы? Башка фәннәрдә кулланылган методларны әдәбият белемендә ни рәвешле файдаланырга? Әдәби әсәрне анализлау ысуллары белән әдәби процессны тикшерү ысуллары арасында нинди уртаклык һәм аерымлыклар бар? Традицион тикшерү алымнарының яшәүчән көчен, аларның яңалыгын ничек сакларга? Бөтен фәннәрнең нигезендә яткан гомуми методологик принциплар белән аерым фәннәрдәге, шул исәптән әдәбият белемендәге методологик принципларның үзара мөнәсәбәтләре нинди? Сораулар күп һәм җитди. Алардан һич тә качып котылып булмый.

Әдәбиятчы галимнең, тәнкыйтьченең фәнни фикерләү ысулындагы йомшак урыннарны табу һәм аларны дәвалау өчен, барыннан да бигрәк, әдәбият белеме методологиясенең үз йөзен ачыкларга, аның әдәбият фәненең төрле өлкәләрендәге хәрәкәт итү мәйданы һәм механизмын, тикшерү ысулларының, алымнарының, принципларының диалектик кулланылышын ачык күзалларга кирәк.

КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында»гы карарында хәзерге әдәби тәнкыйтьнең үсүенә комачаулаган күп кенә кимчелекләр ачыла, «дәвалау» юллары күрсәтелә. Андый кимчелекләр әдәбият тарихы өлкәсендә дә, әдәбият теориясендә дә аз түгел. Һәм алар барысы да бер төенгә — әдәбиятны тикшерү ысулларын, алымнарын камилләштерү заруриятенә барып тоташа. Шуңа күрә дә карарда әдәбият фәне методологиясен үстерүгә җитди әһәмият бирелә.

Чыннан да, бездәге бу өлкәне ныклабрак күзәтсәк, әдәбият фәне һәм тәнкыйть методологиясенә игътибарның җитәрлек булмавын икърар итәргә тиеш булырбыз. Игътибар киму сәбәпле бу өлкәдәге тикшеренүләр дә арткы планга күчте. Фәнни институтларың планнарында да методологиягә кагылышлы темалар озак еллар дәвамында каралмады. Әдәбият тарихына караган хезмәтләр языла, әдәбият теориясенә дә урын бирелә, ә фәнни фикерләү тәгълиматына караган мәсьәләләр һаман читтә кала килә.

Әдәбият фәне методологиясенең бездә җитәрлек дәрәҗәдә эшләнмәгән булуы 1976 елгы теоретик киңәшмәне хәзерләү һәм үткәрү процессында да сизелде. Киңәшмәгә катнашырга чакыру алган байтак әдәбиятчылар махсус методологиягә түгел, ә әдәбият теориясенә яки әдәбият тарихына караган докладлар тәкъдим иттеләр. Күренекле әдәбият белгечләре билгеләвенчә, әдәбият фәне методологиясе әдәбият теориясе белән бик якын мөнәсәбәттә һәм бәйләнештә булсада, бөтенләй үк тәңгәл күренеш түгел. Әдәбият теориясе турыдан-туры язучының иҗат продукты булган әдәби әсәрне, үткәндәге яки хәзерге әдәби күренешне, әдәби процессны тикшерә, гомумиләштерә. Әдәбият фәне методологиясе исә турыдан-туры әдәбиятка түгел, ә әдәбиятка әдәбият фәне аша хезмәт итә: ул әдәбият фәненә әдәби күренешләрне тикшерү өчен юллар хәзерли, фәнни фикерләү коралы буларак ярдәмгә килә. Методология — ул әдәбият фәненең үз теориясе. Шушы тәгълимат нигезендә генә, әдәби әсәрне яки әдәби-тарихи процессны бәяләү принципларын, алымнарын, юлларын файдалану аша гына әдәбият теориясе үзенең конкрет йөзен билгели ала, практик максатына ирешә ала. Шул уңайдан А. С. Бушмин «әдәбият

теориясе» термины белән кысрыклап чыгарылган «гомуми әдәбият белеме» дигән терминны активлаштыруның кирәклеген әйтеп уза[1]. Гомуми әдәбият белеме әдәбият фәнендәге ике теоретик аспектны — әдәбият теориясен һәм әдәбият фәне теориясен (методологиясен) берләштерә. Бу фикер махсус методологиянең әдәбият фәнендә урынын билгеләү ягыннан да, әдәбият фәненең үз структурасын ачыклау ягыннан да отышлы. Цюрих университеты профессоры Макс Верли исә гомуми әдәбият белеменә махсус методология һәм методиканы да кертеп карый[2], әмма ул текстология, әдәбият тарихы өлкәләрен дә өстәп, әлеге терминның чикләрен артык киңәйтеп җибәрә.

Югарыда искә алынган киңәшмәдә аерым галимнәрдә билгеле бер яклау тапкан һәм әлегәчә яшәп килгән бер карашның — аерым фәннәрдәге методологиянең чагыштырмача мөстәкыйльлеген һәм аның әһәмиятен танып җиткермәү дә чагылып калды. Докладлар буенча фикер алышуда катнашкан Баян Гыйззәт үзенең чыгышында, мәсәлән, «әдәбият фәненең мөстәкыйль үз методологиясе юк һәм була да алмый, чөнки ул материалистик диалектика методологиясенә таяна»,— дигән фикер әйтте. Шуннан чыгып ул әдәбият фәненә карата методология терминын түгел, ә методика сүзен генә куллану мөмкинлеген яклады. 20—30 нчы елларда шактый нык тамыр җибәргән әлеге фикернең хәзер инде дөрес түгеллеге методологиягә караган байтак хезмәтләрдә ачылган. Аерым фәннәрнең үз методологиясе булуы ул гомуми марксистик методологиянең ролен инкарь итми. Махсус әдәбият методологиясе бит үзе гомуми фәлсәфи методологик принципларга таяна, шуларны үз тикшерү объектына һәм предметына хас рәвештә конкретлаштыру (гомуми методлар) һәм әдәбият белеменең үзенә генә хас методларын файдалану нигезендә барлыкка килә.

Әдәбият фәне тарихының төрле чорларында төрле методлар кулланылуы һәм шул методларга бәйләнештә төрле юнәлешләр, мәктәпләр формалашуы мәгълүм нәрсә ( мәсәлән, филологик, формаль, биографик, тарихи чагыштыру, социологик, психологик методлар). Иске мәктәпләрнең махсус методларын марксистик әдәбият белеме методологиясе инкарь итми, бәлки аларны берьяклылыктан азат итеп, вазифаларын яңача билгеләгән системада, яңа координациядә файдалана.

Гомуми һәм хосуси методлардан тыш әдәбият белеме методологиясе үзенә күп төрле ярдәмче методларны, материалны оештыруның техник чараларын һәм алымнарын да, җыйнап әйткәндә, фәнни методиканы да сыйдыра. Шул рәвешчә, әдәбият фәне методологиясен методика күләме белән генә чикләү аның функциясен бик нык тарайтуга китерер иде. Әдәбият белеме методологиясе әдәбият галимен һәм тәнкыйтьчене гаҗәп үткен тикшерү коралы белән коралландыра. Бу «корал»ның дәрәҗәләрен Ю. Борев түбәндәгечә билгеләде[3]: 1) әдәби күренешне тарихи үзгәреп торган чынбарлык белән контекстта карарга ярдәм итүче гомуми принциплар; 2) әдәби әсәргә билгеле бер яктан (гносеологик, аксеологик, чагыштыру, биографик, текстологик, стилистик һ. б.) якын килергә, тикшерергә булышучы күп төрле специфик тикшерү ысуллары; 3) әдәби әсәрнең эченә кереп, аның төрле катламнарын һәм элементларын күрергә ярдәм итүче алымнар, «операцион техника» чаралары; 4) әдәби әсәрне аның бөтен структураль бүленешләрендә һәм бөтенлегендә гомум планда теоретик күзалларга ярдәм итүче синтетик процедуралар һәм гомумиләштерү технологиясе.

Аерым фәннәрдәге методологиянең үзенчәлеген һәм чагыштырмача мөстәкыйльлеген танып җиткермәү фәнни фикерләүнең ысулларын, алымнарын гомумиләштерүгә, бу өлкәдәге тәгълиматны баетуга шактый нык комачаулык тудыруын да әйтергә кирәк. Әдәбият фәне методологиясенә игътибарның җитәрлек булмавы фәнни хезмәтләрдә, диссертацияләрдә методологик принципларны һәм алымнарны нигезләүгә чамадан тыш аз урын бирелүдә дә күренә. Авторлар еш кына үзләренең марксистик методологиягә таянулары һәм нигезләнүләре турында артык гомуми сүзләр әйтү белән чикләнәләр.

---

[1] А. С. Бушмин. Методологические вопросы литературоведческих исследований. Ленинград, 1969, 20 бит.
[2] М. Верли. Общее литературоведение (Перевод с немецкого). Москва, 1957.
[3] Ю. Борев. Системно-целостный анализ художественного произведения. «Вопросы литературы», 1977, № 7, 142 бит.

Татар совет әдәбият фәненең марксистик нигездә формалашу һәм үсү тарихына күз салсак, методология мәсьәләләренә игътибарның төрле чорда төрлечәрәк тирбәлүен күрербез. 20—30 нчы елларда фәнни фикерләү ысуллары, алымнары, принциплары белән кызыксынуның үсүен күрмичә мөмкин түгел. Яңа әдәбиятның үзенчәлекләре, әдәбиятның һәм әдәбият фәненең, тәнкыйтьнең нинди принципларга таянуы, милли һәм интернациональ традицияләргә яңа әдәбият нинди мөнәсәбәттә булырга тиешлеге турында газета-журналларда кызу-кызу бәхәсләр бара, шушы бәхәсләрдә яңа совет әдәбият фәненең һәм тәнкыйтенең аерым нигез принциплары ачыклана. Әлеге сөйләшүләрдә Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Рәхим кебек әдәбиятчылар гына түгел, язучылар да актив катнаша. Мисал өчен Г. Ибраһимовның гыйльми һәм тәнкыйть эшчәнлегенә күз салу да җитә. «Татар әдәбияты» исемле мәкаләсендә Г. Ибраһимов җитәкче оешмалар тарафыннан үзенә «пролетариат әдәбиятының нигезләрен язу» бурычы йөкләтелүен әйтеп уза. Әлеге социаль заказны әдип 1924 елны башкарып та чыга.— «Пролетариат әдәбияты турында» исемле хезмәте дөнья күрә. Әдәбият фәненең актуаль методологик, теоретик мәсьәләләрен үзәккә куйган бу хезмәт яңа әдәбиятның принципларын ачыклауда, үсү юлларын билгеләүдә гаять зур роль уйнады һәм әдәбият фәне методологиясен бездә марксистик фәнни нигезләгән беренче җитди гыйльми-теоретик хезмәтләрдән булды. Моннан тыш та Г. Ибраһимов әдәби әсәрне анализлау һәм бәяләү, әдәбият тарихын чорларга бүлү, милли әдәбиятның чикләрен билгеләү принциплары, әдәби стиль, иҗат методы турында байтак мәкаләләрендә сүз алып барды һәм шушы мәсьәләләрдә үз чоры өчен яхшы ук нигезле, әле дә әһәмиятен югалтмаган концепциясен тәкъдим итте («Татар әдәбиятында өченче дәвер», «Аңларга тырышыгыз, туганнар», «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы», «Татар әдәбиятын өйрәнү юлында», «Кара маяклар яки ак әдәбиятлар» һ. б.).

Әдәбият фәненең марксистик нигезгә корылуы җиңел генә бирелми. Бер яктан, фәндә буржуаз әдәбият белеменең «бердәм агым» рухындагы концепцияләренә, искергән принципларына каршы көрәш барса, икенче яктан, шушы көрәштә марксизмны үткен корал иткән әдипләр, галимнәр марксизм тәгълиматын конкрет әдәбият фәнендә кулланганда һәм әдәбиятны тикшерүнең үз методларын тудырганда кайбер үзләре үк хаталанып, абынып куялар. Әдәбият фәнендәге әнә шундый абынусөртенүләр әдәби процесска кире яктан шактый үк нык тәэсир иткән авыру кыяфәтен дә алгалады. Әдәбият фәне методологиясендәге авыруга мисал итеп формализм һәм вульгар-социологизм күренешләрен алырга мөмкин. Алар белән көрәш татар әдәбият белемендә дә барды. Имажинизм, футуризм кебек формалистик агымнарның фәнни яктан нигезсез булулары чагыштырмача тизрәк — 20 нче елларның урталарына инде ачыкланса да, вульгар-социологизм белән көрәш күп тапкыр катлаулырак, авыррак булды һәм озаграк дәвам итте. Бу көрәшне катлауландырган сәбәп — вульгар-социологизм тарафдарларының марксизм терминологиясе белән эш итүләрендә, үзләрен әдәбият фәнендә марксизм тәгълиматы өчен көрәшүчеләр итеп куюларында иде. Алар чыннан да үзләрен шулай дип уйладылар, шуңа ышанып, ихлас күңелдән ялгыштылар. Бу яктан аеруча Х. Наум, Ф. Мөсәгыйть, С. Мортазин кебек тәнкыйтьчеләрнең эшчәнлеге аерылып тора. Әдәбият фәне методологиясе үз үсешендә вульгар-социологизмның әдәби процессны һәм әдәби әсәрне тикшерүдәге тупаслыкларын, дорфалыкларын җиңә барды.

Әдәби күренешләрне һәм әдәби әсәрләрне тикшерүнең принциплары, алымнары ачыклана бару белән бу өлкәдәге бәхәсләр дә 30 нчы елларның икенче яртысыннан башлап тына бара, шулай ук әдәбият фәне методологиясенә игътибар да кими. Моның сәбәпләрен профессор А. С. Бушмин болай дип аңлата: «Бу барыннан да элек 30 нчы еллар урталарыннан гуманитар фәннәргә карата туган догматик мөнәсәбәтнең әдәбият белемендәге иҗади фикерләүгә дә уңай шартлар тудырмавы белән бәйле иде. Әлбәттә, бу вакытта да әдәбият белеме методологиясе бер урында тормады, башка вакытларда үскәнчә (аеруча конкрет тикшеренүләрдә) үсүен дәвам итте. Әмма аның үсешенә фәнни тикшеренүләр тәҗрибәсенең озак вакытлар дәвамында даими рәвештә тикшерелеп тормавы һәм гомумиләштерелмәве кире яктан йогынты ясамыйча калмады. Шул сәбәпле фәнни тикшеренү алымнары өлкәсендәге казанышлар һәм кимчелекләр ачыкланмыйча калды. Фәнни коллективның фикере озак вакытлар дә-

вамында методология мәсьәләләренә җитәрлек дәрәҗәдә мөрәҗәгать итмәгәнгә күрә дә, мөгаен, без алардан читләшкәнбез...»[1]

Рус совет әдәбият белемснә карата әйтелгән бу фикерләр тулысы белән татар әдәбият фәненә дә карый. Тик шунысын өстәп әйтергә кирәктер: бездә 40—50 нче елларда методология мәсьәләләренә игътибарның кимүе тагы да ачыграк һәм тирәнрәк чагылды. Сирәгәеп калган әдәбиятчылар төп игътибарларын әдәбият тарихының аерым чорларын өйрәнүгә, әдәби әсәрләрне барлауга һәм туплауга, аерым язучыларның тормышын, иҗат юлын өйрәнүгә юнәлттеләр. Бу да кирәкле һәм зарури эш иде. Әмма тупланган тәҗрибә, конкрет тикшеренүләрдәге фәнни алымнар, принциплар гомумиләштерелмәде. Ә бу исә әдәбият белемендәге фәнни фикерләү ысуллары турындагы тәгълиматны (ягъни методологияне) үстерүгә нык кына комачаулый. Г. Нигъмәти, Г. Сәгъди, Г. Гали кебек күренекле әдәбиятчыларның татар әдәбияты тарихына һәм әдәбият теориясенә караган хезмәтләрендә, тәнкыйть мәкаләләрендә методологиягә кагылышлы гаять отышлы казанышлар бар. Кызганычка каршы, аларның эшчәнлекләре әлегәчә ныклап өйрәнелгәне, әдәби процессны, әдәби әсәрне анализлаудагы уңышлы фикерләү алымнары тиешенчә гомумиләштерелгәне юк. Такташ, Бурнаш, Кутуй, Җәлил, Ә. Фәйзи кебек әдипләр әдәби тәнкыйть өлкәсендә дә бай мирас калдырдылар. Аларның тәнкыйть мәкаләләренең проблематикасы, эчтәлеге турында ара-тирә сүз алып барсак та, әдәби әсәрне бәяләү принципларындагы, тикшерү алымнарындагы үзенчәлекләрне тирән итеп ачканыбыз юк әле. Ниһаять, 50 нче еллардан соң XIX гасыр, XX йөз башы татар әдәбияты тарихына, татар совет әдәбиятының аерым этапларына караган җитди монографияләр, хезмәтләр язылды (Г. Халит, М. Гайнуллин, Х. Госман, А. Сайганов, И. Нуруллин, Г. Кашшаф, М. Хәсәнов һ. б. хезмәтләре). Әлеге хезмәтләрдән күренгәнчә, галимнәрнең фәнни фикерләү алымнарында уртаклыклар булу белән бергә, аерымлыклар, үзгә хасиятләр дә бар. Аларны өйрәнү, отышлы һәм кимчелекле якларын танып алу, галимнәрнең иҗат лабораторияләренә үтеп керү фәнни фикерләү алымнарын баетуга билгеле бер нигез булыр иде. Дөрес, бу өлкәдә азмы күпме эшләр эшләнә килүен дә икърар итәргә кирәк. Тукай, Әмирхан, Ибраһимов, Такташ кебек классик әдипләребезнең әдәби тәнкыйть эшчәнлеген өйрәнүдә әһәмиятле күзәтүләр ясалганын танымау дөрес булмас иде. Хәзер шушы юнәлештәге тикшеренүләрне тагы да киңәйтергә, әдәбият фәне методологиясенә кагылышлы аспектларны тагы да тирәнәйтергә кирәк булуында шик юк. Чөнки әдәбият фәне методологиясен үстерүдә һәм камилләштерүдә традицияләрнең роле кечкенәдән түгел. Бу уңайдан традицияләр мәйданын да ачыклап үтү кирәктер. Методология өлкәсендәге мирас дигәннән татар әдәбият белеме казанышларын гына күздә тоту дөрес булмас иде. Татар әдәбиятчылары, тәнкыйтьчеләре элек-электән рус галимнәренең, тәнкыйтьчеләренең казанышларына таяндылар, аларның фәнни фикерләү алымнарыннан файдаландылар. М. Хәсәновның «Галимҗан Ибраһимов» (1977) монографиясендә, мәсәлән, әдипнең рус галимнәреннән, тәнкыйтьчеләреннән өйрәнүенә һәм шул нигездә үз принципларын, алымнарын формалаштыруына кагылышлы күп фактлар китерелә.

Сүз дә юктыр, хәзерге татар әдәбиятчылары Г. Ибраһимов, Г. Сәгъди, Г. Нигъмәтиләрнең рус әдәбият фәне методологиясеннән иҗади өйрәнү традицияләрен яңа шартларда дәвам итәләр, үстерәләр. Хәзерге әдәбият фәнендә методология өлкәсендәге традицияләр җирлеге тагы да киңәя төште. Татар галимнәренең хезмәтләрендә М. Храпченко, Л. Выготский, Б. Мейлах, Г. Поспелов, В. Жирмунский, Л. Тимофеев, Ю. Лотман, Б. Сучков кебек рус галимнәренең фамилияләре белән рәттән, күп милләтле совет әдәбияты белгечләренә мөрәҗәгать итү дә еш очрый. Бу иҗади аралашу, мәсәлән, шигырьне тикшерү өлкәсендә аеруча ачык күзгә ташлана. Шигырь белгечләре Х. Госман һәм Х. Курбатов, мәсәлән, үзләренең тикшеренүләрендә казакъ һәм азербайҗан, үзбәк һәм кыргыз, башкорт һәм якут галимнәренең, поляк һәм инглиз, төрек һәм немец әдәбиятчыларының хезмәтләренә дә таяналар, кирәк урында аларның методларын файдаланалар, кирәк урында аларның карашлары һәм фикерләү алымнары белән бәхәсләшәләр. Мәсәлән, Х. Госман белән уйгур галимә

[1] А. С. Бушмин. Методологические вопросы литературоведческих исследований. Изд. «Наука», Ленинград, 1969, 10 бит.

Хамраевның төрки шигырь төзелеше турындагы бәхәсләре[1] асылда аларның фәнни фикерләү алымнары аерымлыгына барып тоташа. Кыскасы, методологиядәге мирасны үзләштерү 20—30 нчы еллар белән чагыштырганда хәзер күп яклы, күп баскычлы процесс булып әверелде. Фәндә артка калмас өчен, методологиядә туып торган яңалыкларны күрү өчен өзлексез укырга һәм өйрәнергә кирәк. Бездәге байтак хезмәтләрнең бер калыптарак төзелүе, 50 нче елларда ук әдәбият фәне мәйданына чыккан аерым галимнәрнең, аспирантура тәмамлап, фән кандидаты исеме алган кайбер әдәбиятчыларның үсүдән туктап, язучы һәм укучыларны канәгатьләндерерлек продукция бирмәүләре менә шушы интернациональ бай мирасны җитәрлек өйрәнмәүләре белән дә бәйле булса кирәк.

Чын сәнгать әсәре — гаять катлаулы организм. Дантены, Шекспирны яки Пушкинны, Л. Толстойны, мәсәлән, дөньяда никадәрле күп галимнәр тикшергән, аларның әсәрләре турында йөзләгән том фәнни хезмәтләр басылган. Әмма шуңа карап кына бу бөек әдипләрнең осталыгы тәмам ачылып бетте дип әйтеп буламы соң? Юк, әлбәттә. Ихтимал, бу тылсымлы, серле «җанны»— әдәби әсәрне — бөтенләй үк ахыргача танып бетереп тә булмый торгандыр. Чөнки тормыш һәр вакыт үзгәреп тора. Чын мәгънәсендәге камил сәнгать әсәре дә бер ноктада гына туктап калмый, яңа буыннар белән бергә яшәвен дәвам итә. Тарихи яңа чорда яшәгән яңа буын исә әдәби әсәрнең элегрәк укучыга барып җитә алмаган яңарак хасиятләрен күреп ала. Шул нигездә әсәрнең яңача яшәеше, яңа сулышы туа, эчтәлеге һәм формасының хасиятләре яңачарак ачылып китә. Шушы ук процесс — тормышның алга баруы белән бергә әсәрнең дә функциональ хәрәкәт итүе, нинди яңа яклары белән ачыла баруы фәнни фикерләү ысулларын камилләштерү бурычын да актуальләштерә.

Әдәби әсәрне тикшерүдә әдәбият фәне шактый бай тәҗрибә туплаган булса да, бу өлкәдәге йомшак урыннар да аз түгел әле. Социологик анализ белән эстетик анализны, хәзерге белән тарихны бергә кушып җиткерә алмау, шигъри форманың эстетик табигатен танып бетерә алмау, форманың эчтәлек белән бәйләнешен караудагы көчсезлек безнең тикшеренүләрдә үзен нык сиздерә. Болар исә методологиядәге йомшаклыклар белән бәйле.

Фәнни-техник революция чорында фәннәрнең бөтен тармакларында методология мәсьәләләренә игътибарның көчәюе очраклы түгел. Һәр өлкәдә фәнни фикерләүнең нәтиҗәле, ышанычлы, отышлы ысулларын эзләү бара. Әдәбият фәне методологиясен камилләштерүне дә зарури рәвештә хәзерге тормыш бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куя. Әдәбият белеме методологиясенә багышланган коллектив хезмәтләрнең соңгы елларда ишәя баруы[2], «Вопросы литературы», «Литературная газета» битләрендә фәнни фикерләү ысулларын камилләштерүгә кагылышлы дискуссияләрнең оештырылуы һәм методологиягә караган материалларның күпләп басылуы да бу өлкәдә җанлы хәрәкәт тууына дәлил булып торалар. Төрле фәннәрдә барган эзләнүләрнең үзенчәлеген чех галиме И. Зелены түбәндәгечә билгели: а) «модель» төшенчәсен һәм модельләштерү алымнарын файдалану; б) математика методларын куллану; в) конкретлык һәм абстракциянең яңа нисбәте туу; г) фәннәрнең үзара бер-берсенә үтеп керүе көчәюе; д) идея көрәше көчәйгән шартларда фәнни фикерләүнең идеологик аерымлануы. Бу сыйфатларны Ю. Борев предметны тикшерүдәге күпьяклылыкка омтылу, анализда системалылыкка һәм бөтенлеккә юнәлеш тоту үзенчәлекләре белән тулыландыра[3].

Әдәбият фәне методологиясенең үзенчәлекләрен, аспектларын тагы да ачыграк күзаллау буенча соңгы елларда байтак уңышлы эзләнүләр булуын әйтергә кирәк. Мәсәлән, А. С. Бушмин китабында[4] әдәбият белеме методологиясенең гомуми фәнни методология, әдәбият теориясе, әдәбият методикасы белән мөнәсәбәтләре карала, әдәбият фәненең гуманитар фәннәр арасындагы урыны һәм роле тикшерелә, әдәбият фәненең структурасы, фәнни тикшеренүләрнең жанрлары һәм типлары

[1] Х. Госман. Татар шигыре. Казан, 1964, М. Хамраев. Основы тюркского стихосложения. Алма-Ата, 1963.

[2] Историко-литературный процесс. Проблема и методы изучения. Ленинград, 1974; Современные проблемы литературоведения и языкознания. Москва, 1974; Методологические проблемы современной литературной критики. Москва, 1976.

[3] Ю. Борев. Системно-целостный анализ художественного произведения. «Вопросы литературы», 1977, № 7.

[4] А. С. Бушмин. Методологические вопросы литературоведческих исследований. Ленинград, 1969.

ачыла, фәнни тарихилык принцибы турында сүз бара. М. Б. Храпченко китапларында да[1] хәзерге әдәбият фәненең житди һәм актуаль методологик мәсьәләләре яктыртыла (әдәбиятта һәм сәнгатьтә прогресс, язучының иҗади индивидуальлеге, стиль мәсьәләләре, әдәбиятны типологик өйрәнү, семиотика һәм модельләштерү һ. б.) И. Г. Неупокоева, Г. И. Ломидзе[2] монографияләрендә әдәбиятларның үзара элементләре, бәйләнешләренең методологик аспектлары ачылса, Н. И. Конрад[3], И. С. Брагинский[4] төп игътибарларын көнчыгыш әдәбиятының методология мәсьәләләренә юнәлтәләр. А. Н. Иезуитов систем методны социалистик реализмны өйрәнүдә файдаланды[5]. Бирeдә методология өлкәсенә караган тик бернично хезмәтнең генә исеме аталды. Шушы өлкәдә эшләүче авторларның исемлеген исә бик күп фамилияләр белән тулыландырырга мөмкин: В. Жирмунский, Л. Тимофеев, Г. Поспелов, Д. Лихачев, Н. Бельчиков, Г. Фридлендер, Д. Марков, Ю. Суровцев, У. Фохт һ. б.

Бөтен ил күләмендә әдәбият методологиясе өлкәсендә барган әлеге җанлы хәрәкәттән безнең әдәбиятчылар да бөтенләй үк читтә тормыйлар. 70 нче еллар татар әдәбият белемендә методология мәсьәләләренә игътибарның арта төшүен, әдәбият белеме һәм әдәби тәнкыйть методологиясенең авторитеты күтәрелә баруын күп төрле фактларда күзәтергә мөмкин. Бу, мәсәлән, марксизм-ленинизм классикларының әдәбият һәм сәнгатькә караган хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итүдә дә чагыла. Конкрет алганда бирeдә сүз 1976 елны Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленин әдәбият һәм сәнгать турында» исемле зур күләмле (37 табак) җыентык турында бара (төзүчеләре һәм редколлегия членнары — М. Мусин, М. Зәкиев, А. Әхмәдуллин, Н. Габитов). Дөрес, бу эш 70 нче елларда гына башланмады. 20—30 нчы елларда ук Маркс, Энгельс, Ленинның аерым мәкаләләре, рецензия һәм хатлары тәрҗемә ителде. 1947 һәм 1960 нче елларны «Ленин әдәбият турында» исемле махсус җыентык чыгару, В. И. Ленинның 45 томлык «Әсәрләр»ен татарча тәрҗемә итү аша татар укучылары бөек революция юлбашчысының марксистик эстетика мирасына керткән өлешен күзаллый алдылар. Соңгы елларда марксизм-ленинизм классикларының әдәбиятка һәм сәнгатькә караган хезмәтләрен тулырак тәрҗемә итеп (аеруча Маркс, Энгельсны), яңа табылган материалларны да татарча кулланылышка кертеп, аларны билгеле бер системага салып бирү бурычы көн тәртибенә баскан иде. Әлеге җыентык шушы ихтыяҗны канәгатьләндерү юлында кирәкле һәм уңышлы адым булды. Җыентыктагы материаллар Маркс, Энгельсның марксистик эстетика фәнен нигезләүләрен, әдәбият һәм сәнгатьнең яңа гомуми методологик базасын эшләүләрен, В. И. Ленинның яңа тарихи шартларда бу теоретик мирасны тагын да үстерүен һәм баетуын, уңышлы дәвам итүен ачык күрсәтәләр. Хәзер бөтен дөнья эстетика мирасына кыйммәтле өлеш булып кергән башка тарихи-теоретик чыганакларны тәрҗемә итү бурычы көн тәртибендә тора.

Гомуми фәлсәфи методология чыганакларына игътибар көчәю белән бергә, әдәбият белеме һәм тәнкыйтьнең конкрет методологик мәсьәләләренә дә игътибар арта бара. Әйтик, соңгы елларда теоретик яки практик максатларны, һәртөрле юбилейларны күздә тотып оештырылган конференцияләрдә әдәбият-сәнгать методологиясенә караган докладларның урын алуына аеруча зур әһәмият бирелә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтында Идел буе һәм Урал янындагы халыклар культурасының үзара бәйләнешләренә багышланган фәнни конференциядә методологик характердагы докладларның тыңланылуы һич тә очраклы түгел[6]. Совет Көнчыгышы әдәбиятларында реализм үсешенә багышлап 1972 елны Бакуда[7], 1975 елны Ташкентта[8] үткәрелгән бөтенсоюз фәнни конференцияләрендә дә

[1] М. Б. Храпченко. Творческая индивидуальность писателя и развитие литературы. Москва, 1970; Художественное творчество, действительность, человек. Москва, 1976.

[2] И. Г. Неупокоева. История всемирной литературы. Проблемы системного и сравнительного анализа. М., 1976; Г. И. Ломидзе. Методологические вопросы изучения взаимосвязей и взаимообогащения советских литератур. Москва, 1963.

[3] Н. И. Конрад. Запад и Восток. Москва, 1972.

[4] И. С. Брагинский. Проблемы востоковедения. Москва, 1974.

[5] А. Н. Иезуитов. Социалистический реализм в теоретическом освещении Л.-д., 1975.

[6] Ю. Г. Нигматуллина. Некоторые проблемы сравнительно-типологического изучения литератур. К. Т. Гизатов. Некоторые методологические вопросы изучения национального и интернационального в искусстве.— «Взаимодействие культуры народов Поволжья и Приуралья». Сборник. Казань, 1976.

[7] Проблемы реализма в литературах народов Советского Востока. (Материалы совещания 1972 г.). Баку, 1974.

[8] Истоки, формирование и развитие социалистического реализма в литературах Советского Востока. (Материалы конференции 1974 г.) Ташкент, 1976.

методологик характердагы чыгышлар байтак урын алды. Г. Ломидзе, З. Кедрина, Л. Якименко, М. Пархоменко, А. Гаджиев, М. Дадашзаде кебек галимнәрнең чыгышында күп милләтле совет әдәбияты яки совет Көнчыгышы халыкларының әдәбиятларына хас уртак методологик-теоретик мәсьәләләр күтәрелсә, Х. Госман, Й. Нигъмәтуллина, И. Нуруллин, Р. Ганиева докладларында татар әдәбиятының конкрет аспектлары яктылыгында гомум төрки әдәбиятларының аерым методологик мәсьәләләре кузгатылды. Күп томлы «Татар әдәбияты тарихы»ның план-проспектын[1] язганда да авторлар коллективына татар әдәбияты тарихының аерым методологик мәсьәләләренә кагылырга һәм хәл итәргә туры килде. Г. Таһирҗановның борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты тарихына кагылышлы язган мәкаләләрендә[2] урта гасыр татар әдәбиятының үзенчәлекләрен билгеләүгә бәйле әһәмиятле методологик күзәтүләр бар.

Бездә әдәбият белеме һәм тәнкыйтьнең үсү юлын гомумиләштерүгә омтылыш та үскәннән-үсә бара. Мәсәлән, Г. Халит, Х. Хәйри, Ф. Әгъзәмов җыентыкларында[3] татар әдәбият фәненең гомуми үсү юлын характерлаган яки аерым чорлардагы үсешен тикшергән мәкаләләр дә урын алган. 1976 елны Алма-Атада үткәрелгән бөтенсоюз тюркология конференциясендә А. Әхмәдуллин татар әдәбият белеменең совет чорында үткән юлы һәм перспективасы турында махсус доклад белән чыгыш ясады[4]. М. Хәсәнов[5], М. Мәһдиев[6], Р. Мөхәммәдиевнең[7] хезмәтләрендә әдәбият белеменең аерым чорлардагы үсеш тенденцияләре, аерым әдәбиятчыларның иҗатлары бай фактик чыганаклар җирлегендә тәфсилле итеп тикшерелә. Соңгы елларда, аеруча КПСС Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать тәнкыйте турында» карары игълан ителгәннән соң, хәзерге әдәби тәнкыйтьнең үсеш тенденцияләрен, тикшерү алымнарын, принципларын анализлауга игътибар бермә-бер көчәйде, хәзерге тәнкыйть торышына караган күп кенә мәкаләләр дөнья күрде. Аларда әдәби әсәрне тикшерү методикасына кагылышлы әһәмиятле генә күзәтүләр очрый, әдәбият фәне методологиясе игътибар юнәлтергә тиешле бәхәсле мәсьәләләр кузгатыла (әдәби тәнкыйтьнең кемгә адресланган булуы, тәнкыйтьнең төрләре һәм жанрлары, фәнни фикерләү культурасы h. б.). Хәзер инде әдәбият белеменең төрле тармакларындагы конкрет хезмәтләрне бәяләүдән, алардагы үзенчәлекләрне ачыклаудан фәнни фикерләү ысулларындагы гомуми үсеш тенденцияләрен ачыклауга һәм гомумиләштерүгә, методика һәм методологиягә караган специфик мәсьәләләрне кыюрак кузгатырга кирәклеге сизелә. Методология өлкәсендәге шундый тикшеренүләрнең зарурияткен аеруча Казан дәүләт университеты профессоры Йолдыз Нигъмәтуллина нык тоеп иҗат итә. Ул бу өлкәдә даими шөгыльләнеп килә, нәтиҗәле теоретик һәм практик эш алып бара. Й. Нигъмәтуллинаның «Әдәби иҗатны комплекслы тикшерү» дигән методик кулланмасы[8] шушы эшнең нәтиҗәсе булды. Бу хезмәттә әдәби әсәрне тикшерүнең төрле дәрәҗәләре һәм аерым модельләре конкрет мисалларда күрсәтелә. Язучының сәнгатьчә фантазия тибын, иҗат индивидуальлеге структурасын билгеләү методикасы да гаять үзенчәлекле һәм оригиналь. Иҗат индивидуальлеген галим катлаулы, күп дәрәҗәле структура итеп карый, һәр катламның элементларын билгели, язучының активлыгы иҗат процессында төрле катламда (дөньяны тою һәм дөньяга караш дәрәҗәләрендә) төрлечә чагылуын ачыклый.

Соңгы елларда фәннең төрле тармакларында күренеш, предметларны комплекслы өйрәнүгә, анализда системалылыкка игътибар көчәйде.

Матур әдәбиятны өйрәнүдә дә комплекслылык идеясе хәзерге әдәбият белемендә әһәмиятле методологик принциплардан санала, перспективалы юнәлешләрнең берсе буларак карала. СССР Фәннәр академиясенең бөтен дөнья культура тарихын өйрәнү фәнни советы, әдәби иҗатны комплекслы өйрәнүнең әһәмиятен искә алып һәм шушы өлкәдәге тикшеренүләрне координацияләү максатыннан чыгып, комплекс-

[1] История татарской литературы в 5 томах. (План-проспект. Казань, 1973).
[2] Г. Таһирҗанов. Әдәбият тарихында иҗтимагый-мәдәни мөнәсәбәтләрнең роле. «Казан утлары», 1976, № 7, 8—9.
[3] Г. Халит. Кешегә һәм чынлыкка мәхәббәт белән. К., 1975; Х. Хәйри. Иҗат чишмәләре. К., 1975; Ф. Әгъзәмов. Яшәү көче. К., 1977.
[4] Тюркоязычные литературы — история и современный литературный процесс. Алма-Ата, 1976.
[5] Мансур Хасанов. Галимджан Ибрагимов. Казань, 1977.
[6] М. С. Магдеев. Татарская советская литературная критика (1917—1932). Автореферат кандидатской диссертации. Казань, 1964.
[7] Р. Мөхәммәдиев. Югалмас мирас эзеннән. «Казан утлары», 1977, № 9.
[8] Ю. Г. Нигматуллина. Комплексный анализ художественного творчества. Учебно-методическое руководство. Казань, 1976.

лы өйрәнү комиссиясе оештырды. Мәскәү, Ленинград, Киевта шушы мәсьәләгә кагылышлы конференцияләр, симпозиумнар булып узды. «Содружество наук и тайны творчества» (1968), «Творчество и современный научный прогресс» (1966), «Проблемы ритма, художественного времени и пространства в литературе и искусстве» (1970), «Поэзия и музыка» (1973) кебек җыентыклар дөнья күрде. Бу өлкәдә аеруча Б. С. Мейлахның зур оештыру эше алып баруын, иҗатны комплекслы өйрәнүнең методологиясенә караган байтак хезмәтләр иҗат итүен әйтәсе килә. Аның эзләнүләре «На рубеже науки и искусства» (Л., 1971) исемендә аерым китап булып та басылып чыкты.

Әдәбиятчыларның әдәби иҗатны тикшергәндә төрле фәннәр белән союзга керүләре игътибарны аеруча җәлеп итә. Әдәби иҗатны тикшерүдә тарих, философия, социология, психология, кибернетика, математика, семиотика кебек төрле фәннәр катнаша, әмма аларның мөмкинлекләре һәм рольләре дә төрлечә. Әдәби иҗатны комплекслы өйрәнүнең аерым мәсьәләләре методологик яктан әле яңа ачыкланып килә, ә байтак аспектлары тикшеренүне көтеп ята. Й. Нигъмәтуллинаның әдәби иҗатны комплекслы өйрәнүгә багышланган теоретик хезмәтләре һәм яңа китабы[1] бөтен союз күләмендә барган шушы өлкәдәге эзләнүләр белән органик кушылып китте.

Китапның беренче бүлегендә әдәби әсәрне комплекслы тикшерүнең аерым мәсьәләләре, конкрет алганда, әдәби анализда комплекслылык һәм системалылыкның үзара мөнәсәбәтләре яктыртыла. II—III бүлекләрдә әдәби әсәрне анализлауда филология һәм психология фәннәреннән файдалану юллары күрсәтелә.

Комплекслылык һәм системалылык төгъбирләре еш кына бергә очрашсалар да, алар аңлаткан мәгънәнең эчтәлеге тәңгәл килми. Системалы-структур анализ фәнни тикшеренү ысулына карый. Комплекслылык исә системалы-анализ белән эш иткәндә башка фәннәрнең методларын, алымнарын, категорияләрен файдалануны күздә тота. Яшерен түгел, аерым хезмәтләрдә комплекслылык идеясен гадиләштереп аңлап, кибернетика, семиотика терминнары кирәксә дә-кирәкмәсә дә мул итеп файдалану белән мавыгулар күренгәләде. Автор күп аспектлы мондый тикшеренүләрдә очрарга мөмкин булган һәр төрле эклектизмнан, башка фәннәрнең казанышларын механик куллanудан саклану кирәклеген искәртә, комплекслылыкны үз зарурияте булганда гына файдалануны яклый.

Й. Нигъмәтуллина системалар һәм структуралар турындагы гомуми тәгълиматны материалистик диалектика закончалыклары яктылыгында аңлатып үтә, аның категорияләрен (система, структура, элемент, функция, процесс, дәрәҗә һ. б.), терминнарының конкрет эчтәлеген ачыклый. Авторның системалы анализның әдәбият фәнендә куллану сферасын һәм механизмын ачыклавына кагылышлы фикерләре, күзәтүләре дә әһәмиятле.

Галим системалы-структур анализның эстетикадагы структурализмнан аерымлыгын да дөрес билгели, структурализмны фәнни тикшерүдәге формалистик ысул дип саный.

Й. Нигъмәтуллина әдәби әсәрне структур өлешләргә таркатуның үзенчә иерархик моделен дә тәкъдим итә. Беренче дәрәҗә — ул поэтика. Аңа галим поэтик ассоциацияләрне, троплар системасын һәм әдәби телне кертә. Икенче дәрәҗә — әдәби образ. Ул үз эченә конфликтны, образлар системасын, сюжет-композиция һәм жанр үзенчәлекләрен, әдәби образлылык типларын һәм әдәби әсәрдәге детерминант системасын сыйдыра. Тагы да югарырак булган өченче дәрәҗәгә — әдәби әсәрнең типологиясенә автор әдәби юнәлешләрне, алымнарны, иҗат методларын, әдәби иҗат типларын кертә.

Хезмәттә философия һәм психология фәннәренең әдәби әсәрне анализлауда нинди күләмдә һәм ни рәвешле файдаланылу мөмкинлекләрен ачыклауга да җитди әһәмият бирелгән, бу өлкәләрдә күп яңа фикерләр әйтелгән һ. б.

Татар әдәбият белеменең һәм тәнкыйтенең яңа биеклекләр яулавы, һичшиксез, әдәбият белемендәге фәнни фикерләү теориясен тагы да камилләштерү, бу өлкәдәге эзләнүләрне активлаштыру, үткәндәге һәм хәзерге тәҗрибәләрне гомумиләштерү, әдәбият белеме методологиясенең үз йөзен тагы да ныграк ачыклау белән аерылгысыз бәйләнгән.

---

[1] Ю. Г. Нигматуллина. Методология комплексного изучения художественного произведения. Изд. КГУ, 1976.

Хатип Госман

# ЯШЬЛӘР ҺӘМ ОСТАЗЛАР

I

Поэзиянең җитди мәсьәләләре турында сөйләшергә җыенганда, сүзне аңлаешлы һәм аңлаешсыз шигырьләрдән башлап китү бик үк җайлы түгел. Аңлаешсыз нәрсәне шигырьләр рәтенә кую гомумән дөрес булыр иде микән?

Шигырь элек-электән кешеләрнең үз күңел тирәнлекләрендә яткан мөһим хис-кичерешләрен үзара уртаклашу, хәсрәт булса — бергә күтәрешү, сөенеч-шатлык булса — бергә тантана итү, катлаулы һәм гомум әһәмиятле рухи-әхлак мәсьәләләре турында бергәләп кичерешү, гомумән кешеләрнең үз рухи сәламәтлекләрен ныгыту чарасы булып килә.

Шигырь кеше күңеленә рухи ләззәт, эстетик куаныч булып керергә тиеш. Аңлаешсыз нәрсә моны ничек эшли алсын? Әлбәттә, һәр аңлаешлы нәрсә — шигырь түгел. Менә алдыбызда — Р. Фәйзуллиннан ике парча:

**ҖӘЛИЛ ТОМНАРЫ ЧЫККАЧ**

Күп эшләгән шагыйрь!
Нык янган!
Ташка басып чыгарганы —
Йөзләп табак...
Дүрт томлыгы тора киштәмдә
күзне иркәләп,
җанга рух биреп.

Ә калган томнары —
төрмә, вәхшәт йотканнары —
күңелемдә йөри әрнешеп.

**КӨЗГЕ ТӨНДӘ**

Дөм караңгы тышта. Суык.
Яңгыр ява, ява...
Китап укудан күзләр дә
Ара таңга таба.
Кипеп улымның юрганын
Иплəбрәк куям.
Аннан кысып кочаклыйм аны.
Ә ул — җылы, кайнар!
Кара төндә нур иңдергән
Нинди бәхетем бар!
... Тышта серле яңгыр кызы
Тора чәчен тарап.
Ә җил аның толымнарын
Тәрәзәләргә сара!

**Ул чибәргә күз дә атмыйм —**
**Торсын чәчен тарап!**
**Ятам уйлап — улым аша**
**Киләчәккә карап.**

Боларның икесе дә бик аңлаешлы. Ләкин беренчесен мин шигырь димәс идем. Гади записка кебек. Информация бирә, күңелне кузгатмый. Сөйләм шигырьгә әверелсен өчен, аңа ассоциация кирәк. Икенче парчада без баштa ук гөлт яктыртылган төнге тын бүлмәне күрәбез, тышта үз җаена рәхәтләнеп яуган яңгырны сизмлибез... Менә көтмәгәндә — тәрәзә турысында чәчен тарап торган яңгыр кызы. Ул күңелеңне, хыялыңны уятып, терелтеп җибәрә, әсәрнең башыннан алып ахырына кадәр — буйданбуйга шигъри нур сирпелә, шигырьнең эчке дөньясы киңәеп, иркенәеп китә. Шул хәл укучыда эстетик ләззәт тудыра. Ләззәт белән сихерләнгән укучы да, шагыйрьгә кушылып, бала аша чын ихластан киләчәккә карый.

Инде остазларга мөрәҗәгать итик.

**Тышта ниләр бар икән:**
**Юллар з ә ң г ә р к а р микән!**
**Б о з т ә р ә з ә а л с у л а н а,**
**П о ж а р м и к ә н, т а ң м и к ә н!**
**Тышта ниләр бар икән!**

(Х. Туфан)

Кары зәңгәр юллар!.. Хыялда иксез-чиксез, карлы, таң алды кырлары... тынычлык, иркенлек, икәүдән-икәү генә күрешү. Дөнья да Син үзең! Нинди хозур, нинди бәхет! Ләкин чынлыкта кинәт — киресе: «Боз тәрәзә алсулана, пожар микән, таң микән?» тирән хәвефләнү. Хыялда инде дөньяның хәтәр коллизияләре, үлем-һәлакәт фаҗигаләре... Шулар арасында синең иң якын, иң кадерле кешең...

Әлбәттә, шигырьдә ассоциация тудыручы сүз төеннәре бер-бер артлы тоташ тезелеп бармый. Көтелмәгән, ләкин зиһенне кинәт сискәндереп, хисне гөлт кабызып җибәргән ассоциация үз тирәсендәге башка сүзләргә, фразаларга да тәэсир ясый, аларга тормыш нуры кертә, гади генә әйтелгән булуларына карамастан, аларда да эмоциональ хасият барлыкка китерә, аларны да шигырьгә әверелдерә. Аннан соң ассоциацияләр — градацияле. Алар арасында үз тәэсире белән бөтен шигырьне яктыртып, берләштереп һәм аның төп юнәлешен, төсмерен билгеләп тора торганнары, шулай ук төп ассоциацияне баетып, тирәнәйтеп җибәрә торганнары булырга мөмкин.

Ассоциацияләр шигырьдә, үзара бәйләнышып, бөтен бер система төзиләр дә рухи дөньяң тирәнлекләренә үтеп, аларны иңләп алалар, яктыртып җибәрәләр. Шунда алар шагыйрьнеке булудан синеке, синең үзеңнеке, чын үз әхлакый хәзинәң булып әвереләләр.

Аларның чыганагы кайда?

Хәсән ага Туфанны тыңлап карыйк. Менә ул нәрсә ди: «Әйтми калырга, язмый калырга мөмкин булмаган хисләр-фикерләр кушылмасының нинди әсәргә әвереләчәге билгеле кебек булса да, яза башлагач, бөтенләй көтелмәгәнчә үзгәрә: тирәнәя, баеый, әллә никадәр яңа табышлар өстәлә аңа. Каян килә соң бу көтелмәгән табышлар? Һәр кешенең күңелендә истә калулар рәвешендә теркәлә барган хәтер хәзинәсе — миллионнарча истәлекләрдән җыелган бай хәзинә бар. Безнең хәтер «аппаратыбыз» язылачак әсәрнең идея юнәлешен кабул итә дә, шуңа кирәк булган шигъри детальләрне эзләп, сайлап, оештырып табып бирә, күрәсең. Хәтер кузәнәкләрендәге хәзинәдә нәрсәләр барын, аларның санын, күләмен мин үзем дә белмим. Анда һәр көннең, һәр кичерешнең эзе калган бит»[1].

Шагыйрь мәсьәләне бик дөрес яктырта. Хәзерге фән, кеше мие унбиш миллиард күзәнәктән — нейроннан тора, ди. Алар сабый бала чагыбыздан алып, безнең барлык күргән, ишеткән, сизгән, тойган нәрсәләребезнең сурәтләрен — аңыбыз рөхсәте белән дә, аңардан рөхсәтсез дә — үзләрендә беркетә баралар һәм гомергә саклыйлар. Без аларны «онытабыз» гына. Ассоциацияләр шушыларга бәйләнгән. Әйтик, безнең кайсыдыр нейронда к а р сурәте, кайсысындадыр т а ң к ә сурәте ята. Аларны бер-берләренә ялгандыру беркемнең дә уена килмәгән. Элек һәркайсы бүтән нейроннар белән бәйләнып хәрәкәт иткән. Ниһаять, һ. Такташ 1926 ел ахырында «аның гыйшкы көзен

[1] Хәсән Туфан. Давыллы еллар лирикасы. Казан, 1970, 20 бит.

чәчәк атты... тәңкә карлар яуган буранда», диде. Укучыларга бу искиткеч тирән шигъри тәэсир ясады.

Академик Иван Павлов тәгълиматы буенча, ике нейронда сакланган ике төшенчәнең, ике сурәтнең беренче тапкыр бәйләнешулары — гадәттән тыш хәл икән. «Тәңкә карлар» дию белән ике тарафта гомер сөргән ике нейронның һәр икесе сискәнеп, уянып китә дә, һәрберсе икенчесенә таба дулкын җибәрә. Дулкыннар очрашып бергә кушыла, һәм шушы кушылудан хис туа, хыялда тәңкә карлар җемелдәп яуган дөнья күренеше ачылып китә. Боларның үз гомерләре эчендә бер-берләренә таба беренче башлап дулкын җибәрүләре булганга, ике араны тоташтырган юл юк. Дулкыннар ике арада яткан бүтән нейроннар катламын ера-ера, аларны да уятып, кузгатып, тәшвиш тудырып, үзләренчә гүяки бер сабан туй ясап йөгерәләр, шул «ыгы-зыгы» дан, күрәсең, үзләренчә көч-куәт җыя-җыя, өстәмә тосләр, моңнар ала-ала тәгәриләр. Шуңа күрә кушылу процессы да аерата тәэсирле, кабынып чыккан хис очкыны да аеруча нурлы була, күрәсең: ул рухка ләззәт китерә.

Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар. Әгәр ике нейрон арасында бер сызылган эздән килеп, дулкыннар еш очраша башласалар, эз сукмакка әйләнә, сукмак такырая, очрашып кушылулар автоматик тøскә керә, һәм хис очкынын тудырудан туктый, рухи ләззәт китерми башлый. Моны да И. Павлов аңлата. Без көндәлек тормышыбызда күбесенчә инде әллә кайчан шундый автоматик төстә әйтелә торган сүзләрне кулланабыз. Бу безнең акыл-зиһен аппаратыбызның гомеребез буе җыеп килгән хәзинәсен «үле капитал»га әйләндермиме, безне «фәкыйрь миллиардерлар» ясамыймы? Бу сорауларда, әлбәттә, хакыйкать бар. Нейроннарның да мөмкинлекләре унбиш миллиард белән генә чикләнми, һәр нейронның тагын унтугыз тармагы бар. Унбишне унтугызга тапкырласак, дүрт йөз миллиард чамасы бәйләнеш мөмкинлеге килеп чыгар иде. Һәр шәхес үзенә аерым бер рухи Галәм бит ул, диган сүзләрнең торган саен ешрак ишетелүе юкка гына түгелдер... Әгәр һәр шәхес шул байлыгының гомер эчендә, ичмаса, ун-унбиш процентын гына гамәлгә кертсә, үз нейроннарындагы сурәтләрне шул күләмдә генә бәйләндерә алса да, ул нинди баеп китәр иде: аның рухи космосының зәңгәр күге ачылыр, кояш, ай һәм йолдызлары балкып китәр, аңа ерак галактикаларның нур томаннары сирпелгәндәй булыр иде; аның үз кешелек кадерен белүе чиксез үсәр, үзендә чиксез көрлек, кодрәт сизәр иде ул, бәхетлерәк булыр иде...

Әмма, ни үкенеч, моңа үз көче белән генә ирешү мөмкинлеге һәркемгә дә бирелмәгән. Моның өчен махсус талант кирәк. Бу эш шагыйрь талантын һәм философ акылын сорый.

Менә шушында без шагыйрьнең тормыштагы роленә килеп чыгабыз. Бүтән кешеләрдә булган сурәтләр байлыгы аңарда да бар. Аңарда да иксез-чиксез рухи-интеллектуаль Галәм, ул галәмдә чиксез киң, чиксез катлаулы һәм өзлексез динамик хәрәкәттәге цивилизация дөньясы сурәтләре дә җыйналган. Кешеләргә әйтер сүзе тугач, аны кешеләр күңеленә илтеп җиткерү, аларныкы иттерү теләге кузгалгач, шагыйрь үз Галәменең кояшын табарга, аны каплап торган болытларны куып җибәрергә тели, бөтен рухи байлыкларын яктыртып күрергә омтыла. Ул аларга җан өрә, аларны терелтеп, үз кодрәтен арттыра. «Чыкчы, и фикрем кояшы! Китсен өстеңнән болыт, бу үлек вөҗданны җанландыр, җылың берлән җылыт!» — дигәндә Тукай, мөгаен, шушындый хәлен күздә тоткандыр. Шагыйрь әйтәчәк фикерен бизәп алырлык яңа бәйләнешләр, ассоциацияләр эзли. Уңышлы табылган беренче бәйләнеш аның иҗат көчләрен терелтеп, бәйдән ычкындырып җибәрә, беренчесе икенчесен табып кабындыра, өченчесен, дүртенчесен... Бу бәйләнешларны шагыйрь үз гомерендә беренче башлап ача бара. Аңарда сөенеч туа — иҗат сөенече. Сөенеч шагыйрьнең күңелен сафландыра бара. Шагыйрь инде рухи кояшы — идеалы белән турыдан-туры сөйләшә: «И минем яктыртучым! Тик син генә һәр җирдә шәм, нәрсә ул дөнья кояшы, син миңа нур бирмәсәң!»

Идеал кояшы тиңлегенә күтәрелгән югарылыкта иҗат процессы тәгәлләнә. Аның бөтен барышы каләм очыннан кәгазьгә төшеп, беркетелеп кала. Инде шигырьне үзлегеннән шигъри ассоциация ясый алмаган кешеләр укый. Шигырь китергән куәт аларга да шагыйрь кичергән ассоциацияләрне үз рухи хәзинәләре нигезендә үзлекләреннән яңартып кичерергә мөмкинлек бирә. Шагыйрь әсәре аларны да үзләре өчен шагыйрь итә, рухи дөньяларын баета.

Әйткәннәргә өстәп, Х. Туфаннан югарыда китерелгән өзекнең дәвамын күчереп үтәсе килә: «Иҗат — бәхет ул, иң матур, иң көчле бәхет ул! Иң бәхетле чагым — иҗади накалда яшәгән чак. Җанның, күңелнең, йөрәкнең, бәгырьнең дөрләгән, кайнаган чагы, уй һәм хиснең аера алмаслык булып кушылып, ташып торган чагы».

## II

Без ассоциацияләрнең гүзәл үрнәкләрен классикларыбызда: Тукайда, С. Рәмиевтә, Дәрдмәндтә, Такташ һәм Туфанда, М. Җәлил шигырьләрендә, шулай ук С. Хәкимдә табабыз. Бер төркем урта буын шагыйрьләр үзләренең иң яхшы әсәрләрендә шул традицияләрне дәвам иттерәләр, баеталар. Яшьләрдән Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов кебек шагыйрьләр дә яңадан-яңа ассоциацияләр ачалар.

**Шыр ялангач урман эчен**
**Күзге салкын кочып тора,**
**Ботактагы буш ояда**
**Бер уч җылы посып тора.**

Моның авторы — Гәрәй Рәхим. Хыялыңда офыгы еракка китеп югалган тирән картина тудыра бу парча. Картинадагы хасиятләрне санап әйтергә мөмкин түгел. Чөнки алар күп һәм бер-берләренә, тере тәннең әгъзалары кебек, аерылгысыз бәйләнеп беткәннәр. Шигырьдә ниндидер, тел белән аңлатып булмый, әмма күңелгә сизелә, шулай да чигенә җитеп, төбенә төгаен генә ирешеп үк бетеп булмый торган ләззәтле сер һәм тирәнлек бар. Сиңа агачлар кызганыч та, ләкин шунда ук урманны тотырып торган салкынча саф һаваны сулавы җиңел дә, рәхәт тә; кошлар китеп беткән булуы үкенеч тә, әмма, аның каравы, оя төбендә посып яткан бер уч җылы сиңа газиз дә, кадерле дә, ул синең хыялыңда ниндидер кадерле истәлекләреңне тәсмерләндерә, төгаен нинди истәлек — анысын ачып җиткерми, ләкин ул ниндидер сафлык, пөхтәлек белән бәйләнгән истәлек, аңарда ниндидер сагыну да бар, үкенеч тә сизелә.

Чын шигъри ассоциацияне ничә генә кайтып карасаң да, сиңа хозур булып тоела, ничә кайтып карасаң да, аның серен төбенә кадәр ачып бетереп булмый. Чөнки чын шигъри ассоциация күренешне хисапсыз күп бәйләнешләры килеп төйнәлгән урыннан җанлы каршылыклары белән бергә әләктереп ала, сурәт аша сине шул төен, шул бәйләнешләр алдына китереп чыгара.

Шигырьдә ассоциация күп төрле чаралар аша ачыла. Гәрәй Рәхим дә аның төрле формаларын куллана. Ул «Язгы авылдан фрагмент» шигырендә гөрләвекләр белән малайларны янәшә китереп күрсәтә: монда да хыялыңда киң офыклы зур дөнья ачыла. Бу гөрләвекләр кай елгаларда айкалып, кай диңгезләргә төшәрләр икән дә, бу малайларның гомер юллары нинди борылмалар ясар, алар нинди давыллар кичәр, зур эшләрдә баһадирлык күрсәтеп, дөньяны ниләр белән хәйранга калдырыр икән... «Тамыр» шигырендә исә автор ассоциациянең шигърият һәм мәгънә чоңгылын аллегория ярдәмендә ача. Әлбәттә, шагыйрь кулланган чараларны исәпкә-санга алырга мөмкин түгел. Тик әйтәсе килә: шундый әйбәт шигырьләр язган Гәрәй Рәхим кайчакта, минем уемча, өлгермәгән нәрсәләр бастырып чыгара. Мәсәлән, «Нәни өйдә нәни җыр» («Зирек бөдрәләре», 64 бит). Зур алмашынулар, зур хәрәкәтләр заманында үзенең кечкенә алачыгында масаеп утырган кеше укучыда зур тойгы кузгата алырмы икән? «Нәни шаяру» булып кына калмасмы бу? Автор исә «җырын» җитди дип тәкъдим итә. Киләчәктә шагыйрь болай эшләмәсен иде.

Роберт Әхмәтҗановтан бер парча китерик:

**Кама өсләрендә күк күкрәде,**
**Сөю антын җиргә биргәндәй.**
**Агачларны җилләр барлап йөрде,**
**Исәннәрме бар да дигәндәй.**

**Агачларны җилләр барлап йөрде,**
**Мин барладым сине йөрәктә.**
**Ах, бу чакны җылы кулларыңның**
**Кирәклеген тойдым бигрәк тә.**

**Бу якларда җилләр — сагыну җыры,**
**Исмәс иде сиңа кирәктә...**
**Кама өсләрендә яшен яшьни,**
**Күкрәүләре — минем йөрәктә.**

Күкрәүләрдә — күкнең җиргә биргән ант көче... Күңелдә ләззәтле билгесезлек тойгысы уяна. Кешенең рухи күкрәүләре яшеннәр белән бәйләнышып китә — кеше сурәте хыялда гадәттән тыш зурая, һәм ул инде безнең күңелдә бая туып өлгергән тойгыларны да үстереп җибәрә, тирәнәйтә, шигъри халәт тудыра. Шуның белән бу парча үзенең эстетик вазифасын үти. Шагыйрь үзенең яңа циклында («Казан утлары», 1977, 4 сан) мондый ассоциацияләрдән читләшкән кебек тоела, киресенчә, аларны үстерәсе, камилләштерәсе булмады микән?

Язучы Сергей Антонов ассоциатив сурәтнең туганда ук идея ягыннан юнәлешле булып тууын әйтә. «Юнәлешле ассоциациядән башка сәнгатьчә сурәтле фикерләүне күз алдына китерү мөмкин дә түгел»[1], — ди ул. Шулай булуы табигый да, чөнки кеше рухының ерак тирәнлекләрендә барган кичерешләр, хисләр хәрәкәтен, алардагы серләрне, сурәтле фикерләүдән торган философияне ассоциация дә ачмаса, тагын нәрсә ача алыр? Ассоциация ул — рухи серләрнең, психология чынлыгының ачкычы. Фальшь катнашса, шигъри ассоциация оеша да, ясала да алмый. Аның өчен самимилек — үтә дә ихласлык кирәк: бу — аның җаны.

Үткән ел Зөлфәтнең «Яңа шигырьләр»е басылып чыкты («Казан утлары», 1977, 2 сан).

**И җыр гынам! Сөйгән җырлар!**
**Бирсен язмыш сезгә мең гомер...**
**Җыр бар, димәк, җан бар! Һәр моңлы җыр —**
**Юлаучыдан калган бер күмер,**
**Елтыр-елтыр янган бер гомер...**

Яхшы шигырь. Тик «юлаучы» сүзе генә эчне пошыра. Юлаучы бит ул юлдагы кешегә болай гына туры килеп, ияреп, янәшә атлап кына киткән кеше, чын юлчы түгел, аңардан учак калуы шикле, һәрхәлдә, мәгънәле түгел.

Әсәрдә киткән бер эстетик хата гына да укучыда шактый кәефсезлек тудырырга мөмкин. Иҗат иясе моны исеннән чыгармаска тиеш. Зөлфәт моң ярата. Сүз аша шигырьгә кергән күңел моңы күп очракта әйтеп бетерелмәгән философик фикер рәвешен ала, шигырьне сабыр агымлы итә һәм бу агымда вакыт-вакыт көрсенү дә сизелеп калган кебек була. Зөлфәт моңы әнә шундый түгел микән? Аның Ә. Еникигә багышлап язылган «Кайчан сәфәр?» шигыренә игътибар итик. Дөньяга кеше туа:

**Кеше дигән чатны кабынганда,**
**Балкып киткән чакта серле эңгер,**
**Ишетеләдер сорау: «Кайчан сәфәр!**
**Көтеп тора сине озын гомер!»**

Кешенең үз гомерендә барасы юллары ерак, менәсе биеклекләре әллә кайларда, аны дөнья ашыктыра. Ләкин менә тагын бер мизгел — яшен яшьнәп сүнә, йолдыз ата. Нәрсә кала кешедән! Шагыйрьнең җавабы бар: ул дөньяда җан җылысын калдыра. Хезмәте кала... Көрсенүле моңнан оптимистик нәтиҗә ясала. Бу төсмерле моң Зөлфәтнең стиль үзенчәлеген тәшкил итә булса кирәк. Дөрес, аның икенче ягы да булырга тиеш. Югыйсә, басынкы моң барлык шигырьләрдә дә тоташ сузылып барса, сүрәнлек сыйфатын алу ихтималы бар. Аның уйнаган, көлгән, ярсыган чаклары да булырга тиеш. Өлкән остазларда — Такташта, Туфанда, Җәлилдә, Хәкимдә — чыннан да ул шундый: бер ярсый, бер — булганына канәгать итә, бер хәсрәт кичерә, бер көлә, шатлана, бер нәфрәтләнә, бер сөя. Аларның шигъри җаннары туктаусыз ялкынлы, эштә, каршылыклар белән өзлексез һәм динамик көрәштә. Шуңа күрә аларда шигъри моңның интонациясе тембрларга хисапсыз бай. Зөлфәт исә әлеге шигырендә «Кайчан сәфәр?» рефренен соңгы тапкыр китерә дә, «Балкыдык та сүндек... язмышлар бер...» ди. Бу шигырьне язган чагында үз күңелендә асраган затның сурәтенә, аның үзенә шагыйрь моның белән нинди сәфәр юрый? — бусы да әйтеп бетерелмәгән, көрсенүгә урын калдырган... Зөлфәттә яңа идеяләр, әле гамәлгә кертелмәгән сурәтләр байлыгы барлыгын без бик ачык сизәбез. Алар ачылыр әле.

[1] Сергей Антонов. Слово. «Сов. Россия», Москва, 1974, стр. 119.

И. Нуруллин болай яза: «Безнең поэзияне берара сугышка каршы көрәш темасы басып китте. Принципта бу начар түгел. Әмма шунысы сәер: андый шигырьләрне күбрәк үзе сугыш ялкынында көеп чыккан шагыйрьләр түгел, бәлки сугыштан соң туганнар яза иде. Димәк, бу буын шагыйрьләренең (барысының да димим) үз заманы, үз чордашлары турында әйтер сүзләре җитенкерәмәгән».

И. Нуруллин биредә үз фикерен ачык өздереп әйтмәгән. **Беренчедән,** сугыш турында язу бар һәм сугышка каршы язу бар. Сугышның үзе турында язганда, әлбәттә, сугыш вакыйгаларын авторның үзе күреп белүе яхшырак. Ләкин бу һәр очракта да мәҗбүри түгелдер. Полтава сугышы, мәгълүм ки, 1709 елда булган, А. Пушкин «Полтава» әсәрен 1828 елда язган. Пушкин үз гомерендә гомумән бернинди дә сугышта катнашмаган, хәрби хезмәттә дә булмаган. Шулай да «Полтава» аның даһи әсәрләреннән санала.

Эш Нуруллин әйткәнчә барса, хәзерге яшь буын һәм киләчәк буыннар арасыннан чыгачак язучылар Бөек Ватан сугышы турында әсәр язмаска тиеш булырлар иде. Әмма ышанып әйтергә мөмкин, Бөек Ватан сугышы турында бер-ике буын язучылары гына түгел, әле күпләр зур-зур әсәрләр иҗат итәр. Монда мәсьәләне иҗат иясенең талант көче һәм гомуми культура югарылыгы хәл итә. **Икенчедән,** сугышка каршы көрәш темасын яктырту өчен әдипнең сугышта катнашкан булуы мәҗбүри түгел. Монда каләм иясенең чын иманлы гуманист булуы кирәк. Сугышта катнашкан шагыйрьләрне алсак, алар иҗатының үзәген нәкъ менә шул социалистик гуманизм хисләре нурландырып торды да инде. Муса Җәлил үзе генә дә моның бөек дәлиле. Җентекли башлагач, Сибгат Хәкимнең 1942 елда фронтта язган «Фронтовик» шигыре искә төшә:

**Фронтовик кайта шәһәргә,**<br>
**Кулында ярасы бар...**

Сөйгәне белән очрашулар. Ике арада аз гына сүзләр белән шундый татлы, шундый бер-берсен яратып сөйләшүләр... Егетнең ярасы инде төзәлгән. Яңадан фронтка китеп бара, ләкин инде «Йөрәге читендә аның мәхәббәт ярасы бар». Әмма бу татлы яра, бәхет ярасы, сугыш җәһәннәме эчендә дә егет күңеленең кешелегенә куәт биреп, изге мәгънә өстәп торачак яра. Без, совет кешеләре, фашист ерткычларга каршы кешелек кадере өчен сугыштык. Сугышта варварлык белән гуманизм бәрелеште. Гуманизм ниндидер томанлы ераклыклардагы серле хыяллар түгел иде безнең өчен, ул һәр солдатның, һәр офицер һәм генералның күңел тирәнлегеннән балкып килә торган кодрәт көче, социалистик гуманизм, социалистик патриотизм көче иде.

Сугышка каршы шигырьләр бүген бөтен дөньяга ишетелерлек чаң булып, аеруча көчле яңгырарга тиешләр түгелме соң? Бу — чорыбызның кискен һәм беренче планда торган таләбе. Сугыштан соң туган шагыйрьләрнең бу темага мөрәҗәгать итүе аларның үз кордашлары турында әйтер сүзләре булмаудан дип санау үзе әллә ничек. Шуңа күрә дә мин Нуруллинның югарыда китерелгән фикерләре уңае белән, **өченчедән,** дип әйтер идем: сугышка каршы темага талантының иң тирәннән килгән куәтен багышлап, соң дәрәҗәдә балкып янган илһам көче белән нәкъ менә яшь шагыйрьләр язарга тиеш. Чөнки туган илне саклау бүген алар кулына тапшырылган. Җирдә тынычлык өчен көрәш сакал күтәргән бабайлардан алып, бүген туган сабыйларга кадәр — һәммәсе өчен чиксез әһәмиятле. Бу — патриотизм темасының конкрет бер өлеше һәм бөтен кешелек язмышына кагылган интернациональ тема. Партиябез һәм хөкүмәтебезнең, Леонид Ильич Брежневның тынычлык өчен көрәшкә чакыру сүзләре һәм аны дөнья халыкларының күтәреп алуы — болар бездә чиксез горурлык тудырмыйлармыни? Шушы хисләр тавышы бөтен дөньяга ишетелерлек әсәрләр иҗат итү өчен шагыйрьләргә илһам чыганагы булырга тиеш!

Безнең яшьләр алай ук ваемсыз түгел. Әйтик, М. Әгъләмов «сугыштан соң туган» яшьләрнең бер вәкиле. Узган ел аның «Бердәнбер кыз турында» балладасы басылып чыкты. («Казан утлары», 1977, 4 сан.) Бу әсәр ихлас күңел, тирән дулкынлану һәм зур осталык белән язылган:

**Ә аның шикелле, илемдә**<br>
**Меңләгән хатыннар үлгәндер...**

Онытма, кешелек! Ул минем
Әнием иде бит — бердәнбер.

Бу юллар шигырьдә тасвир ителгән вакыйганың мәгънәсен кинәт зур югарылыкка күтәреп, безнең бүгенге көнебез белән бәйләп куялар. Безнең социалистик Ватаныбызны, кешелекнең бөтен культурасын фашизм китергән һәлакәттән менә шушындый, һәрберсе үтә дә газиз һәм бердәнбер булган миллионнарча совет ирләре һәм кызлары коткарып калды. Кешелек аларга бурычлы! Аларның һәрберсе, социалистик гуманизм ноктасыннан караганда, мәңгелек яшәешнең иң бөек казанышы, һәрберсе үзенә аерым бердәнбер һәм бәяләп бетергесез кыйммәт иясе — кеше иде.

### IV

Соңгы елларда хәзерге фән белән сәнгать арасындагы мөнәсәбәтләр турында күп кенә сүзләр булды. «Лириклар, физиклар» турында байтак язылды. Шуңа бәйләнешле төстә акыл белән хисне бер-берсенә каршы куярга маташу да сизелеп кала. Мондый нәрсәләр, әлбәттә, файдага түгел. Бу турыда СССРның очучы космонавты Виталий Севастьянов фикерләрен искә төшерү урынлы булыр. Ул гаҗизлектән үртәләнгән кайбер гуманитарийларның фәнгә көнчелек белән сагаеп карауларын һәм, киресенчә, икенче яктагы кайберәүләрнең сәнгатьтән көнләшүен рухи фәкыйрьлек дип саный. Герой космонавт фән белән сәнгатьнең бердәмлеген яклый: «Бергә алынган сәнгать һәм фәннән башка цивилизацияне тагын нәрсә тәшкил итә соң? Алар — кеше иҗади эшчәнлегенең төрле формалары гына... Пушкин белән Лобачевскийның охшашлыгы, минем уйлавымча, аларның үз иҗатларында тормышның баш законы — гармонияне гәүдәләндерергә омтылуларында»[1]. Сәнгатьнең асыл үзенчәлеген тәшкил иткән сыйфатларны фән юкка чыгармый, үзгәртми. Үз эчке бөтенлекләрен саклауда һәм үстерүдә алар мөстәкыйль. Бу инде ачык мәсьәлә.

Сәнгатьнең, әдәбиятның үз фәне бар. Аның шигырь турындагы өлешенә игътибар итик.

Р. Фәйзуллин: «Нигәдер бездә шигырьне, анатомия театрындагы шикелле, кисәкләп аңларга һәм аңлатырга яраталар»,— ди. Шигырьнең төзелешен тикшергән чакта, табигый, аны буын-буын сүтеп тикшерергә, төзелешнең эчке хасиятләренә керергә кирәк була. Фәйзуллин фәнни тикшеренүдәге шул эшне күздә тота. Безнең татар әдәбияты әһелләре арасында фәнни эшне, фәнни анализ алымнарын, кызганычка каршы, шулай патриархальчә гадиләштереп аңлаучы кайберәүләр очрап куя. Бер җае чыккач, «кисәкләп аңлату»ның нәрсә икәнен төшендереп үтәргә кирәк. Бу турыдагы мәгълүматлар журналны укучылар өчен дә файдалы булырга мөмкин.

Үз заманында Н. В. Гоголь болай дип язган: «Пушкин аңа (Жуковскийга.— Х. Г.) тәнкыйть язмый дип, бик каты ачулана иде. Пушкин фикеренчә, нинди генә матур әдәбият әсәре булмасын, аны Жуковскийдан бүтән һичкем шундый шәп ачып ташлап һәм бәяләп бирә алмый иде»[2]. Ачып ташлап — русчада «разъять» диелгән. Әдәби әсәргә анализ ясар өчен, аны «телгәләп», «сүтеп ташлау»ны Пушкин әнә шулай, анатомия театрында кеше гәүдәсен операция чаралары ярдәмендә ачып ташлауга тиңләгән.

Р. Фәйзуллин икенче урында шушы ук мәсьәлә турында язганда югарыда китерелгән сүзләреннән соң «Бу хәзер нормага әйләнде кебек» дип, үзенчә ирония дә ясап ала.

В. И. Ленинның 1914—15 нче елларда язылган «Философия дәфтәрләре»нә күз салыйк. Анда болай диелгән: «Без, өзлексезне өзмичә торып, (аны) гадигә әйләндермәстән, тупаслandырмастан, бүлгәләмәстән, терене үле хәлгә китермәстән, хәрәкәтне күзаллый да, гәүдәләндерә дә, үлчи дә һәм рәсемли дә алмыйбыз»[3]. Диалектиканың асылы шунда, ди В. И. Ленин. Мәсьәлә аңлашылса кирәк, тәфсилләп тормыйк.

Шигырь бер бөтен. Аның ничек төзелгәнен, эчке законнары ничек хәрәкәт иткәнен белер өчен аны, состав өлешләренә бүлгәләп, анатомияләргә кирәк. Эчке өлешләрен таныгач, бу өлешләрнең үзара ничек бәйләнышуларын белгәч, шуның нәтиҗәсендә бер бөтенгә әверелү, яңа сыйфат китереп чыгару закончалыкларын ачарга

[1] «Литературная газета», 1977 ел, 25 май.
[2] «Вопросы литературы», 1977, № 7, стр. 139.
[3] В. И. Ленин. ПСС. Том 29, стр. 233.

мөмкин. Фәннең сыналган чарасы шундый. «Тәнкыйтьче шагыйрьне ничек язарга өйрәтә алуына шикләнәм мин»,— ди Р. Фәйзуллин. Әйдә шикләнсен. Бу аның тарафыннан тик үзен генә күздә тотып әйтелгән, шуңа күрә тар фикер, дип уйлыйк. Тәнкыйтьнең, әдәбият фәненең әдипләрне, шагыйрьләрне өйрәтү-өйрәтмәве турындагы мәсьәләне аерым бер әдипкә бәйләп түгел, бәлки тулаем әдәбиятның процессына, процессның да табигый хәрәкәтенә бәйләп яктыртырга кирәк. Әйтик, татар поэзиясе процессының бүгенге көнен алсак, монда бер Фәйзуллин гына түгел, аның талантлы кордашлары, аңардан күп элек килгән Х. Туфан, С. Хәким кебекләр һәм әдәбият мәйданына яңа гына чыккан яки чыгып килә торган яшьләр бар. Юк, Р. Фәйзуллин хаклы түгел, югары зәвыклы, принципиаль тәнкыйть, әдәбият фәне шагыйрьне шигырь язарга өйрәтүдә катнаша.

Шигырьне гармониягә әверелдергән зур компонентларның берсе, мәсәлән,— ритмик төзелеш. Һәр халыкта ул күп мең еллар элек яралып, акрын-акрын үсә килгән, камилләшкән. Шигырьгә, җырга карата гына түгел, тел закончалыкларына карата да бу шулай: укый-яза белмәгән, грамматика кагыйдәләре турында гомерләрендә бер тапкыр да ишетмәгән картлар, карчыклар нинди искиткеч оста тел белән әкият сөйлиләр. Шул сөйләмне грамматика кагыйдәләре нигезендә анализлап карасаң, искиткеч төгәллек, төзеклек күрәсең. Элек халык шулай ук нота гыйлемен дә белмәгән, ләкин нинди матур көйләр чыгарган. Болар һәммәсе дә закончалыкларны җанлы һәм бөтенлекле хәрәкәт хәлендә отып алып куллану, эмоциональ хәтердә саклау аркасында мөмкин булган. Ләкин цивилизация бөтен нәрсәне катлауландыра, үстереп җибәрә, аерым-аерым яшәгән төрдәш күренешләрне бергә төйнәп, катлаулы яңа бербөтенлекләр хасил итә. Монда инде эмоциональ хәтер белеме үзе генә җитми. Аны фән көче белән коралландырырга кирәк була. Симфонияләр, опералар язам дисәң, музыканың эчке һәм катлаулы закончалыклары хәрәкәтен өйрәнү, алар белән идарә итә белү мәҗбүри. Закончалыклар исә бик озын гомерле алар — гасырлардан-гасырларга үтеп, мускул ныгыткannar, көчләүгә бирешми торган булганнар. Үзләре үк тудырган яңа бәбчекләренә таянып эш итмәсәң, киреләнәләр, каты тотына башласаң, корылма конструкцияләрне аһәңнән мәхрүм итәләр. Алтмышынчы еллар башланганда яшь шагыйрьләр татар шигыре өчен яңа ритмик принциплар эшләп чыгарырга керешеп карады. Тәҗрибәләр аларны барыбер шигырьнең тотрыклы төп закончалыклары юлына кайтарды һәм кайтара.

Р. Фәйзуллин белән И. Нуруллин әңгәмәсендә әдәби мирас турында да фикерләр бар. Фәйзуллин безнең Бөек Ватан сугышына кадәрге поэзиябезне, ничектер, түбәнәйтеп бәяли. Бигрәк тә Такташның иҗатын кечерәйтергә омтылу сизелә. «Такташ татарча гына яңгырый», ди ул. Юк, Такташ иҗаты милли рамкаларда гына чикләнеп калмады. Аның иҗаты, тәрҗемә итмәстән дә, үз оригиналында үзбәк, казакъ, башкорт, чуваш кебек халыкларның поэзиясенә тирән тәэсир ясады. 1945 елны гоминданчылар тарафыннан җәзалап үтерелгән уйгур шагыйре Лотфулла Моталлип үзен Такташ шәкерте дип санаган, дошманга каршы көрәшендә, иҗатында Такташ поэзиясеннән рух алган. Әсәрләре русчага тәрҗемә ителмәвендә Такташ үзе гаепле түгел. Төп сәбәп бәлки аның әсәрләрен тәрҗемә иттерүне безнең әле тиешенчә оештыра алмавыбызга да кайтып кала торгандыр. «70 нче еллардагы халыклар арасында рухи бәйләныш Такташ иҗат иткән 30 нчы еллардагыга караганда нык аерыла. Коммуникация һәм информация чаралары үсә барган саен, Җир-планета кечерәеп калгандай булды», ди Р. Фәйзуллин. Зур язучы иҗатын аның заманындагы коммуникация чараларының торышы белән генә бәяләп булмый, әлбәттә. Алайга китсә, А. Пушкин, Л. Толстой, В. Шекспир кебек даһиларның иҗат дәрәҗәсен безнең заман коммуникация чаралары ноктасыннан яңа баштан бәяләп чыгарырга кирәк булыр иде һәм бу һич тә акыллы эш булмас. Язучы иҗаты, мәгълүм ки, аның үз чоры иҗтимагый тормышын, үз чоры кешесен нинди тирән һәм сәнгатьчә осталык белән тасвирлавы, бу тасвирның прогрессив идеаллар өчен көрәштә нинди ярдәм күрсәтүе белән билгеләнә.

Такташ партия һәм халык белән бергә коммунистик идеаллар өчен көрәшкә керде, шуларны тормышка ашыруда аның иҗаты иң алдынгы сафта булды, ул бөтен халык белән бергәләп социалистик җәмгыятьнең нигезен салышты. Инде ярты гасыр

диярлек вакыт үткән. Совет халкы дигән тоташ яңа гомумилек туды. Такташ шушы җиңүләрнең киләчәген белеп, алар өчен үз талантының барлык куәтен багышлап, ярсып эшләгән шагыйрь. Аның иҗатында шул чордагы халык массаларының рухи омтылышы, көчле ашкынуы гәүдәләнгән. Без «Гасырлар һәм минутлар», «Мокамай», «Киләчәккә хатлар» кебек әсәрләрдә бөтен искелек дөньясын тетрәткән, социалистик җәмгыятьнең нигезен салган киң күкрәкле халыкның баһадирларча сулышын тоябыз; «Урман кызы», «Мәхәббәт тәүбәсе», «Алсу» кебек әсәрләрдә коммунистик хакыйкатьне үзенең иманы итеп алган шул ук халыкның мөлаем табигатен, көчле нечкәлеген, әхлакый пакьлеген күрәбез. Болар һәммәсе чын мәгънәсендә классик шигъри осталык белән иҗат ителгәннәр.

Социалистик җәмгыятебез яңа биеклекләргә күтәрелде. Безнең уңышларда Такташның да өлеше зур. Аның әсәрләре бүген дә үзләренең тулы эстетик гүзәллекләре белән кеше күңеленә байлык бирә, сөенеч, ләззәт китерә. Хәлбуки, Р. Фәйзуллин: «Такташ иҗаты бүгенге һәр яшь шагыйрь өчен әйдәүче үрнәк көчме?» ди дә, «түгел» дигән мәгънәдә язып китә. Биредә автор ике нәрсәне аерып әйтергә тиеш иде. Әйдәүче көч — ул идеал, коммунистик иҗтимагый идеал. Ул аерым шәхес хөкемендәге, аның хуҗалыгындагы нәрсә түгел. Ул миллионнарча халык массалары алып барган прогрессив, революцион көрәшләр нәтиҗәсендә туган иң бөек максат. Такташка килсәк, ул коммунистик идеал өчен көрәш матурлыгын килер буыннар өчен дә үрнәк булырдай шигъри образларда беркетеп калдырды. Такташ юк инде. Ләкин аны иҗатка әйдәгән идеал яши, киләчәк өчен көрәшкә кешелекнең яңаданяңа көчләрен күтәрә бара, күтәрә бара. Бүгенге яшь шагыйрь өчен дә, урта яшьләрдәгесе, карты өчен дә әйдәүче көч әнә шул. Шушы әйдәүче көч кодрәтен сәнгать көченә әверелдерүдә Такташ поэзиясе — үрнәк, бу — шигърият мәктәбе. Моны күздән төшерергә тырышу беркемгә дә файда китермәс.

Бездә аерым китап булып та, газета-журналларда да шигырьләр күп басыла. Җанны куандырган әсәрләр дә булмый калмый. Шулай да зәгыйфь әсәрләр байтак. Иң элек тематик яктан бертөслелек зур булуын әйтергә кирәк. Адым саен диярлек көнкүреш вaклыкларын шигъриләштерергә тырышу, теге яки бу кош-кортка карап моңаюның әле бу, әле теге шагыйрьгә күчеп йөрүе, камыштан курай ясап, курай сызгырту белән мавыгулар, тагын шуның шикелле, безнең революциягә кадәрге поэзиябездә үк инде булып үткән әйберләрне ваклап кабатлаулар — болар барысы да шигърият өчен артык йөк төсен ала.

Әсәрләрнең беришесе, үтелгән эш турында язма хисап биргән шикелле, булган хәлләрне бернинди җанлы сурәтсез, шигъри аһәңсез һәм ваемсыз интонация белән рифмага салып сөйләп чыгудан тора. Шигъри үлчәмнәр дә канәгатьсезлек тудыра. Берара, шигырьләрнең яңа формасын чыгарабыз дип, шигырь үлчәмнәре сүтеп ташланган иде. Парадоксаль нәтиҗә килеп чыкты: беркадәр тәҗрибәдән соң шагыйрьләр иң борынгы төрки язма шигыренең 12 ле, 7 ле үлчәмнәренә кайтып төштеләр. Берәүләре 12 ле нигезендә ак шигырь эшләделәр. Уңышлылары да булды. Әмма җиделек артык озынга сузылды: шигырь китабының кайсы битен ачма, шул җиделек килеп чыга да күңелне төшерә. Чөнки бу үлчәм — асылда такмак үлчәме, аның интонация мөмкинлекләре тар һәм чикле, озынга сузылса, бер яңгырашлыга — монотонлыкка әверелеп китә. Ул, күрәсең, кыска күләмле әсәрләрдә генә матур ишетеләдер. Өлкән шагыйрьләребездән Һ. Такташ, Н. Исәнбәт, Х. Туфан, алардан соң килгән Әхмәт Фәйзи, Сибгат Хәким — һәрберсе, татар шигыренең борын-борыннан эшләнеп килгән казанышлары нигезендә, төрки халыклар поэзиясендә гомумән күренмәгән яңа-яңа форма өлгеләре иҗат иттеләр. Хәзерге шагыйрьләр агаларыннан калган бу мәктәпнең эшчәнлеген нигә дип үстермәскә тиешләр?

Шигырь гармония дидек. Ассоциация нәтиҗәсендә хыялыңда бөтен бер дөнья булып туган картина үзе белән сиңа нииндидер шигъри музыка да алып килә, рухи дөньяңны гүзәл авазлар белән тутыра. Ассоциатив сүз, ритм, интонация һәм адәм күзе, колагы аерып җиткерә алмаган, ләкин күңел, хис зирәклеге тоя ала торган тагын нииндидер бүтән бик күп әрсез эстетик зәррәләр — болар барысы бербөтенгә, шигырьгә әверелеп, синең рухыңа моңлы һәм интим мәгънәләр сөйли. Шигырь төзелеше — шул күп санлы «әрсезләрнең» берсе. Әгәр ул үзенең көен югалтса, кыллары бушаган сазга әверелеп кала. Безнең классиклар — Тукай, Дәрдмәнд,

Сәгыйть Рәмиев, Һ. Такташ, Х. Туфан кебек осталар, сазның кылларын тиешле сизгерлектә тотар өчен күп төрле өстәмә чаралар кулланалар: аллитерацияләр, ассонанслар, анафоралар, эпифоралар, градацияләр, ялгаулар, рефреннәр, тагын бик күп бүтән чараларны эшкә җигәләр. Алар шигырен укыганда син үзеңне май аеның кояшлы көнендә, шау чәчәк тулы болын уртасыннан баргандай тоясың, алдыңда — киң дөнья, баш өстеңдә — югарыда чиксез зәңгәр күк, һавада миллион һәм миллионнарча бал кортлары, шөпшәләр, канатлы бөҗәкләрнең, кошларның тагын әллә никадәр нәни мәхлукатнең музыкасы белән тулган моң диңгезе...

Кайбер урта буын һәм яшь шагыйрьләрнең әсәрләрен укыганда әнә шул моң ишетелми. Бу бәлки үткәннән калган шигъри мирас байлыкларына игътибар кимүдәндер? Монда уйланырга урын бар.

Поэзиябез турындагы уйланулар, Р. Фәйзуллин белән И. Нуруллинның өңгәмәсе уңае белән туган фикерләр моның белән генә чикләнми, әлбәттә. Әмма мин хәзергә шушында нокта куеп торырга булам. Башкалар фикерен тыңлыйк.

### РЕДАКЦИЯДӘН

**Хөрмәтле укучы!**

**Поэзиябезнең актуаль мәсьәләләре һәм үсеш тенденцияләре турында сөйләшүне күздә тотып, журналыбыз сәхифәләрендә ачылган яңа рубрикада сезнең игътибарга бүген икенче материал тәкъдим ителде. Шактый күләмле булуларына да карамастан, мөгаен, аларның һәр икесе белән танышып чыккансыздыр. (Беренче материал журналның 3 нче санында басылды.) Сөйләшүне башлап җибәрергә җөрьәт иткән авторларның кайбер тезислары сезне уйлануларга да этәрергә мөмкин, бәхәсле фикерләрнең дә булуы ихтимал. Чөнки поэзия кебек киң колачлы, нәфис һәм гармонияле жанрга, шигырьгә һәм җырга без төрле критерийлардан чыгып якын киләбез, һәркемнең үз таләбе бар, эстетик зәвыкларыбызда да аерымлыклар булмый калмас. Бер үк шигъри әсәрне ике укучының абсолют бер төрле кабул итүе шикле булган кебек, яраткан шагыйрьләребезнең дә бер үк исемнәр булмавы бик мөмкин. Шуны истә тотып, редакция әлеге сөйләшүдә мөмкин кадәр күбрәк авторларның, тәнкыйтьче һәм шагыйрьләрнең генә түгел, киң масса поэзия сөючеләрнең дә үзләрен борчыган мәсьәләләр буенча чыгыш ясавын планлаштыра. Аерым алганда, укучыларыбызның түбәндә тәкъдим ителгән сорауларга җавабы һәм шул юнәлештәге уйланулары да билгеле бер дәрәҗәдә кызыксыну уятыр һәм фикер алышуның практик әһәмиятен үстерә төшәр иде:**

**— Дөнья һәм туган илебез әдәбиятларыннан кайсы шагыйрьләрне яратып укыйсыз?**

**— Поэзиябез тарихыннан сезнең өчен аеруча кемнәр якын?**

**— Бүгенге татар поэзиясе үрнәкләрен нинди чыганаклардан укыйсыз (китап, журнал, альманах, газета һ. б.)?**

**— Замандаш шагыйрьләребездән (мөмкин булса, өлкән, урта буын һәм яшьләрдән аерым-аерым) кемнәрнең иҗатын һәм нинди сыйфатлары өчен үз итәсез?**

**— Бүгенге татар поэзиясенә, сезнеңчә, нинди кимчелекләр хас?**

**— Агымдагы тәнкыйть (поэзия тәнкыйте) белән танышып барасызмы, һәм ул сезне ни дәрәҗәдә канәгатьләндерә?**

**Сорауларны, әлбәттә, әле байтак дәвам итәргә мөмкин булыр иде. Ләкин шул кадәргесе ачык булса кирәк, безне, барыннан да элек, 70 нче еллар татар укучысының поэзиягә мөнәсәбәте, аның көндәлек һәм рухи тормышында бу жанрның нинди роль уйнавы кызыксындыра.**

**Сорауларга җавап, аерым уйланулар һәм фикерләрне түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2. Дом прессы, «Казан утлары», отдел критики.**

**Фикер алышуга өлеш керткән укучыларга редакция алдан ук үзенең рәхмәтен белдерә.**

# ТУКАЙ ТОМНАРЫН УКЫГАНДА

„Тукай — һәр буын тарафыннан тигез хөрмәт ителәчәк шагыйрь. Ул сине туган көнеңнән алып гомереңнең ахырына чаклы озата килә. Гомер эчендә син аңа әллә ничә тапкыр мөрәҗәгать итәсең. Сабый вакытта күңелеңә синең «Су анасы» шом сала, төштә «Шүрәле»се кытыклап теңкәңә тия. Иртәдән инде «Туган тел»ен көйләп уянасың. Юк, укымыйсың, көйлисең»,— дип яза Сибгат Хәким шагыйрьнең яңа дүрт томлыгына кереш сүзендә [1].

Шагыйрь күңелен шагыйрь яхшы аңлый. Тукай шигырьләре чыннан да җырлап торалар. Аларның байтагын укып кына аңлап булмый кебек. Җырларга, көйләргә яки җырлаучыны тыңларга кирәк. Шул чакта гына Тукай шигырьләренең гүзәллеген тоеп була:

**Нәкъ Казан артында бардыр бер авыл —**
**Кырлай диләр,**
**Җырлаганда көй өчен «тавыклары җырлай» диләр.**
**Гәрчә анда тугъмасам да, мин бераз торган идем;**
**Җирне әз-мәз тырмалап, чәчкән идем, урган идем...**

«Гөлҗамал», «Иске кара урман», «Син сазыңны уйнадың»
кебек көйгә салынган әсәрләр дә шул хакта сөйли.

Үз гомере дәвамында һәркем Тукай белән кат-кат очраша. Бу ниндидер бер серле ихтыяҗ. Олы һәм мәңге яшь шагыйрьгә багышланган һәрбер яңа сүз, аның әсәрләрен үз эченә алган һәрбер китап зур кызыксыну уята.

Каршыбызда Тукайның яңа томнары. 4 китап. Бу басма Тукайның тормышы һәм иҗатын өйрәнүгә нинди яңалык алып килә? Аның әдәби-иҗтимагый әһәмияте нидән гыйбарәт?

Шагыйрьнең иҗади эшчәнлеге 1904—1905 елларда башланып, 1913 елга кадәр дәвам итә. Нибары тулар-тулмас 10 ел. Шул вакыт эчендә ул никадәр гүзәл шигырь-поэмалар, мәсәл, фельетон, очерк һәм мәкаләләр язып өлгергән! Әдәбиятның нинди жанрларында гына эшләми ул! Дүрт томлыкны кулга алгач та, шагыйрь иҗатына хас киң диапазон, форма төрлелеге, бай эрудиция сокландыра.

Тукайдан соң 65 ел вакыт үтте. Бу — бер буын гомере. Шул вакыт эчендә ил һәм халык тормышында искиткеч зур вакыйгалар булып узды: җир шарын тетрәткән социалистик революция, гражданнар сугышы; яңа тормыш өчен кырыс көрәш; Бөек Ватан сугышы; коммунизм таңында космоска һөҗүм... Башка тугандаш халыклар белән бергә, татар халкының да көнкүреше, тормышы тамырдан үзгәрде. Культура, әдәбият һәм сәнгатебез моңа кадәр күрелмәгән киңлекләр һәм биеклекләр яулады. Татар әдәбияты яңа шигырьләр, поэмалар, Тукай заманында тик бөреләнә генә башлаган повесть һәм романнар хисабына баеды. Хәзер ул бөтенләй яңа — Бөек Октябрь кояшы астында формалашкан социалистик реализм юлыннан үсә. Ел саен йөзләрчә китап, шигырь-поэмалар чыга, романнар языла. Әдәбият һаман үсә. Тукай һәм аның шигърияте дә торган саен матуррак, яктырак балкый. Һәр буын аны

---

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр, дүрт томда. I том. Редколлегия: А. Әхмәдуллин, С. Хәким, М. Шабаев, Г. Халит, Р. Гайнанов. Гали Халит редакциясендә. Томны төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Р. Гайнанов. Нәшрият редакторы — Р. Даутов. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975; 2 том, 1976; 3 том, 1976; 4 том, 1977. Алга таба җәяләр эчендә том һәм битләр генә күрсәтеләчәк.

үзенчә кабул итә, тирәнрәк аңлый бара. Шагыйрьнең яңа дүрт томлыгы белән танышкач, без моңа тагы бер тапкыр инанабыз.

Тукай әсәрләреннән торган беренче дүрт томлык 1955—1956 елларда басылып чыккан иде. Бу басма әлегә кадәр үзенең әдәби һәм фәнни әһәмиятен югалтканы юк. Тукай иҗатын өйрәнү өчен ул әле хәзер дә җитди чыганакларның берсе булып тора. Чөнки ул мөһим фәнни принциплар нигезендә төзелеп, киң һәм тирән аңлатмалар белән тәэмин ителгән иде. Яңа дүрт томлыкны төзүче Рашат Гайнанов та ул басманы җентекләп өйрәнеп чыккан, аның уңай якларыннан киң файдаланган. Бу хакта дүрт томлыкның беренче томында ачыктан-ачык әйтелгән: «Томнарның бүленеше һәм жанр принциплары нигездә элеккеге дүрт томлыктагыча...» (1 том, 5 бит.)

1955—1956 елларда чыккан дүрт томлыкның беренче ике томында Тукайның шигъри әсәрләре, өченче һәм дүртенче томнарда проза әсәрләре, мәкалә һәм хатлары урнаштырылган. Яңа дүрт томлыкта да шагыйрь әсәрләрен аерым томнарга бүлү шул ук принципларга нигезләнә.

Ләкин бу ике басма бер-берсен тулысынча кабатлый икән, дип уйлау һич тә дөрес булмас иде. Билгеләп үтелгәнчә, «үзенең фәнни эшләнеше, тулылыгы белән бу бөтенләй яңа басма» (1 том, 5 бит). Чыннан да бу шулаймы — тикшереп карыйк.

Элеккеге дүрт томлыкның икенче томында «Халык әдәбияты», «Халык моңнары» һәм «Җырлар дәфтәре» дигән бүлекләр бергә тупланып бирелгән иде. Әлеге бүлекләрнең беренчесе — «Халык әдәбияты» — Г. Тукайның 1910 елда «Шәрык клубы»нда укыган лекциясенең конспекты, «Халык моңнары» — шагыйрь тарафыннан өзерләнеп, 1910 елда «җыючысы Шүрәле» имзасы белән чыгарылган җыентыктан алынган... «Җырлар дәфтәре»нә карата элеккеге басмада мондый аңлатма бирелгән иде: «Уральскида яшәгән чагында Тукайның үз кулы белән төзелгән җырлар җыентыгы. Бу җыентыкның кульязма оригиналы 1946 елда табылды һәм хәзерге көндә СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының кульязмалар фондында саклана. Текст кульязма буенча алынды»[1].

Яңа дүрт томлыкта бу бүлекләр бөтенләй башкача урнаштырылганнар. «Халык моңнары» шигъри әсәрләрдән генә торган икенче томга кертелгән. «Халык әдәбияты» дүртенче томда — шагыйрьнең әдәби тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре белән рәттән урын алган.

40—50 нче елларда Тукайныкы дип исәпләнгән «Җырлар дәфтәре» яңа дүрт томлыкка бөтенләй кертелмәгән. Һәм бу бик табигый... 1966 елда Казанда Г. Тукайның 80 еллык юбилее уңаена оештырылган фәнни сессиядә халык иҗаты белгече И. Надиров «Тукай һәм халык җыры» дигән доклад белән чыгып, 1946 елда табылган «Җырлар дәфтәре»нең Тукай иҗатына мөнәсәбәте булмавын тәфсилләп дәлилләгән иде[2]. Яңа дүрт томлыкны төзүче бу җитди фактны истә тоткан һәм бик хаклы рәвештә «Җырлар дәфтәре» Г. Тукай томнарына кертелмәгән.

Билгеле булганча, Г. Тукай әсәрләре арасында хәзерге укучыга аңлашылмый торган корама әдәби телдә язылганнары да бар. Бу типтагы әсәрләр шагыйрьнең элеккеге дүрт томлыгына да кертелгән иде. Әйтик, «Гыйлемнәр бакчасында», «Шәкерт яки бер очрашу», «И каләм!» кебек шигырьләр һәм «Сугыш һәм Государственная дума», «Заманыбызның язучы һәм журналистлары турында» дигән мәкалә турында», «Җавапка җавап» шикелле мәкаләләр. Мондый әсәрләрнең тәрҗемәләре кирәк, әлбәттә. Элеккеге дүрт томлыкның төзүчеләре дә моны яхшы аңлаганнар. Тик тәрҗемәләрне урнаштыру принцибы гына анда башкача иде. Мәсәлән, «Гыйлемнәр бакчасында» шигыре томның 12 нче битендә, ә инде аның тәрҗемәсе 217 нче биттә урын алган иде. Башка әсәрләр һәм аларның хәзерге әдәби телгә тәрҗемәләре дә бер-берсеннән ярыйсы ук ерак тора иделәр. Яңа дүрт томлыкта исә Г. Тукайның иске телдә язылган әсәрләре һәм аларның тәрҗемәләре янәшә урнаштырылганнар.

Тукай тарафыннан 1905 елга кадәр язылган өйрәнчек шигырьләр элеккеге басмада да бар. Беренче томның «Искәрмәләр»енә керештә шагыйрьнең «Укыгыз, кызлар, укыгыз!», «Туйга бардым мин бүген...», «Мөгаллим Нурый» кебек шигырьләре урын алган иде. Бу әсәрләр яңа дүрт томлыкка да кертелгән. Тик алар «Искәрмә һәм аңлатмалар» бүлегендә түгел, бәлки Тукайның шагыйрь буларак беренче адымнары-

[1] Габдулла Тукай. Әсәрләр, дүрт томда. 2 том, Казан, 1955, 369 бит.

[2] И. Н. Надиров. Тукай и народная песня.— Китапта: Габдулла Тукай. Казан, 1969, 186—187 битләр.

на багышланган махсус «Кушымта»да урын алганнар (I том, 345—356 битләр).

Күргебезчә, күп томлыкны төзү принциплары төрле үзгәрешләр кичергән. Моны ничек бәяләргә соң?

Бер карасаң, яңа дүрт томлыкны төзүдә нәтиҗәле ысуллар да бар кебек. Мәсәлән, иске телдә язылган шигырь-мәкаләләрне һәм аларның тәрҗемәләрен рәттән урнаштыру укучылар өчен төрле уңайлыклар тудыра. Шул ук вакыт шагыйрьнең иске телдә язылган һәм башлангыч шигырьләрен беренче томның соңгы битләрендә урнаштыру әдипнең иҗади үсешен дөрес чагылдыра алмый. Бу хакта профессор И. Нуруллин язып та чыкты инде [1].

Күп томлыкта әдипнең иҗади эволюциясе дөрес чагылыш табарга тиеш. Шагыйрьнең башлангыч шигырьләрен беренче томның беренче битләрендә, иске телдә язылган әсәрләрне хронология буенча урнаштырып, оригинал белән рәттән хәзерге әдәби телгә күчермәсен биргәндә отышлырак булыр иде кебек.

Бөек шагыйрьнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү буенча бездә күп эш башкарылды, йөзләрчә тикшеренү-мәкаләләр язылды һәм язылып тора. 1974 елда Г. Тукайга багышланган библиографик күрсәткеч басылып чыккан иде [2]. Китаптагы мәгълүматларга караганда, 1956—1970 елларда, ягъни 15 ел эчендә, Тукай, аның иҗаты һәм тормышына карата басылып чыккан китап, мәкалә, очерк, рецензияләрнең гомуми саны 900 дән артып киткән.

Олы шагыйрь әсәрләрен халыкка җиткерү, аның мөмкин кадәр тулы җыелмасын дөньяга чыгару буенча да җитди эзләнүләр алып барыла, практик адымнар ясала. Тикшерелә торган дүрт томлык нәкъ өнә шул хакта сөйли.

Халкыбызның сөекле шагыйре Габдулла Тукай томнарын чыгару төзүчедән һәм редактордан гаять зур җаваплылык, тырышлык һәм төгәллек таләп итә. Шагыйрьнең һәрбер сүзе дөрес бирелергә тиеш. Нәкъ шуңа күрә төзүче, текст һәм искәрмәләрне хәзерләүче Р. Гайнанов «бу дүрт томлыкка кертелгән әсәрләргә шагыйрьнең үзе исән чакта чыккан барлык басмалары буенча яңадан текстологик тикшерү» үткәргән (I том, 5 б.). Китаптагы материалларның иң зур күпчелеге беренчел чыганаклардан — Тукай заманындагы газета-журналлардан, җыентыклардан һәм кулъязмалардан алынган. Мәсәлән, элеккеге дүрт томлыкта «Иттифак хакында» шигыренең тексты 1909 елда дөнья күргән «Г. Тукаев шигырьләре, дүртенче дәфтәр» буенча басылган иде. Р. Гайнанов исә беренче чыганакка — 1905—1907 елларда «Фикер» газетасына мөрәҗәгать итә һәм әлеге шигырьне газетаның 1905 елгы 25 декабрь санынннан ала. Яисә «Фәрьяд» шигырен алыйк. 1955—1956 еллардагы дүрт томлык өчен ул 1908 елда басылып чыккан «Г. Тукаев диваны» исемле җыентыктан алынган иде. Яңа басмадагы текст исә «Әльислах»ның 1908 елгы 1 январь саныннан алынган. Мондый мисалларны шактый күп китереп булыр иде.

Әйтелгәнчә, дүрт томлыклар икесе дә жанр һәм хронология нигезендә төзелгәннәр. Димәк, аларга кертелгән әсәрләрнең урнашу тәртибе дә бер үк төсле булырга тиеш иде. Ләкин ике басманы шул күзлектән чагыштырып карасак, алар арасында шактый гына аерма да булуы күзгә ташлана. Әйтик, шагыйрьнең 1909 елда язылган шигырьләре элеккеге дүрт томлыкның икенче томында түбәндәге тәртиптә бирелгән иде: «Тәрәтдөт вә шөбһә», «Күңел», «Пигамбәр», «Исемдә», «Хатыннар хөррияте», «Авыл җырлары» (Өченче көлтә), «Күрсәтә» һ. б. Яңа дүрт томлыкның икенче томында исә шул ук әсәрләр бөтенләй башкача урнаштырылганнар: «Күңел», «Тәрәтдөт вә шөбһә», «Җавап», «Хатыннар хөррияте», «Авыл җырлары» (Өченче көлтә), «Сәфилгә каршы язарга теләгән каләмгә», «Пигамбәр» һ. б. Хикмәт нәрсәдә соң? Бу хакта соңгы җыелманы төзүче, беренчел чыганакларны барлау нәтиҗәсендә, байтак әсәрләрнең язылу вакытлары ачыкланды»,— дип искәртеп уза. (I том, 5 бит.)

Шул ук беренче томның «Искәрмә һәм аңлатмалар»ында Р. Гайнанов бу төзәтүләрнең нинди конкрет юллар белән баруы хакында болай ди: «ТАССР Дәүләт архивында «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма китапларны теркәү дәфтәре» саклана (420 фонд, I тасвирлама). Анда Казанда басылган һәр китапның дөньяга чыгу датасы һәм тиражы күрсәтелгән. «4 нче дәфтәр»нең чыгу датасы 5 январь дип куелган. Г. Тукайның беренче тапкыр китапларында чыккан әсәрләренең датасы шул дәфтәр буенча алынды, шуңа күрә бу басмада әсәрләрнең хронологик тәртибе элек-

[1] И. Нуруллин. Яңа табышлар, кайбер югалтулар.— «Социалистик Татарстан», 1977, 13 октябрь.

[2] Г. Тукай. Библиографик күрсәткеч. Казан университеты нәшрияты. 1974.

ке басмаларга караганда байтак үзгәрде, дөресрәк итеп алынды» (I том, 359 бит).

Тукай иҗаты искиткеч бай һәм катлаулы. Аның әсәрләре гаять күп газета-журналларда һәм җыентыкларда басылган. Байтагы Тукай чорында ук аерым китап булып чыккан. Әйтик, шагыйрь 1904—1908 елларда язган әсәрләр «Фикер», «Тавыш», «Таң мәҗмугасы» кебек газеталарда, «Уклар», «Яшен», «Ялт-йолт» һ. б. журналларда дөнья күргән. Шул ук елларда шагыйрь берничә китап та чыгарып өлгерә: «Г. Тукаев шигырьләре» («Шигырьләр көтепханәсе»ннән 3 нче дәфтәр); шул ук исемдәге 4 нче дәфтәр; «Печән базары, яхуд яңа Кисекбаш», «Җуаныч», «Алтын әтәч» һ. б. Дүрт томлыкның соңгы томында китерелгән мәгълүматларга караганда, 1907—1913 елларда — нибары 5—6 ел эчендә — Тукай 33 китап әзерләп чыгара. Шагыйрьнең үз сүзләре белән әйтсәк, «бәхетсез милләтнең бәхетсез угылы, бәхетсез почмакның әсир былбылы булган» (4 том, 249 бит) әдип коточкыч авыр шартларда яши, танышларыннан әҗәткә акча сорап интегә, яшәр өчен рәтле урын таба алмый аптырый. Шуның өстенә аны гомер буе төрле авыру, чир җәфалый. Ләкин әнә шундый авырлыкларга, киртәләргә дә карамастан, ул үзенең илаһи бер эшен, фидакарь хезмәтен туктатмый.

Әле бүген дә Тукай язган әсәрләрнең барысы да табылган һәм басылып чыккан дип булмый. Ләкин бу юнәлештә инде шактый күп эшләнгән. Соңгы дүрт томлык моның ачык мисалы.

Тукай әсәрләрен мөмкин кадәр тулы итеп дөньяга чыгару юнәлешендәге беренче әһәмиятле һәм чын мәгънәсендәге фәнни эш 1955—1956 елларда башкарылган иде. 1976—1977 еллар дүрт томлыгы бу юнәлештәге мөһим эзләнүләрнең, фәнни тикшеренүләрнең дәвамы булып тора. Томнарны хәзерләү барышында шагыйрьнең элек билгеле булмаган псевдонимнары ачыклана, элегрәк беркайда да басылмаган яки дөньяга чыгып та, вакытлы матбугат шүрлекләрендә, архив тузаннары астында калган әсәрләре табыла һәм укучылар игътибарына тәкъдим ителә.

Билгеле булганча, үзенең беренче әсәрләрен Г. Тукай «Әлгасрел-җәдит» исемле кулъязма журналында урнаштырып бара[1]. Бу журнал турында төзүче болай ди: «Журналның һәр саны баштан ахырга Тукайның ачык, матур (каллиграфик) язуы белән язылган: ул аның фактик редакторы да, секретаре дә булган—дөресрәге, журналны башлыча үз кулы һәм үз язмалары белән чыгарган» (1 том, 415 бит). Г. Тукайның өйрәнчек әсәрләреннән «Әхмәтсафа әфәнде», «Тугъды, көн тугар кеби», «Хәрап итде» шигырьләре дүрт томлыкка әнә шул кулъязма журналдан алып кертелгән. Соңгы икесе Тукай җыентыкларына беренче тапкыр керә.

Бу басмада Тукай томнарына беренче кат кертелгән әсәрләр гомумән аз түгел, аларның һәркайсына тукталуны без күз алдында тотмадык. Бу — махсус тикшеренүләр, эзләнүләр эше. Югарыда телгә алынган рецензиясендә И. Нуруллин мондый өстәмәләргә кискен каршы чыкты. Аның фикерләрендә дә хаклык бар, әлбәттә, бигрәк тә «Казанда бөлгән Әхмәтҗан бабай Сәйдәшев кыйссасы» кебек конкрет әсәрләргә карата. Әмма Р. Гайнановның Тукай әсәрләрен мөмкин кадәр тулы итеп дөньяга чыгару теләгеннән чыгып, эзләнү һәм тикшеренүләрен дә бөтенләй кире кагу дөрес булмас иде. Кайбер хаталары булса да, төзүченең нияте изге. Димәк, киләчәктә әнә шул юнәлештәге тикшеренүләрне киңәйтергә һәм тирәнәйтергә кирәк. Бу эшкә Г. Тукай иҗатын өйрәнүче галимәдәбиятчыларның барысын да тарту һичшиксез уңай нәтиҗәләр бирер иде.

Ниһаять, дүрт томлыкның «Искәрмә һәм аңлатмалар»ы турында берничә сүз. Алар һәр томның дүрттән бер өлешен тәшкил итә. Еш кына Тукай әсәреннән берничә тапкыр зуррак. Моның ачык мисалы рәвешендә «Мужик йокысы», «Теләнче», «Безне урынсыз яманлыйлар» һәм башка күп кенә әсәрләргә бирелгән аңлатмаларны күрсәтергә мөмкин. Шагыйрьнең «Исемдә калганнар» дигән автобиографик язмасына карата 65, «Актык сүзләр» исемле бер битлек парчага 15 пункттан торган аңлатма бирә.

«Искәрмә һәм аңлатмалар»ның эчтәлегенә күчсәк, аларның гаять зур әһәмияткә ия булуын күрербез. Аларда Г. Тукайның тормышы һәм иҗаты, шул чорның иҗтимагый-политик вакыйгалары, Казан, Уфа, Оренбург кебек шәһәрләрдә татар культурасы, вакытлы матбугат, редактор-нәширләр, шагыйрь-язучылар турында чиксез күп һәм киң мәгълүматлар бирелә. Искәрмәләр белән танышып чыккач, автор Тукайга

---

[1] Бу журналны 1906—1907 елларда Уральскида Ҡ. Мотыйгый-Төхфәтуллин тарафыннан чыгарылган «Әлгасрел-җәдит» («Яңа гасыр») журналы белән бутарга ярамый.

нисбәтән архив материалларын, шул чордагы газета-журнал, китап-җыентык һәм башка чыганакларның барысын да җентекләп тикшереп чыккан дигән фикер туа. Төзүче бик күп газета-журналларның чыгарылу чоры, урыны, редакторы, юнәлеше, Тукайның аңа мөнәсәбәте турында бай мәгълүматлар биреп бара.

Әдипнең «Бозау кадәрле зур фәлсәфә (яки акчасыз игълан)» дигән фельетоны бик үзенчәлекле алым белән язылган. Автор аны «Россиянең төрле өлкәләрендә һәм төрле вакытта чыккан газета-журнал, китап бастыру оешмалары, типографияләр, әдәби әсәрләр исемен алып, шуларның сүзлек мәгънәсен файдаланып язган» (4 том, 351 бит). Фельетонда барлыгы 56 исем кулланылган. Төзүче әнә шуларның һәркайсына аңлатма биреп бара.

«Искәрмә һәм аңлатмалар»да мәҗбүри рәвештә түбәндәге мәгълүматлар да бирелә: әсәр беренче тапкыр кайда һәм кайчан басылган, аннан соң шагыйрьнең нинди китапларында урнаштырылган, әсәрдә нинди редакцион үзгәртүләр булган, дүрт томлыкка ул каян алып кертелгән.

Тукай әсәрләрендә еш кына хәзерге укучыга аңлаешсыз сүзләр һәм гыйбарәләр очрый. Төзүче аларга да тулы һәм тәфсилле аңлатмалар биреп бара. Гомумән алганда «Искәрмә һәм аңлатмалар» һәрбер томны баетып, күркәмләндереп тора, Тукай әсәрләренең иҗтимагый-әдәби мәгънәсен конкретлаштыра, әһәмиятен киңәйтә һәм тирәнәйтә.

Тукай турында күп языла, еш языла. Чөнки безнең көннәрдә халкыбызның рухи тормышын, культурасын, сәнгатен һәм әдәбиятын, хәтта бүгенге әдәби хәрәкәтне дә бөек шагыйрь исеменнән башка күз алдына китереп булмый. Әмма Тукай иҗаты өйрәнелеп бетте дип уйлау зур ялгышлык булыр иде. 1913 елның 14 мартында Клячкин больницасында язылган «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсендә Тукай: «Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле»,— дип язган иде (4 том, 248 бит). Ул заман килде инде дип әйтәсе килә хәзер. Соңгы дүрт томлык Тукай иҗатын һәм аның тормышын «инәсеннән җебенә кадәр» өйрәнү юнәлешендә бүгенге көнгә иң әһәмиятле адым булып тора.

**ФАТИХ УРМАНЧЕЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты, доцент.**

# ТАТАР СОВЕТ КИТАБЫ УЗГАН ЮЛ

Талия Сәфәргалиевна Корбангалиеваның күптән түгел дөнья күргән хезмәтендә[1] аз өйрәнелгән мәсьәлә — Совет властеның беренче ун елында Татарстан китап нәшрияты башкарган гаять зур эшчәнлек яктыртыла. Китап төпле һәм дәлилле материалларга нигезләнеп язылган. Автор республикабызда нәширлек эшенең материаль-техник нигезе туу тарихын күздән кичерә, китап таратуны җайга салу юлында кылынган эшләрне күрсәтә, чыгарылган басмаларның төп юнәлешен һәм эчтәлеген билгели.

Мәгълүм булганча, 1917 елларда бөтенләй яңа нәшрият системасы урнашты, совет китабын чыгару эше җайга салынды. Т. С. Корбангалиева, хаклы рәвештә, илебезнең милли республика һәм автономияле өлкәләрендә нәшрият үсешенең үзенчәлекле булуын әйтеп уза. Монда беренче чиратта ике моментны күздә тотарга кирәк. Беренчедән, 1920 елда халкыбыз тормышында тарихи әһәмиятле вакыйга булды — Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелде һәм, икенчедән, полиграфия промышленносте национальләштерелде.

Бөек Октябрь Социалистик революциясе җиңгәннән соң, Джон Рид әйткәнчә, «басу станокларының көрәш чоры башланды, чөнки калган бөтен корал инде Советлар кулында иде». Типографияләрне национальләштерү һәм республикада бердәм совет нәшрияты үзәге төзү, тулаем алганда, Татарстанда 1921 елның маена тәгәлләнә: Казанда — унсигез һәм республика кантоннарында ун типография дәүләт милкенә күчерелә.

Бер үк вакытта, 1918 елның беренче яртысында контрреволюцион матбугат үзәк-

[1] Т. С. Корбангалиева. Татарстанда китап басу эше. Казан, 1977.

ләрен һәм басмаларны ябуга зур әһәмият бирелә, алар материаль җирлектән мәхрүм ителеп, көннән-көн үз укучыларын югалта бардылар. Дөрес, гражданнар сугышы елларында, республика территориясенең бер өлеше вакытлыча интервент һәм акгвардиячеләр тарафыннан басып алыну сәбәпле, кайбер типографияләр советка каршы юнәлеш алдылар. НЭП башланган чорда да шундыйрак характерда берничә китап дөнья күрә. Бу күренешләр исә үз вакытында кискен рәвештә тәнкыйтькә дучар ителделәр. Нәкъ менә шуңарга да монография авторына яңа нәшрият системасы һәм аның материаль-техник базасы төзелү процессын, гражданнар сугышы чорында бу эшнең шактый катлаулана төшүен тулырак яктыртырга һәм аерым басмаларга үтеп кергән буржуаз-милләтчелек идеологиясенә каршы Татарстан большевиклары алып барган рәхимсез көрәшне тагы да калкурак итеп күрсәтергә кирәк булгандыр дип әйтәсе килә.

Совет властеның беренче елларында китап, газета-журналлар бастыру һәм тарату эше белән партия-совет һәм хәрби оешмалар, Советларның милли секцияләре шөгыльләнә. Үзәк мөселман хәрби коллегиясе 1918—1919 елларда ярты миллион данә күләмендә 22 өндәмә чыгара. 1920 елның июленә 56 брошюра һәм китап дөнья күрә. Алар арасында Ш. Усмановның «Канлы көннәр» һәм «Беренче адым» исемле пьесалары үзенчәлекле урын алып торалар. Үзәк мөселман комиссариаты, атаклы революционер Мулланур Вахитов җитәкчелегендә, К. Маркс, Ф. Энгельс, В. И. Ленинның аерым хезмәтләрен татар теленә тәрҗемә итү һәм дөньяга чыгару эшен дә җайга сала.

Мәгълүм булганча, В. И. Ленин совет хөкүмәте декретлары һәм карарларының төрле милләт хезмәт ияләренә ничек җиткерелүе белән шәхсән кызыксынып килгән. Мөселман комиссариатына 1918 елның июлендә милләтләр халык комиссариаты җибәргән хатта болай диелә: «Бүгенгә кадәр эшче-крестьян хөкүмәтенең нинди декретлары, мөһим боерык һәм карарлары мөселман телләренә тәрҗемә ителүен, ничә данәдә басып чыгарылуын, күпме таратылуын һ. б. тиз арада хәбәр итүегезне иптәш Ленин тәкъдиме белән үтенәбез».

Гражданнар сугышында актив катнашкан язучы Всеволод Вишневский бу кырыс елларда фронтта газеталарның икмәк, патрон һәм снаряд кебек үк югары бәяләнелүе турында яза. Шул уңай белән җирле партия-совет органнарының матбугат эшенә нинди ярдәм күрсәтүләренә игътибар итү кызыклы. Казанны ак интервентлардан азат итү белән үк Вакытлы революцион губерна комитеты «Эш» исемле көндәлек татар газетасы чыгару өчен 50 мең сум акча бүлеп бирә. Казан Советы каршындагы милләтләр эше бүлеге отчетында мөселман эшчеләре, крестьяннары һәм кызылармиячеләре арасында газета һәм өндәмәләрнең тиз арада һәм уңышлы таралуы турында әйтелә. Газетада үзәк һәм җирле власть органнарының барлык боерык, карар һәм белдерүләре даими рәвештә урнаштырып барыла, халыкның культура-агарту, экономик-политик тормышы һәр яклап яктыртыла, бер үк вакытта Совет властен һәм социаль революцияне ныгыту һәм үстерү өлкәсендә киң агитация эше алып барыла (карагыз: КПССның Татарстан өлкә комитеты партия архивы, 36 фонд, 235 саклау берәмлеге, 61 кәгазь).

Монографиядә күрсәтелгәнчә, бу елларда татар матбугаты марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләрен басып чыгаруга аеруча зур әһәмият бирә. 1918 елда К. Маркс белән Ф. Энгельсның «Коммунистлар партиясе манифесты» татар телендә дөнья күрә. Гражданнар сугышы елларында Казанда ел саен В. И. Ленинның ике-өч хезмәте татар укучысына тәкъдим ителә. 1925—1927 елларда бу сан 18—26 га җитә. Шул чорда ук дәһи Ленинның татар телендә тематик җыентыклары чыгарыла башлый. Аларны тарату һәм өйрәнү татар халкында марксистик-ленинчыл караш формалашуга чиксез зур уңай тәэсир ясады.

Т. С. Корбангалиева хезмәтендә шулай ук киң аудиториягә исәпләнгән политик әдәбият, уку әсбаплары, крестьяннар өчен китаплар, фәнни-популяр һәм матур әдәбият әсәрләре чыгару эшен яктыртуга зур урын бирелә. Өлкә большевиклар партиясе җитәкчелегендә Татарстан нәшриятының культура революциясе үткәрү, илне социалистик үзгәртеп кору бурычларын хәл итүдә актив катнашуы күрсәтелә. Ул вакытта Казанда китапларның Идел буе халыклары — рус, татар, чуваш, мари һ. б. халыклар телендә басылуын да әйтергә кирәк. Республикабыз башкаласында шулай ук бу халыклар өчен дәреслек һәм уку

әсбаплары киң колач белән чыгарыла. Моның исә милли мәктәпләр үсеше өчен әһәмияте гаять зур була.

1921—1927 елларда гына да нәшрият крестьяннар өчен 457 исемдәге китап һәм брошюра тәкъдим итә. Бу — авыл халкын культура-политик агартуга кертелгән зур өлеш. Боларның күбесе татар игенчеләре өчен махсус әңгәмәләр, политик һәм авыл хуҗалыгы темаларына багышланган брошюралар.

Фәнни әдәбиятны күздән кичергәч, барыннан да элек аның күп темалы булуына игътибар итәсең. Бу чорда чыккан китаплар фәннең төрле өлкәләренә — тарихка, туган якны өйрәнү фәненә, тел белеменә, табигый фәннәргә карый. Шулардан Каюм Насыйриның сайланма әсәрләр җыентыгы, М. Корбангалиевның иҗтимагый һәм культура-агарту эшчәнлеген яктырткан Г. Рәхим хезмәте махсус игътибарга лаек. Бер үк вакытта студентлар өчен дәреслекләр бастыру эше юлга салына. Фәнни-популяр әдәбият чыгару да читтә калмый. Болары исә иң элек киң катлау укучыларны белемнәрнең төрле өлкәләре белән таныштыруны күздә тотып чыгарыла. Казанда басылган фәнни һәм фәнни-популяр әсәрләр үз вакытында халык арасында киң тарала. Бу сериядә чыккан 51 басма В. И. Ленинның Кремльдәге шәхси китапханәсендә саклана.

Совет властеның беренче ун елында илебездә татар язучыларының 322 әсәре дөнья күрә, шуларның 235 е Казанда басыла. Г. Ибраһимов, Ш. Усманов, К. Тинчурин, М. Гафури, һ. Такташ һәм башка бик күп әдипләрнең шул елларда басылып чыккан әсәрләре бүген күп милләтле совет әдәбиятының горурлыгына әверелде. 1925 елдан «Татар әдәбияты китапханәсе» басыла башлый. Рус һәм совет әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен татар теленә тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару эше дә шушы елларда җайга салына.

Гомумән, монография авторы татар совет китабы барлыкка килүдә, үсүдә һәм аның укучылар арасында зур уңыш казануында Татарстан китап нәшрияты чиксез зур роль уйнады дигән нәтиҗә ясый. Бүген Татарстан китап нәшрияты — Россиядә иң зурлардан берсе. Ел саен анда 6 миллионданәдән артык гомуми тираж белән күп санлы китап дөнья күрә.

Соңгы елларда җирле промышленностьны национальләштерү, республикада китап басу эшенең үсеше һәм татар матбугаты тарихын тикшерү нәтиҗәсендә язылган байтак кына хезмәтләр басылып чыкты. Т. С. Корбангалиева китабы алар арасында игътибарга лаеклы урын алып тора. Чөнки бу халкыбыз узган данлы көрәш һәм иҗат юлын дөрес һәм тулы чагылдырган китап. Хезмәттә китерелгән материаллар Коммунистлар партиясе һәм дәүләтебезнең күп милләтле совет китабын үстерүдә олы кайгыртучанлык күрсәтүен дәлилле итеп раслыйлар.

**Алексей ЛИТВИН,**
**тарих фәннәре докторы.**

# ЗАРИФ БӘШИРИ

*(1888—1962)*

Зариф Шәрәфетдин улы Бәшири 1888 елның 5 маенда Казан губернасы Чүти авылында (хәзер Татарстанның Апас районы) туа. Башлангыч белемне туган якларында ала һәм Беренче рус революциясе елларында үзенең тәүге шигырь һәм мәкаләләрен яза. «Казан мөхбире» газетасының 1906 ел, 20 нче санында аның «Яшә, хөррият!» дип исемләнгән беренче шигыре дөнья күрә. Әдәби эшләнеше ягыннан шактый түбән булуына да карамастан, ирекле тормышка һәм революциягә дан җырлаучы әлеге шигырь заман сулышын, шул чор яшьләрнең теләк-омтылышларын чагылдыруы белән игътибарга лаек. Ул түбәндәге юллар белән башлана:

**Яшә, хөррият, яшә,**
**Хисапсыз гасыр аша.**
**Хөррият яшәве белән**
**Милләт һавага аша.**

З. Бәширинең тынгысыз каләме 1907 елның көзендә, Казанга килеп «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга кергәч, аеруча нык активлаша. Мәдрәсәдә уку һәм аны тәмамлаганнан соңгы елларда ул «Казан мөхбире», «Йолдыз», «Вакыт» газеталары һәм «Шура» журналы белән актив язышa, «Чүкеч» журналының секретаре булып эшли. Шушы еллардан алып аның бер-бер артлы шигырь җыентыклары чыга башлый. Шул чорда яшәгән һәм иҗат иткән балалар язучылары арасында ул иң активы була. Әмма Зариф Бәширинең язган әсәрләре сан ягыннан искиткеч күп булсалар да, әле сыйфат ягыннан шактый түбән. Әдип иҗатына замандаш тәнкыйтьчеләре биргән бәя дә моны ачык күрсәтеп тора. Аерым алганда, аны Г. Тукай һәм Җ. Вәлидиләр принципиаль рәвештә тәнкыйть утына алалар.

З. Бәшири поэзиясе тематикасы белән шактый киң. Аның күп кенә әсәрләрендә революциягә кадәрге хезмәт ияләренең авыр тормыш шартлары сурәтләнә, көнкүрештә киң таралган тискәре яклар тәнкыйть ителә. Шагыйрьнең балалар тормышыннан алып язылган һәм табигать күренешләрен тасвирлаган шигырьләре дә аерым игътибарга лаек.

З. Бәшири яшьли чуваш телен, тормышын һәм культурасын өйрәнеп, вакытлы матбугат битләрендә бу тугандаш халыкның тормыш-көнкүреше, этнографиясе һәм фольклоры турында кызыклы гына очерклар язып чыга.

Зариф Бәшири үз чорында халык тарафыннан яратылып укылган «Чуваш кызы Әнисә» повестеның да авторы. Чуваш кызы образында хезмәт сөючән, яхшы күңелле, шаян табигатьле авыл кызы мәхәббәтенең капитализм шартларындагы драмасы сурәтләнә. Бу әсәр күрше халыклар арасындагы дуслыкны күрсәтүе белән дә кыйммәтле.

Бөек Октябрь революциясеннән соң, үзенең актив әдәби эшчәнлеген дәвам итү белән бергә, З. Бәшири халык мәгарифе һәм вакытлы матбугат органнарында зур эш алып бара, бөтен энергиясен яшь Совет республикасына хезмәткә багышлый. Гомеренең соңгы елларында ул Уфада яши.

# КАЙНАР ЙӨРӘКЛЕ ГАЛИМ

*Хатип Госманга 70 яшь*

Фәнни конференция бара. Залда илебезнең төрле төбәкләреннән килгән зур галимнәр. Профессор Х. Госман төрки халыкларның шигырь төзелеше турында доклад укый. Куелган проблема җитди. Моңарчы төрки шигырен, шул нисбәттән татар шигырь төзелешен аңлатуда берьяклырак караш яшәп килде. Күп галимнәр төрки шигырь төзелешен гарәп кануннарына нигезләнеп тикшерделәр. Бу исә төрки халыкларда борын-борыннан үз шигъри системасы формалашмаган, ә гарәпләрдән алынган дигән ялгыш фикергә этәрде.

Профессор әлеге карашның ялгышлыгын күңеле белән электән үк сизә иде. Әмма ул дәлилләнмәгән... Ә исбат ителмәгән фикернең фәндә әһәмияте юк. Шуның өчен татар шигырен әдәбият фәненең яңа казанышларына таянып тикшерергә кирәк иде. Профессор эшкә керешә. Башта борынгы төрки мәкальләрдә, әйтемнәрдә шигырь күзәнәге ничек ялралуын һәм үсә башлавын күзалларга, аннан халык тәнендә туган шигъри күзәнәкләр ничек язмага күчүен һәм безнең заманга кадәр нинди үсеш, үзгәреш кичерүен тикшерергә кирәк булды. Айлар, еллар узды, тау-тау китаплар, кульязмалар карап чыгылды. Ниһаять, күзәтүләргә, анализларга нигезләнеп, фәнни ачыш ясалды: төрки шигырьнең үз юлы бар, шигъри система башка халыклардан кермәгән, ул үз телебезнең чараларына нигезләнеп барлыкка килгән, үскән һәм камилләшкән. Залдагыларның күпчелеге профессорның бу нәтиҗәләрен хуплап каршы алды. Каршы чыгучылар да булды. Әмма галимнең дәлилләре көчле, ышанычлы иде. Бәхәсләрдә аны җиңә алучы табылмады. Профессорга төрле яклап сораулар яуды, язма рәвештә дә бирделәр. Ул һәммәсенә җавап бирә барып, бер кәгазьдә тукталып калды. «Әллә күзләрем ялгыш күрәме» дигәндәй язуны әйләндергәләп карады. Аннан, бер фикергә килеп, эчтәлеген залга игълан итте:

— Иптәш Усманов, бу тәфсилләп тикшерүнең нигә кирәге бар? Шагыйрьләребез шигырь төзелешен белмәсәләр дә, язалар ич әле.

Залдагылар аптырашта калды. Аларның күбесе Хатип аганың шәкертләре, тегеләйме-болаймы профессорның катнашы белән фәнгә яисә әдәбиятка аяк баскан кешеләр, һич югында, аның лекцияләрен тыңлаган, хезмәтләренең кыйммәтен яхшы белгән һәм аларга нигезләнеп эш итүчеләр иде. Хөрмәтле профессорга бирелгән бу мәгънәсез сорауны ишетеп тору аларга бик кыен тоелды, күрәсең, уңайсызланып башларын иделәр. Профессорның да бу «галим»гә ачуы чыкты, йөрәген әрнетте бугай, күзләреннән нәфрәт чаткылары сибелеп киткәндәй булды. Ләкин ул үзен тотып калыр өчен көч тапты, тыныч кына тавыш белән:

— Минем иң яратмаган нәрсәм — фәндә өстән-өстән йөрү... Фәнгә менә шундый галимнәрнең борын тыгуы бик аяныч, — дип сүзен тәмамлады.

Бу вакыйганың булуына шактый вакыт узды. Әмма шул конференциядә әйткән «иң яратмаганым — фәндә өстән-өстән йөзү» дигән сүзе Хатип Госманның һәр мәкаләсен, һәр китабын караган саен искә төшә торган булып китте. Чөнки тикшерелә торган объектның төбенә-тамырына төшү, төп хасиятен белергә тырышу аның барлык гыйльми хезмәтләренә дә хас әйбер. Бу аның иманы иде.

Х. Госман фәнгә әдәбият дөньясыннан килде. Ул 30—40 нчы елларда шагыйрь һәм прозаик буларак танылды. «Кырлар лирикасы» (1931), «Кан тавышы» (1934), «Йосыф», «Мин куккә күтәреләм» (1937), «Ялкынлы йөрәк» (1943), «Ут сызыгында» (1945) кебек әсәрләре укучылар тарафыннан җылы каршы алындылар.

Аның әдәбияттан килүе фән эшендә дә зур ярдәм итте, шагыйрьләрнең иҗат лабораториясенә үтеп керергә, аларның иҗат үзенчәлекләрен тирәнрәк ачып салырга мөмкинлек бирде. Моннан тыш ул яшьтән үк рус һәм Көнбатыш әдәбиятларын җентекләп өйрәнеп, Алабуга укытучылар әзерләү һәм Казан педагогия институтларында Көнбатыш әдәбияты буенча лекцияләр укырга да өлгергән иде.



Х. Госман беренче фәнни хезмәтен һ. Такташ поэзиясенә багышлый. Әмма Такташ поэзиясе гаять катлаулы. Беренче чорда ул романтик шагыйрь булып күзалланса, соңга таба социалистик реализмга таба юл тота. Аның эчке иҗади үсеш-үзгәрешен ничек, кай тарафтан ачарга, аның иҗат лабораториясенә ничек ачкыч табарга? Шул вакыт аның Көнбатыш әдәбиятларын яхшы белүе ярдәмгә килә. Көнбатышта исә мондый шагыйрьләр булган. Х. Госман Такташ иҗатын Гёте, Шиллер, Байроннар кебек даһилар белән янәшә куеп, чагыштырып карый һәм шунда Такташның бөеклеге һәм аның шигъри эволюциясе ачылып китә. Бу фән дөньясына яңа гына килеп кергән яшь галимнең беренче уңышы була. 1951 елда ул Казан университетында шушы темага кандидатлык диссертациясе яклый.

Шул ук елда аңа Казан университетының татар әдәбияты кафедрасы белән җитәкчелек итүне тапшыралар. Татар әдәбиятын чын-чыннан фәнни нигезгә салып укыту эше яңа гына җайга салынып килгән еллар. Студентлар өчен дәреслекләр юк дәрәҗәсендә, укыту планнары, методик күрсәтмәләр юк. Әдәбиятның борынгыдан алып хәзерге көнгәчә үткән юлында тикшерелмәгән «ак таплар» бихисап. Нидән башларга? Кафедра җитәкчесен шул нәрсә борчый. Ул көн тәртибенә әдәбият тарихындагы «ак таплар»ны бетерү, иҗатлары моңарчы җитәрлек өйрәнелмәгән, исемнәре тарих томаннары артында югалып калган язучы һәм шагыйрьләрне яңадан халык арасына кайтару бурычын куя. Ләкин моның өчен кадрлар тупларга, фән мәктәбе булдырырга, фәнни тикшеренүләрнең юнәлешен билгеләргә кирәк иде. Фидакарь хезмәт белән айлар, еллар үтә торды. Татар әдәбияты кафедрасы акрынлап кирәкле кадрлар белән тулыланды, фәнни хезмәтләр, программалар, методик кулланмалар, дәреслекләр басылды. Кафедра эше җайга салынып китте. Монда, әлбәттә, кафедра җитәкчесенең роле бигрәк тә зур булды.

Университетта эшләү чорында Х. Госман «Социалистик революция һәм татар поэзиясе» дигән темага күләмле монография яза. (Бу хезмәт аның 1962 елда яклаган докторлык диссертациясенең нигезен тәшкил итте.) Галим әлеге монографиясендә социалистик революция алды елларыннан алып 1930 нчы елларга кадәрге поэзиябезне тикшерә. Әдәби процессны иҗтимагый тормыш белән ныклы бәйләнештә ача, яңа совет поэзиясенең нигезе ничек барлыкка килүен тасвирлый, революция тудырган поэзиядә әдәби осталык үсеше мәсьәләләренә киң туктала. Бу монография 20 нче еллар татар поэзиясен тикшерү буенча хәзер дә бердәнбер күренекле хезмәт булып кала.

Гомумән, Х. Госман соңгы 20—25 ел эчендә шактый гына зур фәнни кыйммәткә ия хезмәтләр язды һәм китаплар чыгарды. Аның «Такташ поэзиясе» (1953 ел), «Бөек Октябрь революциясе һәм татар поэзиясе» (1960) һәм «Егерменче елларда татар поэзиясе» (1964), «Татар шигыре» (1964), «Шигырь төзелеше» (1975 ел) кебек китаплары поэзиябезне тикшерүдә күренекле урынны алып торалар. Моннан тыш Г. Кандалый, Мөхәммәдъяр кебек шагыйрьләрнең җыентыклары, «Татар поэзиясе антологиясе», һ. Такташ, М. Гафури, Ш. Бабич әсәрләренең укучыларга тәкъдим ителүендә һәм «Татар халык иҗаты» дигән күләмле китап чыгуда да өлкән галимнең өлеше гаять зур. Шуның өстенә урта мәктәпләр өчен дәреслекләр төзүгә кертелгән хезмәтне дә искә алыйк. Аның газет һәм журнал сәхифәләрендә дә әледән-әле әдәбиятның төрле проблемаларына бәйләнешле мәкаләләре басыла килде. Хәзер галим «Борынгы татар әдәбияты» дигән ике томлык хезмәт әзерләү белән мәшгуль. Бу ике томлык татар әдәбиятының борынгы чыганакларын өйрәнүдә моңарчы күрелмәгән зур фәнни хезмәт булыр дип көтелә.

Күренекле галим фәндә алмаш әзерләүгә дә зур әһәмият бирә. Аның җитәкчелегендә унлап диссертация язылды һәм якланды. Кайчандыр Х. Госманның шәкертләре булган М. Х. Хәсәнов, М. И. Мәхмүтовлар хәзер югары авторитетка лаек фән докторлары. Ул дистәләгән кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклауда

оппонент булды. Югары Аттестация комиссиясе әгъзасы буларак, фәнни хезмәтләргә рецензияләр язып, күпме яшьләргә фатиха биргән ул, фән юлына чыгарга ярдәм иткән...

Университет галимнәренең фәнни эше педагогик хезмәт белән бергә алып барыла. Х. Госман бу өлкәдә дә күп тырышлык куя. Без дә шул университетта укып Хатип аганың «Әдәбият белеме» буенча лекцияләрен тыңлау бәхетенә ирешкән кеше. «Бәхетенә ирешкән» дим. Чөнки ул укыган лекцияләрне тыңлау чыннан да бәхет иде. Аның зур илһамланып, оста һәм эчтәлекле итеп укыган лекцияләре әле дә хәтердә...

Университетка керү имтиханнары тапшыргандагы бер вакыйга истә калган. Әдәбият буенча сорауларга җавап биреп бетергәч, бер кырыйдарак утырган мәһабәт абый миңа сәер генә сорау бирде:

— Энем, тәрәзәгә кара әле, ни күрәсең, шуны сөйлә,— диде.

Башта аптырап калдым... Коридорга чыккач, бер-беребездән сорашабыз. Теге профессор абый шактый кешегә «Әниең турында сөйлә», «Туган авылың турында...» кебек сораулар биреп утырган икән. Без ул серле сорауларның ни өчен бирелгәнлеген ул вакытта төшенә алмадык, әлбәттә. Соңыннан гына аңлашылды, ул Хатип аганың укырга дип килгән яшьләрнең фантазиясен, эмоциональлеген, кыскасы, иҗади сәләт дәрәҗәсен чамалап утыруы булган икән.

Чыннан да 50 нче еллардан соң әдәбиятка килгән язучы һәм шагыйрьләрне күз алдыннан кичерсәң, аларның күпчелеге университетның татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укыган кешеләр. Бу бер дә очраклы хәл түгел. Чөнки кафедра һәм аның җитәкчесе Хатип ага әдәбиятыбызның киләчәге өчен өзлексез кайгыртучанлык күрсәтеп килделәр.

Бәхәссез, Х. Госманның милли кадрлар әзерләүдәге хезмәтләре гаять зур. Ул безнең республикада гына түгел, илебез күләмендә дә билгеле. Галим фидакарь хезмәте белән югары хөкүмәт бүләкләренә лаек булды. Ул «Почет билгесе» ордены кавалеры, шулай ук «Фидакарь хезмәте өчен» һәм В. И. Ленинның 100 еллык юбилей медальләре белән бүләкләнде.

Хатип ага Бөек Ватан сугышы ветераны. Ул авыр сугыш елларын башыннан ахырына кадәр кичеп чыкты. Башта Төньяк-Көнбатыш фронтның «Ватан өчен» газетасы сотрудникы, аннан сугышчан офицер булып фашизмның оясына кадәр барып җитте. Сугышта күрсәткән батырлыклары билгесе булып аның күкрәген «Кызыл Йолдыз» ордены һәм күп санлы медальләр бизи.

Болар бары да күзгә бәрелеп торган хезмәтләр генә. Авылдашлары Хатип абыйны (Пермь өлкәсе Чернушка районының Сулмаш авылы) зур галим булудан тыш, 20—30 нчы елларда авылда пионер, комсомол эшләрен башлап җибәрүчеләрнең берсе, күмәкләшү чорында үзенең ялкынлы сүзе һәм эше белән аларга ярдәм итүче активист буларак та беләләр.

Күренекле галим, филология фәннәре докторы, язучы, педагог Хатип ага Госманга 21 майда 70 яшь тула. Җитмеш ел аз түгел. Гомернең көзе якынлаша дигән сүз. Әмма халкыма хезмәт итим дип җилкенеп торган кеше йөрәге картаямыни? Ул һаман сафта, университетның татар бүлеге студентларына лекцияләр укый, фәнни эш алып бара, төпкыйть мәкаләләре яза, яңа иҗат планнары белән яши. Кыскасы, Хатип аганың көзләре бик мул килә. Ул көзнең җимешләре эреләр һәм татлылар. Әле аның күңел бакчаларында өлгерәселәре никадәр! Гомер көзләрең озын, җылы һәм кояшлы булсын, Хатип ага! Йөрәк ялкыныгыз сүрелмәсен!

**Рәшит ЯГЪФӘРОВ.**

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Зәки Нури**

## ХАТКА КАРШЫ ХАТЛАР ЯЗДЫК

«ПАРТИЗАН КИТАБЫ»ННАН



Немецларның шома телле булуы, сүзгә юмарт икәнлеге безгә сугыш башланыр алдыннан ук билгеле иде инде. Кемнәредер, үзләренчә оста хәйләләп һәм күзгә карап ялганлый-ялганлый, күп-күп уйдырма яза. Типографияләр шуны газета һәм журналларда, я кечкенә, я зур листовкалар итеп, мөрәҗәгать, приказ яки кисәтүләр төсендә күпләп бастыра. Аннары шул агуны самолетлары җиргә сибә һәм шымчылары күпләп тарата. Нинди генә җай тапмый да, ничек кенә кыландырмый иде, каһәр.

...Тар елга аша безнең ярга нәп-нәни бер уенчык көймә килә. Уенчык булса да, үзе моторлы — тыр-пыр итә. Без, посттагылар, куак арасыннан күренмичә генә шул тәти йөзгечкә карыйбыз. Су өстенә үз буразнасын сыза да сыза гына бит. Буе, чама белән, аршыннан артык. Төртке-төртке булып, ерактан ук ишекләре-тәрәзәләре күзгә чалына. Капитан күперчеге дә күренә. Хәтта утлары да бар кебек. Үтә дә сәере шул: карандаш хәтле генә мачтасында ак флаг җилферди, җилдә җәелгән чагында флагның ниндидер буй-буй сызыклар белән сырланганлыгын шәйләргә мөмкин.

Нигәдер «Көймә килә, көймә килә, көймә килә эзе юк, хаты килә, сүзе килә, сөйләшергә үзе юк» дигән җыр искә төшә. Әлбәттә, урынсыз хисләнү һәм күңелнең һич кирәксезгә дулкынлануы инде бу. Нинди хат килсен дә, нәрсә көтәргә кирәк ди безгә чик буе елгасының аръягындагы немецлардан? Ә менә безнең белән сөйләшергә сөйгән ярларыбызның бирегә килә алмаулары көн кебек ачык.

Килә дигән көймәбез җәен балыгыныкы шикелле тупа башы белән ярга төртелде. Һаман бер көйгә көчәнгән автомат моторы аны юеш ком белән сөзештереп үзенчә бераз маташты-маташты да, җәе һәм мае бетеп, күрәсең, шып тынды.

Көтелмәгән «кораб»ның хикмәтен белергә кирәк иде. Старшинабыз аңа винтовкасындагы штык очын сак кына тидереп карады:

куык кебек буш, җип-җиңел икәне беленде килмешәкнең, димәк, шартлау-нитү куркынычы юк иде.

Ап-ак нәни йөзгеч менә инде старшина кулында. Барчабызның күз карашы шуны капшый. Инде җил юктан җилфердәми башлаган, салынып төшкән флагка караучы да юк. Ә бит бөтен этлек шуңарда булган лабаса! Аңардагы буй-буй сызымнар акка кара белән русчалап язылган хат булып чыкты.

Кәгазьдәге язуны түгел, ә язулы ситсы җилкәнне укыйбыз. Мөмкин хәтле остарак әйтергә тырышып, рус телендә сырлаганнар: «Яһүдләр Россиясенең солдатлары, комиссарлары һәм командирлары! Сезне бирегә безнең Гитлер иленә каршы сугышка алып килделәр. Шәфкатьсез Сталин оештырган походка эләгүегез бик кызганыч. Чөнки сездән башлатырга теләгән сугыш, беренче чиратта, үзегезнең барыгызның да — димәк ки, сез масаеп һәм горурланып «сөекле Ватан» дип атаган Советлар Союзының да юкка чыгуы белән бетәчәк. Акылсыз булырга ашыкмагыз, яшәргә телисез икән — безгә көчләп тагачак сугышыгызны башлаганчы ук безнең якка күчеп калырга тырышыгыз. Күрәсез ич, арабыздагы елга киң түгел, теләсә нинди караңгы һәм тын минутны табыгыз да — йөзеп чыгыгыз бу якка. Бу кечкенә кораб эчендә бер мең кешелек чакыру кәгазе — рөхсәт язуы бар... Рәхим итәсез! Соңыннан үкенмәслек булсын... Социализм изүеннән котылырга мөмкинлек бар әле. Мең-мең тапкыр кабатлап әйтәбез: рәхим итәсез! Мөмкинлек бар әле!»

Язуны бездән соң полк штабында һәм политбүлектәгеләр укыды. Кыска гына итеп — бары тик өч җөмләле — җавап җибәрү тиеш табылды. Шул ук бәләкәч «корабның» инде кызыл ситсы җилкәненә язылган сүзләр теге якка китте:

«Йөрәкләребездәге нәфрәт хисләре санынча сәлам-пулялар кабул кылыгыз.

— Хат җибәреп, безне тагын да көчлерәк иттегез.

— Безнең җирләрдә мәңгегә ятып калуыгызны көтегез!..»

Моторын әйбәтләп боргач, көймә дә теге тарафка бик җәһәт барып сыенды.

Хат алышу, әлбәттә, артык дәвам итә алмады. Июнь аеның егерме икенче иртәсендә безнең палаткалар, безнең парктагы туплар өстенә кайдандыр очып килгән самолетлардан бомбалар, кайдандыр аткан туплардан миналар, ә елганың аръягыннан исә хәтта үзләре үк безгә күренеп торган минометлар һәм пулеметлардан ут ява башлады. Аръяктагылар дигәнебез инде безнең артиллерия полкы урнашкан мәйданда иде. Дошман белән бугазга-бугаз килеп сугышу чикнең иң кырыенда башланды. Танкка ата торган тупларыбызның күбесе, шулай ук туп-туры бомба төшкән полк штабыннан берничә кеше, шул исәптән безнең белән бергә «кораб» каршылаган старшинабыз һәлак булды. Гитлерчылар исә, бик күп төрле язуларында белдергәнчә, яшен тизлеге белән һөҗүм итәргә, август тирәләрендә Мәскәүдә үзләренең җиңү парадын үткәрергә ашыгалар иде. Безнең полк билгән кечкенә мәйданда озак маташмадылар. Булган бар нәрсәне яндырып, кыра алган хәтлесен кырдылар да ары уздылар. Инде көн уртасында танклар өстенә трусиктан гына менеп басып, кояшта кызынып, шул якка өстәмә көч булып баручы бик күп хәрбиләрне дә күрергә туры килде.

Без, шулай ук күп санлы исәннәр, артта калдык, дошманның үзенчә итеп әйтсәк, без инде камалган идек. Шул тирә урманындагы бер чиркәү подвалына ике дустыбызның ярасын бәйләргә дүртәү төшкән икәнбез. Дүртәү генә дә түгел. Арабызда тагын ике немец бар! Япь-яшь солдатлар. Йөзләрендә — ачу һәм каргыш карасы. Дош-

миләр, сөйләшмиләр. Дөресен әйткәндә, алар белән лыгырдап утырырга безнең әле вакыт та юк. Инде штабка тапшырып булмый үзләрен — без бит хәзер дошман тылында. Вакыт бар әле — сөйләшербез, телләре ачылыр. Чөнки без аларны «тел» буларак кулга төшергән идек. Ә хәзер, барыннан да элек, яралы дусларны кайгыртырга, аларны аякка бастырырга кирәк.

Урман эчендәге чиркәү янында безнең кухня машинасы ватылып калган икән. Туп-тулы ризык. Подвалдан чыгып күрүгә беренче куанычыбыз шул булды. Машинага тагылган казан әле суынып та җитмәгән — итле һәм бәрәңгеле куе аштан җылы бәреп, тәмле ис бөркеп тора. Кузовта бар да бар: ипи, сохари, чәй-шикәр, колбаса, сыр... Хәтта ике савыт эчемлек тә табылды. Дөрес, берсе башланган иде — машинасы белән саубуллашканда, шофер капкалап киткәндер, күрәсең... Кыскасы, тирә-юнь искиткеч тыныч, өс-баш әлегә бөтен, тамак муеннан тук, әмма бик авыр көннәр. Чиркәүгә килүчеләр булса да куркыныч юк — подвалга, әлбәттә, кермәячәкләр. Ә немец егетләре белән безнең эш пешмәде. Бердән, тел белү җитмәде булса кирәк, икенчедән, безнең кайгыбыз алардамыни хәзер! Кылларын тарткалап, нәрсәдер белмәк булып карыйбыз. Нәрсәгәдер инандырып, нигәдер күндереп-ышандыру теләге дә бар: юк, берсе дә кабул итми. Чытык йөзле, җирән чәчле, немец мундиры эченә буен-сынын курадан ясап тыккан шикелле бер шыксыз буйлысы, ниһаять, кесәсеннән русча һәм немецча язып типографиядә басылган кәгазь чыгарды.

— Бу — мин, бу — автор! Бу — мой политика. Бу — мой кәгазь. Мин писал.

Ак ситсыга язылган теге сүзләр иде бу. Җавап бирмәдек. Кызганычка һәм бәхеткә каршы, икесенең берсенә дә тимәдек. Хәтта безнең саф һавалы тын урмандагы мул ризыклы оябызда үзләрен генә хуҗа итеп калдырдык. Яралы иптәшләребезне исән саклап, качыппосып, Белостоктан башлап чигенәсебез бар иде.

Көнчыгышка ашыккан немец машиналары, танк һәм самолетлары сасыткан һава сулышны кыса. Янган авыллар урынында тырпаеп калган кара морҗалар илбасарның алдагы кара көне булып күренә. Тулысынча диярлек хәрабәгә калган калаларны күреп күзләрдән яшь чыга. Кырларда әле генә өлгергән игеннәр башакларын җиргә иеп елыйлар сыман. «Кемгә калдык без,ниләр күрәсе бар икән алда?» ди кебек һәр нәрсә.

Олы юлларга чыкмыйча, дошман техникасы шаулаган тирәләрдән читтәрәк булырга тырышып, чигенәбез дә чигенәбез. Кичен нинди дә булса бер хуторга яки авылга керер булсаң — анда дошманның килү-килмәвен җентекле күзәтергә кирәк. Ә кермичә булмый: тамак ялгыйсы, яңа хәбәрләр ишетеп беләсе бар. Иң мөһиме шул, басып алган җирләрдә илбасар үзен ничек тота?

Толочино тирәсендәге бер авылның кырый йортына су эчәргә кердек. Биш-алты яшьләр чамасындагы бер малай капка төбендә каршылый.

— Су эчеп буламы сездә, егеткәй? — дибез.

— Була, ник булмасын. Әнә кое бар, сиртмәсе эшли. Квас кына юк.

— Нишләп юк?

— Чөнки кичә фронтка баручы немецлар кергән иде. Ике машинага төялеп килделәр: чөмерделәр-чөмерделәр дә квасыбызны, мичкә төбеннән үле чучка баласы килеп чыкты. Җеннәре чыккан немецлар әнине эзли башлады. Ә ул, «кунакларга» йомырка алып килим әле, дигән сылтау белән, тайган икән. Чучка үләксәсен мичкәгә әни үзе салган булган... Ярый әле, немецлар шүрләп һәм ашыгып, авыл-

дан кинәт чыгып сыздылар. Чөнки урман ягыннан мылтык аткан тавышлар ишетелде. Ә анда, абыйлар, нindидер бандит партизаннар бар икән, имеш. Буламы соң шундыйлар?

— Үзең әйтмешли, була, балакай, ник булмасын, менә без үзебез дә хәзер гитлерчыларны үтерүче шул «бандит» партизаннар инде.

Сиртмәле коедан шул чак су эчерткән малайга чын күңелдән әйтелгән рәхмәтне, конвертларга салып, бу көннәрдә дә юллыйсы, ишетерәсе килә.

Әлбәттә, ул хәзер үзе дә агайдыр инде. Әмма аңа сугыш елларындагы немец игъланнары һәм белдерүләре, мөрәҗәгатьләре бәлки билгеле түгелдер.

Истә калганнарының берничәсен сүз уңаенда әйтеп тә узыйк булмаса.

«...Гражданнар! Авыл һәм шәһәрләрегездә качып калган коммунист, командир, комиссар һәм яһүдләрне яшерсәгез — сезнең үзегезне атачакбыз.

...Фюрер гаскәрләренә бирмәс өчен ризык яшерүчеләргә — берниндиди допрос һәм судсыз үлем җәзасы!..

...Төнге сәгатьтә урамга чыгып йөрү катгый тыела. Ут яндырмаска. Бу — совет самолетларына сигнал бирү дип саналачак. Гаепле кешеләрнең барысы да атып үтерелергә, йорт-җиренең көле күккә күтәрелергә тиеш»...

Бу бит шул ук хатлар — чик буендагы теге елга аша шул ук немецлар йөздереп чыгарган шул ук кисәтүле, куркытулы, янаулы мөрәҗәгать сүзләренең дәвамы.

Еллар үтте, бик күп сулар акты дигәндәй, ниһаять, без шул ук белорус җирләрендә Витебск казаннары кайнар көннәргә дә килеп җиттек. «Казан» дигән төшенчә ул чакта дошманның бер төркем гаскәрен камап алып, аны шул түгәрәк казанда кайнату шикелле дөмбәсләүне аңлата иде. 1944 елның җәендә һөҗүм итүче безнең гаскәрләр инде үзләре үк шүрләп чигенә башлаган гитлерчыларны нәкъ шулай дөмбәсләде дә. Саннары инде дүрт йөз меңгә җитә язган белорус партизаннары исә бу һөҗүмгә илбасарларның үз тылыннан торып юл ачышты.

Көчле дә һәм күңелле дә булды ул һөҗүм. Туган җирләребездән илбасарларны бомбардирлар гүләве, туплар шавы, «катюшалар» уты дөрләве куды. Алар хәтта кая басарга белми чапты ул көннәрдә. Ә мәңгегә дөмегеп калганнары аннан да күбрәк иде.

Егып салынгач та баш күтәрергә көннәр-атналар буе кыймаганнары аз булмаганлыгын да әйтик.

Тылларын «чистарту» тәртибендә, бу һөҗүм алдыннан немецлар Витебск өлкәсе партизаннарын да, авиация, танк һәм пехота көче белән кысрыклап, Березина елгасына хәтле чигендергәннәр һәм таркатканнар иде. Командирыбыз Орша шәһәре депосының элекке начальнигы булганга, Заслонов бригадасы партизаннары инде егерме алтынчы июньдә азат ителгән Оршага җыелырга тиеш иде. Иван Вашкин һәм мин — ике разведчик, ике җайдак — шул калага кайтып барабыз. Немецлар куылганнан соң һавалар да сафланып киткән, чәчәкләр дә күркәм балкый, урманнар да күңеллерәк шаулый иде. Атлар янәшә торып үз җайларына атлый бирә, ә без исә әйтеләсе сүзләрне, куанычлы хисләрне тик күңеллерәк, тантаналырак итеп, шаяртыбрак аңлатырга тырышабыз. Юлыбыз уңда тау хәтле үк булып күренгән калкулык буйлап иңкүлектән уза. Моңарчы немецлар гарнизоны булган Обольцы авылыннан чыктык. Чеченево дигән авылга җитәргә нибары ярты чакрым ара бар иде.

һәм... кинәт, көтмәгәндә, тагын сугыш теле белән шаярту ишетәбез. Нәкъ баш өстебездән, һаман шулай ук ямьсез сызгырып һәм чыжлап, өч-дүрт пуля очып узды. Ширбәт эзләп очкан умарта кортлары кебек: үзләре безли, үзләре чакмый. Бик тә сәер атыш иде бу. Җавап бирергә калса — бездә дә автоматлар бар ич. Атларны калку басу ягына борып туктаттык. Корал — кулда. Көтәбез. Әмма атучы юк. Тагын көтәбез. Аяз көн күгенә ракетадан яшел сигнал чөелә. Ниндидер ак ситсы болгыйлар. Димәк, анда кемнәрдер бар, юлыбыз ашыгыч булса да, күрми узу ярамый иде.

Атларыбызны үргә чаптырабыз. Менсәк-карасак — ни күрдек дисезме? Ап-ак арыш кырын ямь-яшел итеп чуарлап бер төркем немец ята. Безне күрүгә торып бастылар. Бит-башлары кап-кара. Йөзләре суырылган, үзләре калтырый. Без «Тыныч булыгыз» дигәнрәк ишарә ясагач, кайберәүләре хәтта җиңел сулап елмаеп та куйды. Арадан берсе аягүрә басты да безгә баш иде, аннары «ур-ур» дип башлап үзенекеләргә нәрсәдер әйтте дә, ике солдат башыннан ике пилотка алып, шуларга тегеләрнең сәгатьләрен салдырып тутыра башлады. Икенчесе исә барчасының автомат һәм пистолетларын җыеп бер кучкә өйде. Аннары күкрәгенә кулын куеп, «биредә ышанычлы документым да бар» дип әйтте. Ике пилоткадагы сиксән алты сәгатьне исә безнең икебезгә тапшырганда офицер, үзенә калса, көчәнеп түгел, ә бары тик эчкерсез булырга тырышып бер генә нәрсә үтенде:

— Зинһар хәрби комендатурага илтеп куя күрегез. Минем авторотадан Витебск казанында исән калганнар шушылар. Бу кырда инде алты көн ятабыз. Авылга керүе һәм кешегә күренүе куркыныч. Солдат булмасагыз да, күрәм, сез хәрбиләр, зинһар хәлебезгә керегез. Дәһшәтле сугыштан исән калганбыз икән — яшик тә инде. Берберебезне үтерешмәс-кырышмас өчен яшик...

Теләкләре кабул ителде. Беребез атын авылга тиз генә юргалатты да, бер малай аннан олау белән килде. Корал һәм сәгатьләрне шуңа салдык. Немецлар, әнкәләренә ияреп су буена ашыккан үрдәк бәбкәләредәй, бер-бер артлы тезелешеп шул арба артыннан атладылар.

Рясноның барча йортларыннан диярлек хәзинәдә булган барлык ипи һәм бәрәңгене җыеп көтелмәгән «кунакларга» барча хатын-кыз (чөнки бөтенесенә берәр сәгать эләкте!) аш-су пешергән арада без «кунаклар» башлыгы белән танышып алырга теләдек. Авторотаның командиры булган икән. Сугышны Белосток өлкәсендә безнең чик буенда башлаган.

— Беренче һөҗүмне танкларга ата торган полкны тар-мар итүдән башладык. Икебезне әсир иттеләр дә, сезнекеләр безне атна буе ашатты, эчерде, хәтта кемнәрдәндер яшереп урман аланындагы чиркәү подвалында асрады. Һәм без исән калдык... Ә Гитлер сугышының өермәле җилләре безне тагын үз кочагына бөтереп алгач... менә без Витебск казанында кайнап та исән калдык. Моның өчен кемгә тиеш булса, шуңа рәхмәт!

Офицерның күзенә текәлебрәк карарга туры килде. Ничектер таныш шикелле. Төсе шул, кашларын еш-еш сикерткәләве дә шундый. Тукта, теге чакта ашарга биргәнне алмаганда бик усал итеп караган иде түгелме соң? Тәртәгә бик каты типсә дә, шул «тел»нең телен кисмичә калдык түгелме соң без?!.

Әйе, шул немец, шул офицер булып чыкты. Инде хәзер аның күкрәк кесәсендә нинди документ барын да белергә кирәк.

Сорыйбыз, күрсәтә һәм аңлатырга ашыга:

— Бу, дөресен әйткәндә — пропуск, бу — пароль. Шуны күрсәтеп, күпләр үзен совет хәрбиләренә плен бирелергә хаклы санады.

Чөнки бөтен сүзләре дә дөрес, барысы да чын моның. Хатны яттан белүче солдатларның да бик күбен беләм мин. Андыйлардан берәү безнең арада да бар. Сәбәбе шул: тизрәк әсир төшәр өчен ятлаганнар. Гитлер коткысына бирелеп, без язган мәгънәсез хатларга каршы иң мәгънәле, иң гади һәм иң төшендергеч чын солдатча хат дип саныйм мин моны һәм, истәлек итеп, әсир итүегез өчен рәхмәтләр әйтеп, минем бөтен булмыш авторота исеменнән аны сезгә бирәм.

Тылга җибәрелгән совет матбугатыннан укып без инде белә идек ул хатны. Аны украин дуслар — әллә каләм осталары, әллә үткен телле җор партизаннар инде?! — үз телләрендә усал шигырь итеп язганнар.

Исеме дә бик дөрес куелган: «Фашист көчегенә — Гитлер әнчегенә». Бик күпләргә бик дөрес адресланган хат ул. Фашистлар: «Башларыбыз исән кала күрсен, бары тик әсир генә итегез!» дигән сүзләрне, күзләребезгә ялварулы карап, шул хатның шундый сүзләре белән үтенделәр:

«Син бер ата эт белән бер ана эттән яралган, һәм синең әшәке токым дөньяга таралган. Әйткәнебез хак саналгыры (бугазыңа казык кадалгыры!). Исәннәрбез, сауларбыз, урмандагы нык имәндәй шауларбыз... Синең өереңә исә чын күңелдән шуны телибез: сөйләсәгез— телегез корсын, йөгерсәгез — аягыгыз сынсын, аркагызга таяклар яусын, салкыннарда туңып катыгыз, тизрәк кереп гүрдә ятыгыз... Син бит әле күптән түгел генә шапырынган идең, канлы кулларыңны уып акырынган идең, явыз өереңне җыйган, үз тиреңә көчкә сыйган идең: имеш, партизаннарның тетмәсен тетәм, алар торган авылларны көл-күмер итәм, барчасының канын эчеп туенам, һәм биергә килә мин зур җиңү туена,—дигән идең. Имеш, изәм мин дошманымны һәм аның сулышын буам, мин алар өстенә зур танклар куам, күңеллерәк булсын өчен —самолет та өстәрмен. Җитәр, чиге булсын минем тылымдагы кыргый эшләрнең! Тынычлап калыр юлларым, сезнең барыгызга да кулым җитәр!..— дигән идең.

Ә без әйттек сиңа, кеше ашаучы: һәр адымыңда сине үлем көтәр! — дидек.

Диңгез суын эчеп бетереп булмый, кендектән югары сикереп булмый, яланда искән җилне диңгезгә күчереп булмый. Нәкъ шуның кебек үк, без партизаннарны да күрергә, кырырга мөмкин түгел — мең тапкырлар антлар итсәң дә, кайсы якка эзләп китсәң дә — юк, мөмкин түгел! Чөнки без үч алучылар, хак юлдан баручылар. Куркытмый безне машинаң, куркытмый танкларың, яндырырбыз-көйдерербез утларга салып барын. Кирәксә — капкын куябыз, кирәк икән — тешлибез. Бөтенесен эшлибез.

Машинагыз алга атыла... Һәм минага бәрелеп ватыла. Танкларыгызны да шулай ук ватабыз. Кыскасы, барчагызга капут сезнең, барчагызның анасын сатабыз. Кыскасы, сез инде барыгыз да — тере үләксә, берегез дә лаек түгел шуннан артык теләккә.

Ә самолетларыгыз безне эчләр катырып көлдерде генә. Урман өсләреннән очып үттеләр, пуля һәм бомбалар сиптеләр, миналарыгыз да бертуктаусыз шартлады, ләкин үлем безне тапмады. Настя әбинең ике тавыгын үтергәнсез дә күпер төбендә бер сыерның койрыгын өзгәнсез... Ышансаң ышанасың, ышанмасаң — кирәкми, билләһи дип әйтәбез, сезгә шуннан артыгы кирәкми.

Ат башлы зат син! Алай гына да түгел, чучка колаклы ат син. Акылың булса, безнең радионы тыңлар идең дә, дөреслекне аңлар идең. Башыңда чүп үлән үсә, башыңда томан, фронт хәлләрен ишетсәң — колагың тонар. Очкычларың генералы Кицингерга ышанма, Украина комиссарың Кохыңны да тыңлама — без көчле дигән булып,

сине алдый алар, ялганлаган сүзләренең очын-очка көчкә ялгый алар. Мактанып язганнар икән: имеш, партизаннарны кырабыз! Ә без андый бушбугазны бары көлеп тыңлап торабыз.

Ә фронт хәлләрен сиңа белергә кирәк иде. Меңләгән этең дөмекмәгән көн хәзер сирәк инде! Сезнекеләрне безнекеләр тукмый, шуңа күрә безнең күңелләр көр, ишет тә шуның барысын — хәзердән кабергә кер!

Ай-һай яхшы тукмыйлар да соң! Миңгерәтмичә сукмыйлар, үтермичә екмыйлар. Курск һәм Орел янында сезнекеләр күпләп кыйналды — бер кабергә берничә гаскәр җыйналды. Белгород янында да арнецлар каны күп акты, анда да синекеләр кабергә кереп ятты. Сицилиядә дә кирәгегезне бирәләр, Донбасста да ипи шүрлегегезне төяләр. Партизаннар сез фрицны рәхәтләнеп сыйлый, чөнки халык үче һич йөрәккә сыймый!..

Ишетәсеңме, чучка борын! Бу дөньяда калмый сезгә урын.

Күпне әйттек шикелле, ләкин сезгә барыбер аз болар. Ышбу хатны 1943 елның җәендә Н отряды партизаннары яздылар» [1].

Фашистлар ашаган-эчкән арада без авылдагы таныш-белешләрнең өйләренә кергәләп йөрдек, безнең гаскәрләр һөҗүменең инде Минск тирәсендә башлануы хакында түбәләрне күкләргә тидереп сөйләштек.

Инде әсирләр белән дә, авыл белән дә аерылышырга вакыт иде.

Сугышка чаклы авыл советы, ә сугыш елларында исә немецларның волость идарәсе булган бина янындагы мәйданга чыктык. Немецларны, шул бина каршысына тезеп, яшел чирәмгә утыртканнар. Әмма алар бөтенләй немец түгел кебек инде. Өс-башларында — тоташтан безнең кием: берсе совет солдатының иске чалбарын, берсе киндер ыштан киеп алган, күлмәкләре гаять чуар, арада ямаулылары һәм ертыклары да аз түгел. Ә авылның күпчелек бала-чагасы, хәтта хатын-кызлар һәм карт-коры да — яшел сукно китель чалбарлар, пилоткалар кигән! Тиздән тантана ителәчәк җиңүебез парады яки карнавалына килергә махсус әзерләнәләр диярсең.

Күңелле дисәң дә күңелле тамаша ичмаса!

Ә хикмәт шунда икән: немецлар үз киемнәрен үзләре салып халыкка өләшкән, безгә нәрсә дә ярый дип, биргән теләсә нинди кием-не алганнар. Исән калган башлары өчен рәхмәт әйтергә бүтән чара булмаганга, әлбәттә...

Немец киемле авылдашлар — тезелешеп утырган немецлар рәте артына барып басты. Каршыга өстәл чыгарып куйдылар. Авторота сугышчылары арасында әлеге хатны яттан белгән берәү өчен трибуна иде бу. Үз командирлары шулай теләгән: «Әйдә, истәлеккә шуны да укып калдырсын инде, белсен-ишетсен халык...»

Тәбәнәгрәк буйлы, киярена галифе чалбар һәм жилет эләккән бер солдат ул хатны, төрле ишарәләр ясый-ясый, үзенекеләргә мөрәҗәгать итеп, артистларча диярлек матур итеп, пафос белән укыды. Башта немецлар, аннары безнекеләр кул чапты.

Шушы алкышлардан соң «таралышырга!» дигән бүтән сигналны көтәргә кирәк тә түгел иде. Якындагы комендатуралы авылга немецларны без, әлбәттә, озата бармадык. Аларны, кораллары кырда ук төялгән арбага утырып, ике малай алып китте. Юл күрсәтер өчен...

Безнең маршрут исә Орша ягына таба дәвам итте.

1976.

---

[1] Хатның төп нөсхәсе Ватан сугышы партизаннарының атаклы башлыкларыннан берсе Сабуров архивында саклана.

## Гамил Афзал

### Уены-чыны белән...

Халыкка акыл өләшәм
Уены-чыны белән,
Тәрәккый өчен көрәшәм
Уены-чыны белән.

Искелекне тәнкыйть итәм
Уены-чыны белән,
Яңалыктан мактау көтәм
Уены-чыны белән.

Мактаганны әйбәт диләр
Уены-чыны белән,
Хурлаганны гайбәт диләр
Уены-чыны белән.

Лирикада гөрләп торам
Уены-чыны белән,
Сатирадан шүрләп торам
Уены-чыны белән.

Елмаям да сызланам мин
Уены-чыны белән,
Шайтанны да кызганам мин
Уены-чыны белән.

### Кызганычка каршы

Рестораннар ачык тора,
Кызганычка каршы,
Баш авыртса кер дә сора,
Кызганычка каршы.

Ике егет кул бирделәр,
Кызганычка каршы,
Ишек ачып юл бирделәр,
Кызганычка каршы.

Син, бай абзый, юмарт, диләр,
Кызганычка каршы,
Күңелләрне юат, диләр,
Кызганычка каршы.

Алып коньяк, алып сыра,
Кызганычка каршы,
Яшь йөрәкләр янып тора,
Кызганычка каршы.

Мин бик оста диеп җырга,
Кызганычка каршы,
И тотындым мактанырга,
Кызганычка каршы.

Биш тә сиксән, ун да сиксән,
Кызганычка каршы,
Получкадан җилләр искән,
Кызганычка каршы.

Акыл керде «янгач» кына,
Кызганычка каршы,
Хәерчегә калгач кына,
Кызганычка каршы.

## Төлке белән Карга

*Иске мәсәлнең заманча варианты*

Алла биргән сырны тешләп Карга иптәш,
Агач башына кунып бисмилла иткәч,
Күзе төште: Төлке килә биеп-биеп,
Ашау вакытын көтеп кенә йөргән кебек.

— Сандугачкай, — диде Төлке кырын ятып, —
Сиңа хәзер операга керер вакыт,
Җырлачы, дус, дан шаулатып Европага,
Шаккатсын бер иң шәп җырчы-артистлар да.

Сырны Карга тырнагына кыстырды да:
— Экономик белем хас, — ди, — безнең чорга,
Малны хәзер ычкындырмый тырнак, — диде, —
Крылов чоры үтте инде, дурак! — диде.

## Анкета

Мин революция дә ясамадым,
Аның контры да булмадым,
Тәк,
Тудым да пава суладым.

Тарих тәгәрмәче әйләнгәндә
Туктасын дип таяк тыкмадым.
Буржуй класс безгә бәйләнгәндә
Буш имезлек кабып йокладым.

Ыштан белән балык тоттым мин,
Иң әшәке сүзләр оттым мин,
Тарих арбасына утырырга
Халык арасыннан чыктым мин.

Көрәк кулда иде, сәнәк кулда,
Ямаулы чалбарда буш кесә.
Баш борылды минем уңга-сулга,
Кайсы яктан көчле җил иссә.

Һәр фигура гел үзенчә бора,
Миңа инде нәрсә борасы!
Фигураның ярдәмчесе була —
Юлны бозмый чапкан юргасы.

Регламентлы гомер уткәрәм мин,
Күтәр дигәч, кулны күтәрәм,
Тантаналы минут кичерәм дә,
Төшер дигәч, кулны төшерәм.

Зур мандатлар ятмый кесәләрдә,
Урта хәлле актив булганмын.
Мин, мөгаен, ямьле кичәләрдә
Доклад тыңлар өчен туганмын.

... Даның күкрәп барса гасырларга,
Әрсез хыял чикләрне белми.
Юк, кирәкми, кыстамасыннар да,
Зур начальник буласы килми...

## Кашфел Задә

### Чехов язганча...

Сердәшем — Чехов язганча! —
«Маэмай иярткән» ханым.
Нәни болонка бүлмәдә,
Исеме «Маркиз» аның.

Баскычтан менеп, баскач та
Звонок төймәсенә,
Шашынып өрә шул әнчек, —
Җир тетрәвенме сизә?

Көнләпме гүзәл хуҗасын,
Әллә уйнапмы юри? —
Ул синең янда бик озак
Агрессив төстә йөри!

... Сердәшем — Чехов язарлык,
Романга лаек ханым.
Болонкасына нан биреп
Ул гәпкә күчә тагын.

Бальзак стилендә матур,
Гаҗәп бай «будуар»да
Сөйләшәбез, гөрләшәбез,
Китаптагыча — бар да.

... Тик бер мин кунак булмыймдыр
Ханымның бүлмәсендә:
Бик еш кагылып китәләр
Звонок төймәсенә.

... Тетрәвен җанның сизәмсең,
Ник, «Маркиз», өрәсең, ә?!

## Ганимед

*Зөлфәткә*

Юк, язмыштан узып килми бәхет,
Истигъдатлы заттан булсаң да:
Яшь Ганимед тансык Юпитерга,
Яшь шәкертләр кирәк остазга.

Мәңгелектә исемең — Олимпта син,
Гәрчә гади сакый син анда.
Җирдә исә кеше тиз искерә,
Яңаларга мода дөньяда!

Килә буын, китә... Үсә тора
Яңа яшь шәкертләр остазга.
... Юк язмыштан узмыш. Кими бәхетең,
Истигъдатлы җаның булса да.
Әнә Ганимедлар күккә ашкан,
Акырып-елап җирдә туса да.

Әллә шулмы үрнәк дөньяда?!

## Рөстәм Мингалимов

### Миңа ничек ышанырсың?

Тау артында бер таш булыр,
Таш эчендә чәчәк булыр.
Аны барып алырсың.
Эчендә чәчәк күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?!

Яр өстендә бер таш булыр,
Таш эчендә бер кош булыр.
Аны барып алырсың.
Эчендә кошын күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?!

Су төбендә бер таш булыр,
Таш эчендә кеше булыр.
Аны үрелеп алырсың.
Эчендә кеше күрмәсәң,
Миңа ничек ышанырсың?!

Бер ташыңнан чәчәк ясыйм,
Бер ташыңнан мин кош ясыйм,
Бер ташыңнан кеше ясыйм,
Шунда миңа ышанырсың.

### Кем кычкыра?

Әле көннәр җылы тора,
Әле август ае гына...
«Күз кылә!» — дип
Кем кычкыра?
Ышанырга микән моңа? —
Тыңлап йөрим бу тавышны,
Мин урманны тыңлап йөрим.
Әллә монда бармы икән
Кеше телен белгән бүре?!
Әллә шундый куян бармы,
Кычкырамы «Күз кылә!» — дип?!
Кем кычкыра, үзен күрмим:
«Күз кылә!» ди. Ишетелә бит.

Әй алдакчы — азгын төлке!
Синме шулай кычкырасың?
Әйткән сүзең дөрес булса,
Качып кына кычкырма син.
... Тукта, төлке булмады бу;
Август каеннары икән:
«Күз килә!» дип кычкыралар,
Тавышлары —
Соры икән.

## Әкәмәтнең ике авызы

Чирәмдә йөри чын казлар,
Чын малай булсаң син монда,
Бу гел гаҗәп түгел.
Узып барса бер матур кыз,
Син аңа «Исәнме?» дисәң,
Бу да гаҗәп түгел.
«Әйдә икәү уйныйк!» дисәң,
Аңа чәчәк өзеп бирсәң,
Бу да гаҗәп түгел.
Йөгерсәгез, егылсагыз,
Кыз еласа, син юатсаң,
Бу да гаҗәп түгел.
Шунда, имеш, каршыгызга
Килсә нииндидер әкәмәт?!
Әкәмәтнең ике авызы,
Бер күзе, биш мөгезе булса,
Бу да гаҗәп түгел.
Кулларын сузса әкәмәт:
«Миңа бир бу кызны!» — дисә.
Син куркыныч әкәмәтне
Мөгезеннән алып күтәрсәң,
Аны шулай болгап торсаң,
Аннан еракка тондырсаң,
Бу да гаҗәп түгел.
... Инде казлар ерак йөрсә,
Кыз өенә кайтып китсә...
... Сиңа ялгыз кыен булса,
Бу да гаҗәп түгел.
Барып казларга кушылсаң,
Син ак каз була алмассың,
Бу да гаҗәп түгел.

Малай дигән исем йөртеп,
Чын малай була алмасаң?! —
Менә бу инде гаҗәп,
Бусы әйбәт түгел.

*Журналыбызның былтыргы 6—7 саннарында чыккан «Без бәләкәй чакларда» повестена карата укучылардан редакциягә һәм автор исеменә хатлар килде. Алар повестьны кызыксынып укуларын язалар. Кайберәүләр күптән югалткан танышларының исемнәрен шушы әсәрдә очраталар, тарихка, бүгенге көн проблемаларына кагылышлы мәсьәләләр хакында автор белән фикерләрен уртаклашалар. Шул хатларның кайберләрен укучыларыбызга тәкъдим итәбез.*

Хөрмәтле Мирсәй Әмир ага!

«Без бәләкәй чакларда» повестеның беренче китабын бик яратып укып чыктым. Сезнең буын белгән, безнең буын да бераз «койрыгын» күреп калган, якын киләчәктә ерак тарихка әйләнеп калачак авыл тормышын, халыкның шатлык-кайгыларын, көнкүрешнең көн дә туып торган мең төрле мәшәкатьләрен бөтен ваклыклары белән чынбарлыкның нәкъ үзе итеп сурәтләү өчен, ул тормышны үз күзләрең белән күреп, аның эчендә кайнарга кирәк булган шул.

Ул заман кешеләренең әдәп кагыйдәләре, тәрбия ысуллары хәзерге заман өчен дә үрнәк булырлык булган икән. Бала тәрбияләү турында берниндн китап укымаган ата-аналар нинди яхшы кешеләр тәрбияли алганнар. Моңа алар табигатькә якын булулары, гомер буе хезмәт белән яшәүләре аркасында ирешкәннәрдер. Тормыш никадәр авыр булмасын, балаларның бала чагын кояшлы, шатлыклы итәргә тырышканнар. Аһ-зарларын, вакытыннан алда балаларга сиздермичә, күңел түренә катлау-катлау итеп салып, эчтән генә кичергәннәр. Балада яхшы кешелек сыйфатлары тәрбияләүне үтә җаваплы һәм үзләренең иң изге бурычлары дип санаганнар. Хәтта башка кешеләрнең балалары язмышы өчен дә үзләрен җаваплы хис иткәннәр. Бик тә күркәм сыйфатлар бит! Безнең заман кешесе үзенә күчерердәй матур гадәтләр аларда җитәрлек.

Әсәрнең теле юморга бай, матур. Уфа белән Оренбургны тоташтырган, ике ягында ак каеннар тезелгән олы юл, шул юлдан, тарантаска утырып, калага барганда кечкенә Мирсәяфнең ашкыну-соклanулары, Агыйдел буйлары, мәһабәт таулар, башкорт авылларын тасвирлаганда никадәр шигърият! Туган як табигатенең гүзәллеген, беренче мәхәббәттәй итеп, шулай назлап сурәтләү каты күңелләрне дә битараф калдырмас.

Ш. Маннурның «Агымсуларга карап» повестенда һәм Сезнең бу әсәрегездә әниләргә дан җырлау җанга бик якын булып калды. Әсәрдә ана образы җылы бер дулкын булып тирбәлеп тора. Аналар йөрәге мәрхәмәткә, мәхәббәткә никадәр бай, юмарт. Алардагы гаделлеккә, әхлакый сафлыкка сокланмый мөмкин түгел. Семья, балалар хакына теләсә нинди фидакарьлеккә әзер алар. Ана турында язган юлларыгызда, шагыйрь әйтмешли, «нәкъ бер кочак кояш бар сыман». Өлкән язучыларның мондый әсәрләре безнең әниләргә тыйнак һәйкәл, матур симфония ул. Гомумән, Горькийлардан килгән традицияне дәвам иттерүче өлкән язучыларыбызның автобиографик әсәрләренең тәрбияви әһәмияте бәяләп бетергесез. Алар укучыда бүгенгенең кадерен белү, киләчәкне тагын да матурлауга омтылу хисләре тәрбияләү белән кыйммәт.

**Н. ЗАРИПОВА.**

Кукмара районы, Мәчкәрә авылы.

Хөрмәтле Мирсәй абый!

Мин, «Казан утлары»н даими укып баручы буларак, Сезнең «Без бәләкәй чакларда» дигән автобиографик повестегызны да укып чыктым. Бик ошады ул миңа. Бөек Ватан сугышы елларында авыл малае булганлыктан, ат, үгез белән интеккән, утын белән арбаларым авып җәфа чиккән чакларымны уйламастан исемә төшердегез. Әсәрнең теле дә матур: үзе гади, үзе тапкыр да язылган.

Сезнең әсәрне мин «Белорет — Чишмә» тимер юлы трассасында эшләгәндә укыган идем. «Казан утлары» — миңа юлдаш ул. Мин андагы шигырьләрне ял иткәндә иптәшләремә дә кычкырып укыйм. Ләззәт һәм илһам алам.

Мирсәй абый! Сезнең әсәрләрегез миңа мәктәп елларыннан ук таныш. Алар безгә эшебездә һәм тормышыбызда көч һәм дәрт өсти. Шуның өчен кайнар рәхмәт Сезгә!

Коммунистлар сәламе белән
**Әмир МӨЛЕКОВ,**
Башкортстан, Кырмыскалы районы, Иске Шәрәй авылы.

Хөрмәтле Мирсәяф иптәш!

Сәлам һәм изге теләкләр Сезгә.

«Без бәләкәй чакларда»ны укып чыктым да, таныш булмаган кешегә хат язарга уйладым. Хикмәт шәхси танышлыкта гына түгел бит. Узганда «Агыйдел» дә, «Балыкчы ялганнары» да укылган. Язучы йөрәктә җылы урын алган.

Бүген кулга каләм алуның аерым сәбәбе бар: мин унтугызынчы ел башында Стәрлетамакта торган, күп кенә совет активы белән танышкан, егерменче елларда комсомол өлкә комитетында һәм, Давыт Юлтый белән бергәләп, «Башкортстан»да эшләгән кеше.

Повестьның беренче өлешендә миңа таныш авыллар, географик атамалар, хәтта тормышыма бәйләнешле кеше исемнәре очрый башлады. Тасвирланган тормыш, үзем кичергән сәхифәләр авыл энциклопедиясе кебек тоелды.

«Беренче укытучым» турындагы битләрне укый башлагач, мин иске көндәлегемне алдым да 1919 елда Мәскәүдә Я. М. Свердлов исемендәге коммунистик университетта укучыларның исемлеген эзләп таптым. Башкортстаннан баручы 30 кеше арасында икенче урында Һидият Сибгатулла улы Сәгъдиев тора. Аның университетның Совет бүлегендә «Үзәк һәм җирле идарәләр» секциясендә укуы, өстәмә рәвештә рус теле һәм математика дәресләренә йөрүе язылган. Аның Азнай волосте Тирмән-Елга авылы башкорты икәне әйтелгән.

Миннән 7—8 яшьләргә өлкәнрәк бу курсант активлардан, әңгәмәләрдә актив катнашучылардан иде. Асадуллаев мәктәбе клубында Борһан Мансур рәислегендә уздырылган бер митингта (анда шәрык илләре вәкилләре дә бар иде) ул башкортлар исеменнән чыгыш ясады...

В. И. Ленин 1919 елның 11 июль, 29 август көннәрендә свердловчыларга «Дәүләт турында» лекция укыган иде. 1969 елда «Правда» газетасы (10 июль) шул турыда безнең истәлекне басты. Бу иске дуслар арасында хат язышa башлауны кузгатып җибәрде. Әмма Сәгъдиевнең кайда икәнлеге беленмәде. Шуңа күрә «Минем беренче укытучым» үзем өчен бер ачыш, югалганны табу булды.

Укуны тәмамлагач, Сәгъдиев белән мине Петроградка җибәрделәр. Аны атлы дивизия политбүлеге мөдире иттеләр, мин «Салават» газетасын чыгару эшенә чумдым. Сугыш беткәч, башкорт кызылармеецларын укытырга керештек. 1920 ел уртасында мин вагоннардагы күчмә типографияне Раевкага китереп, Стәрлетамактагы Башполиграфка тапшырдым. Хәтерем ялгыштырмаса, Сәгъдиев мәгариф комиссариатына кайтты...

Сезгә сәламәтлек һәм авыр, мәшәкатьле хезмәтегездә уңышлар теләп,

**ХӘЙДӘР ИШМОРАТОВ.** Минзәлә.

## ӘДӘБИ ЕЛ ЙОМГАКЛАРЫ

7 һәм 8 февраль көннәрендә Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында 1977 әдәби ел йомгакларына багышланган җыелыш булып үтте. Прозаикларыбыз һәм шагыйрьләребез, драматурглар, публицистлар, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр үткән елда укучыларның киң массасына күпме һәм нинди иҗат җимешләре бүләк иткәннәр, әдәбиятыбызны нинди яңа әсәрләре һәм хезмәтләре белән баетканнар, туктаусыз үзгәрә һәм яңара бара торган тормыш-чынбарлыкның иң күркәм хасиятләрен сәнгатьчә үзләштерүдә, хезмәт кешесенең тирән һәм күпкырлы күңел дөньясын чагылдыруда уңыш-табышлары ни дәрәҗәдә — шул хакта җитди сөйләшү, фикерләр уртаклашу иде ул.

1977 елда матбугат битләрендә дөнья күргән проза әсәрләре хакындагы докладны филология фәннәре кандидаты Рифат Сверигин сөйләде. Ул үткән елның роман-повесть кебек күләмле әсәрләргә, заманыбыз геройларын гәүдәләндергән хикәяләргә шактый мул ел булуын билгеләп үтте. Г. Ахуновның «Идел кызы» романын, М. Әмирнең «Без бәләкәй чакларда», Ә. Баяновның «Тавыш — табигать бүләге», Г. Рәхимнең «Көннәр язга авышкач», Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы» повестьларын һәм башка күп кенә әсәрләрне әдәби тормышыбызда вакыйга булырлык, әдәбиятка яңа образлар алып килә торган җитди әсәрләр дип бәяләде. Докладта прозаикларыбызның иҗади табышлары, әсәрләрдәге хис-фикер байлыгы анализга алынды, аерым йомшак яклар, кимчелекләр күрсәтелде, алдагы бурычлар, җитәсе үрләр күздән кичерелде.

1977 елның тезмә әсәрләре хакында шагыйрь Зөлфәт Маликов доклад ясады. Ул шигъриятебезнең заман белән бергә атлавын, шагыйрьләрнең бүгенге көн проблемалары белән дулкынланып, иҗат ялкынында гамь чигеп, заманыбызның иң җитди мәсьәләләрен калку һәм лаеклы гәүдәләндерергә омтылып иҗат итүләрен сөйләде. С. Хәким, Н. Арсланов кебек өлкән буын каләм осталары, И. Юзеев, С. Сөләйманова, Р. Фәйзуллин. Г. Рәхим, Роберт Әхмәтҗанов, Ф. Шәфигуллин, Р. Хәлиуллина, М. Әгъләмов, К. Булатова һ. б. кебек урта һәм яшь буын шагыйрьләренең күп кенә әсәрләренә докладта югары бәя бирелде.

Үткән елдагы очерклар һәм публицистик әсәрләргә багышланган докладында Илдар Низамов та каләм ияләребезнең гражданлык активлыкларын, аларның тормыштагы өлгереп җиткән һәм хәл ителергә тиешле мәсьәләләрне күтәргән мәкаләләр, хезмәт батырларының әдәби портретлары һәм башка төрле материаллар белән матбугатта еш чыгыш ясауларын билгеләп үтте, алда торган бурычларны хәл итүдә публицистларны тагын да зуррак дәрт һәм ялкын белән эшләргә чакырды.

Җыелышта шулай ук сәхнә әсәрләре турында драматург Туфан Миңнуллин, балалар әдәбияты хакында шагыйрь Роберт Миңнуллин, яшүсмерләргә багышланган әсәрләр хакында Равил Кукушкин, Татарстанда яшәүче рус язучылары иҗаты турында Геннадий Паушкин, татарчага тәрҗемә ителгән әсәрләр хакында Рим Ширязданов доклад сөйләделәр. Әдәби тәнкыйть хакында филология фәннәре кандидаты Рафаэль Мостафин, Татарстан Язучылар союзы идарәсенең 1977 елдагы оештыру эшләре турында идарәнең председатель урынбасары Фәрваз Миңнуллин, союзның яшь язучыларны иҗади үстерү буенча алып барган эшләре хакында идарә консультанты шагыйрь Илдар Юзеев докладлары тыңланды.

Шагыйрь Сибгат Хәким, филология фәннәре докторы Нил Юзиев, театр белгече, сәнгать фәннәре кандидаты Илтани Илялова, Язучылар союзының Әлмәт бүлеге секретаре шагыйрь Әдип Маликов, драматург Диас Вәлиев, шагыйрь Гәрәй Рәхим, балалар язучысы Ләбибә Ихсанова, прозаик Фатих Хөсни, шагыйрь Салих Баттал, яшь шагыйрь Госман Садә, прозаиклар Җәүдәт Тәрҗеманов, Вакыйф Нуруллин, Язучылар союзы идарәсе секретаре прозаик Мөсогыйть Хәбибуллин, шагыйрь Зәки Нури трибунага чыгып, ел дәвамында дөнья күргән әсәрләрнең идея эчтәлек һәм сәнгатьчә эшләнеш дәрәҗәләре, аларның заман таләпләренә ни дәрәҗәдә җавап бирүе, уңай һәм кимчелекле яклары, бүгенге әдәби хәрәкәт, иҗат һәм оештыру мәсьәләләре хакындагы фикерләре белән уртаклаштылар, хезмәт кешесе образын тагын да калкурак, тирәнрәк һәм тулырак гәүдәләндерүдә, чорыбызга лаек булырлык әсәрләр иҗат итүдәге яңа бурычларны күңел күзе аша үткәрделәр.

Җыелышта КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире Мөдәррис Мусинович Мусин катнашты. Үзенең чыгышында ул иҗат көчләрен тирән идеяләр, бүгенге һәм киләчәк рухы белән сугарылган киң күләмле әсәрләр иҗат итүгә тупларга, заманның алга әйдәп баручы күренешләрен, КамАЗ кебек бөек төзелешләрнең бүгенге чынбар-

лыкка ясаган тирән йогынтысын кыюрак өйрәнергә һәм әдәбиятта калкурак сурәтләргә чакырды.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов җыелышка йомгак ясады.

### ПОЭЗИЯ КИЧӘСЕ

8 февраль көнне Казан шәһәренең Төзүчеләр культура сарае залына йөзләрчә әдәбият сөючеләр җыелган иде. Әдәби елга йомгак ясау уңае белән монда зур поэзия кичәсе булып үтте. Шагыйрьләребездән Нури Арсланов, Әхмәт Исхак, Илдар Юзеев, Нәби Дәүли, Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин, Рөстәм Мингалимов, Зөлфәт, Роберт Миңнуллин, Разил Вәлиев, Клара Булатова һәм башкалар үзләренең яңа шигырьләрен укыдылар. Кичәне өлкән шагыйрь Сибгат Хәким алып барды.

### ТАНТАНАЛЫ КИЧӘ

Казанның Актерлар йортында күренекле татар совет язучысы Фатих Хөснинең тууына 70 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып үтте. Аны кереш сүз белән язучы Вакыйф Нуруллин ачты. Юбилярның иҗат юлы хакында филология фәннәре кандидаты Рифат Сверигин доклад ясады. Республика иҗат оешмаларыннан, предприятие һәм учреждениеләрдән килгән вәкилләр әдипне юбилее белән кайнар котладылар, яңа иҗат уңышлары теләделәр. КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев Фатих Хөснигә Октябрь Революциясе ордены тапшырды. Язучы хөкүмәтебезнең бу югары бүләгенә совет әдәбиятын үстерүгә керткән хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән лаек булды. Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

### ФРОНТОВИК ЯЗУЧЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШУ

Татарстан язучыларының Г. Тукай исемендәге клубында фронтовик язучылар белән очрашу кичәсе булды. Совет Армиясенең 60 еллыгына багышланган бу кичәдә М. Горький һәм Г. Тукай премияләре лауреаты Сибгат Хәким, өлкән шагыйрьләребез Нури Арсланов, Әхмәт Исхак, Мөхәммәт Садри, язучылар Госман Бакиров, Геннадий Паушкин фронт истәлекләре белән уртаклашып, совет солдатларының тиңсез фидакарьлеге хакында сөйләделәр, әсәрләрен укыдылар. Анда шулай ук мәрхүм фронтовик шагыйрьләр Шәрәф Мөдәррис, Әнвәр Давыдовның магнитофон тасмасына язып алынган чыгышлары тыңланды.

### МУСА ҖӘЛИЛГӘ БАГЫШЛАП

СССР Кораллы Көчләренең 60 еллыгы уңае белән Васильево санаториендә Советлар Союзы Герое патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган рәсемнәр күргәзмәсе оештырылды. Күп художникларның төрле жанрда иҗат иткән әсәрләрен хронологик тәртиптә тезеп күрсәтү шагыйрьнең тормыш юлын бер бөтен хикәят итеп күз алдына бастыра.

### ӘДИПЛӘРЕБЕЗ ӘСӘРЛӘРЕ ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР ТЕЛЛӘРЕНДӘ

«Прогресс» нәшриятында «Европа поэзиясе» дигән сериядән 3 нче томның 2 нче китабы чыкты. Ул Советлар Союзы халыкларының классик һәм бүгенге шагыйрьләре иҗатын берләштерә. Шигырьләр рус телендә һәм инглиз, немец, француз телләренә тәрҗемәдә бирелә. Китапка Советлар Союзы Герое Муса Җәлилнең «Була кайчак», «Җырларым», «Катыйльгә» дигән шигырьләре кергән. Алар танылган тәрҗемә осталары С. Липкин, В. Ганиев, С. Маршак тәрҗемәсендә, ә «Була кайчак» дигән шигырь оригиналында да бирелгән.

*
* *

«Советская Россия» нәшриятында «Подвиг» сериясеннән «Этих дней не смолкнет слава» дип исемләнгән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде.

Китапта илебез шагыйрьләренең Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы темасына багышланган шигырьләре тупланган. Н. Исәнбәтнең «Колчаковцы» (1919 ел) дигән шигыре В. Журавлев тәрҗемәсендә бирелгән.

*
* *

Киевнең «Днипро» нәшрияты «Советский рассказ» сериясеннән РСФСР автономияле республикалары, милли округлары, край һәм өлкәләрендә яшәүче язучыларның хикәяләр җыентыгын чыгарды. Бу инде шундый җыентыкларның икенчесе. Рәсемнәр белән, матур оформлениедә чыгарылган ул китапта Г. Бәширов, И. Гази, Ә. Еники, Ф. Хөсни, М. Рафиков хикәяләре күренекле урын алып тора.

### «ИДЕЛ — УРАЛ АРАСЫНДА»

Ижевск шәһәренең «Удмуртия» китап нәшрияты әнә шул исем белән Урта Идел һәм Урал буе тугандаш республикаларында яшәүче күренекле язучы һәм шагыйрьләрнең соңгы елларда иҗат иткән әсәрләреннән тупланган җыентык бастырып чыгарды. Китапта Татарстан әдипләреннән С. Хәким, Г. Ахунов, З. Нури, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин һәм Р. Кутуй әсәрләре дә урнаштырылган.

*
* *

Март аенда Каракалпак АССРның башкаласы Нукус шәһәрендә каракалпак әдәбиятына нигез салучы Бердахның тууына 150 ел тулуга багышланган тантана булып

үтте. Бу зур әдәби бәйрәмдә РСФСР, Украина, Үзбәкстан, Әзербайҗан, Кыргызстан, Казагыстан, Таҗикстан республикаларыннан күренекле язучылар катнашты. Юбилейга Татарстаннан шагыйрь Равил Фәйзуллин барды. Ул тантаналы җыелышта һәм телевидениедә чыгышлар ясады, Нукус һәм Хуҗаиле шәһәрләрендә укучылар белән очрашуларда катнашты.

## ӘДӘБИЯТНЫ ПРОПАГАНДАЛАУЧЫЛАР КИҢӘШМӘСЕ

Ленинград шәһәрендә СССР Язучылар союзы әдәбиятны пропагандалау бюросының пленумы үткәрелде. Анда союздаш һәм автономияле республикалар, өлкәләрдәге пропаганда бюролары җитәкчеләре чакырылды. Пленум КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында илебез халыклары әдәбиятлары казанышларын пропагандалауның торышын тикшерде. Башка оешмалар белән бергә Татарстан Язучылар союзы пропаганда бюросы эшчәнлеге дә уңай яктан билгеләп үтелде. Пленум эшендә Татарстан Язучылар союзы идарәсе секретаре язучы М. Хәбибуллин һәм пропаганда бюросы җитәкчесе Эльс Гаделев катнашты.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты һәм матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел 1 март Указы белән язучы **Мөсәгыйть Мөдәррис улы Хәбибуллинга Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты **Ирек Вәли улы Баһмановка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел 16 февраль Указы белән, **Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен, Ленин комсомолы исемендәге Казан дәүләт яшь тамашачы театры артисты **Юрий Александрович Максимовка Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет хореография сәнгате өлкәсендә ирешкән уңышлары өчен, Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле балет солистлары **Фердинанд Миңһаҗ улы Гыймадиев** һәм **Равил Гыйбадулла улы Хәлиуллинга**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел 23 февраль Указы белән, **Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

*
* *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге уңышлары өчен, Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең солист-вокалистлары **Шамил Сабир улы Әхмәтҗановка** һәм **Мөҗип Йосып улы Садыйковка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1978 ел 23 февраль Указы белән, **Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

## УРАМГА — ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕ

Башкортстанның Октябрьск шәһәрендәге урамнарның берсенә Кызыл Армия командиры, Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар шагыйре Хәйретдин Мөҗәй исеме бирелде. Шул уңай белән анда шагыйрьнең полкташлары, мәктәп укучылары, язучылар, җәмәгать оешмалары вәкилләре җыелды. Тантанада патриот-шагыйрь эзләреннән йөреп язылган «Үлемнән көчлерәк» дигән китап авторы Самат Шакир да катнашты.

## МУСА ҖӘЛИЛ АРХИВЫ

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият, тарих институтының фәнни архивында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты патриот шагыйрь Муса Җәлилнең 500 эшне берләштергән зур архив фонды тупланды. Күптән түгел бу материаллар архив эше таләпләренә җавап бирерлек дәрәҗәдә эшкәртелде һәм укучылар, тикшеренүчеләр кулына бирерлек хәлгә китерелде.

Беренче мәртәбә герой-шагыйрь архивы Татарстан Язучылар союзы тарафыннан институтка 1954 елның июнь аенда өлешчә тапшырылган иде. Филиал китапханәсендә саклангыннан соң ул 1960 елда фәнни архивка алына. Муса Җәлилнең кулъязмалары һәм аның иҗаты, тормышына караган аерым материаллар соңгы елларда да керде. 7 папкадан торган шактый зур күләмдәге яңа материаллар исә фондны бермәбер баетты. Аны институтка герой-шагыйрьнең тормыш иптәше Әминә ханым Җәлилова тапшырды. Шагыйрь фонды 5 тасвирламага бүлеп эшкәртелде. Беренче тасвирлама 1918—1941 елларга караган, бер өлеше әле бүгенгәчә дөнья күрмәгән шигырь, поэма, сәхнә әсәрләре, дөнья һәм рус классикларыннан тәрҗемәләрдән гыйбарәт. Иҗатының төрле чорларын эченә алган һәм күп вариантлы бу әсәрләр шагыйрьнең үсешен һәм иҗат лабораториясен тулырак күз алдына китерергә мөмкинлек тудыра. Җәлил биографиясенә, әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенә караган тасвирламалардан шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлын өйрәнүчеләр байтак кына кызыклы бай материаллар таба алалар.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА БАГЫШЛАП

Идел буе хәрби округы органы «За Родину» («Ватан өчен») газетасы бу елгы 19 нчы санын (22 январь) безнең татар совет әдәбиятына багышлап чыгарды. «Рухи байлыгыбыз» дигән мәкаләдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов әдәбият һәм культурабыз өлкәсендәге бүгенге казанышларыбыз турында сөйли. «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури мәкаләсе «Һәр вакыт алгы сызыкта» дип исемләнгән. Засловов җитәкчелегендәге легендар партизаннар отрядының элекке разведка командиры татар әдәбиятының сугышчан традицияләре һәм фронтовик язучылар иҗаты турында сөйли. Газета үз укучылары игътибарына шулай ук Ә. Еники хикәясен, Н. Дәүли, И. Юзеев, М. Әгъләмов шигырьләрен, Ш. Маннаповның Муса Җәлил турында нәсерен һәм Р. Мөхәммәдиев информациясен тәкъдим итә. Битнең урта җирендә татар әдәбиятының аксакаллары—фронтовик әдипләрнең күмәк фоторәсеме урнаштырылган.

## ПОЭЗИЯ СЕКЦИЯСЕНДӘ

28 февраль көнне Татарстан Язучылар союзының поэзия секциясе утырышында яшь буын шагыйрьләреннән Зөлфәтнең «Утлы бозлар» исемле яңа шигырьләр җыентыгы тикшерелде. Фикер алышуда шигъриятебез аксакалларыннан Сибгат Хәким, Нури Арсланов, шагыйрьнең буындашлары Мансур Вәлиев, Әхмәт Гадел, Мөдәррис Әгъләмов, Ринат Мөхәммәдиев, Марсель Галиев һәм поэзия секциясе җитәкчесе шагыйрь Рәдиф Гатауллин катнашты. Чыгыш ясаучылар җыентыкка кергән шигъри әсәрләргә югары бәя биреп, китапның дөньяга чыгуы поэзиябез тормышында үзенчәлекле вакыйга булуын билгеләп үттеләр, шагыйрьгә кайбер киңәшләрен белдерделәр.

## ФИЛОЛОГЛАР КИҢӘШӘ

В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетында Татарстан һәм Башкортстан автономияле республикаларындагы университетлар һәм педагогия институтларындагы татар, башкорт әдәбияты һәм теле кафедралары мөдирләренең юл көнлек семинар-киңәшмәсе булып үтте.

Киңәшмәдә югары уку йортларында әдәбият, тел укытуның иң актуаль проблемалары тикшерелде, фольклорны өйрәнү, әдәби әсәрләрне анализлау һ. б. мәсьәләләр каралды. Филология фәннәре докторлары, профессорлар М. З. Зәкиев, Ә. Н. Киреев, И. Г. Нигъмәтуллина, Д. Г. Тумашева, Г. Х. Әхәтов, Н. Х. Ишбулатов, Г. Ф. Саттаров, филология фәннәре кандидатлары, доцентлар А. Г. Яхин, М. С. Мәһдиев, Т. Н. Галиуллин, И. Г. Вәлитов һ. б. иптәшләр әдәбият һәм тел үсешенә, вузда бу фәннәрне укыту мәсьәләләренә багышланган докладлар белән чыктылар.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлекнең январь ахырында уздырылган утырышында нефть төбәгендә яшәүче язучыларның үткән елдагы иҗат эшчәнлегенә йомгак ясалды. Бүлек җитәкчесе Ә. Маликов докладыннан соң, фикер алышуда язучылар Х. Хәйруллин, Җ. Рәхимов, С. Сөләйманова, Ш. Бикчурин, әдәбият берләшмәсе җитәкчеләре Ә. Галиев, Ф. Зәйнагыйтдинов, Я. Хөснетдинов, КПССның Әлмәт шәһәр комитеты инструкторы А. Хисамиев һ. б. катнашты. Утырыштагылар яңа елга иҗади һәм оештыру эшләре планнарын билгеләделәр.

*
* *

Әлмәттәге 1 номерлы техник училищеда драматург Сәет Кальметов белән очрашу булды. Ул үзенең фронт язмаларын һәм юмористик әсәрләрен укыды, укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

*
* *

Әлмәт әдәбият берләшмәсе утырышында яшь авторлардан Венера Туктарова, Әхмәт Фәтхетдинов, Роберт Рәкыйпов, Шәриф Хисамиев иптәшләрнең хикәя һәм шигырьләре тикшерелде. Шагыйрьләрдән Г. Афзал, С. Сөләйманова аларның әсәрләренә анализ ясадылар, киңәшләрен әйттеләр.

*
* *

Бүлек утырышында драматург Юныс Әминовның «Имтихан» исемле яңа пьесасы тикшерелде. Әсәр әхлак мәсьәләләрен күтәрә. Фикер алышуда катнашкан С. Кальметов, Г. Афзал, Ә. Маликов, Әлмәт татар дәүләт драма театры режиссеры Р. Абдуллаев һәм башкалар пьесаны яхшырту юнәлешендә авторга файдалы киңәшләрен әйттеләр.

*
* *

Язучы Рафаил Төхфәтуллин хикәя жанры турында Әлмәт әдәбият берләшмәсе членнары белән кызыклы әңгәмә үткәрде, үзенең иҗат тәҗрибәсе белән уртаклашты.

*
* *

Нефть ягында яшәүче язучылар февраль аенда укучылар белән күп кенә очрашулар үткәрделәр. Бөек Ватан сугышы ветераннары Р. Төхфәтуллин, С. Кальметов һәм Ә. Маликов Әлмәт мәктәпләрендә булып, укучыларга татар әдәбияты турында сөйләделәр, сугыш истәлекләре белән уртаклаштылар.

Шагыйрә С. Сөләйманова Әлмәттәге 4 нче номерлы китапханәдә укучылар белән очрашты, үзенең яңа шигырьләрен укыды, сорауларга җаваплар бирде.

М. Хәсәнов һәм К. Булатова Азнакай нефтьчеләренең культура сараенда үзешчән композитор Сания Әхмәтова иҗатына багышлап үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә чыгыш ясадылар.

# ӘНӘС КАМАЛ



Шушы елның 18 мартында татар совет драматургы һәм театр эшлеклесе Әнәс Камал (Камалетдинов Әнәс Галиәсгар улы) озакка сузылган каты авырудан соң 71 нче яшендә вафат булды.

Әнәс Камал 1908 елның 20 февралендә Казанда, татар драматургиясенең классигы Галиәсгар Камал семьясында туа. Кече яшьтән артистлар, язучылар, музыкантлар белән — татар культурасы эшлеклеләре белән аралашып үсә. 1931 елны ул Казан театр техникумын тәмамлый. 1931—1935 елларда Минзәлә колхоз-совхоз театрының директоры һәм сәнгать җитәкчесе. 1935—1955 елларда Татарстан китап нәшриятында редактор, аннары Язучылар союзында әдәби консультант, «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли.

Әнәс Камал иҗат эше белән үсмер чагында ук шөгыльләнә башлый. Ә 1928 елда язган «Биш меңле Гайнетдин» комедиясе аңа драматург исеме алып килә. 50 елга сузылган әдәби иҗат дәверендә ул күп санлы комедияләр, скетч, инсценировка, интермедияләр иҗат итә, «Давыл», «Туй», «Ике көч» исемле әсәрләре халыкка киң танылa. Драматургның иң яхшы пьесалары «Сайланма әсәрләр» исемле бер томлыгына тупланган. Ул — 1939 елдан СССР Язучылар союзы члены.

Әнәс Камал татар драматургиясенә нигез салган Г. Камал турында сәнгатьчә матур, тирән эчтәлекле истәлекләр китабы язды, әдәби тәрҗемә өлкәсендә күп эшләде, яшь драматургларның әсәрләрен укып, аларга гел булышып торды, бер пәрдәле комедияләр, эстрада җыеңтыклары төзеп бастырды, озак еллар буена Язучылар союзының драматурглар секциясе эшендә катнашты.

Үзенә һәм иптәшләренә карата таләпчән, туры сүзле, киң күңелле, юмор хисенә бай, олы җанлы каләмдәшебезнең якты истәлеге безнең күңелләрдә гомер буе сакланыр.

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның алтынчы саны Барлас Камаловның «Ярсөяр әрәмәсе» исемле повесте белән ачыла. Яшь прозаиклардан Ә. Сәйфетдинов «Җырла, иркәм» повесте һәм С. Хафизов «Согданолла» хикәясе белән катнашалар.

Шигырь яратучыларга Нури Арслановның «Бакча юлы», Фәнис Яруллинның «Бер сүз әзлим», Зиннур Мансуровның «Кояш чыгышы» дигән шигырьләр циклын, Фәннур Сафинның «Казан гомеро» исемле шигырен тәкъдим итәбез.

Әдәби мирас белән кызыксынучылар Гали Хуҗиевның «Ярата идем мин сезне...» дигән героик драмасын укырлар.

Очерклар бүлеге бай. Анда француз әдибе А. Ремакль, Д. Шәрәфетдинов, Г. Хәбибуллин, Г. Волковларның КамАЗ, республикабызның күренекле кешеләре, интернациональ дуслык, халкыбызның гореф-гадәтләре турындагы очерклары урнаштырылган.

Ш. Рахманкуловның «Бию — егет һөнәре» очеркы татар балет сәнгате сәхифәләренә карый.

Бу санда да «Әдәбият тарихына материаллар», «Әдәби тәнкыйть», «Китап күзәтү», «Төрлесеннән» бүлекләренә караган кызыклы хезмәтләр белән танышырга мөмкин.

Журналыбыз байтактан бирле «Мәсәлчеләр мәҗлесе»н алып бара. Бу санда сез Әбелфәрәҗнең «Кызыклы вакыйгалар» китабыннан өзекләр укырсыз.

«Елмаеп та, көлеп тә», «Безнең календарь», «Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары»ннан кечкенә хикәяләр, тапкыр сүзләр, кызыклы информацияләр табарсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210